ISSN 0206–4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.2005



# Tatarstan Respublikası Prezidentı
# UKAZI

## "Tatarstan Respublikası Xalıq şağire" digən maqtawlı isem birü turında



"Tatar ədəbiətın üsterügə zur əleş kertkən əcen şağir, Tatarstan Respublikası Yazuçılar berlege əğzəse **Minnullin Robert Məğəllim ulına** "Tatarstan Respublikası Xalıq şağire" digən maqtawlı isem birergə.

Tatarstan Respublikası Prezidentı **M. Ş. ŞƏYMİEV**

*Qazan, Kreml', 2005 yıl, 25 aprel'.*
*N—UP — 128.*

**Казан утлары**

**Qazan utları**

*2005*

# 7

**(993)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир— 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары— 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге—43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Иманыңнан бер язсаң... *Роман* .......... 5
Роберт МИҢНУЛЛИН. Яңа шигырьләр. .......... 37
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Мәкер. *Повесть* .......... 42
Ирек САБИРОВ. Уй ярында, уел буенда... *Шигырьләр* .......... 82
Луиза ЯНСУАР. Офыкларга таба йөгерәмен... *Шигырьләр* .......... 86
Рифә РАХМАН. Чикерткә. *Хикәя* .......... 91
Гөлзада ӘХТӘМОВА. Галәм, дөнья, тормыш мәгънәләре. *Шигырьләр* .......... 101

**ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ–ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ**

Василий ШУКШИН. Бүреләр. *Хикәя* .......... 96
Вячеслав АР-СЕРГИ. Бу–борынгы һәм мәңгелек дөнья. *Шигырьләр* .......... 104

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Мөхәммәт ГАЛИ. Пожарныйлар. *Хикәя* .......... 107

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Илдус САДЫЙКОВ. Йөрсәң күрерсең, күрсәң белерсең .......... 115
Безне санадылар. Рәфикъ Юнысның БТК башкарма комитеты рәисе урынбасары Дамир Исхаков белән әңгәмәсе. .......... 128

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Рөстәм ЗАРИПОВ. Төрле-төрле уйласак та... .......... 141

**ФӘН**

Флүн МУСИН. Әдәбият тарихын яңача өйрәнү .......... 148
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге .......... 159
"Татар энциклопедиясе" битләреннән .......... 175
Раиф МӘРДАНОВ. "Бу китап хан догасы берлә тәмам..." .......... 164

**ХӘТЕР**

Зөфәр ДӘҮЛӘТОВ. Соңгы көннәр хатирәсе .......... 170

**САФА САБИРОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ**

Камил КӘРИМОВ. Иске йорт аксакалы .......... 172

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Хәмидә ГАРИПОВА. Күңел күзе ни күрә? .......... 180

"Казан утлары" архивыннан .......... 184
Укучы сүзе .......... 186
Котлыйбыз! .......... 187
Берлекнең яңа әгъзалары .......... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .......... 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман Р. МИР-ХАЙДАРОВА "Двойник Китайского императора" (окончание); повесть Т. ГАЛИУЛЛИНА "Коварство", рассказ Р. РАХМАН "Кузнечик"; стихи Р. МИННУЛЛИНА, И. САБИРОВА, Л. ЯНСУАР, Г. АХТЯМОВОЙ.
"Дружба литератур — дружба народов": рассказ В. ШУКШИНА "Волки" (в переводе Ф. Шарафутдиновой), стихи В. АР-СЕРГИ.
"Из сокровищницы татарских рассказов": рассказ М. ГАЛИ "Пожарники".
"Публицистика": И. САДЫКОВ. "Нужен нам берег Турецкий"; "Перепись населения татар не огорчила". Обстоятельное интервью Р. ЮНУСА с этнологом Д. Исхаковым.
Дискуссия "Герой нашего времени": статья Р. ЗАРИПОВА.
"Наука": статья Ф. МУСИНА "Новые подходы в истории литературы";
А. ТИМЕРГАЛИН "Словарь нации".
"Страницы из "Татарской энциклопедии"; статья Р. МАРДАНОВА о поэме "Нуры содур".
"Память": статья З. ДАВЛЕТОВА "Прощание с Г. Афзалом."
К 90-летию С. Сабирова статья К. КАРИМОВА.
"Книжное обозрение": Х. ГАРИПОВА рецензирует книгу Н. Гиматдиновой.
Из фотоархива журнала.
Слово читателя.
Новые члены Союза писателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: работа художника А. ТИМЕРГАЛИНОЙ "Старая Казань. Мечеть Гусмана"; писатель Л. Закир.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry ": R. MIR-HAIDAROV, Novel. "Double of Chinese emperor" (ending); Story by T. GALIULLIN "Devilry", R. RAHMAN "Grasshopper";
Verses by R. MINNULIN, I. SABIROV, L. YANSUAR, G. AHTAMOVA.
"Friendship of literatures is friendship of nations": story by V. SHUKSHIN "Wolves" (in translation by F. SHARAFUTDINOVA), verses by V. AR-SERGI.
"From treasury of tatar stories": story by M. GALI "Firemen".
"Publicism": I. SADYKOV. "We need Turkish beach"; "Population Census didn't afflict Tartars". Detailed interview of R. YUNUS ethnologist D. Ishakov.
Discussion "Hero of our time": article by R. ZARIPOV.
"History of literature": article by F. MUSIN "New approaches in history of literature".
"Science": A. TIMERGALIN "Dictionary of nation".
"Pages from "Tatar encyclopedia"; article by R. MARDANOV about poem "Nury sodur".
"Memory": article by Z. DAVLETOV "Farewell with G. Afzal."
To 90th anniversary of S. Sabirov article by K. KARIMOV.
"Book review": H. GARIPOVA reviews the book by N. Gimatdinova.
From photoarchive of magazine.
Word of reader.
New members of Union of writers.
Diary of social-cultural life.
On our covers: work by A. TIMERGALINA "Old Kazan. Gusman Mosque"; writer L. Zakir

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.06.2005 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А–469. Тираж 7011.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.

**Рауль Мирхәйдәров**

## ИМАНЫҢНАН БЕР ЯЗСАҢ...

РОМАН

### III БҮЛЕК

*Татар банкы, махсус вәкаләтле полковник, Алма-Ата фалчысы, Яздан әкәнең яшерен көче, балык промышленносте министрына парчалы халат, Югары судтагы үтерүче, Шурик, Җираф, Изге, Кәрлә һәм башкалар, реквием һәм Күпер Булатка багышланган аятьләр*

Обком секретаре йортындагы мәҗлестән соң бер еллап узгач, Булат Мөэминович диңгез буенда, Ялтадан ерак түгел "Форос" санаториенда ял итте. Ябык типтагы шифаханә яр буендагы менә дигән бакчада урнашкан, якын гына ил чиге үтә, шунлыктан бер генә чит кеше дә юк, бусы исә ял итүче мөһим адәмнәр өчен бик унайлы, шуның өстенә, хезмәт күрсәтүчеләр дә өйрәтеп куелган. Кыскасы, партия номенклатурасы яхшылап ял итә белә иде. Алар эшләгәндә дә үз ишләре арасында, ял иткәндә дә чит-ятларны араларына кертмиләр.

Менә шунда Казакъстан компартиясенең бик югарыда утыручы бер работнигы белән танышты да инде ул. Танышу үзе дә бик кызыклы гына килеп чыкты. Ялга килүенең икенче көне генә иде әле, кичке аштан соң розарий янында ялгызы гына басып тора, кайда барырга, бильярднымы, киногамы, әллә башка берәр җиргәме дип баш вата иде, аның янына берәү килде дә саф үзбәк телендә эндәште. Мәхмүтов якташым дип белеп сөенеп тә өлгермәде, тегесе үзе белән таныштырып, үзбәк телен каян белүен әйтеп тә салды. Чимкенттан икән, ә анда инде берничә йөз еллар дәвамында казакълар белән үзбәкләр ингә-иң яшиләр.

Сөйләшү-аңлашу башланып кына киткән иде әле, яна танышы тик торганда:

—Халыклар дуслыгы нинди бөек көч, карагыз әле, әнә ничек гөрләп чәчәк ата ул!—дип әйтеп салмасынмы.

---

*Ахыры. Башы 6 санда.*

Көтелмәгән бу сүзләрдән Мәхмүтов чак кына кулындагы су шешәсен төшереп җибәрмәде."Мондый бушкуыклар гына җитмәгән иде",—дип уйлап куйды ул кәттә киенгән бу кеше белән танышуына үкенеп.

Әмма тегесе мәгълүм күләмдә генә тынлык саклап алганнан соң, тагын дәвам итте:

—Әнә карагыз, ике якут ашыкмый гына бильярдныйга кереп бара. Шаушу ясатучы әрмәннәр аксыл костюм кигән озын буйлы адәм янына җыелышкан, грузиннар ерактагы беседкада урын алган. Хәзер, мөгаен, берәрсе шәрап алып килер дә күмәкләшеп озын көйләрен җырларга тотынырлар. Алар компаниясенә эләгеп карыйсы иде бер. Дәрәҗәләрен белүче латышлар галстук такмый гына чыкмый да чыкмый инде, аларның яраткан шөгыле аллеялар буйлап йөрү. Әрмәннәр белән грузиннарга караганда азрак алар, эстоннар да шул чама, хәзергә алар латышлар белән дә, литвалылар белән дә аралашырга ашыкмый. Бер атналап күзәтәм инде. Ә менә украиннар шулкадәр күп, хәтта алар берничә компания оештырган. Шулай алга таба да дәвам иттереп булыр иде, әмма тукталам, чөнки үзегез дә күреп торасыз. Аларга кушылмаган Шәрекъ, ягъни Урта Азия генә кала. Менә шунлыктан, мин сезгә килеп кушылдым да инде, хәзер без халыкларның бөек дуслыгын тәшкил итәбез.

—Курыкмыйсызмы соң?—диде ул әңгәмәдәшен сынап карарга теләгәндәй, шунын өстенә, андый-мондый провокация булмагае дип шикләнә дә иде.

—Юк, курыкмыйм, милләтара мөнәсәбәтләр минем профессиям. Мин фәннәр докторы, республикада бу өлкәдә абруйлы белгечләрдән саналам.

—Кызык, фәнни хезмәтләрегездә дә шундый фикерләр ярылып ятамы?

—Аллам сакласын, идеология—бер, ә тормыш бөтенләй башка. Без, галимнәр, аны тормыштан читкәрәк алып китү өчен ярыш алып барабыз шикелле.

—Ничек кенә булмасын, уңышка ирешкәнсез бит әнә. Фәннәр докторы...

—Әйтмәгез дә инде, уңышлар җитәрлек, инде мин академик, членкорр...—Һәм нишләптер икесе дә көлеп җибәрделәр.

Үткен, усал акылга ия кеше икән, кызганыч, цинизм дигән нәрсә инде җанына кереп оялаган, дип уйлап куйды Мәхмүтов яңа танышы турында.

Әмма К. исемле танышын ул бүген илдә катлауланган милләтара мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә исенә төшермәде. Хикмәт бөтенләй башкада иде, К. Үзәк Комитет аппаратында эшли һәм анда картаеп беткәнче утырырга җыена иде бугай. "Ышанычлы, җайлы, уңайлы—саклык кассасындагыга караганда да яхшырак",—дип шаяртырга ярата иде ул. Аппаратта эшләү елларында К. берничә бүлекне алыштырып өлгергән һәм партия элитасындагы, республика хакимиятенең югары эшелонындагы келәм асты көрәшен кемгә караганда да яхшырак белә иде. Аның акыллы һәм күзәтүчән кеше булуында шик юк. Монысын берничек тә кире кагып булмый. К.нең үз сүзләре белән әйткәндә, ул теманы аркылыга буйга йөреп чыккан кеше.

Табигый ки, сүз ара сүз чыгып, алар үз республикаларындагы хәл-әхвәл, бөтен илгә таныш булган җитәкчеләре, аларның һәр яклап яшерен көндәшлеге турында да фикер алышмый калмадылар.

Узган елдан бирле үзен четереклерәк хәлдә сизүче Булат Мөэминович сак һәм К.га караганда шикләнүчән кеше буларак, күбрәк тынлап тора, мыегына чорный һәм сүз дилбегәсен тулысы белән Алма-Ата кешесенә тапшырган иде. Андый-мондый бәхәслерәк сорау килеп чыгуга ук ул акланып куя торган булды:

—Хөрмәтле К., караңгы бер районда утырып мин ниләр генә белә алыйм,

ди. Минем төп эшем—сөт артымы, савым, центнерлар, чәчү, уру, җылы һәм газ бирү, астагыларның бетмәс шикаятьләрен тикшерү... Зур политика бездән читтәрәк ул.

Казакъстаннан килгән иптәш Мәхмүтовның шулай итеп сүздән качарга омтылуын аңламый калмагандыр, әлбәттә, нишлисең, һәркемнең үз каланчасы, ә ул чакларда әле ачыктан-ачык сөйләшү мөмкин түгел, вакыты җитмәгән иде. Хәер, К. ның Үзбәкстан турында Мәхмүтовка караганда күбрәк белүе дә ихтимал, тумышы белән Чимкенттан, Ташкенттан сәгать ярымлык юлдагы каладан булган иптәш туган якларындагы вәзгыятьне белми калмас.

Ләкин, ничек кенә булмасын, К. һәрвакыт диярлек куркыныч темалар тирәсендә бөтерелә, шуның белән хокуклары шактый киселгән райком секретарен сагаерга мәҗбүр итә иде. Күрәсең, эчендә ниндидер борчу булгандыр, җанын әрнеткән бер-бер хәл тынгы бирмәгәндер, юкса, үзенең һәлакәтенә таба шул кадәр ашкынмас иде; хәер, заманалар үзгәрсә, аның янадан очышта булу ихтималы да юк түгел түгелен. Гәп куерту шундый куркынычрак фикерләр тирәсендә чуалды да чуалды.

Бервакыт, инде үзе дә хәтерләп бетерми, ниндидер уңай белән Булат Мөэминович болай дип әйтеп ташлаган иде:

—Ә бездә бөтен мәсьәләләрне, бигрәк тә кадрлар мәсьәләсен бары тик Беренче генә хәл итә, Үзәк Комитет секретарьларын үзе теләгәнчә алыштыра бирә.

К. бераз уйланып торды һәм:

—Бик шәп, димәк, үзе хәл итә,—дип куйды.

Мәхмүтов кабынып китте:

—Аңлый алмыйм, бу бит принципсызлыкка тартым! Сез әле генә кәмәк хәл итү, партия демократиясе ягында идегез, ә хәзер патша заманындагы шикелле бер кешенең ялгыз хакимлеген яклыйсыз. Моның нәрсәсе яхшы?

Аның шулай кабынып китәчәген белгәндәй, К. бер дә югалып калмады:

—Хикмәт шунда, кадерле дустым,—бездә республика белән Беренче түгел, ә аның ярдәмчесе идарә итә. Бөтен куркыныч та шунда,—диде.— Үзәк Комитет секретарьларын, депутатларны йомышчы малайлар урынына йөгертә, чынлыкта авантюрист булган ул бәндәне мин Казакъстанның Гришка Распутины дияр идем. Комсыз, аумакай кеше, хәтта Беренчегә Мәскәүдән килгән почтаны башта ул ачып карый, мондый хәлдә нинди дәүләт серләре турында сүз булырга мөмкин?!.

—Ничек инде ярдәмче?—ул колагына ышанмады, моны башка берәүгә әйтсәң, ышанмас, көлкегә күтәрер иде. Әмма К. ни сөйләгәнен белә иде.

—Әйе шул, иң гади бер ярдәмче! Картинаны тулыландыру өчен шунысын да өстим әле, безнең Беренчегә коточкыч зур йогынтысы булган тагын берәү бар. Анысы—ГАИның махсус патруль дивизионы башлыгы, ниндидер бер полковник. Аны республика буйлап бөтен сәфәрләрендә озатып йөри. Менә шушы ике кеше, үз нәсел-нәсәпләренә таянып, чынлыкта Казакъстан белән җитәкчелек итәләр дә.

Кайда барсаң, шунда бер балык башы икән, дип уйлап куйган иде Мәхмүтов. Ләкин Форосны искә төшерүе бүген бөтенләй башка уңайдан иде. Баксаң, анда аның язмышы, аның тормыш мәсьәләсе тагын бер кат хәл ителгән булган икән бит.

Обком секретаре йортындагы мәгълүм кичәдән соң тормышы кискен үзгәрде дип әйтеп булмас, үзгәрешләрне хәтта Мияссәрә дә сиземләмәде, шул Халтаев кына ешрак кереп йөргәли башлагандыр да. Анысын исә күршелек белән дә аңлатып була иде.

Хәтта тоткан урыны ныгыды да кебек, обком секретаре рәсми

чыгышларында аның районын үрнәк итеп куя, хуҗалыкларын өлкә “маяклары” дип атый башлады. Ә инде шәхси очрашулар, күрешүләр вакытында, мәҗлесләрдә Мәхмүтовны ачыктан-ачык дустым, үрнәк коммунист ди иде.

“Мин сезнең абруегызны күтәрешергә тиеш”,—ди иде ул һәрчак райком секретарена.

Мәхмүтов шулай ук Халтаевның бәйләнчек опекунлыгын да тоймый, кем белә, бәлки полковник вакыт узганын көткәндер, йә булмаса, аның артында һәм аның исеменнән нәрсә дә булса эшләгәндер, монысы караңгы. Шулай да өлкәдә аның райком секретаре белән дуслыгы хакында имеш-мимешләр ишетелгәли башлаган иде инде. Аның белән житди бәрелешләр дә булмады шикелле, шулай да полковникның шактый нык басымы астында район җәмәгать туклануын Яздан әкәгә бирергә туры килде. Тагын ярты елдан Яздан әкәнең икенче бер танышы, теге вакытта Сары Таш мәхәлләсе чәйханәсендә бергә пирәшләгән Сәлим Хәсәнович килеп чыкты, аңа райпотребсоюзны житәкләүне тапшырдылар. Идарә җепләрен кулыннан ычкындырмаса да, көннәр узган саен ул үзен кем кулындагыдыр курчак итеп тоя башлады. Шушы хис яшәргә комачаулый, үзеңне ир-ат, чын кеше, коммунист итеп хис итәргә комачаулый, мондый кара минутларда башына тагын үзенә кул салу уе керә, чөнки ул бүтән юл күрми иде.

Кәтүкнең районга бишенче визиты чираттагы күңел төшенкелегенә сәбәп булды. Фороска китәргә бер айлап вакыт калган чак иде.

Районга ул бөтенләй көтмәгәндә, берниндн кисәтүсез килеп төште, ялгызы гына да түгел иде. Башка вакытларда шефының сәфәре хакында ярдәмчесе алдан ук кисәтеп куя, ашау-эчүнең ничек оештырылырга тиешлеге хакында кинәшләр бирә, мәҗлескә кемнәрне чакырырга, кемнәрнедер исә якын да җибәрмәскә кирәклеген әйтә торган иде. Хәер, ул каһәр суккан көнне обком секретаре янында ярдәмчесе юк иде, кунакларның мондый ашыгычлык белән килеп төшүе сәбәпләре дә соңрак кына аңлашылды.

Алар Аксай ханының “Волга”сында килеп төштеләр, байтактан инде бик күп, хәтта артык сүзләр, имеш-мимешләр ишетсә дә әлегәчә танышу мөмкинлегеннән мәхрүм яшәгән адәмне дә шул көнне беренче тапкыр күрде Мәхмүтов. Ак “Волга”ны хәрбиләрчә яшькелт төскә буялган, джипны хәтерләтүче елгыр машина озатып килә һәм артык күзгә ташланмас өчен булса кирәк, бераз ара саклый иде. Райком янында ул машинадан төшкән биш әзмәвер аерым төркем хасил итеп торды, күзләре хуҗаларында булды. Андыйлар хакында күзләре белән ашый, диләр бугай. Озын буйлы, таза-нык ир-атларның берсенең инендә Япониядә эшләнгән сөйләшү җайланмасы, игътибар беләнрәк карасаң, аларның коралланган икәнен дә абайларга була. Машинаның арткы утыргычында ике автомат мылтык күзгә ташлана, алар аны яшерергә азапланмыйлар да иде.

Болар нукерлар булып, Әкмал ханны озатып йөрүчеләрдән исәпләнелә, бу очракта хәтта алар бераз азрак та иде әле.

Бераз каушап калгандай тоелучы Наполеонны һәм агач күләгәсенә яшеренгән Арипов кешеләрен күргәч, Булат Мөәминовичка башта сәер бер уй килгән иде, Аксай ханы бер генә минутка Заркент өлкә комитетына кергәндер дә, хуҗаны кәнәфиеннән тартып торгызып, берниндн каршы төшүләрен дә тыңлап тормастан, районга барырга мәҗбүр иткәндер.

Әмма, ни өчен? Хәер, аның фаразы чынлыкта дөреслеккә туры килә, барысы да нәкъ шулай булган иде.

—Булат Мөәминович, синнән тиеш, кара мин сиңа нинди кунак алып килдем, танышыгыз.—Кәтүк үзенең югалып калуын яшерергә, Арипов

алдында үз өлкәсендә нинди көч һәм йогынты белән файдалануын күрсәтергә теләп азаплана иде.

Үтә гади киенгән, төптән юан чыккан, тыгыз тәнле ир өлкә хуҗасына мыскыллы елмаюын яшереп тә тормыйча, Мәхмүтовка кулын сузды һәм тин күргәндәй эндәште:

—Әкмал Арипов булам. Сезнең хакта, һәр яктан житешле районыгыз хакында күп ишеткәнем бар. Эш төшеп Назарбәккә баруым әле, юл унаеннан сезгә сугылып чыгарга булдым, хуҗагыз, иске дустым Әнвәржан мине озатырга булды, чакырусыз, кисәтүсез килеп төшкәнгә гаеп итмәссез.

—Рәхим итегез!—Ул чакырылмаган кунакларга ишекне кин итеп ачып жибәрде, боларнын яхшы хәбәр белән йөрмәгәнлеген күнеле сизенгән иде инде.

Кабинетка кергәч, әллә махсус шулай эшләде, әллә сизмәмешкә салынды, Кәтүк кабинет хуҗасынын урынына утырды, райком секретарена телефон куелган читтәге өстәл янында урнашырга туры килде. Бу маневрны Арипов сизми калмады, әлбәттә, ирен читләренә елмаю кунды. Тирән мәгънәле елмаю иде бу, андый көлемсерәү еш кына сүзләрдән дә күбрәкне аңлата. Бу очракта да шулай иде, нигә минем алда күркәдәй кабарынасын, өлкә хуҗасы икәнлегенне күрсәтергә телисенме? Елмаю астында, шиксез, шушы мәгънә ярылып ята иде.

Шәрекъта беркайчан да килеп керүгә эш хакында сөйләшә башламыйлар, әдәпсезлекнен сон чиге саналган мондый гамәл хупланмый, йолалар изге. Ләкин Әнвәр Абидович монда да сүз жебен үз кулына алырга теләп, гадәттәгечә сәламәтлек, балалар турында сорашып тормастан, әле ярты еллап элек кенә обком фатихасы белән оештырылган ат заводы турында гәп куерта башлады. Кинәт-капылт башланган сүз, хәтта, Әкмал ханны да гажәпкә калдырды, анын ирен читләренә тагын сәер көлемсерәү кунды, ирексездән, кабинет хуҗасы белән күзгә-күз карашып алдылар. Бу юлы анын көлемсерәве "хам нишләтсән дә хам инде ул, аннан башканы көтеп булмый", дигәнне аңлатырга тиеш иде. Әнә бит, хәтта дустынын хәл-әхвәлен дә белешеп тормады.

Мәхмүтов белән таныштырып, Кәтүк аны Әкмал ханга үзенен ин якын дусларынын берсе дип атады.

—Әкмал әкә,—диде ул бернинди кереш сүз-фәлән ясап тормастан,—синен ат заводы белән кызыксына, ярдәм итәргә, киңәшләр бирергә тели, Аксайда анын йөзгә якын менә дигән аты бар, яртысыннан артыгын белгечләр бәяләп бетергесез кыйммәт, дип сөйлиләр. Күршен шефлыкка алу белән сөенергә тиешсен.

"Нилектән шефлыкка алмакчы була әле?"—Мәхмүтовнын башыннан шөбһәле уй йөгереп узды. Арипов бер дә ярдәмчел, сәлә кешегә охшамаган, киресенчә, белгән хәтлесеннән аннан качарга, очрашмаска тырышырга кирәклеге аңлашыла иде. Анын белән бер мичәүдә булмаганга сөенергә генә кирәк. Әнә, озатып йөрүче нукерлары да бер дә ат белгеченә охшамаганнар, бер чакрымнан ук аларнын азу ярган башкисәр икәнлеге сизелеп тора, көпә-көндез, яшеренмичә винтовка асып йөреп кара әле.

—Каян бездә ат заводы булсын әле, Әкмал әкә, башлап кына киләбез, сезнен Аксай көтүендәгенен яртысы да юктыр. Менә бер өч елдан мактанырлык нәрсә булыр дип уйлыйм, һичшиксез дөнья базарына чыгачакбыз. Ә ярдәм итәргә теләвегезгә рәхмәт. Мин сезгә белгечләремне жибәрергә әзер, ин элек нәселле атларнын төгәл исәбен булдырырга кирәк, нәсел эшендә селекциядән дә мөһим нәрсә юк,—дип жавап кайтарды ул һәм шунын белән кунакларга ат заводына барып йөрүнен кирәк түгеллеген аңлатырга теләп.

Сүзнен бөтенләй башка юнәлеш алуын күреп, Әкмал хан Кәтүккә усал

караш ташлады һәм нәфрәтен, усаллыгын яшереп тормыйча янә елмайды. Бусы “ник кирәк миңа синең бу боргалануың, шефлык хакында лыгырдавың, чүбек чәйнәвең, ник килгәнне нишләп турыдан-туры әйтмисең”, дигәнне аңлатырга тиеш иде булса кирәк.

Кабинетта туган киеренкелекне чәйгә чакырып кергән секретарь кызның күренүе генә беразга бушата төште. Чәй өстәле райкомның арткы ишегалдындагы бакчада әзерләнгән иде. Табын янында да чакырылмаган кунак обком секретарена тирән мәгънәле карашлар ташлап алды, ул сүз боткасы куертмыйча, турыдан-туры һөҗүмгә күчәргә кирәклеген әйтергә тели иде. Ләкин анысы, нишләптер, Аксай ханының ник килгәнлеген ачыктан-ачык әйтергә базмады, бары тик өстәл яныннан торганда гына үзенең югалып калуын акларга теләгәндәй, теләмичә генә әйтеп куйды:

—Шулай да, кадерле дустым, ничек башлап җибәргәнегезне күрсәтегез инде, обком секретареннан сезнең яшерен серләрегез булырга тиеш түгел.

“Мәскәү” колхозында урнашкан ат заводына ярты сәгатьтән соң гына барып җиттеләр. Ихатага кергәндә Булат Мөэминович кунаклар артыннан “джип”тагы әзмәверләрнең дә кереп килүен күреп алды, моңа кадәр аларерактарак калуны мәгъкул күрә иде.

Көтелмәгән кунакларны элегрәк илдә генә түгел, чит илләрдә дә яхшы танылган ат юырттыручы, хәзер директор булып эшләүче Фәрхәд Ибраһимов каршы алды. Ариповны күрүгә үк аның йөзе ап-ак булды, мине нишләп кисәтеп куймадың дигән шикелле, шефына шелтәле караш ташлап алды. Фәрхәд барысы белән дә кул биреп исәнләшеп чыкты, Ариповка, күрмәмешкә салышып, кул бирмәде. Булат Мөэминович Аксай ханының йөзенә ачулы тимгел бәреп чыгуын да күреп алды, әмма анысы үз-үзен тыеп калды, ачуын эченә яшерде.

Моннан биш ел элегрәк Әкмал хан Фәрхәдне эшкә чакырган иде инде, ләкин Аксайда ике атна булганнан соң, үгетләүләр һәм мул акча вәгъдә итүгә дә, янауларга да карамастан, ул мең ярым тәңкә хакына ялчы булып йөри алмыйм, дип белдерде. Аксай ханы аңа шундый хезмәт хакы билгеләгән иде. Хуҗаның иң яраткан атлары асрала торган абзарда алар шактый нык бәрелешеп алдылар. Әкмал хан чыдый алмыйча, күп тапкырлар күнегелгән гадәте буенча камчы белән кизәнгән иде, Фәрхәд камчыны эләктереп алды да сабын урталайга сындырып өйрәтелмәгән ат ябылган аранга ташлады. Тән сакчылары соңга калды, ат өйрәтүче ул чакта ханның үзәгенә үтәрлек итеп, аның хактаниләр уйлаганын барысын да әйтеп бетерде. Фәрхәдкә нык кына эләкте ул чакта, канга батырып ташладылар, ай буе диярлек хастаханәдә аунарга туры килде.

“Хастаханә урынына җир асты зинданына озатасы, рәшәткәгә чылбыр белән бәйләп куясы булган икән”,—дип ачу белән уйлап куйды Әкмал хан, монда үзенең элеккеге ат карауучысын очратырмын дип аның башына да кереп карамаган иде.

Араннарны карый-карый алга атладылар. Яшь атлар куркынып читкә тайпылды, ярсып кешнәште, күзләрен кан басты—аларның ат абзарында бу кадәр ят кешене күргәннәре юк иде әле. Фәрхәд абзар өчен аеруча борчыла, инфекция-фәлән эләкмәгәе дип курка, җинел ышанучан атларга берәр нәрсә каптырмасыннар дип тә шикләнә иде. Чөнки монда аның иң яраткан, иң яхшы, киләчәккә иң зур өмет баглаган атлары асрала.

Ат заводына элегрәк килгәне булмаганга Кәтүк шунда гына үкенеп куйды, дәрәҗәле кунакка хуҗалыкны үзе сурәтләп биргән булыр иде, шулай да сынатырга теләмәде, гадәтенчә иң алдан атлый бирде, иреннәре арасыннан сокланулы авазлар чыгып торды:

—Кара сана, Әкмал, нинди матур ат!

Яки:

—Бу айгырны Буцефалдан аерырлык түгел, билләһи!

Ләкин Әкмал хан беркемне дә ишетми, хәтта Фәрхәд турында да оныткан иде инде, аның карашы йотарлык булып алга ташланган. Абзарның түренә житәрәк ул яңа буялган араннар яныннан алга ыргылды.

—Менә, менә ул Абрек!—дип шатланып кычкырып жибәрде һәм артыннан юырткан обком секретарен да көтеп тормастан, данлыклы айгыр янына кереп тә китте.

Фәрхәд кунактан бу кадәр әрсезлек көтмәгән иде, ирексездән кычкырып жибәрде:

—Араннан чыгыгыз тизрәк, Абрек карантинда!

Әмма Әкмал хан беркемне дә ишетми иде инде, ул күз явын алырдай матур туры айгырның муенын сыйпый, үз-үзен белештерми сөйләнә иде:

—Абрек, кадерлем минем, жан кисәгем, алтыным, ниһаять, мин таптым сине...

Шунысы гажәп, беркемгә башбирмәс айгыр зифа муенын ана таба игән һәм йомшак иреннәре белән Ариповның чигәсенә ышкыла иде.

—Таныды, мине шунда ук таныды!—Хан исерек шикелле бер үк сүзләрне кабатлады да кабатлады, ул арада аның янына башкалар да жыелып өлгерде.

Фәрхәд тә аранга кермәкче иде, ләкин ниндидер яман сизенү белән Булат Мөэминович аның кулыннан тотып алды, егетнең бөтен тәне калтыранганын сизеп алды.

Биш минут үтеп китте, ун минут... Янында кешеләр барлыгын онытып Әкмал хан Абрек белән сөйләште дә сөйләште. Кәтүк берничә тапкыр эндәшеп карады, әмма тегесе борылып та карамады, ә Абрек янына, аранга керергә обком секретаренең кыюлыгы житмәде. Абрекның дуамал айгыр икәнен, аның янына хәтта ат караучыларның да керергә яратмавын ишеткәне бар иде.

Горур һәм баш бирмәс Абрекның бөтенләй таныш булмаган кешегә иркәләнүен күзәтеп торган арада, "джип"тан төшкән кешеләр аранга якын ук килгәннәр иде инде. Арипов көтмәгәндә борылып аларга боерык сүзләрен кычкырды:

—Йөгән китерегез!

Озатып йөрүчеләрдән кемдер матур итеп, көмеш тәнкәләр һәм ярымасылташлар белән бизәп эшләнгән йөгән сузды.

—Ошыймы?—дип сорады әле һаман ат белән уйнавын дәвам иттергән Арипов, ат ризалыгын белдергәндәй башын иде һәм бик жиңел генә үзен йөгәнләргә мөмкинлек бирде.

Абзардагы кешеләр аһ итеп куйды, чөнки туганнан бирле тәрбияләп үстергән ат караучыларга да аның болай буйсынганы юк иде әле. Әкмал хан атларны аңлау, аларны буйсындыру сәләте барлыгын күрсәтте. Мөгаен, ул алар белән кешеләргә караганда жиңелрәк аңлаша иде булса кирәк.

Фәрхәд тә башкалар шикелле үк аранда барган хәлләрне күзәтеп торды һәм Абрекның үз-үзен тотышына шаккатты, чөнки горур айгырны ул бөтенләй башка яктан белә иде.

Әмма Аксай хужасы атны тезгенләп араннан чыгара башлауга гипнозга бирелеп хәрәкәтсез калгандай тоелган Фәрхәд кинәт айнып китте һәм аларга каршы ташланды:

—Бирмим!

Кулларын жәеп, араннан чыгу юлын гәүдәсе белән каплады. Болар барысы да шулкадәр көтелмәгәнчә булды ки, Абрекның иркәләнүен күзәтеп сихерләнгән кешеләр, хәтта тән сакчылары берни дә аңлый алмый калдылар. Бары тик Арипов бар көченә Фәрхәднең күкрәгенә төртеп жибәргәч һәм

усал тавыш белән: "Кит юлдан, эт җан!"—дип кычкыргач кына аннарына килделәр.

Ләкин ул чакырылмаган кунакны чыгару турында уйлап та карамады. Әкмал хан алдында моннан нәкъ биш ел электәге кебек нәфрәт тулы кайнар күзләр яна иде.

—Нәрсә карап торасыз, алып ташлагыз бу ахмакны!—дип акырып җибәрде ул һәм өч әзмәвер Фәрхәдкә ташланды.

Абрекны иярткән Акмал хан абзар ишегенә таба унлап адым ясарга да өлгермәде, үзен тотып торган кешеләрне тирә-якка бәреп, Фәрхәд аны куып җитте һәм тезгенгә ябышты.

—Юк, Абрек сиңа уенчык түгел, ала алмассың, ул дәүләтнеке!

—Нинди дәүләтнеке?—дип кайтарып сорады Әкмал хан, ат юырттыручының сүзләрен һәм аның бу кадәр үҗәт катгыйлыгын ул чынлап та аңламый иде. Ләкин шул ук мизгелдә йөзе үзгәрде, битенә, муенына кызыл таплар бәреп чыкты, күрәсең, ул ат караучының әле ярты сәгать элек кенә кул бирмичә үзен ничек мәсхәрә иткәнлеген исенә төшерде бугай. Монысын инде беркем дә көтмәгән иде, кинәт ул кулыннан беркайчан да төшерми торган камчысы белән кизәнде һәм Фәрхәднең битенә сукты. Коточкыч көч белән селтәнгән камчы аның кашын ярды, сул күзенә тиде. Фәрхәд ирексездән күзен куллары белән капларга мәҗбүр булды, ә ярсуыннан акылын югалткан хан аны камчы белән яруын дәвам иттерде. Ат заводы директорын коткарырга беренче булып якынрак басып торган Кәтүк ташланды, ләкин Әкмал хан, тыкшынма дигәндәй, аны этеп кенә җибәрде. Җене котырган чакта аның теләсә кемне үтергәнче кыйный алганын белгән обком секретаре нәселле ат яратучыны тагын бер тапкыр коткарырга тырышып карады.

—Алаймы, син дә алар белән бергәме?—дип ярсуына буылды кунак һәм Кәтүккә камчы белән шулкадәр каты кизәнеп сукты ки, тегесенең пиджагы аркасыннан икегә ярылып чыкты. Үз-үзен белештерми башлаган кунакны Мәхмүтовкә ике куллап буып алырга, туктатырга туры килде.

Кешегә әйтсәң кеше ышанмаслык ямьсез, җирәнгеч күренеш булды ул, ләкин арттырып та, киметеп тә булмый, барысы да шулай... моны хәтта искә төшерүдән дә бала йоннары кабара иде.

К. ның әйтүенчә, хәтта Политбюро члены, биниһая зур республиканың Компартиясе беренче секретаре булган дәрәҗәле абзыйның авантюрист ярдәмчесе һәм ГАИ полковнигы кулында курчак булуын белү җандагы киеренкелекне алып ташларга ярдәм итте, үз-үзенә кул салу турындагы уйлар томандай таралып очты.

"Минем өстәге кешеләр бер төрле вәгазь сөйләп, икенче төрле уйлаган һәм яшәгән вакытта мин үзем нәрсәне үзгәртә алам да, нәрсәгә ирешә алам соң"—дип уйланды ул котырынучы дингез шавына колак салып йокысыз үткәрелгән төннәрендә.

Дөрес, республикада яшәүче һәм азмы-күпме власть чыгырының ничек әйләнүеннән хәбәрдар теләсә кайсы кеше кебек үк, аның да Арипов турында ишеткәне бар иде. Әмма үз күзе белән күргәннәре шулкадәрле гайре табигый, шулкадәрле мәнсезлек белән төренгән иде ки, аларга хәтта чынлап та шулай булдымы соң әле дип, ышанасы килми иде. Кайчандыр ул Аксайга партия өлкә комитетының беренче секретарен кертмәгән икән, дип сөйләгәннәре бар. "Джип"та утырган әзмәвер егет кебекләр бер генә сорау биргәннәр:

—Син кем, ник, нинди максат белән киләсен?—дигәннәр. Юкса, машинаның өч нульдән гыйбарәт номеры азмы-күпме башы эшләгән кемсәгә үзе үк кемнең кем икәнен кычкырып тора лабаса.

Обком секретарена йомышчы малай шикелле үзенең кемлеген, Аксайга нинди унай белән килүен аңлатып бирергә туры килгән. Ләкин документ күрсәтү дә, җентекле җавап та ярдәм итмәгән, имеш. Әзмәверләр көлемсерәп кенә куйган:

—Бар, абзый, өеңә кайт та борыныңа киртләп куй, безгә чакыру белән генә киләләр, бүген Әкмал әкәнең эше күп, борчып йөрмәскә кушты,— дигәннәр.

Өлкә хуҗасы, ҮК члены, СССР Верховный Советы депутатына кире кайтып китүдән башка юл калмаган.

Тагын берничә көннән Аксай хөкемдары белән тагын бер бәрелеш булып алды һәм обком секретаре бюроның гадәттән тыш утырышын җыярга карар итте. Агропромышленность берләшмәсе директоры белән коммунистларча сөйләшергә кирәк иде. Бюро әгъзалары бер сәгать көттеләр, ике... Әкмал Арипов күренмәде, аны алырга өлкә милициясе башлыгын—генералны җибәрделәр, әмма ул да буш кул белән кайтты. Шул чакта обком секретаре үз кулы белән янаулы чакыру язып яна чапкын җибәрде. Анысы бер сәгатьтән әйләнеп кайтты, секретарь җибәргән кәгазьнең икенче ягына ярым надан хан өлкәнең партия җитәкчесен иң әшәке сүзләр белән мәсхәрәләп, әгәренки бу көчек өрүдән туктамаса, аның тормышы өчен җавап бирмәячәген белдергән иде.

Үз акылындагы берәр кеше моңа ышана алыр идеме? Булат Мөэминович та ышанмады. Менә хәзер, өлкә хуҗалыгын таркатып ташлаган, партия һәм халыкның миен череткән өчен җавап тотар көннәр килеп җиткәч, моңа кадәр бер генә юньле нәрсә дә эшләнмәгәнлеге ачыкланылды, барысы да искечә калган иде.

Сер пәрдәсе күтәрелә башлады, хәбәрдарлык колач җәйде, хәтта инде расланып, матбугатта игълан ителгән хәтлесе дә адәм ышанмаслык, кыргый һәм мәгънәсезлекнең соңгы чиге булып тоела иде.

Әнвәр Абидович белән Арипов бер-берсен уздырыр өчен ни генә кыланмаганнар да, нинди генә башбаштаклыкларга бармаганнар!

Мәсәлән, Әкмал хан турында зур күләмле әдәби әсәр язарга өлгерми калганнар, Әнвәр Абидович турында исә үзбәк һәм рус телләрендә аерым басма булып та, калын журналларда да роман дөнья күргән, хәтта Мәскәүдәге иң зур нәшриятларның берсе китап итеп чыгарырга тиеш булган, әмма өлгерми калган. Роман чыгарга нибары бер ай калганда аның төп каһарманын кулга алганнар да тиражны макулатурага җибәрергә туры килгән. Газет-журналлардагы очерклар исәпкә керми, Мәскәүдәге калын басмаларга каләмхак әкияттәгечә булган. Елгыр каләмле бер журналист хатынга Аксай ханы бриллиант кашлы йөзек бүләк иткән, ди. Кәгазь сырлаучыларга юмарт вә мәрхәмәтле булып күренгән Әкмал әкә шул ук вакытта төгәл бухгалтер язмалары да алып барган: бу нәрсә кайда һәм күпмегә алынган, кемгә, кайчан һәм ни өчен бүләк ителгән, хәтта кибеттән алган счет кәгазен беркетеп куярга онытмаганнар. Елгыр журналистка бүләк ителгән бриллиант кашлы йөзекнең дә товар чегы сакланып калган.

Аның каруы, Арипов үзе хакында фильм төшерткән, Заркент секретарен барыбер уздырган. Үзбәк кинематографистлары эшли белә, буран котырган бер мәлдә Аксай ханының упкынга төшеп баручы сарык көтүен ничек итеп туктатуы, халык байлыгын саклап калуы турындагы күренеш үзе генә дә ни тора. Күз ачкысыз буранда акылыннан шашкандай ыргылучы аңгыра сарыкны упкын читендә тотып кара әле син! Тәэсирләндергеч күренеш! Дөрес, кино төшерүчеләр күз ачкысыз буран үкергәндә ничек итеп көтүнең таудагы упкын янына куып китерелүен күрсәтеп тормадылар, азмы-күпме

кеше ышанырлык кадр эләктерү өчен ничә дубль ясалуы да сер булып калды. Жан-фәрман тырыша торгач, көтүдән нибары биш-алты сарык калгандыр да. Ә нинди шәп, баш әйләндергеч кадр төшерелде, Феллини үзе көнләшерлек булды.

Әкмал ханның экраннарына чыгуын белгәч, Әнвәр Абидович үзен кая куярга белмәде, Ташкенттагы кино эшлеклеләренә юл эзли башлады. Ләкин тегеләре бик җайлап кына баш тарттылар. Әкмал әкә көндәшләренә юлны бикләп куярга өлгергән иде инде. Әмма Наполеонның өч ел Мәскәүдә укып йөрүе эзсез узмаган, дуслар ярдәм итте, нәкъ менә алар Оборона министрлыгы студиясенә чыгарга киңәш иттеләр дә.

—Бу инде сиңа Ариповның үзешчән, һәвәскәр кино төшерүчеләре түгел,—дип мактанган иде Тилләхаҗиев дус-ишләре арасында. Фильмны акыл эшчәнлегенә юнәлдерелгәнрәк итеп төшерергә кушты. Дөрес, кемдер Ариповны уздырып, упкынга ат көтүен куып кертергә тәкъдим иткән иде итүен, ләкин, ат—сарык кына түгел, таптап китүләре, яисә үзеңнең үк упкынга мәтәлүең бар, шунлыктан, Әнвәр Абидович бик кызыкса да, бу фикердән баш тартырга туры килде. Сценарийны Шәрәфәт язды, фильмда аның шигырьләре яңгырады. Каләмхакны исә мулдан түләделәр.

Үзбәкстан кинематографистлары Аксай ханыннан акчаны мулдан каерсалар да, сметага сыеп бетә алмыйча интеккәннәр иде, Әнвәр Абидович моңа юл куя алмады. Ул гадирәк, аңлаешлырак юлдан китте—өлкәнең авыл эшчәннәренә культура ихтыяжларына билгеләнгән 287 мең сумны үзе хакындагы фильм төшерүгә җибәртте. Ник җибәртмәскә, "Заркент йолдызы" дигән үтә тыйнак исемле фильм кышлак эшчәннәренә дә күрсәтеләчәк ич. Барысы да мантыйкка сыя. Әмма өч йөз мең сумга якын акчалары урланган мамык үстерүчеләргә фильмны күрергә насыйп булмады, Шәрәфәтнең кино шедеврын күрергә өлгерә алмый калдылар, чөнки беренче тамашачылар сыйфатында аны СССР прокуратурасы тикшерүчеләре карады, аларны обком секретареның биографиясе кызыксындыруы гаҗәп түгел.

"Ярышучы" көндәшләрдән Ин-иң югарыдагы абзый да калышмады, ләкин монда инде бөтенләй башка колач һәм башка таләпләр хөкем сөрде.

Мамыкны өстәп язуларда кулын ныгыткан агай күз буяу өчен нинди генә адымнарга бармый иде. Әйтик, чираттагы юбилейга алтын юдыру фабрикасының эшли башлавы турында рапорт бирергә кирәкме? Рәхим ит, рапорт әзер! Тау-баету комбинатының карьерлары әле казылып кына ятамы, ята бирсеннәр, Мәрҗәнболактан яшереп кенә ике состав руда китерттеләр дә, юбилейга ун килолы алтын кирпечне коеп та куйдылар.

Президиум өстәлендә алтын пирамида ул көнне балкып утырды, күзенне алырлык түгел иде һәм сакларга куелган Гохран кешеләре аннан күзләрен алмадылар да.

Купшы нотыклар, мактаулы телмәрләрдән соң пичәтләнгән, эченә кирпеч тутырылган "дипломат"ны аларга тапшырдылар, ә алтын үзе истәлек өчен "Әти"гә калдырылды. "Әтиебез" шул алтыннан иң оста зәркәннәргә махсус сызымнар буенча ике театраль сумка ясарга кушты. Белгечләр оста эшенең һәркайсын йөзәр меңгә бәяләделәр. Бер сумканы "Әти" Леонид Ильичның хатынына, икенчесен үзенең хәләл җефетенә бүләк итте. Бүләк булса—бүләк булсын, йөрәкләрне яндырсын, диләрме әле! Экспертлар андый зиннәтле ридикюльләрнең хәтта Екатерина II дә, Англия королевасында да булмаганлыгын ачыкладылар. Гади совет житәкчесе белән ярышып кара син!

Әкмал хан белән Наполеонның жанны өшетердәй башка кыланмышлары хакында ишеткәне булса да, аларны ул чынга алмаган иде, чөнки болар барысы да бераз гына жирле төсмерләр дә шәйләнүгә карамастан, Кыргый

Көнбатыштагы гамәлләрне, итальян мафиясе чалымнарын хәтерләтәләр иде.

Имеш-мимешләрнен берсе аеруча хәтердә уелып калган. Югары уку йортларынын берсендә укытучы булып эшләүче Абрам Ильич атлы адәм турында иде ул. Шешә белән дусрак булганмы, һаман саен айныткычка эләгә икән бу. Тәрбияле, тыныч холыклы кеше буларак, ыгы-зыгы куптармый гына, тиешлесен түләп, милиция хезмәткәрләренә рәхмәт әйтеп кайтып китә икән. Кайчагында штраф түләтеп тә тормыйлар, югарыдан шылтыратуга, кәефләнеп алган доцентны иплә кенә машинага утыртып өенә хәтле озатып куялар, ди. Әмма еллар узу белән доцентнын холкы үзгәрә башлаган.

—Минем кем икәнемне беләсезме, белмисез, әмма белерсез, ишетерсез але,—дип айныткычта эшләүче иске танышларын аптыратып бетерә икән. Анын эчен-тышын белеп бетергән, нинди күлмәк-ыштан, нинди оекбаш киюен, иртән нәрсә белән баш төзәтүенә хәтле өйрәнеп өлгергән айнытучылар аптыраштa калган. Көннәрдән беркөнне анын концертыннан тәмам гарык булган карт майор кул селтәгән дә: "Әйдә инде, сөйлә алай булгач, кем син?"—дигән ди.

Каешы салдырылган чалбарын, төшеп китмәсен өчен кулы белән тоткан хәлдәге Абрам Ильич бер мизгелдә тураеп киткән һәм алтын балдаклы бармагын түшәмгә төбәп, тирән горурлык хисе белән әйткән:

—Мин егерме дүрт мәртәбә фәннәр докторы һәм дә ки кырык сигез мәртәбә кандидат булам!—дигән.

Егерме дүрт тапкыр фәннәр докторына майор үзенең шәхси запасларыннан алып аракы эчерткән, хәтта алып кереп йокларга яткырган.

Икенче тапкырында Абрам Ильич тагын үзенең кемлеген аңлатырга тотынган һәм бары тик майорга эч серләрен бушаткач кына тынычланып йоклап киткән. Берничә тапкыр шулай кабатланган, әмма доцент килгән саен докторлык дәрәҗәләрен арттыра бара икән. Анын мактануына чыдый алмаган майор ышанмыйча башын чайкаган:

—Азрак эчәргә кирәк, хөрмәтлем,—дигән.—Үткән юлы сез егерме алты мәртәбә доктормын дип лаф орган идегез, бүген инде егерме сигез тапкыр!

Гадәттә тыныч холыклы доцент кабынып киткән.

—Әйе шул, шушы өч айда минем диссертацияләрем буенча тагын ике кеше докторлык яклады, шунлыктан егерме сигез була да инде ул,—дигән. Ышанмаганга гарьләнеп, диссертация темаларын да, алар буенча кемнәр яклаганын да әйтеп ташлаган.

Абрам Ильичның диссертацияләре төрле-төрле булып, нигездә, җәмгыять белемәнә багышланганнар, халыклар дуслыгы темасы өстенлек ала икән. Аларның хәтта житмеш варианты бар, ди. Әдәбият белеме буенча да хезмәтләре житәрлек: хәзерге заман прозасы, поэзиясе һәм драматургиясендә уңай герой, яки проза, поэзия һәм драматургиядә милли характерлар бирелеше. Шәп бит!

"Эти" әсәрләре буенча докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре тулы бер киштә алып торганнар, ләкин ул аларны теләсә кемгә бирми икән, бәяләре дә сизелерлек дәрәҗәдә кыйммәтрәк йөргән.

Әле сугышка кадәр үк төзелгән иркен квартир киштәләр белән тулы булып, аларда тормышта булырга мөмкин теләсә нинди темага диссертацияләр саклана, барысы да алфавит буенча тәртипкә салынган, каталоглар саны гына да егерме дүрттән артып китә иде. Моны ватылмый һәм туктап тормый торган конвейер диярга булыр иде. Әгәр дә кемдер сораган темага диссертация кул астында булмаса, фәнни эшкуарлык, заманча әйткәндә, гыйльми бизнес буенча эшләп ятучы коллегалар ярдәмгә килгән. Мәскәү, Ленинград, Киев, Тбилиси, Новосибирск вә һәм фәндә

танылган башка калалардан авиабандероль бер атнада килеп житә. Фирма сәгать кебек төгәл эшләп яткан булып чыкты.

Диссертацияләр коеп ятучы доцент берничә тапкыр айныткычка кереп чыккан, кергән саен теле ачыла бара, сак вә шикләнүчән майор үзләре хакында айныткычта нинди сүзләр сөйләнеп ятуын тиешле кешеләргә житкерергә кирәк тапкан. Абрам Ильичка телен кыскартырга киңәш иткәннәр, киңәш үтемле булганмы, шуннан соң ул бер ел буе диярлек айныткычка эләкмәгән. Ләкин вакытлар узу белән кисәтү онытыла төшкән булса кирәк, барысы да янадан кабатланган, бу юлы инде доцент шешәдәш дусларына барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп биргән: обком секретаренә докторлык диссертациясе язып бирүен дә, ОБХСС башлыгының хатынына, туган көненә тагын бер докторлык диссертациясе әзерләп ятуын да калдырмаган.

Утыз тапкыр фәннәр докторының Әнвәр Абидовичка язып биргән докторлык диссертациясе турында искә алуга бер көн дә узмый, бичара көпә-көндез шәһәр урамында самосвал астына кереп һәлак була. Чуерташ төягән машина астына. Шунысы сәер, машина анын районындагы автобазадан урланган булып чыкты, шунлыктан ул фажигагенең барлык нечкәлекләре белән танышырга мәжбүр булды да. Машинаның жинаять кылу өчен махсус урлануы тикшерүчедә шик тудырмады тудыруын, ләкин уйланыр урын бар иде, әйтик, машинаны якынрак жирдән, Заркентның үзеннән табып булмады микәнни. Жинаятьне тикшерүдә жин сызганып полковник Халтаев катнашуга карамастан, үтерүчене таба алмадылар. Барысын да алдан исәпләп куелганча, юл һәлакәте дип игълан иттеләр, шуннан зыян күрүче исерек булган дигәнгә дә ерак калмады. Доцентның хатыны анын ашказаны авырта иде, өч көн буе авызына тамчы да эчемлек капмады, дип тәкрарласа да, болар расланмады, экспертиза галимнең канында һәм ашказанында алкоголь тапты. Хәер, моны эшләве авыр түгел, алдан уйлап эшләнгән мондый жинаятьләрдә һәлак булучының авызына бер шешә аракы коеп китүләре хакында күпләр белә иде.

Мәхмүтов инде йоклап китә алмаячагын аңлап алды, ятып торунын мәгънәсе юк, шунлыктан ул шоферы Госманны черем дә итмәгән көйгә каршы алырга булды. Иртән "Коммунизм" колхозына барып кайтырга кирәк. Карасуда, үзе төзеткән һәм ин яраткан күпереннән ерак түгел тау битендә, утыз гектарда йөзем бакчасына нигез саласы бар иде. Хикмәт шунда, ул жирләрне Әхмәтжановлар гаиләсе ун елга арендага алмакчы, колхоз житәкчеләре каршы төшә, янәсе арендаторлар хужалык исәбенә умырып табыш алырга жыена. Эшләр яхшыдан китсә, күпме акча керәчәген дә исәпләп чыгарырга өлгергәннәр. Үзеннекен булдыруга караганда, кеше кесәсендәгесен санау жинелрәк шул. Эшнең унай китәчәге шикләндерми иде, чөнки Әхмәтжановлар гаиләсенең башы—сиксәнне узган булуга карамастан, әле шактый таза һәм нык Базар әкә ихатасындагы бакчада мул уңыш бирүче ниндидер бер йөзем сортын саклап кала алган, бөтен өметләре шунда иде. Базар әкәнең бабасы да, атасы да йөзем үстерү белән танылган кешеләрдән санала.

Булат Мөэминович күп балалы арендаторлар гаиләсенә ярдәм кулы сузуны үзенең намус эше буларак кабул итте, кешеләргә жиргә хужа булу хисен кайтарасы иде бит. Үз жирең, үз уңышың. Барысы да үзеннән тора. Юкса, районда гаилә подряды дигән нәрсәне кертеп булмый, бөтен нәрсәне әле тегеләй, әле болай боргалап халыкның желегенә үткән мәгънәсез реформалардан гарык булганнар иде инде.

Ләкин ничек кенә тырышмасын, райком секретаренын уйлары барыбер Әхмәтжановлар гаиләсе мәшәкатьләре тирәсендә генә туктап кала алмады, баштан Кәтүк китми иде.

Халтаевны Заркентка күчермәсә дә, ул полковниктан башка бер генә гамәл дә кылмый, аңа органнардагы теләсә кемгә караганда, хәтта бажасы, ОБХСС башлыгы Нурматовка караганда да ныграк ышана иде бугай. Бәлки Халтаевны юри үзәккә алмый торгандыр да, чөнки ул барыбер кул астында, Заркенттан нибарысы илле чакрымда, ике көннең берендә полковник хуҗасы янына барып кайта. Гап-гади полковникның аерым вәкаләтләре барлыгын өлкәдә барысы да белеп өлгергән иде инде.

Хәзер Наполеон Мәскәүдән килгән кунакларны кабул итүне бары тик Халтаевка гына ышанып тапшыра, чөнки Леонид Ильичның куәтле кияве белән дуслашып кала алмаганына бик үкенә иде. Шунлыктан, Мәскәү кунаклары һәрчак аның игътибар үзәгендә булырга тиеш иде. Ул хәтта ниндидер йомыш белән балык промышленносте министры килеп чыккач, аны патшаларга гына күрсәтелә торган кадер-хөрмәт белән каршы алды. Юкса, коры җирләр хөкемдары саналучы Кәтүккә диңгез кинлекләре хуҗасының артык кирәге юк иде. Кем белә, бүген балыкчылык белән җитәкчелек иткән кешенең иртәгә халык контроле яисә партия контроле белән идарә итү ихтималы юкмы?! Барысы да булырга мөмкин. Менә шул чакта инде аңа янәдән дуслык җепләре сузуның кирәге калмас.

Кабул итү, каршы алу бер нәрсә, иң мөһиме—халык йоласы, бездә гадәтләр шундый дигән сылтау белән кунакка зур суммада ришвәт төртә белү иде. Бу өлкәдә полковник тиңе күрелмәгән оста булып чыкты да. Ул алучыга да һәм бирүчегә дә уңайсызлыклар тудырмый торган гади һәм бер үк вакытта кире каккысыз ысул уйлап тапты, шуның өстенә, акча алуны инкарь итәрлек юл калдырыла иде.

Бохараның укалап чигү остаханәләрендә полковник бик күп итеп затлызиннәтле, парчалы бизәкле бәрхет халатлар тектереп алды, һәрберсенә тирән вә киң кесәләр салдырды. Халатны бөтен халык алдында кунакның иңнәренә салалар, мондый йоладан баш тартуы кыен, кесәдә банк төргәгендәге акчалар ятканлыгын беркем сизми. Акчасы да төрлечә була, монысы инде кунакның дәрәҗәсенә карый. Әйтик, союз күләмендәге министрга йөзләкләр төргәге кулайрак булса, ваграк түрәләргә илләлек, яисә егерме бишлекләр дә ярый иде.

Шушы вакыйгалардан берничә ел үткәч, элеккеге балык министрына кылган гөнаһлары өчен җавап бирергә туры киләчәк; мөмкин булган байтак ришвәтләрне таныса да, ул Заркентта алынган бакшиш хакында ләм-мим, чөнки полковник Халтаев уйлап чыгарган ысулның һич кенә дә шик тудырырлык вә исбатларлык түгел икәнлегенә ышана. Әмма тикшерүчеләр дә милиция башлыгыннан аңгырарак түгел иде шул. Тагын ун меңне дәүләт казнасына кайтарырга кирәк, дигәч, элеккеге министрның күзләре маңгаена менде, ул затлы халатны өстемә кию түгел, кулыма алып караганым да юк, дип ант итәргә тотынды. Кая инде ул кесәләрен тикшереп тору. Әмма өенә кайткач, министр тикшерүчегә шылтыратырга һәм чыннан да кесәдән бер төргәк йөзлекләр килеп чыгуын әйтергә мәҗбүр була, акчаларны иртәгә үк банкка тапшырып, квитанция китерәчәгенә ышандыра.

Кәтүк полковникка "Әти"нең үтенече белән бәйле башка нәзберегрәк йомышларны да ышанып тапшыра башлады. Аңа, әйтик, Мәскәүдәге көндәшләрен күзәтергә, ял вакытларында үзләрен ничек тотуларын белеп торырга кирәк. Бөтен компромат нигездә курортларда җыела. Мондый очракларда Югары абзый аңа гына түгел, Әкмал ханга да мөрәҗәгать итә, чөнки аңысының тулы бер шымчылык бюросы эшләп ята. "Әти" үтенеченнән башка да "кирәкле" кешеләрне фаш итәрлек компромат җыю белән шөгыльләнә иде.

Үз мәнфәгатьләренең кай тирәдәрәк әйләнгәнлеген Аксай ханына бик

белдерергә теләмәгән очракларда Беренче Кытай патшасы сынарына таяна торган булып китте. Ләкин, шулай да, эш Мәскәү тирәсенә барып терәлә калса, "Эти" күбрәк Әнвәр Абидовичка ышана, чөнки бу яклардагы яшерен бизнесның, ягъни күләгәдәге икътисадның башында торучы Артур Шубаринның дусты икәнен белә. Ә анысы өчен чишелмәслек берниндиi мәсьәлә дә юк.

"Эти"нең үтенечен обком секретаре Шубаринга җиткерә, аның кешеләре Халтаевныкына караганда югарырак даирәдә бөтерелә, эшкуарлар даирәсендә Япон дип танылган Шубаринның Мәскәүдә дус-ишләре хәттин ашкан, ул Беренченең йомышларын үтә бер җаваплылык хисе белән башкара, бирелгән отчетларга хәтта фоторәсемнәр белән бергә магнитофон язмалары да теркәлә торган иде.

Бик сирәк булса да, эш мәнфәгатьләреннән чыгып, Кәтүккә Шубарин белән Халтаевны да таныштырырга, бергә бәйләргә туры килгән чаклар булды. Ләкин алар бер-берсен күрә алмыйлар, кулыннан килсә һәм мөмкинлеге чыкса, полковник Артур Александровичны тере көйгә тотып ашарга әзер иде, ләкин Шубаринга теше үтмәгәнлеген, аның үзенең теләсә кемне көлгә әйләндерерлек куәте барлыгын белү кулын тота иде.

Менә бүген, тәүбә-истигъфар көнендә, Мәхмүтов бөтен тормышын күз алдыннан кичерде, ничек яшәгән, ничек эшләгән, намусы чистамы? Боларның барысы хакында хисап тотар вакыт җиткән иде.

Хәзер генә ул йә хөкем ителгәннәр эскәмиясендә утыручылар авызыннан, йә матбугат битләреннән сонга калган, тәүбәгә дә, үкенүгә дә охшаш аклану авазлары янгырый тора, янәсе ул берни дә белмәгән, аны утыртканнар, мәҗбүр иткәннәр. Хәер, ничек кенә мәҗбүр итәләр иде әле, кайбер колхоз председательләрен райком секретарьлары кабинетларына бикләп, кулларына өчәр потлы гер тоттырып, тәртипсез мәктәп балаларын җәзалагандай, янап һәм кыйнап, фәлән-фәләнчә мамык җыйдым дип, өстәп язуларга мәҗбүр итәләр иде. Барысы да шулай. Ләкин шул ук вакытта, хәзер барысы да инде "Эти"гә сылтанса да (үлгән кешедән нәрсә сорап була), аның тарафыннан ризалык бирелмәгән башбаштаклыклар да хәттин ашкан иде.

Мияссәрәгә бервакыт туры рейс белән Кара Түбәдән Мәскәүгә очарга туры килде. Җәй челләсенең котырган чагы булып, кояшта температура инде алтмыштан узган, тын алырлык түгел иде. Самолетны вакытында бирделәр бирүен, юлчыларны кертеп утырттылар, ә очкыч кузгалырга җыенмый да. Сонгы елларда Аэрофлотның гадәтенә әйләнгәнчә, рейсның ник тоткарлануы турында игълан да юк, һич югы, сәбәбен генә әйтсәләр дә күнел тынычланыр иде. Эсселеккә чыдый алмый кемнәрдер һушын югалтты, йөрәк чирлеләр агарып чыкты һәм бары тик сәгать ярымлап вакыт узгач кына салонда кырык яшьләр тирәсендәге бер ир күренде. Кулына "дипломат" тоткан, энә-җептән киенгән һәм бөтен кыяфәте белән ерак башкаладан килгәнлеген сиздереп торган бу адәм ашыкмый гына салонда урынын эзләп тапты һәм шуннан соң гына самолет күккә ыргылды. Аэрофлот белдерүләреннән башка да очкычның ни өчен тоткарланганы барысына да ачыкланды. Күрәсең, кәттә кунак булгандыр, диештеләр.

Мияссәрә белән янәшә утырган пассажир сонга калган бу кешене белә булып һәм гади генә әйтеп куйды, Кара Түбә обком секретаренең Мәскәүдә укучы аспирант улының фәнни җитәкчесе ул, диде. Мәскәүгә килеп җиткәч, багаж алырга чират торганда Мияссәрә эчендә кайнаган ачуга чыдый алмады, яшь профессор янына килеп туп-туры сорау бирде: "Оят түгелме сезгә, сезнең аркада өч йөздән артык кеше эсселектән газап чикте",—диде.

Мәскәү кешесе Мияссәрәдән түбәнчелек белән гафу үтенде һәм сонга калу сәбәпләрен аңлатыр алдыннан үзенең бүтән беркайчан да Урта Азиягә

килмәячәген белдереп өлгерде. Анын сүзләренә караганда, унайсыз хәл болайрак килеп чыккан икән. Китәсе көнне улынын фәнни житәкчесен өлкә хужасы кунакка чакырган. Табын әзер, кунаклар жыелган, ә хужа юк та юк, эшендә тоткарланырга мәжбүр булган. Самолет очарга өч сәгатьләп вакыт калганда гына табын янына утыра алганнар, кунак капкалап алырга да, шәрабтан, тегесеннән-бусыннан авыз итәргә дә өлгергән һәм жаен туры китереп, китәргә тиешлеген, Аэрофлотнын аны көтеп тормаячагын әйтеп алган. Бәлки хужага Аэрофлотнын мөстәкыйльлеге, үзбаш эш итүе турында әйтү ошамагандыр, бәлки бүтән сәбәпләре булгандыр, ул пылаудан авыз иттермичә барыбер жибәрмим, а самолет, арба булмаса да, барыбер көтеп торыр, дигән. Шул ук минутта аэропорт башлыгына шылтыратып Мәскәү рейсын анын мөхтәрәм кунагыннан башка жибәрмәскә әмер биргән.

Икенче бер шундыйрак очрак та Аэрофлот белән бәйле иде, анысына Булат Мөэминович үзе шаһит булды.

Бервакыт шулай өлкә комитетында хужалык житәкчеләренен ниндидер кинәшмәсе уздырылды, ана кирәге дә, кирәкмәсе дә дигәндәй, бөтен азмы-күпме кәнәфи биләүчеләр чакырылган иде. Алфавит тәртибендә предприятие житәкчеләреннән кемнәрнен килгәнлеген барлый башлагач, ниндидер зур булмаган бер төзелеш идарәсе башлыгынын юклыгы ачыкланды.

Кәтүк шартларга житте, обком хәтле обкомны санга сукмаска кем ул, күтәрелгән борынны бик тиз төшерә беләбез без, дип ярсырга керește. Ана төзүченен трест житәкчесе чакыруы буенча Ташкентка, начальнигы белән очрашуга киткәнлеген әйтеп карадылар. Кая ул! Самолетнын инде һавага күтәрелгәнлеген ишетүгә, ул аэропортка шылтыратты һәм Ташкентка житеп килүче самолетны кире борып кайтарырга кушты. Лайнерны бору гына житмәгән, тынлаусыз инженерны җилтерәтеп обкомга китереп житкерү өчен ул аэропортка өлкә милиция башлыгын жибәрде. Дөрес, төзүче инженерны кинәшмә залына кулларына богау салмыйча гына алып килделәр килүен, милиция полковнигы заданиенен үтәлүе хакында рапорт биргәндә өлкә хужасы имән бармагын янаулы кыяфәттә өскә күтәрде һәм төзелеш идарәсе начальнигына төртеп күрсәтеп, залга игълан ясады:

—Обкомда узган кинәшмәне санга сукмаучы һәркем менә шушылай китереләчәк. Кирәк булса жир астыннан табарбыз!—диде.

Власть сөючән, бер нәрсәдә тыелу белмәгән түрәләр ни теләсәләр шуны эшләделәр, мондый кыргыйлык аларга "өстән" төшерелмәгән, һәркайсы үзе белгәнчә кылана, үзенчә мөгез чыгара иде.

Хужалык эшләренә кереп баткан һәм ерак бер районда эшләп ятучы Күпер Булат Әкмал ханнын көтмәгәндә шулай югары күтәрелүенә аптырый, республикада анын чикләнмәгән властька ия булуына шакката, монын сәбәпләрен анлый алмый иде. Шулай берчакны ана Ташкентта, улы янына кунакка баргач очраклы рәвештә генә Копполанын "Крестный отец" фильмын карарга туры килде. Әйтергә кирәк, ни тәнгә, ни жанга дигәндәй, фильм анда әллә ни тәэсир калдырмады һәм ул кайчан да булса аны исенә төшерермен дип уйламаган да иде. Ә искә төшерергә туры килде. Бу роман инде бездә дә басылып чыккач, ул "Знамя" журналынын ике номерын да табып алды һәм игътибар белән укып чыкты. Анын үзе өчен кайбер нәрсәләрне ачыклыйсы бар иде. Хәзер ул Әкмал ханнын кыланышлары турында матбугаттан укып та, тикшерүнен ничек барганын Халтаевтан ишетеп тә белә иде инде. Марио Пьюзо да, Коппола да әсәр героен сурәтләгәндә фактларга, суд материалларына таянганнардыр, әмма дә ләкин аларны бөтен дөньяга таныткан ижат фантазиясе Аксай ханы кылган гамәлләр янында югалып, төссезләнеп кала иде. Совет власте урнашканнан

соң алтмыш ел узгач үзеннен шәхси ханлыгыңны оештырып кара әле, аның белән хәтта феодализм чорындагы ханлыклар да тиңләшә алмас иде.

Лондонда балавыз фигуралар музее булдырган мадам Тюссоның үз коллекциясендә Әкмал хан сынын да булдырырга теләве бер дә гаҗәп түгел.

Менә кадәр беркем дә белмәгән, беркем дә юньләп ишетмәгән бер кышлакта утыручы ханның республика Югары суды председателен алып атуы үзе генә дә ни тора. Хәзер бу бөтен республикага мәгълүм факт. Мондый нәрсә дон Карлеоннның да кулыннан килмәгәндер. Менә бик гади бер факт сәбәп булган имеш. Югары суд рәисе ниндидер бер зур түрәнең хатыны белән чуала башлаган, бер карасаң, гап-гади тормыш чуалчыклары кебек. Әмма моны болай гына калдырып буламы?! Рәнҗетелгән түрә үч алырга карар бирә һәм иң каты җәза итеп мәкерле уйнашчыны кәнәфиеннән мәхрүм итү чарасын сайлый. Бөтен илендә шулай булгач, моннан да кулайрак ысул юк та юк инде ул. Ир-атның бөтен өстенлеге вазифа белән үлчәнә дә бит. Кәнәфидән, азмы-күпме дәрәҗәле урыннан мәхрүм ир-ат шунда ук кеше күз алдында кечерәеп, бәләкәйләнеп кала. Шәрекъны һәм Кавказ якларын азмы-күпме күргән кеше яхшы белә, бу иң куркыныч үч, чөнки монда дәрәҗәсе булмаганнар тере мәеткә тиң. Портфельсез кешене чекрәеп торса да күрмиләр, алар буш урын. Тере мәеткә нинди генә хатын-кыз кызыгыр икән? Үзен рәнҗетелгән дип санаган ир ранглар табелендә хөрти донжуанга караганда күпкә биегрәк баскычта торган, һәм шунлыктан, шундый коточкыч үч алу планы корган да инде. Тик судья ягында да шактый саллы адәмнәр булып, алар юл куймаган. Ни генә эшләп карамаган түрә агаебыз, акчасын да, малын да җәлләмәгән, әмма максатына таба бер кәррә дә алга бара алмаган. Менә шунда инде ул Аксайга, Ариповка баш иеп барырга мәҗбүр булган. Башка юл калмаган.

Гаҗәп, тормышта "Крестный отец" сюжеты төп-төгәл кабатлана. Әкмал хан, табигый ки, югары кунакның көтелмәгән визиты хакында, аның ни өчен нәкъ менә Аксайга гаделлек эзләргә килүе сәбәпләрен дә төгәл белгән, шулай булуга карамастан, контор коридорларында бер атналап тозлагач, ягъни көттереп газаплагач кына кабул иткән. Очрашкач та әле: "Яхшы чакларда бер дә итагать саклап тормый идең, хөрмәт визиты белән килеп чыгу башыңа кереп тә карамады, ә артыңа килеп терәлгәч, үрмәләп килеп җиттең", дип битәрләп җанын кыйнаган.

Хуҗаны гаделлек хисе дә, кунакның намусы мәсьәләсе дә борчымый, әлбәттә, ләкин Югары суд рәисенә мөнәсәбәттә аның үз планнары да булып, ул байтактан инде ул урынга үз кешесен утыртырга чамалап йөргән була. Менә шунда аларның мәнфәгатьләре тәңгәл килә дә. Бер атуда ике генә түгел, өч куянга тидереп буласы. Беренчедән, республикадагы иң мөһим постларның берсен үз кулына ала; икенчедән, бик дәрәҗәле кешене вассалына әйләндерә һәм нәкъ менә аның кулы белән судьяны бәреп төшерә; өченчедән, халык арасында абруен күтәрә, гаделлекне, игелек һәм намусны яклаучы буларак танылa.

Барлык танылган кешеләргә җыелган кебек үк, судьяга да шактый бай досье әзерләнгән булып чыга. Кеше язмышларын хәл итүче адәмнең донжуанлыктан тыш та гөнаһлары хәттин ашкан, төртеп күрсәтә белергә генә кирәк. Әкмал хан аңа иң каты компроматларны тапшыра һәм Югары суд бинасында гауга куптарырга куша. Барысын да нәкъ ул әйткәнчә эшлиләр, барысы да шулкадәр табигый килеп чыга ки, үзен кәнәфидән башка күз алдына да китерә алмаган судья менә-менә аннан очып төшәчәген сизенеп, ярдәм сорап "Әти" янына чаба. Тегесе инсәләрен генә җыера, халык арасында яманаты чыккан мондый гауганы хәтта ул да каплап кала алмый. Кыскасы, судьяны очырталар. Аннан алда гына Арипов, һәр көн

диярлек гадәткә кергәнчә, хөкүмәт телефоны буенча Беренче белән сөйләшкән, вакантлы урынга кемне утыртуның мәслихәтрәк булачагын да әйтеп куйган була.

Аксай ханы республикада азмы-күпме билгеле кешеләрнен һәркайсына кушамат тагарга ярата, аларның кайберләре халык арасында да кин мәгълүм. Мәсәлән, өлкәдәге идеология секретарен ул колгадай буе өчен Жираф дип атаган, үзе юкта анын хакында башкача әйтмиләр дә. Шунысы кызык, мәгълүм бер кешегә тагылган кушамат ат көтүендә кабатлана, үзе яраткан атларны шул исем белән атый. Хәтта "Әти" дә читтә калмаган, ана әйтелә торган "Шурик" кушаматын көтүдә холкы белән Беренчегә охшаганрак айгыр йөртә. Эстафетаны Беренчедән алган, кайчандыр үзе куйдырган Бикхуҗаевны ул муллага охшаганрак кыяфәте өчен Фәрештә дип атый, хәер, дөреслек хакына әйтергә кирәк, анысы бер дә изгелек белән аерылып тормый. Киресенчә булмаса. Икенче бер яранын, кодрәтле Яллаев урынына эчке эшләр министры итеп утыртылган Пиргашевны ул Кәрлә дип йөри. Үзе өчен дә ташлама ясамаган, ана хөрмәт белән Хуҗа дип эндәшәләр. Әмма инде "Безнең Сталин" дип тә җибәрсәләр, ул күз алдында үзгәрә, йөзе кояштай балкый башлый. Кара Түбә секретаре үзен "Безнең Ленин" дип әйттергән кебек, анын да янгыравык исемнәрдән башы әйләнә иде. Маршал Гречко исеме исә аерым бер хөрмәткә, хәтта тылсым көченә ия, кемдер ана "Сез Гречко шикелле" дип ычкындыра калса, ул үзен бәхетнен җиденче катында хис итә иде. Ләкин бу күпләр өчен сер. Күрәсен, Әкмал хан көч алдында баш ия һәм үз кулы астында маршал кебек армия тоту хакында да хыяллангандыр.

Кемнәр нәрсә хакында гына хыялланмый, ниләр генә кыланмый, шунысы кызык, хакимияттә өстәгеләр вә һәм астагыларның хыял-максатлары бер тамчы судай охшаш иде. Әйтик, Беренченен кинәт кенә Октябрь яшьтәше буласы килде ди, һәм шулай булды да, ул нәкъ шул көндә туган булып чыкты һәм үзенең гомер дәфтәрен Ил белән бергә алып бара башлады.

Сүз уңаеннан, Кәтүкнең иң еш һәм яратып әйтә торган "коммунист тыйнак яшәргә тиеш" дигән тәгъбире дә "Әти"неке булып, тугрылыклы шәкерт монысын да остазыннан урлаган иде. "Әти"нен дусты да калышмады, Беренче майны—хезмәт иялӘренен Бөтендөнья бәйрәмен үзенең туган көне дип игълан итте, бу көнне уздырылучы парадлар һәм демонстрацияләр, күнел ачулар барысы да анын хөрмәтенә багышлана кебек тоела башлый иде. Хатынының да күнелен күрә белде, сигезенче март анын туган көне дип игълан ителде. Болай китерелгән бүләкләрне ачыктан-ачык кабул итәргә кулайрак, аларны икеләтә китерсәләр дә комачауламый. Нишлисен, бәхетле кешеләргә ике бәйрәм шулай бергә килә инде ул.

Үзләренең гомер юлларын ил тарихындагы бөек даталарга бәйләп кую артык гаҗәп тоелмый, башкасы гаҗәпләндерә: ни "Әти"нен, ни анын Аксайдагы дустының балачак һәм яшьлек елларын чагылдырган төп документларның әле бүгенгәчә табылганы юк.

Хатынының сенлесенә карата Кәтүкнең мөнәсәбәте нинди дер бозыклыкка—патологиягә охшаган иде. Арипова да нәкъ шундый ук патологик дәрт булып, ул күбрәк хайваннарга тартыла, атлар янында булуны кешеләр белән аралашудан өстенрәк күрә иде. Кайдадыр ишеткәне бар, имеш, атлар арасында яшәгән кешенең гомере озын була. Шунлыктан ул ат көтүен ишәйткәннән ишәйтә барды, хан сараена охшатып ат абзарлары төзетте. Аксайда атлар кешеләргә караганда әйбәтрәк яши иде. Анын шулай ук арысланы, тәвә кошы, күз күрмәгән, колак ишетмәгән балыклар асралучы

буасы бар, шуның өстенә, Карахан атлы усал-явыз эт асрый, якын-тирә авылларда ул тешләмәгән, ул ташланмаган кеше сирәктер. Әнә шул Карахан белән Саман кушаматлы чаптар аның дөньяда иң сөйгән җан ияләре иде. Тагын бер сәер ягы бар ханның, ул шул җан ияләрен һәм хәтта кешеләрне бер-берсенә каршы котыртырга, сугыштырырга ярата. Әтәч яисә бытбылдык сугышы, этләрнең өерелеп сугышуы дигәндә элеккеге трактор бригадасы хисапчысының авызыннан селәгәй ага башлый. Ул хәзер бик сирәк очрый торган тагын бер гамәл тапты, анысы—айгыр сугыштыру. Сөекле Караханы да сугыш чукмары булып, бәрелешләрдә дистәләп көндәшен чәйнәп ташлаган усал эт иде. Бүре буар этенең көченә шулкадәр дә нык ышанган иде Әкмал хан, көннәрдән бер көнне Караханны җиңгән этнең хуҗасына егерме биш мең сум бүләк бирергә җыенуы хакында игълан иттерде. Андый кеше табылды һәм якын-тирәдәге халыкны бөек хуҗаның этенең куәтен күреп шатланырга стадионга кудылар. Ләкин... Карахан җинелде һәм аны хурлыклы үлемнән бары тик җиңүче эт хуҗасының пистолеттан атып үтерүе генә коткарып калды. Вәгъдә ителгән бүләкне исә хуҗа бирергә уйламады да, талап җыйган байлыгы белән аерыла алмый иде ул. Кәефе яхшы чакларда ул еш кына “Әйе, мин саран, үтә саран кеше” дип кабатларга ярата һәм шаркылдап көлә торган иде.

Йөз, йөз илле яшькә кадәр яшәү хыялыннан ул беркайчан да ваз кичмәде, һәм шунлыктан, бөтен буш вакытын ат сараенда, мәрмәр колонналар куелган, агачны бизәкләп-сырлап ясалган ишекләр куелган абзарда үткәрә торган булды. Хәер, аларны абзар дип әйтү гөнаһ булыр, чын хан сарае кебек бизәлгән зиннәтле корылмалар иде алар. Кинәшмәләр, кунакларны кабул итү кебек рәсми чаралар да шунда уздырыла, һәркайда телефон аппаратлары. Озын итәкле толыпка төренеп, кулдан тукылган келәм-паласлар түшәлгән сарайда ул Саман белән Карахан янында төн үткәрергә гадәтләнеп китте. Әйе, атлар, хәтта иң усал һәм кыргый, башбирмәсләре белән дә ул уртак тел таба, буйсындыра белә. Аны үз гомерендә бер генә тапкыр ат тешләде, Дон токымлы яшь айгыр иде ул. Әкмал хан ике дә уйлап тормый шунда ук пистолет тартып чыгарды һәм аны атып та үтерде. Хайваннардан тыш, икенче яраткан нәрсәсе корал булып, ул аларны беркемгә дә ышанып тапшырмый, сәгатьләр буе сөтә-җыя, үзе чистарта, үзе үк куллана да.

Атларны артык күп тотканлыктан, айгыр сугышы оештыру бернигә тормый. Бу кадәр исрафчыл рәвештә үз заманында чын ханнар да күнел ача алмаганнардыр. Тамырларындагы канынны катырырлык күренеш ул. Күзләрен кан баскан хайваннар яман хырылдаган тавыш чыгарып бер-берсенә ташланалар, дагалаган тояклары тәннәрен ерта, ыржайган тешләре бер-берсенең итен умыра, яшь, бармак тигәнгә дә калтыранып китүче тәннәреннән кан ургый, яраланган атларның кешнәве сугыш кырындагы яралы солдатлар ынгырашуын хәтерләтә. Җиңелгән айгырны шунда ук пычак астына җибәрәләр, кичкә бишбармак әзер була. Әкмал хан итләрдән иң асылы дип җылкы итен саный, иң тәмле җирләреннән аңа махсус казылык әзерлиләр.

Ит авыз итү мәҗлесендә ул ит буларак табынга куелган айгырның нинди токымнан булуын, кайдан кайтартылуын, элегрәк нинди сугышларда җиңүен тәфсилләп сөйләргә ярата. Бирәннәрчә ашап һәм эчеп утырган, еш кына уйнаш белән тәмамланучан бу мәҗлесләрдә игътибарлырак кеше ниндидер бер каннибаллык-зәнкилек чалымнарын да тоемлар иде.

Әгәр дә Булат Мөэминович кемгәдер житмешенче еллар ахырыннан башлап, Наполеонны кулга алып хөкем иткәннән соңгы ике елны кертмичә, карарларны беркайчан да мөстәкыйль рәвештә кабул итмәдем дисә, аңа

беркем дә ышанмас иде. Ышануы кыен. Футболда да шулай, әгәр судья ниндидер бер команда файдасына уйный башласа, гадирәк әйтсәк, аның бу жуликлыгын бөтен стадион күреп тора, жинелгән команда шундук сизеп ала дип уйлыйсызмы. Ысуллары санап бетергесез күп аның. Кесә карагын кулыннан тотып булмаган шикелле, нәрсәнедер күрми калырга, яисә бөтенләй мөһим булмаган башка берәр гамәл күзгә ташланырга мөмкин. Уен кызганда кагыйдәләрне бозмавынны исбатлау ай-һай авыр, шул ук вакытта кагыйдәләрне дә төрлечә аңлатып була...

Бер карасаң, Тилләхажиев беркайчан да турыдан-туры хокук тәртибенә каршы килүче гамәл кылырга кушмады, әйтик, акча сораганы булмады. Районлагы барлык азмы-күпме төшемле, мөһим саналган урында Халтаев—Тилләхажиев кешеләре утырганлыгын райком секретареннан башка беркем дә раслый алмый.

Яздан әкә белән Халтаевның дус-ишләре керемле урыннарны иярләү белән бергә, районнан башлап республикага кадәр булган барлык дәрәжәдәге органнарда депутатларга әверелделәр.

—Депутат кагылгысызлыгы шәп нәрсә ул!—пылау капкалап утырганда милиция башлыгы исерек баштан еш кына шулай шапырынырга ярата башлады һәм үз кешеләрен депутат мандаты белән тәэмин итәргә тырышты.

“Ижтимагый дәрәжәләрең белән бүләкләрең күбрәк булган саен утыру ихтималың да кими бара”.—Билгеле бер даирәдә канатлы әйтемгә әйләнгән бу тәгъбир полковник уйлап чыгарган сүзләр иде һәм ул еш кына шаяртып “Утыртам мин сине!” диярга ярата башлады. Аның авызыннан чыккан бу сүзләрнең дистәләрчә төсмере булып, кайберәүләр тәгәри-тәгәри көлә, кайберәүләрнең исә йөзе кәгазь кебек агара иде. Ул бу тәгъбирне шулхәтле яратып куллана башлады ки, хәтта көннәрдән бер көнне яраткан нәни оныгы артык шаяра башлагач, аңа да гадәте буенча “Утыртам мин сине!” дип ычкындырган имеш.

Кәтүкне утыртканнан соң ике ел узды. Элеккеге райком секретарьларыннан бары тик Булат Мөэминович кына үзенең постын саклап калды. Ул еш кына бу хакта уйлана һәм бернинди шик калдырмый торган бәхәссез фикергә килде: аның районы батыруга бирешми торган бердәнбер корабль булып чыкты, чөнки Тилләхажиев аның шулай булырга тиешлеген алдан уйлап эш иткән, аны акылсыз һәм киләчәкне күзалламаучы адәм, дип булмый да булмый инде.

Текә күтәрелеп киткән көннәреннән башлап ук Тилләхажиев һәрчак тылны тәэмин итү хакында уйланган, теләсә нәрсә кылырга мөмкин көннәрнең үтәсен белгән, менә шул чакта инде аңа бар яктан килгән, бар яктан тәртипле район кирәк булачак. Шул ук вакытта хуҗасын да онытмаган, анысын аумакайлыкта, надаплыкта һәм комсызлыкта гаепләрлек булмасын. Боларны Мәхмүтов хәзер генә аңлады. Шуңлыктан, Тилләхажиев районны туган-тумачасына вә тәлинкә тотучыларына бирмәгән, Раимбаевның йөз мене дә кызыктырмаган. Чөнки яңа хуҗаларның районны бер-ике елда талап бетерәчәкләрен, как сөяккә калдырачакларын яхшы белгән ул. Алтын күкәй салучы тавык озын гомерле булырга тиеш. Обком секретарена өлкәнең йөзен якты итеп күрсәтүче витрина кирәк булган. Район чын мәгънәсендә алдаусыз, өстәп язуларсыз булсын, мул тормышта яшәсен, житәкчесе киң фикерле, укымышлы, мөстәкыйль һәм... нәрсә беләндер аңа тиешле, тупасрак итеп әйткәндә, аның кармагына эләккән кеше булырга тиеш. Шулай булып чыкты да түгелме соң? Башкалар кебек кызыл келәмдә урмәләп йөрмәсә дә, барыбер муенчаклы иде.

Мөстәкыйльлеге бар идеме? Шулайдыр. Ул башкаларга караганда бәйсезрәк иде. Бар житәкчеләрне дә мамык житештерүгә бәйләп буып

алдылар, ә ана зыянлы хуҗалык урынына табыш китерүчән нәселле ат заводы корырга рөхсәт иттеләр. Ул мыштым гына районнан мамык үстерүне бөтенләе белән кысрыклап чыгарды һәм Заркентны яшелчә, җиләк-җимеш белән тәэмин итүгә күчте.

Тилләхаҗиевнын моны рөхсәт итүендә мамык өчен, өстәп язулар өчен бик күпләрнең башы очачагын алдан ук сиземләү ятмыймыни? Берәр төрле башлангыч белән килгәндә өлкә комитетында аңламау яки каршы төшү сизелдеме? Андый очракны ул хәтерләми. Бәлки, ул коры идея-прожект белән (анысына обком секретаре үзе дә маһир) генә түгел, ә әзер исәп-хисап, нигезләмә белән килгәнгә күрә игътибар белән колак салганнардыр. Күпер төзүче инженер белеме аны проектның берничә вариантын эшләргә, чагыштырма анализ ясарга этәрә, бу исә обком секретарена ошый һәм ул аны башкаларга үрнәк итеп куя торган иде. Ни генә булмасын, Беренче вариантларны чагыштыра һәм отышлысын чамалый иде.

Әгәр дә ул райпотребсоюз председателен яисә җәмәгать туклануы җитәкчесен эшеннән алырга уйласа, моны берәрсе дөрес аңлар идеме. Тегесенең дә, монысының да хуҗалыклары өлкәдә иң алдынгылардан, республика күләмендә берничә тапкыр бүләккә лаек булдылар. Яздан әкә пешекчеләре Үзбәкстан декадасы көннәрендә Мәскәүдә, Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә үзбәк кухнясын халыкка таныттылар. План үтәлеше, рентабельлек, үзкыйммәт, продукция җитештерү—барысы да ал да гөл. Алдынгыларның алдынгылары. Контордагы һәр почмакта кызыл байрак. Коллективларның үзеннән дә, аларның эшенә карата да райкомга шикаять-фәлән килгәне юк. Кем аңласын? Әйе, аны төрле яктан чорнап алган кешеләрнең кулы чиста булмаса да, элэктерүләре нык, бу капкыннан акыллы һәм чиста куллы кеше ярдәменнән башка котылырлык түгел.

Шушы елларда ул нәкъ менә Яздан әкәнең Кәтүк алдында ышанычлы кеше икәнлеген аңлады да. Танышуның беренче көннәрендә, Сары Таш мәхәлләсе чәйханәсендә утырганда аның Халтаевны берничә тапкыр урынына утыртуы исенә төште, шулай булмыйни, чөнки акча капчыгы аның кулында. Тирә-яктагылар күзенә ташланмыйча гына хакимлек итү осталыгына менә кемнән өйрәнергә кирәк. Аның катылыгы, энергиясе, эшкуарлыктагы сизгерлеге, кирәгендә тәкәллеф саклап, кирәгендә тешләрен күрсәтә белүе дә көнләшерлек.

Моннан дүрт еллап элек, әле мамык Наполеоны үз көчендә, үз иярендә чагында ниндидер бер мәҗлестә мактанып Халтаев Яздан әкә турында болай дигән иде:

—Ул, һичшиксез, миллионер. Миллионнарының күпме, икеме, өчме, бишме икәнен беркем дә белми. Шул акчалары белән ул Кәтүккә күтәрелергә ярдәм итте дә инде. Беренче өч ел буе академиядә укыганда Яздан әкә белән без икәүләп Мәскәү юлын таптадык. Табигый, буш кул белән түгел. Мәскәүдә тормыш кыйммәт, ә безнең шеф колач белән яши, аңлавыбызча, киләчәктә кирәк булачак дип, кирәкле дусларын да таба белгән. "Пекин" яисә аның каршындагы "София" рестораннарында утыз яисә илле кешегә исәпләнгән мәҗлесләр корган булды, шул ике рестораны ярата ул.

Яздан әкә юк-бар сәбәп белән райкомга килми, Мәхмүтов белән танышлыгын, якынлыгын беркемгә дә сиздерми, ә эшләрен, язылмаган кагыйдәләрне төгәл саклап, Халтаев аша хәл итә иде.

"Чын власте булган кешеләр аны кумпайтып күрсәтергә тиеш түгел!" Яздан әкәнең тормышта тоткан бу кагыйдәсен дә ул соңрак белде.

Ул килгәч район үзәгендә теләсә кайсы башкаланың бизәге булырлык мәһабәт ресторан бинасы калкып чыкты, подрядчигы да, проекты да

табылды һәм ул халык арасында бик тиз абруй казанып өлгерде. Анда утыру өчен хәтта якын-тирә шәһәрләрдән килә башладылар. Яздан әкә, күрәсең, аның шулай булачагын күздә тоткандыр да. Ни генә булмасын, ял итү сәнгатенең үзенчәлекләрен, кешеләрнең ни-нәрсәгә әйләнеп каплану мөмкинлеген яхшы үзләштергән ул. Һәр җирдә диярлек шашлык, чебурәк, лагман сатучы затлы киосклар пәйда булды, пирожный, кондитер, шәрекъ тәм-томнары цехлары ачылды. Сумса, манты, тандыр кебаб кебек нәрсәләр пешерелә башлады, тавык ыслау җайга салынды. Шулай итеп, якындагы кошчылык фабрикасы да чәчәк ату чорына керде. Кеше һәм машиналар күп йөри торган чатларда бинибая зур казаннарда мәмрәгән пылау исләре таралды, өчәр чиләк сыешлы самавырлар җырларга керешге.

Әгәр дә кем дә булса сәүдә киметеп үлчәү, алдау, акчаны азрак кайтарып бирү исәбенә яши дип уйласа, нык ялгыша, болар барысы да үтелгән этап, сабыйлык чоры авыруы. Хәзер андый вак табыш канәгатьләндерми, андый вак каракларны Яздан әкә үз нокталарына якын да җибәрмәс иде.

—Сатып алучыны яратырга, хөрмәт итәргә, тәмле һәм матур итеп ашатырга кирәк, безнең бурыч шундый!—Кул астында эшләүчеләргә ул һәрвакыт шуны тәкрарлап торды һәм кайчан да булса һәр гаилә аның даими сатып алучысы, клиенты булыр дип хыяллана иде. Аның сәүдә нокталарында заказ буенча кабартма, сумса, башка төрле милли камыр ризыклары пешерәләр, кайнар көйгә үк аларны мотороллерларда илтеп тә бирәләр.

Җәмәгать туклануының нинди куәткә ия булганын хуҗадан башка беркем дә белми, чөнки ашханәләрнең өчтән икесе шәхсән аныкы, аларны ул үзе төзетте һәм үз акчасына тота, рәсми кәгазьләрдә, табигый ки, аларның берсе дә юк. Тикшерүче органнар аның кулыннан ашаганга күрә, моны эшләү бер дә кыен түгел иде. Яздан әкә сыйфатны бар нәрсәдән дә өстен күрә; әгәр дә мәгәр ул кайда да булса капкаларга керә, яисә пешерелгән ризыкны өенә алып кайта икән, бу инде барлык параметрлар буенча ин каты тикшерүгә дучар булу дигән сүз. Үзен алдаганны аның җене сөйми һәм алдатырга юл куймый. Халык ангыра түгел, ул сыйфатлы әйберне генә ала, табыш исә сату күләменә бәйле. Хәер, аны алдау чынлыкта мөмкин гамәл түгел, чөнки ул бер казан пылау яисә лагманның күпме торганын, сарык түшкәсеннән ничә данә шашлык чыгасын тиенenә һәм граммына кадәр белә, хуҗалык исәбе дигән нәрсә ин югары кимәлдә булып, ул сатылмый калган яисә бозылган ризыкны списать итү дигән нәрсәне бөтенләй белми һәм белергә дә теләми иде.

Ризыкны малга ашатуның ин зур гөнаһ икәнлеген ул һәрчак тукып тора, үзенең симертү базасы һәм ярдәмче хуҗалыгы булуга карамастан, мал-туарга ашханәдән бернинди өлеш чыгарылмый. Ярдәмче хуҗалык дигәннәрең дә хуҗасына мул керем биреп тора. Һәр якшәмбе Яздан әкә ярдәмчеләре белән бергә базарга яшь мал-туар алырга чыга. Симертү хуҗалыгының көтүлекләре колхозныкы белән янәшә, дәүләттә терлекне баш саныннан исәпләгәнлектән, арык бозаулар, таналар, ябык сарыклар янында мунча хәтле үгез, яисә берсе-берсе йөз егерме килограммнан артыкка тартучы Гиссар токымлы симез тәкәләр йөргәненә беркем дә игътибар итми. Табигый ки, сизмәмешкә салышу Яздан әкә тәмле телле булган өчен генә эшләнми, акчасын тамыза белә, әмма ул унысы белән кире кайта, ашханәләрендә беркайчан да яна итнең өзелеп торганы юк. Ярдәмче хуҗалык—симертү базасы дип аталган конвейер сәгать кебек эшли, матбугатта рекламалана, җитәкчеләрне сихерләгәндәй итә һәм күпләр Яздан әкә азык-төлек программасын хәл итүнең хәлиткеч юлын тапкан дип уйлыйлар иде. Эшкә кертеп җибәрелгән акча ай саен икеләтә арта бара, рентабельлек һәм үз-үзенне аклау дигән нәрсәне Яздан әкә бары тик шулай

гына аңлый, хезмәт хакын мулдан алучы пешекчеләр алны-ялны белми эшли, җәмәгать туклануы көннән-көн ныграк таныла.

Ләкин Яздан әкәнен тормыш мәнфәгатьләре җәмәгать туклануы белән чикләнә, дип уйлаучылар нык ялгыша, чынлыкта районның бөтен тормыш җепләре аның кулында, нефтебазадан башлап шәһәрара автобуслар хәрәкәтенә кадәр барысы да аның күз уңында. Яздан әкәнең улы Шәүкәт баш инженер булып эшләгән автопредприятиедә, мәсәлән, автобус маршрутлары төгәл ун тапкырга артты!

Райпотребсоюз председателе булып алган Сәлим дә Яздан әкәнең туганы, Халтаев тарафыннан Сары Таш мәхәлләсендә оештырылган очрашуда ул да бар иде. Дөрес, Сәлим Хәсәнович үзе дә төшеп калганнардан түгел, әмма барыбер Яздан әкә ярдәменнән башка гап-гади уртакул бер райпотребсоюзны андый да биеклекләргә күтәреп булмас иде. Чит илләргә чыгарылган бал, арахис, дару үләннәре, күрәгә, киптерелгән йөзем—кишмиш, тире һәм каракүл, сөяк һәм "Ак мусалас" дип аталучы менә дигән шәраб өчен өлкәгә кайткан барлык дефицит товарның яртысы Сәлим Хәсәнович складларына килеп эләгә.

Әгәр дә хуҗалык эшләре белән шөгыльләнүчеләр партработниклар дәрәҗәсендәге реаль властька ия булса, мәнле адәмнәр партия аппаратына ашкынмас һәм Тилләхаҗиев иң мәртәбәле эшкуар булып танылыр иде, ни генә дисәң дә, хәтта буш җирдә дә акча ясау әмәлләрен белә иде ул.

Бервакыт ул Булат Мөэминовичтан гражданнар оборонасы өчен ашыгыч рәвештә складлар төзеп бирүен үтенде, өстән шундый күрсәтмә төшкән икән. Оборона максатларында, димәк, тиз, сыйфатлы һәм вакытында булырга тиеш. Склад техникасының иң соңгы яңалыклары белән җиһазландырылган объектны торгызып та куйдылар, ул хәтта Яздан әкә ресторанынннан да тизрәк үсеп чыкты.

Объектны тапшырганнан соң нәкъ бер атнадан Булат Мөэминовичны яна уку елына мәктәпләр төзү барышын тикшерүгә багышланган кинәшмәгә чакырдылар. Анда шәһәрнең янгын сүндерү идарәсе башлыгы көтмәгәндә бик усал чыгыш ясады һәм сүз уңаеннан гына социалистик милекне тиешенчә саклауны тәэмин итмәгәнгә күрә иртәгәсе көннән Заркенттагы өлкә сәүдә базасы биналарын пичәтләп куячагын белдерде. Бусы инде аяз көнне күк күкрәгәндәй булды, бер-бер артлы әллә нинди тәкъдимнәр яңгырады, ләкин берсе дә проблеманы тамырдан хәл итү юлын күрсәтә алмады. Янгын сүндерүчеләр башлыгыннан һич югы ярты ел вакыт бирүен сорап карадылар, ләкин ул сүзендә катты да калды, җаваплылыкны обком секретаре шәхсән үз өстенә алганда гына моңа риза булачагын белдерде.

Менә шул чакта Кәтүк Мәхмүтовка яңа корылган гражданнар оборонасы складларын вакытлыча сәүдә базасына биреп торырга тәкъдим итте дә. Шулай итеп, иң кирәкле товарлар һәм дефицит тупланган складлар Наполеон теләгән җиргә күчеп утырды.

Ләкин ул моның Яздан әкә тарафыннан оештырылган хәйләкәр алым икәнен әле башына да кертеп карамый иде. Бары тик озакламый хрусталь, мебель, келәм, палас, көмеш, алтын, кун, парфюмерия, спиртлы эчемлекләр, кием-салым, аяк киемнәре, трикотажның бәясе күтәреләчәге хакында яшерен хатлар ала башлагач кына нидер төшенде кебек. Ел саен әле бер, әле икенче әйбер кыйммәтләнде, кайбер товарларның бәяләре берьюлы икеләтә, хәтта өчләтә. Дәүләт бәяләр комитеты рәисе шулкадәр тырышты ки, аның бу көчәнүен табигый ки югарыда күрми калмадылар, аңа Социалистик Хезмәт Каһарманы дигән мактаулы исем бирелде, түшенә алтын йолдыз медале тактылар.

Булат Мөэминович бәяләр күтәрелүдә валюта биржасындагы шикелле

үк тиз арада коточкыч баю мөмкин икәнлеген анлый иде, бары тик аны алдан белергә һәм товарларны яшереп өлгерергә генә кирәк.

Алтмышынчы еллар башында бер тапкыр сабак алган иде инде ул. Бернинди кризис-фәлән тоемланмаган, бәяләр күтәрелү, инфляция хакында сүз дә булырга мөмкин түгел бер заманда, газеталар язганча, ил жиде чакрымлы адымнар белән алга ыргылып, Американы куып житү һәм узып китү өчен көрәшеп яткан көннәрдә, партия совет кешеләренең бүгенге буыны коммунизмда яшәячәк дип лаф органда,—халык тарафыннан артык сизелмәгән бер нәрсә булды—коньякның бәясе ике тапкыр арттырылды.

Өлкәдән яшерен хат алуга ук Булат Мөэминович райпотребсоюз председателен чакырып алды һәм коньяк сакланучы складларны пичәтләп куярга кушты.

Районның сәүдә хужасы иннәрен генә жыерды:

—Гафу итегез, нинди коньяк, бетте бит ул. Дүрт вагон чамасы бар иде барын, план үтәлмәгәнлектән, аны да сатуга чыгардык. Кызганыч, бер-ике әржәсен туйга калдыра алмаганмын,—дип аһ орды ул һәм секретарь кабинетыннан шылтыратып баш бухгалтерны чакырып китертте.

Кәгазьләрдән күренгәнчә, нәкъ кичә генә спиртлы эчемлекләр сатудан кергән гаять зур сумманы банкка күчергәннәр булып чыкты. Әгәр төнлә кайнатасы Әхрар Гыйниятович шылтыратмаган булса, бу вакыйга шуның белән тәмамланган да булыр иде. Сәүдә эшмәкәрләре бәяләр күтәрелү хакында каяндыр белеп алганнар һәм коньяк төялгән утызлап вагонны аның районындагы райпотребсоюз базасына илтеп яшергәннәр дә майлы калжа эләктерәчәкләрен түземсезләнеп көтәләр, ди. Боларны кайнатасы бәйнә-бәйнә сөйләде һәм иртәгә үк районга читтән тыш вәкаләтләр бирелгән комиссия киләчәген, аның үзенең бу эштә турыдан-туры катнашырга тиешлеген әйтте. Фактлар расланды һәм ул чакта сәүдә эшмәкәрләренең байтагы хөкем жаваплылыгына тартылды.

Әлбәттә, ул елларда тимердәй нык Гыйниятовның сәүдәгәрләр белән әже-гөже килүе хакында сүз дә булырга мөмкин түгел, хәтта дошманнары да алай уйлый алмас иде. Партия хакимиятенең нинди генә кимчелекләрен күрсәтсәләр дә, караклыкта, коррупциядә гаепли алмадылар. Алары соңрак, Леонид Ильич властька килгәч башланды.

Сәлим Хәсәновичның шефы, өлкә потребсоюзы башлыгы Ягъфәров өеннән генә дә биш миллион сумлык кыйммәтле нәрсәләр төяп чыктылар, әле мона йорт, каралты-кура кебек күчемсез милек һәм тулы бер автопаркка тиң машиналар керми. Яраннарында бишәр миллион сум булганда, Наполеонның үзе хакында ни әйтерсең! Әтисенең каберенә күмгән хәзинәдән генә дә йөз алтмыш жиде килограмм алтын һәм бизәнү әйберләре чыкты, аларның барысы да антиквар кыйммәткә ия булып, чын асыл бәяләрен башка да китерерлек түгел. Хужа хәзер алтын гына ала, дигән Халтаев ялгышмаган булып чыкты.

Биш-алты елда ун поттан артык алтын жыю жинел эш түгел, моның белән көне-төне шөгыльләнергә кирәк. Шуның өстенә, мәйданы белән Франция кадәрле өлкә белән дә житәкчелек ит. Кәтүкнең бажасы полковник Нурматов та йоклап ятмаган, анысын өлкәдә беренчеләрдән итеп, көндәлек ясак жыеп йөргәндә кулга алдылар. Биш ел эчендә ул портфель вә "дипломат"ларда өенә ике миллионлап акча ташып өлгергән булып чыкты.

Суд хроникасы белән танышканнан соң гына Булат Мөэминович ювелирторг базасы складларының ни өчен нәкъ менә аның районында урнашуын, ни өчен нәкъ менә монда өлкәдәге иң зур "Гранат" ювелир кибете ачылуын төшенде кебек. Соңрак аның директоры булып алган Мәхкам Юлдашев дигән адәм Сары Таш чәйханәсендә аның белән табындаш

булганнарның өченчесе иде, ул да һич тә авырыксынмый-нитми егерме биш менгә кушылган иде. Димәк, алар ул чакта Раимбаев кызыккан районны Халтаев белән бергә шулай итеп Наполеоннан сатып алганнар булып чыга. Мәҗлестә Яздан әкә белән бергә катнашканнарның дүртенчесе Сибгат Хәкимович Сафиуллин булып, анысы озакламый бер дә кызыктырмый торган урынга утырды, район банкын җитәкли башлады. Бер-ике елдан андагы коллектив тулысынча алышынды һәм аны халыкта "татар банкы" дип йөри башладылар, шул ук вакытта татарларның йөз тәнкәлек хезмәт хакына кызыгуына шаккатып тел шартлаталар иде. Чебешне көз көне саныйлар икән шул! Чираттагы бәя күтәрелү алдыннан алтын, хрусталь, келәм, мебель, күн, аракы сатып алу өчен Яздан әкә каядыр яшереп саклаган миллионнарын күтәреп чапмаган, банкта утыручы ата хәйләкәр Сафиуллин белән бергә алар үз акчаларыннан бер тиен дә чыгармаганнар, рәхәтләнеп дәүләтне алдый биргәннәр! Монысын да Булат Мөэминович бик сонга калып аңлады.

Хәзер, инде байтак еллар узганнан соң бер генә комиссия дә урлашу-фәлән булганлыгын исбатлый алмаячак, тиене тиенгә туры киләчәк, кәгазьләрдә барысы да ал да гөл булачак. Документларга черки дә борын тыгарлык түгел. Яшерен трестның акыл казанын тәшкил иткән Яздан әкә белән Сафиуллин шулкадәр чиста һәм пөхтә эшләгәннәр ки, бер генә эзне дә таба алмассың. Алар янында йөргән Булат Мөэминович җүләрнең җүләре булган икән. Аның беркатлылыгыннан рәхәтләнеп көлгәннәрдер инде.

Наполеонны кулга алганнан соң Халтаев һәм аның дуслары бераз шикләнә калсалар да, артык курку галәмәте сиздермәделәр, чөнки эшләрендә барысы да ал да гөл булып, кулдан эләктерергә инде соң иде. Халтаев еш кына форма киеп төннәрен Заркентка китеп югала башлады, бәлки Әнвәр Абидовичның гаиләсенә ярдәм иткәндер, бәлки конфискациягә эләкмәгән мал-мөлкәтне урнаштыру белән мәш килгәндер. Барысын да берьюлы чыгарып салырга Наполеон беркатлы җүләр түгел, ун пот алтын биреп барысын да телдән яздырды һәм шик болытын куып таратты. Ә аның резерв өлеше булмаган дип беләсенме, булса, ул аның районында сакланмыймы? Уйласаң уй җитәрлек.

Яздан әкә даирәсендәгеләрдән бары тик Сафиуллин гына юкка чыкты. Өлкәдә дәрәҗәле кешеләрне кулга алганнан соң бер ел узгач, ул ашыкмый-кабаланмый гына пенсиягә чыкты һәм билгесез тарафларга китеп барды. Үзенең вәкаләтләрен исә үзгәртеп кору заманындагы катгый таләпләр нигезендә тапшырды, азау ярган өлкә комиссиясе банк эшчәнлегендә бер генә житешсезлек тә таба алмады. Киресенчә, район масштабларына хас булмаганча, бар эшнең югары профессиональ дәрәҗәдә башкарылуын билгеләп үттеләр. Халтаев белән бер тәртәгә мичәүләнгән Сафиуллинның хәзер инде башкала тирәсендәге берәр төбәктә, тыйнак, әмма дә ләкин бик тә зәвыкъ белән төзелгән яхшы гына йортта яшәп ятуы да ихтимал, табигый ки, фамилиясе дә бөтенләй башкадыр. Бөтенесен алдан исәпли белүче, алдан күрүче кеше ул. Булат Мөэминовичның аны Яздан әкә белән Тилләхаҗиевның мәкерле капкынына эләккән мәгълүм аш мәҗлесеннән соң бүтән очратканы булмады, хәтта аның төс-кыяфәтен дә төгәл генә хәтерләми иде. Сибгат Хәкимович хәтта Заркенттагы гаиләсен дә районга күчереп тормады, һәр көнне аны кияве шәхси "Волга"сында эшкә китерә һәм аның бер генә тапкыр да сонга калганы булмады.

Мамык Наполеонының, үзен бер үк вакытта кытай патшасының сыңары дип атаган кеше төзегән империянең җимерелгәненә өч ел үтеп китте, аның инде бүтән күтәрелерлек чамасы юк. Бусы—мәңгелеккә...

"Хәзер инде кем бугазыннан буа, вөжданын кушканча яшәргә кем

комачаулый?—Мондый сорауларны Булат Мөэминовичнын үз-үзенә берничә тапкыр биреп караганы булды.—Намуслы исеменне кайтару өчен ниләр кылдын, нишләп ятьмәгә чорнап алган Халтаев, Юлдашев, Йосыпов кебекләрне куып таратмыйсын!"

Кая инде куып тарату, нәселле атлар яратучы Әкмал ханны кулга алганда бөтен илгә сасысы чыккан шомлы Аксайга барырга да курыктын, дип танырга мәжбүр булды ул.

Үз күз алдында үскән, балаларын шикелле үк якын һәм кадерле чаптарларынны һәм юртакларынны коткарырга бармадын, ул чакта да күнеленне кара шом басты, дәүләт атлары өчен ул сина күпме сәмән бирде, дип сорау ихтималыннан котын алынды.

"Кайчанга хәтле шулай куркып яшәргә була?" дигән сорауны ул берничә тапкыр кабатлады, әмма җавабын таба алмады.

Каракүл тиресе житештерүче колхоз председателе, өлкән яшьтәге дусты, узган ел вафат булган Сәрвәр әкәне исенә төшерде. Ничектер бервакыт анын янына барасы иткән иде. Барса, дусты эштә юк, авырып тора, өендә ята, диделәр. Өенә керергә туры килде.

Карт чыннан да сырхап ята, дөресрәге, аны кыйнап ташлаганнар, бөтен жире күм-күк булган иде. Райком секретарен күрүгә аксакал яшьләрен тыя алмады, әмма бу авыртудан, сызланудан түгел, күнел төбенә утырган юылмас юшкыннан, рәнжүдән иде. "Нинди хурлык, карт көнемдә адәм рисвае иттеләр, чал чәчләремә дә карап тормадылар",—диде ул көч-хәл белән иреннәрен кыймылдатып.

Монын тарихы болайрак булып чыкты. Кәтүк кешеләренен экспортка әзерләнгән каракүл тиреләрне талавыннан тәмам гарык булган Сәрвәр әкә зур бер партияне яшереп куйган, чит илләргә икенче сортлы товар жибәрмәссен бит инде. Моны кемдер чаккан һәм тегеләр килеп, канга батырганчы кыйнап акыл өйрәтеп киткәннәр, бүтән болай кыланмассын янәсе. Котырган этләрдәй бу адәмнәр мәнге шулай яшәрбез дип уйлаганнар булса кирәк.

Кайчандыр районнын абруен күтәрешкән, аны аякка бастыруда төп таяныч булган дустын истәлегенә, ичмасам, анын белән булган хәлне актарып чыгар, фаш ит, Сәрвәр әкә кем кыйнаганны, моны кемнәр күреп торганын, кем чакканын—барысын да бәйнә-бәйнә сөйләгән иде бит.

Ләкин үз-үзенә никадәр генә сораулар бирмәсен, газапланган жанын битәрләмәсен, башы иелгәннән-иелә генә барды, чөнки акланырлык сәбәп юк иде. Ләкин шуны да анлый, төшенә—кеше булып калу өчен һәрчак ниндидер мөмкинлек була ул, файдалана гына бел. Ләкин монын өчен ихтыяр көче, вөждан, кыюлык, үзеннен хаклыгына инану, принципларына хыянәт итмәү кирәк. Бүген шулай ук ул кеше дигәнен зәгыйфь бер зат, шайтан котыртты, дип тә әйтә алмый, үзен аклар өчен унайлы сәбәп вә сылтаулар да эзли алмый.

"Исендәме, алар белән аралашудан күнелен болганып, укшып интеккән, хәтта коскан иден?—дип сорау бирде ул үз-үзенә.—Шул чакта аларны янына якын жибәрмәгән, караклыкка һәм ришвәтчелеккә кереп батмаган булсан... Урлашканым, ришвәт алганым юк, дисенме? Ә алар белән табындаш булу, "мин бернәрсә дә күрмим, бернәрсә дә белмим" дигән караш белән яшәвен аларга оятсыз рәвештә районны таларга, миллионнар тупларга юл ачмадымыни?"

Кирәкле кешеләрнен хатыннарына, кызларына, сөяркәләренә вә дәхи тәртипләре шикле булган туташ вә ханымнарга, унга да, сулга да таратылган каракүлдән ил никадәр валютадан колак какты... Синен нәселле чаптарларынны Наполеон бер Ариповка гына бүләк итмәде ләбаса, житез

чабышкыларны яратучылар илдә күп, ай-һай күп булып чыкты, барысы да аксөяк графлар шикелле кыланмакчы. Шулкадәр газап күреп төзелгән бер ат заводыннан гына да миллионнарча доллар урланды түгелме?..

Көтмәгәндә хәтеренә ерак яшьлектә, даладагы Оренбургта калган Ертык Закир килеп төште. Төшмәслек тә түгел. Төрек Госманның үзен Форштадттагы варисы итәргә теләвенә алданмады бит, чөнки жулик буфетчылар һәм ресторан хуҗалары исәбеннән ашау-эчүне түбәнлек санады. Хәтта алтын приискаларында, Ертык Закир да, аның дингезче дуслары да рэкетирлар күпме кодаламасын, алтын юдыручыларның хәләл өлешенә кермәделәр, чөнки намус дигән нәрсәләре булган, үз көчең белән тапмаган ризык намуслы кешенең тамагыннан үтми ул.

Бер карасаң, Наполеон Төрек Госманнан куркынычрак түгел түгелен, әмма ул аңа каршы тора алмады, курыкты. Икесе дә җаһилләрнең җаһиле, усал, каты куллы, алардан гаделлек вә миһербан көтү мәгънәсезлек булыр иде, икесенә дә кешелеклелек гайре сыйфатлардан.

Чәй розасы һәм үрмә гөлләр чорнап алган таш коймага карап ул уйлануын белде, карашы яхшылап планлаштырылган, тәрбияләнгән бакча түренә төбәлде. Бакчы, тулган ай яктысында монда нинди матур манзара ачыла икән бит, зеңләп торучы чиста күктән әйтерсең лә арыган, йокыга талган җир өстенә талгын тынлык вә иминлек бөркелә, әмма аның җанында гына бер кәррә дә тынычлык юк һәм була да алмый.

Һәм нәкъ шул мизгелдә ул менә хәзер, кичекмәстән, нәрсәдер кылмаса, пәрәвездәй үзен чорнап алган ятьмәдән котылу чарасын күрмәсә, калган бөтен гомерен бер хәшәрәт сыман, сатлык җан булып үткәрәчәген аңлап алды.

Әйтерсең, ниндидер бер билгесез көч аны сәкедән тартып торгызды һәм ул аңа буйсынып, Халтаевлар ишегалдына илтүче җилкапкага таба юнәлде. Моңа кадәр әле аның беркайчан да күршесе ихатасына аяк басканы юк иде. Ишегалдында тынлык, бер җан иясе күренми, бары тик верандада гына тонык ут балкый иде. Мәхмүтов озак уйлап тормастан, беренче эләккән тәрәзәгә шакыды. Полковник бик сак йоклый торган кеше булып чыкты, шунда ук өй түрендәге тәрәзәләрнең берсе ачылды һәм аннан хуҗаның тузгыган башы күренде, ул күршесен таныды булса кирәк, тавыш-тынсыз гына янадан бүлмә караңгылыгына чумды һәм берничә минуттан киенеп, таранып дигәндәй чыгып та басты.

—Нәрсә булды?—Күршесенең агарып калган йөзенә күз төшерүгә милиция башлыгының иреннәре арасыннан шундый сүзләр чыкты. Гаҗәп түгел, райком секретаре барлы-юклы сәбәп белән төн уртасында йоклап яткан кешене уятмас лабаса.

Моннан ике атна элек кенә Халтаев кыюлыгы белән таң калдырырлык бер операция эшләп ташлады һәм әле дә үзенең шул башсызлыгына гаҗәпләнүдән туктамый иде. Бөтенесе дә Раимбаевның туганнарыннан башланды. Көтмәгәндә килеп кергән туган-тумача баш әйләндергеч тәкъдим ясады: әгәр полковник Раимбаевны төрмәдән урлый алса һәм аның гаиләсенә ялган паспортлар ясап бирсә, аңа йөз мең сум акча бирәселәр икән. Бандитлар да, дәүләт хәтле дәүләт тә яшерен миллионерны чистартып бетерә алмаган, туплаган сәрмаясы әле дә җитәрлек икән. Аңлаганы шул булды. Раимбаевның туганнары кул кушырып утырмаган, күрше Таҗикстанның ерактагы бер районында йорт сатып алганнар. Барысын да уйлаганнар, исәпкә алганнар, әмма Раимбаевны төрмәдән тартып чыгару кулларыннан килмәгән. Шунлыктан полковник янына килгәннәр дә. Паспорт өчен полковник егерме биш менне аерым сораган иде, анысын алдан ук биреп куясы. Әгәр эш пешми икән, акчаны кире сорарлык

булмасын. Моны полковник яхшы белә. Республика Югары судында әшнәләре житәрлек, югары урыннарда утыралар. Һәм ул илле менне кыстырып шулар янына китте.

Кирәкле кешене табып, ана ярлыкау-акланута эләккән кешеләр исемлегенә Раимбаев фамилиясен кертергә тәкъдим итте. Прокуратура тәкъдиме белән Югары суд ай саен диярлек шундый гуманлы карарлар чыгарып килә, гаепләре булса да аны таныган, чын мәгънәсендә тәүбәгә килгән кешеләр гаиләләре янына кайтарыла иде.

Әмма андый кәгазь бернича кулдан үткәнлектән, аклауга жинел генә ирешеп булмый, ә икенче тапкыр омтылу шик тудырырга мөмкин. Менә шунда алар ачыктан-ачык ялганга барырга карар бирәләр дә, рәсми бланклар һәм пичәт белән дә эш итүче бер хатынны табалар һәм... аны сатып алалар. Азат итү турындагы ялган карар тотып, элеккеге миллионерны коткарырга полковник үзе китеп бара, иптәшкә Раимбаевнын туганын ала.

Хезмәт белән төзәтү колониясенә якшәмбе көнне иртән, начальство юграк чакта килеп керәләр. Башта бөтенесе дә майлагандай бара, хәтта Раимбаевны алып чыгарга зонага чапкыннар жибәрәләр, ләкин иң соңгы минутта яшь кенә лейтенант килеп керә һәм бөтенесен бутап ташлый. Кәгазьләр белән танышкач, начальстводан виза кирәклеген әйтә. Ни дисән дә, Раимбаев унбиш елга хөкем ителгән, андыйларны аклау бик сирәк була торган хәл.

Карарны тотып офицер чыгып китүгә үк Халтаев белән ярдәмчесе дә ишеккә ташлана. Аны беренче тукталышта ук төшереп калдырып, үзе Ташкентка ыргыла, "Волга"сын мөмкин булган иң югары тизлектә куып. Югары судтагы танышы янына барып керә, барысын да аңлатып бирә. Алай-болай тикшерү-фәлән башлана калса, аларны да исәпләп чыгарырга мөмкиннәр ләбаса. Иң куркытканы шул. Шуннан инде алар икәүләп бланк белән пичәт табып биргән хатын янына ашыгалар. Сәбәбе дә табыла, янәсе унышлы операцияне юарга, акчаның калган өлешен—биш мен сумны тапшырырга кирәк. Хатынның уяулыгын киметү өчен банк төргәгендәге иллелекләрне шунда ук кулына тоттыралар да мәжлес корып утыру өчен шәһәр читенә чыгып китәләр. Табигать кочагында бераз төшереп алалар һәм алардан кәррә дә шикләнмәгән хатынны үтереп, мәетенә ут төртеп яндыралар. Бернинди эз калмый, ни генә дисән дә, полковникның тәжрибә сорап куршегә керәсе юк, Югары суд әгъзасы да заманында булачак юристларга криминалистика нигезләрен укыткан кеше.

"Бәлки, Раимбаев белән Югары судтан югалган хатын турында берәр хәбәр бардыр, бәлки шуна таң тишегеннән ишек шакыгандыр?"— Халтаевның башына килгән беренче шөбһәле уй шундый булды.

Шик-шөбһә, курку хисләреннән, ниһаять, арынып өлгергән Мәхмүтов тыныч, гадәти тавыш белән әйтеп салмасынмы:

—Гаделсез юл белән тапкан акчаларын үз ирке белән ихтыяри рәвештә кайтарган кешеләр жинаять жаваплылыгыннан азат ителә. Болар сезгә мәгълүмдер, дип уйлыйм, полковник.

—Димәк, безне дә капшарга жыеналар икән,—дип куйды полковник саңгырау тавыш белән, күнелендә яшерен шатлык хисе уянды, чөнки төнге визитны ул Раимбаев белән бәйле булмагае дип нык курыккан иде.

Үз уйларына баткан райком секретаре Халтаев әйткәннәрне колагы янынннан гына үткәреп жибәрде.

Милиция башлыгы озакка сузылган авыр тынлыкны күтәрә алмады, сорау бирде:

—Нәрсә, әллә прокуратурадагы иске дусларыгыз берәр нәрсә сиздердеме?

Мөгаен, дәшми калырга яисә жеп очын бик үк чыгармыйча нәрсәдер

әйтергә кирәк булгандыр, әмма ул ялганлап азапланырга да, боргаланырга да теләми иде, шунлыктан турыдан-туры ярды да салды:

—Юк, беркем дә кисәтмәде. Кызганычка каршы, дусларым минем ике яклы пычак икәнемне белмиләр, юкса, инде күптән кул бирмәсләр иде. Барысын да үзем хәл иттем, алга таба болай яшәп булмый. Сезгә юл куюда үзем гаепле, шунлыктан сезгә төрмәдән һәм хурлыктан котылу юлын күрсәтергә булдым. Иртәме-соңмы—алар барысы да калкып чыгачак.

Халтаевны алыштырып куйдылармыни, йокымсырау, курку хисе бер мизгелдә юкка чыкты.

—Булат әкә, тынычлан, үзеңне дә, дусларыңны да һәлакәткә илтмә. Без дә бит сезне кайчандыр үлем элмәгеннән йолып алган кешеләр. Без булмасак, мөгаен, инде әллә кайчан Коми АССРда яисә икенче бер җәһәннәм тишегендә урман кисеп яткан булыр идегез. Нервыларыгыз какшаганга охшый, әйдә, иң яхшысы бераз салып алыйк, таңга кадәр берике сәгать утырыйк, иртән теләсә нәрсә хакында яхшылап сөйләшербез, аңлашырбыз, тәүбә итү турында гәпләшсәк тә булыр. Без башсыз адәмнәр түгел ләбаса, эшләребез дә ул кадәр үк начар дип әйтмәс идем, ике ел үтте, бер эз дә калмады шикелле, ә инде Тилләхаҗиевның теле чишелер дип шикләнсәгез, курыкмагыз, анысын бөтенләй баштан чыгарып ташларга да була, чөнки аның үз мәнфәгатьләре бар, кирәгеннән артык бер сүз дә әйтмәячәк. Исегездә тотыгыз, ул һәрвакыт "Сезнең район тыюлык зонасы", ди торган иде. Монда прокуратураны якын җибәрмәячәк ул. Бездән башка да прокуратурага эш җитәрлек, без кем әйтмешли, вак балык. Алар анда югары эшелондагыларның эшен актарып чыгара алмый интегәләр, Мәскәүдә, партконференциядә дүрт кеше турында ниләр генә сөйләмәделәр, хәтерлисездер? Ташкентта да, Мәскәүдә дә үлем яки яшәү мәсьәләсе хәл ителә. Уен-муен гына түгел. Республика прокуратурасы үзе үк бүген ярдәм сорап аһ орыр хәлдә, бик күп шома егетләрнең тормышы кыл өстендә, кайберләре көчсезлектән барысына да кул селтәгән, ә шулай да... суд әле барыбер безнең кулда. Прокурор үзе дә, урынбасары да могҗиза белән генә исән калганны да беләм мин, икесен дә агулап теге дөньяга озатмакчылар иде. Берсен инде хастаханәдә вируслы гепатит белән бүләкләгәннәр, икенчесенә өлгерми калганнар. Төп уколлар алда буласы булган да, аларның әшнәсе—милиция генералы нәрсәдер сизенеп, үзенең врачларын китереп тутырган, үз даруларын, шприцларын, стерилизаторларын китерткән, палата янына сак куйдырткан да хастаханәнең барлык кешеләре белән сөйләшеп чыккан, хәтта пешекчеләрне дә калдырмаган. Күрәсең, мафия турындагы фильмнарны алар да карый, ниятебезне сиземләделәр. Шулай булгач, бөртек тә шикләнмә, аларда безнең кайгы түгел.

—Анысыннан курыкмыйм мин, хатынымның, балаларымның күзенә туры карый алмыйм. Хәер, ни эшләргә икәнен тикшерергә килмәдем мин сезнең янга. Мин инде барысын да хәл иттем һәм... сезне дә кисәттем, дип беләм. Өйләдән соң мин обкомга китәм, ни булса да булыр, мин тәүбә итәргә карар кылдым.

Райком секретаренең үз сүзендә каты торганлыгын чамалап, Халтаев көтмәгәндә сүзеннән кире кайта башлады:

—Мин дә бит тимердән түгел, уйлый-уйлый как сөяккә калдым, төннәрен керфек тә какмый чыгам, әле прокуратурадан килеп чыгарлар, әле бандитлар һөҗүм итәр, дип калтырыйсың. Аларның минем белән исәп-хисаплары башкача. Әнә сез верандага менеп җитәргә өлгермәдегез, мин пистолет белән тәрәзәгә ыргылдым. Әгәр дә сез чын күңелдән тәүбә итәргә булгансыз икән, мин дә сезнең белән, кем белә, бәлки узып та китәр, кичерерләр,

кеше үтергәнем юк... Шунын өстенә, мин бик яшерен бер серне беләм, аның хакына жинеллек килмәгәе...

Кунак "ә" дә димәде, "жә" дә димәде, ул үзен килеп чыгышын исенә төшереп өркетергә жыеналар, дип уйлаган иде, шунлыктан дәшмәүне артык күрде.

Полковник исә тагын тынычлыгын югалтып өлгерде, кабалана башлады:

—Әкмал хан инде өч ай Лубянкала, әмма акчасы кайда яшерелгәнлеген әйтми. Ә мин беләм, сезнен нәсел атларыннан "Чегән"не Аксайга илткәндә сизеп алдым. Атны көн жиләсрәк чакта булсын дип, тәүлек буе алып барырга туры килде, шул чакта Әкмал әкәнен ышанычлысы салган баштан серне чишеп ташлады.

—Әйе, мондый мәгълүмат өчен бик күп нәрсәне гафу итәргә мөмкиннәр,—дип жанланып китте төнге кунак, чөнки ул сүзнең астрономик саннар белән исәпләнүче суммалар хакында баруын тәгаенли иде.

—Сезнең карардан, Булат әкә, башта каным боз булып каткан иде, ә хәзер эчемдә ут яна, ай-һай зур әйбергә алынасыз, бөтен республиканың асты өскә киләчәк. Әйдәгез, бераз салыйк, шунсыз тынычланып булмас. Ничек мач килүен кара, минем холодильникта "Золотое кольцо" бар, Сәлим Хәсәнович һәдия кылган иде.

—Мөгаен, сез хаклыдыр, дару өчен бер илле грамм тотсак ярар, гади төн генә булмады бу, көне дә жиңелләрдән, димәс идем... Ир-ат дигәнең сүзенә тугры булырга тиеш, һич югы картлыгында намустан да кыйммәтрәк нәрсә юк икәнен аңларга тиеш ул. Хәтта ирек тә, тормыш үзе дә аннан кыйммәтрәк түгел.

—Әйе, әйе, нәкъ шулай,—дип кабатлады зиһене таралгандай тоелган Халтаев.—Мин шешәне алып чыгыйм, сез түтәлдән кыяр, помидор, борыч, суган, рәйхан ала торыгыз. Күз ачып йомганчы салат ясап ташлыйбыз, аракы янына шуннан да шәбрәк нәрсә юк та юк инде ул.

Полковник йорт авызындагы төшкән теш урыны шикелле ыржаеп торучы ишектән кереп югалуга, Мәхмүтов бакчаның аргы башына, яшелчә түтәлләре янына китеп барды. Халтаев түтәлдән яна гына өзеп алган яшелчәне, үлән-сәләнне генә ярата, башкасын белергә дә теләми, хәер, аның белән аралашып, ул үзе дә шушы гадәткә күнекте. Күршеләре керә-нитә калса, Мияссәрә дә иң беренче эше итеп бакчага чыгып китә торган булды.

Полковникның ихатасы нык, бакчасы яхшылап каралган, помидорлар бер жепкә тезгәндәй саф-саф булып тора, һәрберсе селекция станциясендәге кебек казыкка бәйләнгән, номер сугылган бирка гына житми. Сорты да әйбәт, Юсупов помидорлары дип йөртелә торганнардан. Аларның берсе-берсе ярты килога тарта, арада бер килодан артыклары да очрый, тик аччик-чучук дигән салатка помидорның ваграгы әйбәт. Ул ефәк пижама итәгенә хатын-кызлар шикеллерәк иттереп, түтәлдән түтәлгә күчә-күчә помидор, кыяр, борыч жыйды. Суган кыяклары белән рәйхан үләне өзәсе генә калды, алардан башка салат—салат булмый.

Шул чакта бакчанын хужасы да килеп чыкты, бер кулында "Золотое кольцо" шешәсе, икенчесендә яшелчә, үлән-сәлән салу өчен жамаяк тоткан иде. Кунак яшелчәләрне ул сузган жамаякка салды, рәйхан үләненен кайда үскәнлеген сорап алды.

Хужа ерактагы койма буендагы түтәлгә, агачлар күләгәсендә тагын да шомлырак тоелган караңгылыкка таба ымлады һәм алар икәүләп рәйхан үскән почмакка атладылар.

Рәйхан жиргә ятып, тәбәнәк үсүчән, шунлыктан, Мәхмүтовка яшь һәм сусылрак сабакларны өзү өчен жиргә хәтле иелергә туры килде, һәм нәкъ шул мизгелдә ниндидер сасы ис аңкыткан чүпрәк тоткан юан һәм кыска

бармаклы кул аның авыз-борынына капланды, ярты битен томалап алды. Ул ычкынырга тырышып тыпырчынып карады, әмма полковникның тимердәй нык куллары ычкынырга һичбер өмет бирми, чүпрәктән килүче истән ул аңын югалта башлады, ләкин милиция башлыгының өстенә иелгән усал чыраен күрерлек хәлдә иде. Анысы төкерекләрен чәчеп ысылдады:

—Үзгәрергә, яңача яшәргә теләдеңме, булмас! Без берни алдында да туктап калмыйбыз, артка юл юк. Арипов миллиарды табылды дип сөенденме, мин аны белсәм дә әйтмәс идем! Теге чакта Тилләхаҗиев син хәшәрәтне юкка төрмәдә черетмәгән, үз башыма саклап калганмын икән...—Ярсуына буылган Халтаев әле бик озак мыгырданды, ләкин ул аны ишетми иде инде.

Аңын югалтып барган мәлдә ул үзенең тормыш белән бәхилләшүен аңлап алды һәм ни гаҗәп, күз алдына балачак еллары, туган йорты, Мияссәрә һәм беренче вә икенче никахтан туган балалары түгел, ә үз гомерендә бер тапкыр да күрмәгән, бары тик Ертык Закир сөйләве буенча гына белгән Төрек Госман килеп басты.

Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төндә таныш түгел шәһәрнең ювелир кибете янында гасабиланып милиционерлар йөренә имеш.

Тимер рәшәткә тотылган тәрәзә янында Төрек Госманның агарып калган очлы йөзе шәйләнә.

—Бернәрсә дә калдырмагыз, ялап чыгыгыз,—ди ул актарып ташланган сейф янында мәш килүче кәсептәшләренә,—барыбер кем дә булса килеп керәчәк, мин монда калам, сезнең китүне каплап торачакмын.

Банда аны үгетләргә керешә, бергә китәргә өнди, Колгасар Федька белән Фимка Бернштейн сакка үзләре калмакчы. Ләкин егерме җиде яшьлек Госман үз сүзендә каткан:

—Китегез, сез әле яшьләр, ә мин үземә тигән чаклы яшәдем инде...

Алар тиз генә кочаклашалар һәм түбә аркылы чыгып гаип булалар, шул ук минутта атыш башлана.

"Нишләп Төрек Госман?—Инде сүнеп баручы аңны җавапсыз сорау биләп ала. Үзен газаплаган сорауга җавапны тормыш чигендә чагында булса да алып каласы килә һәм таба да:—Юк, Халтаев калмас иде, башкаларны капламас иде".

Полковник билбавы астыннан нечкә озын без тартып чыгарды һәм пижаманы ычкындырып, колагын райком секретареның күкрәгенә куйды, йөрәкнең кайда икәнлеген чамаларга кирәк... Һәм әле күптән түгел генә ниндидер бер үтерүдә кулланылган һәм җисми исбатлау чарасы булып саналган безне төгәл хәрәкәт белән кабырга астына батырды. Бу шулкадәр тиз эшләнде ки, райком секретаре эһ итәргә дә өлгермәде, күкрәгеннән бер тамчы кан чыкмады. Махсус үтерү коралының эзен иң оста белгечләр дә табарлык түгел иде.

Мияссәрә гадәттәгедән иртәрәк уянды, йокысы йокы булмады, йөрәге сызлап интектерде, әмма таң атып килгәндә килеп туктаган Госман машинасының тавышын ишетмәде. Ул ашыкмый гына ишегалдында юынды, чәчләрен тарады, бары тик шуннан соң гына җәйге кухняга таба атлады һәм айванда йоклап ятучы ирен күреп алды. "Коммунизм" колхозына бармаска булган ахрысы, йоклап калган микән, дип уйлап алды ул һәм уятырга теләп айванга күтәрелде. Яхшы булды әле, ашыкмыйча гына икәүләшеп чәйләп алырбыз. Иреннәре иренең чигәсенә тиюгә бөтен тәне куырылып килде, чырыйлап кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.

—Нәрсә булды?—Койма артында Халтаев тавышы яңгырады, ләкин Мияссәрә инде аны ишетер хәлдә түгел, ул үз-үзен белештермичә калтырана иде. Биленә хәтле чишенгән полковник муенына аскан сөлгесен

жилфердәтеп ишегалдына беренче булып йөгереп керде. Мияссәрәнең кычкыруы шулхәтле көчле булып бөтен мәхәлләгә ишетелгән ахрысы, хәтта урам аркылы яшәүче күршеләре йөгереп керә башлады.

Моннан нәкъ өч сәгать элек ясалган хәрәкәтләр белән Халтаев колагын райком секретаренең күкрәгенә куйды һәм кайгылы тавыш белән әйтте:

—Инфаркт. Моторы түзмәгән.

Күз ачып йомганчы ул хуҗа сыман кешегә әйләнде дә куйды, кемгәдер "Ашыгыч ярдәм" машинасы чакырырга кушты, кемгәдер Мияссәрәне өйгә алып керергә кирәклеген ымлады. Биленә кадәр чишенгән һәм муенындагы тастымалын алмаган килеш ул әле бик озак күрсәтмәләр бирде, кемгә обкомга шылтыратырга, кемгә кабер казу эшләрен оештырырга, кемгә оркестр чакыртырга... Бөтенесе дә ашыгыч, чөнки йола кушканча мәетне кояш баеганчы гүргә индерергә кирәк.

"Ашыгыч ярдәм" машинасы килүгә, ул вакытта инде киенеп өлгергән Халтаев йорт хуҗасын машинага үзе күтәреп алып чыкты, ерып чыкмаслык төрле рәсми кәгазьләрне эшләтү һәм үлем турында таныклыкны тизрәк алу өчен врачлар белән бергә хастаханәгә үзе барасы итте. Ул судмед-экспертиза һәм прокуратура кешеләре белән мәетне ярып маташмаска, артык мәшәкать тудырмаска кирәклеге хакында да катгыян сөйләшеп өлгергән иде инде, шулай да һәр нәрсәгә борынын тыгарга яратучан, артык кызыксынучан бәндәләр мәеткә кагылып бимазаламасыннар өчен үзе барырга булды.

Мәетне сәгать биштә алып чыгарга булдылар, анынчы өлкә үзәгеннән делегация килеп житәргә тиеш, Ташкенттан укучы улларының кайтуын да көтәргә кирәк иде. Вакытның кысан булуына карамастан, бөтенесен дә ашыкмый-кабаланмый, ыгы-зыгысыз, ниндидер бер тантаналылык белән башкардылар, ишегалдына килеп кергән һәркем монда хөкем сөрүче кайгылы матәмне сизеп ала, барысы белән дә җәйге парад мундиры кигән каты куллы полковник җитәкчелек итә иде. Ярты сәгать саен Яздан әкә белән Сәлим Хәсәнович кереп-чыгып йөрде, алар белән бергә килгән тавыш-тынсыз адәмнәр Мияссәрә өстенә төшәсе бөтен мәшәкатьне үз өсләренә алдылар.

Бер-бер артлы машиналар килеп туктады, алар җеназа вакытында кирәкле нәрсәләрне алып килделәр, савыт-саба дисеңме, мәетне алып чыкканда хушлашу сүзләрен әйтергә тавыш көчәйткеч җайланма дисеңме, барысы да вакытында килеп җитте. Ихатаның аргы башында, кура җиләге куаклары янында кемнәрдер симез тәкә чала, зур казаннар астында учак дөрли, Яздан әкә кешеләре бу юлы да үз осталыкларын күрсәтергә җыена иде.

Рәсми матәм йоласы башланырга берәр сәгать калганда, Халтаев ихатасына уелган капка аша йортка күп еллар буе Мәхмүтовлар хуҗалыгында бакчачы булып эшләгән һәм хәзер мулла вазифаларын башкаручы Хәмрәкол әкә килеп керде. Аны ак кәфенгә төрелгән мәет куелган олы залда көтәләр иде инде. Тирә-якта мәчеттәгечә аякларын бөкләп полковникның иң якыннарыннан исәпләнүче ун-унбиш кеше утырган. Мулла һәрберсе белән кул биреп исәнләшеп чыкты һәм полковникның башларга ярый дигәнне аңлатучы ымын күргәч, ясин чыгарга кереште. Хәмрәкол әкәнең тавышы чиста һәм матур булып, аятьтән аятькә тагын да моңлырак һәм куәтлерәк яңгырый бара иде. Һәм ясин чыгу үзенең иң югары ноктасына килеп җиткәндә генә көтелмәгән вакыйга булды.

Коридорда ниндидер ыгы-зыгы, шау-шу ишетелде, кемдер ишекне кинәт каерып ачты һәм бусагада елаудан шешенеп беткән Мияссәрә күренде; ләкин ул юньләп бер сүз әйтергә дә өлгермәде, аңа олы яшьтәге хатыннар ташланды, ике яктан җитәкләп залдан алып чыгарга маташа башладылар.

—Туктатыгыз бу кыланууны, мулланы куып чыгарыгыз, ул чын коммунист иде, беркайчан да сезнең кебек икейөзлеләнеп йөрмәде. Ишетәсезме!— дип кычкырды Мияссәрә һәрьяктан эләктергән куллардан котылырга теләп, күзләреннән туктаусыз яшь акты.—Ул Күпер Булат иде, Күпер Булат булып калыр да...

Мулла берничә генә секундка югалып калгандай булды, әмма полковникның кырыс карашын күреп, элеккедән дә көчлерәк тавыш белән дога укуын дәвам итте.

—Алып китегез, күрмисезмени, кайгыдан акылын югалткан бит ул,— дип ысылдады полковник иң кырыйда утыручы адәмгә, анысы исә үзеннән һич көтелмәгән житезлек белән сикереп торды һәм хатыннарны бүлмәдән төрткәләп чыгарып җибәрде.

Әлеге адәм яңадан урынына утырырга да өлгермәде, Халтаевның тагын бер боерыгы яңгырады:

—Халык җыела башлады, әйт, матәм музыкасын куйсыннар. Ишек янына бас та, мулла укып бетергәнче беркемне дә кертмә. Мин хәзер җирдә аның җаны өчен җаваплы бәндәмен, иң яхшы дустымны, газиз күршемне чын мөселманча җирләрмен.

Ир-атлар тавыш-тынсыз гына залдан чыгып киттеләр һәм озак та үтми мәхәллә өстендә дистәләрчә динамиклар аша көчәйтелеп Вердиның реквиемы аһәңнәре дулкынлана башлады, ә йортта Хәмрәкол әкә Корьәнгә иелеп дога укуын дәвам иттерде.

Тагын ике сәгатьтән соң җеназа уңаеннан эшләнә торган барлык йолалар үтәлеп беткәч, мәрхүм белән хушлашырга килгән кешеләр, җирле җитәкчеләр, партиядәш һәм көрәштәш иптәшләре чыгыш ясаганнан соң Мәхмүтовның җәсәден яхшылап бизәлгән машинага чыгарып салдылар. Матәмгә җыелганнар акрын гына зиратка таба юл алды. Барысыннан да алда, көтмәгәндә кинәт вафат булган райком секретареның орденнары һәм медальләре куелган кызыл бәрхет мендәрчек тотып полковник Халтаев атлады. Ул юк-юк та көрәктәй куллары белән яшьләрен сөртеп ала һәм бу көчле, нык ихтыярлы кешенең тирән кайгыда икәнлеге бөтен кешегә дә аңлашыла иде.

Өлкә җитәкчеләреннән бераз арттарак, тиешле дистанция саклап Халтаев яраннары атлый, Заркенттан килгән мөһим түрәләрнең колакларына өтек-төтек кенә чалынган сүзләреннән алар Күпер Булат урынына полковник Халтаевтан да кулайрак кеше юклыгын да чамалаганнар иде.

❋

## Роберт Миңнуллин

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Хуш инде, иске Казан!

И борынгы, иске Казан!
Күңелне җилкетәсең.
Аерылабыз, хуш инде!..
Мин китмим, син китәсең.

Исем китеп карап йөрим—
Абына да сөртенә...
Иске Казан юкка чыга,
Иске Казан сүтелә.

Ничек түзәдер бу Казан
Тарихның җәберенә?
Йортлар түгел, ә халкымның
Хәтере җимерелә.

Юк, юк, дошманнар җимерми,
Җимерәбез үзебез.
Борынгыдан берни калмас—
Бераз гына түзегез!

Без төзибез өр-яңасын,
Ул озак торыр микән?
Ул балкып торыр микән соң,
Безнеке булыр микән?..

Уза заман, туза Казан...
Казан гына тузамы?
Туза бит тарих тузаны...
Күңел шуңа сызамы?

Юкка чыга иске Казан...
Мин инде нишли алам?
И борынгы, изге калам,
Сиңа кул изәп калам.

Юкка чыга иске Казан...
Яңасы ничек булыр?!
Яңа чорлар көтә безне—
Ничекләр кичеп булыр?!

### Яшәр идем...

Яшәр идем мин бу җирдә
Былбыл булып кына,
Сайрар идем көйләремне
Талга кунып кына...

Очар идем мин биектә
Бөркет булып кына,
Күзәтер идем җиремне
Өстән торып кына...

Кайтыр идем туган җиргә
Кырказ булып кына,
Гомер итәр идем илдә
Оя корып кына...

Ә мин һаман яшим әле
Кеше булып кына...
Кош була алырмын, ахры,
Кабат туып кына.

---

Роберт МИҢНУЛЛИН (1948) – *Татарстанның халык шагыйре; татар, рус, башкорт телләрендә дөнья күргән күпсанлы (лирика, балалар өчен шигырьләр, җырлар, публицистика) китаплар авторы. Казанда яши.*

## Татар башы башка киселмәсен!

Әй бит нинди шәп егетләр булган!
Куркытмаган хәтта үлем дә.
Батыр булып, татар булып калган
Ул егетләр дошман өнендә!

Алар әле һаман исән кебек,
Алар әле безнең йөрәктә...
Безгә бүген Муса Җәлил кирәк,
Җәлилчеләр кирәк бигрәк тә!

Без дә бүген җәлилчеләр кебек,
Без дә бүген Җәлил хәлендә.
Һәр татарның җаны тулы яра,
Булмаса да яра тәнендә.

Татарга да кояш чыгып ала,
Тарих бит ул аклы-каралы.
Ничә тапкыр чыгаралар инде
Халкыбызга үлем карары.

Шундый ук хәл хөкем сөрә бүген—
Барасы юк ерак-еракка.
Стенага китереп терәделәр,
Тик басасы калды курокка...

Гильотина юкмы безнең өстә?—
Баш очына ешрак карагыз!..
Ерагаймый, якыная гына
Җәлилчеләр белән арабыз.

Җәлилчеләр булыйк, әй егетләр!
Җәлил булыйк, шагыйрь иптәшләр!
Куркып тормыйк башны кисәрләр дип,
Барыбызныкын да кисмәсләр...

Баш имгән татар! Нишлисең бит,
Баш имгән башны кисәләр.
Нишләр идек бүген, дошманнарга
Башын игән татар, дисәләр?!.

Ачы да соң татар язмышлары!
Бер уйласаң, исең китәрлек...
Татар башы башка киселмәсен!
Киселгәннәре дә җитәрлек...

## Курыкмагыз, тешләсеннәр!

Этләр талый! Әйтерсең лә,
Казан—этләр оясы.
Хуҗасыз ул ач этләрне,
Белмим, кая куясы?!

Урамыннан узып булмый,—
Өскә этләр ташлана.
Югыйсә, этләр җитәрлек
Ул этләрдән башка да.

Өерләре белән алар
Сикерәләр өстеңә.
Әллә үзләре шундыйлар,
Әллә кемдер өстерә...

Әллә алар хуҗасызлар,
Әллә инде кыргыйлар.
Шагыйрь диеп тә тормыйлар—
Тешләргә дип ыргыйлар.

Тешли алар хатын-кызын,
Картын, бала-чагасын...
Белмиләр алар чамасын,—
Күрүче юк чарасын.

Юк ул этләргә тиюче,
Юк аларны тыючы,
Һич югында, җыеп алып
Юк бер ябып куючы.

Ул җаваплы кешеләрне,
Белмим, ни эшләтергә?
Ах, берәрсен шул этләрдән
Бер генә тешләтергә?!.

Өер-өер этләр йөри,
Ул этләр арта тора.
Тешләргә дип берсе—алда,
Калганы артта тора...

Чукыныш китсен этләре!—
Өер-өер йөрсеннәр.
Курыкмагыз, тешләсеннәр,
Кагылмагыз, өрсеннәр!

Тимик! Эт белән эт булу
Егетләр эше түгел.
Һәм тимибез, кызганабыз,—
Эт бит ул кеше түгел.

## Шагыйрь

*Әллә кем дә түгел кебек.*
В. Тургай

Әллә кем дә түгел кебек,
Гап-гади бер кеше.
Шигырь язу—бар белгәне,
Бар эшләгән эше.

Бер карасаң, патша кебек,
Бер карасаң, гыйбат.
Безгә аның үзе түгел,
Гыйбатлыгы кыйбат.

Бер карасаң, әүлия ул,
Бер карасаң, салмыш.
Кайсы чакта хактыр да ул,
Кайсы чакта—ялгыш?..

Үзе акыл иясе ул,
Үзе исә җүләр.
Ул шул акыллы килеш тә
Җүләр булып үләр.

Әллә кем дә түгел кебек,
Ә бит нинди сүзе?!
Нинди генә булса да ул
Милләтенең йөзе.

Гадәти бер кеше шундый
Сәер буламыни...
Була... Сәер булмаса, ул
Шагыйрь буламыни?!

## Әнкәйләрне берүк рәнҗетмәгез

Әнкәйләрне берүк рәнҗетмәгез,
Әрнетмәгез—сәбәп тапмагыз,
Әнкәйләрнең нечкә күңелләрен
Күз карасы төсле саклагыз!

Беребез дә мәңгелеккә килми,
Аларның да җаны бер тына...
Әнкәйләрне ялгыз калдырмагыз,
Тапшырмагыз картлар йортына!

Нурлы, җырлы булмас—әнкәгезне
Сыйдырмаган фатир, йортыгыз.
Әнкәйләрне берүк ташламагыз,
Ана каргышыннан куркыгыз!

Әнкәйләрне берүк елатмагыз—
Күз яшьләре безгә төшмәсен.
Әнкәйләрнең ачы күз яшьләре
Ләгънәт булып төшсә, нишләрсең?!

Әнкәйләр ул безне кичерер дә,
Ходай гына ләкин кичермәс.
Әнкәйләрнең догасыннан башка
Авыр юллар җицел кичелмәс.

Газиз әнкәйләр дип җан атыгыз,
Газиз әнкәйләр дип яныгыз!
Әнкәйләрне берүк рәнҗетмәгез,
Эчегездә булса җаныгыз!

Әнкәйләргә тавыш күтәрмәгез!
Һәм күтәрелмәсен кулыгыз!
Сездән әнә гыйбрәт алып тора
Яныгыздагы кыз-улыгыз.

Әнкәйләрне берүк онытмагыз,
Әгәр дә сез кеше икәнсез.
Онытсагыз, гөнаһларга батып,
Сез үкенеп гомер итәрсез!

Әнкәйләрне берүк рәнҗетмәгез,
Милләткә бит аның хурлыгы.
Аналарга булган хөрмәт белән
Бәяләнә милләт зурлыгы.

Мин хурламыйм монда берәүне дә.
Әйбәт балалар бар, бар алар!..
И аналар! Үстерсәгез иде
Халкыбызга лаек балалар!

## ...заман

Иркәләнер заман түгел,
Әрнер һәм сызлар заман...

Моңланыр, җырлар заман бу,
Утырып елар заман...

Әхлакка түгел, акчага
Башларны орган заман...

Орлыксыз чәчкән заман бу,
Чәчми дә урган заман...

Азгын заман, азган заман,
Үзең дә азар заман...

Шигырь язар заман түгел,
Акылдан язар заман...

Юләр кебек тик торганнан
Авызын ерган заман...

Бигрәк озакка китте бу—
Һич узмый торган заман...

## ...бетералмыйлар

Рәсәй шундый бөек ил ул—
Зурлап бетералмыйлар.

Рәсәй шундый фәкыйрь ил ул—
Хурлап бетералмыйлар.

Юк, Рәсәй ул шундый бай ил—
Урлап бетералмыйлар...

## Үзгәртеп кору

Үзгәртеп корабыз, дидек.
Үзгәртеп коралмадык,

Үзгәрттек, коралмадык,
Егылдык, торалмадык,

Әле булса
Пычак та кыралмадык...

Шулай шул, без тәртәләрне
Тиз генә боралмыйбыз.

Төз генә баралмыйбыз,
Нормаль ил булалмыйбыз,

Ә шулай да
Үзгәртми торалмыйбыз...

## Туган җир

Мине тапкан туфрак бит ул,
Мине баккан җир бит ул...
Туган җирен онытмаган
Ир генә чын ир бит ул!

Туган җирен онытучы
Башкалардан ким бит ул, —
Каберенә бер урын да
Тапмаска мөмкин бит ул.

Ә туган җир бик иркен ул,
Туган җир бик киң бит ул.
Иң гүзәл җир, иң газиз җир...
Туган җир иң-иң бит ул!

Мин агызган кендек каны,
Мин тамызган тир бит ул...
Һәммәбезнең туган җире
Изге җиргә тиң бит ул!

Әнкәм кебек берәү бит ул,
Әткәм кебек бер бит ул...
Мин кайтасы туфрак бит ул,
Мин ятасы җир бит ул!

*2004 — 2005.*



**Тәлгат Галиуллин**

# МӘКЕР

ПОВЕСТЬ

Фикеренне аңлап, җөпләп, һәр сүзенне зиһененә сеңдереп утыручылар белән шыгрым тулы залда чыгыш ясавы җан рәхәте, тән сихәте икән. Казан каласыннан махсус чакыру белән килгән профессор Әмир Әхмәдиев Ижау дәүләт университеты галимнәре, талиб-талибәләре, башка уку йортларыннан килгән кешеләр, татар җәмәгатьчелеге каршында археология фәненең казанышлары, бигрәк тә аның үзенчәлекле юнәлеше— нумизматика хакында инде өченче сәгать гәп алып бара. Чәчләренә ак көмеш тамчылар ингән, уртача буйлы, тыгыз гәүдәле олы галим таяныч йә илһам эзләгәндәй, почмаклы сакалын сыпыргалап ала да, чал тарих серләрен үзләрендә саклаган табылдык тәңкәләрне күрсәтә-күрсәтә аларның сугылган чоры, мәгънәсе, эчтәлеге турында, Тукайның "Без тарихта эзлебез..." дигән атаклы сүзләрен китерергә дә онытмыйча, иренмичә, ниндидер эчке тәм, ләззәт табып сөйли. Үз фәненә мөкиббән киткәнлеге һәр сүзеннән аңкып тора. Нотык тәмамланып, дәррәү кул чабулар залны селкетеп алганнан соң, галим төрле өлкәләргә, татар халкының үткәненә, киләчәгенә, хәзерге дөньяның торышына, сәяси-икътисадый хәлләргә, хәтта галәм серләренә кагылышлы бихисап күп сорауларга җавап тота. Яше алтмышның өстендә булуга карамастан, хәрәкәтчән, сөальләрнең юнәлешен тиз аңлап алучан профессор үз белгечлегенә мөнәсәбәте булмаган кызыксынуларга, гади яшәеш буразнасына төшүдән дә тайчынып тормыйча, һәркайсына вәземле аңлатма бирергә тырыша. Заманында хор өчен амфитеатр белән эшләнгән, түшәме, диварлары акка буялган мәһабәт залда утыручыларда җылы тәэсир калдырасы, ошыйсы килүе сизелеп тора. Бу—теләсә кайсы лекторның табигый хыялы. Әлеге очракта профессорның тырышуының сере тагын да тирәндәрәк ята иде. Заманында ул җирле университетның тарих-филология

---

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938)—*прозаик, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы; күпсанлы китаплар («Дәгъва», «Тәүбә», «Элмәк», «Төнге юллар», «Шигърият баскычлары» һ. б.)* авторы. *Казанда яши.*

факультетына укырга керү имтиханнарын уңышлы гына тапшыргач, төссез чырайлы декан урынбасары! "Сез студент булырсыз кебек, өегезгә кайтып, тыныч кына чакыру кәгазе көтегез"—дип, озатып җибәргән иде. Әмирне эзләп тапкан документта, киресенчә, "Хөрмәтле Фәлән-фәләнович, Сез конкурстан узмадыгыз",—дип язылган булып чыкты. Дүрт елын флот хезмәтенә биргәннән соң, үзен рәнҗеткән, кешегә санамаган Ижау белән ваклашмыйча, укырга Казан университетына керә, шунда аспирантура уза, кафедрада эшкә калдырыла һәм байтак еллардан соң үз көче, табигый сәләте һәм үҗәтлеге нәтиҗәсендә танылган абыз-галим дәрәҗәсенә күтәрелә. Инде буыннар алышынып, төссез чырайлы декан урынбасары урынына "төслеләре" килгән булса да, Әмирнең Ижау университеты халкына "Менә сез кемне югалттыгыз", дигән фикерне сиздерәсе килде. Әлбәттә, сине танышларын-белешләрен тыңлаганда сайравы күңеллерәк. Тулы залда аның бер танышы да юк дисәң дә була, тик ниндидер күзләр генә аны күптәнге ахирәтедәй кирәгеннән артык игътибар белән, карашын бер мизгелгә дә читкә алмыйча күзәтә, үзен ике арада рухи җеп сузарга тырышкандай тота. Чаткылы күзләренең төсләрен ерактан ачыклавы кыен, әмма хуҗалары икенче рәттә утырган ханым икәнлеген сиземли нотыкчы. Янында утырган университет проректоры язмача килгән сорауларны укыган арада Әмир Әхмәдиев үзенә игътибарлы күзләрнең иясе турында уйланып алырга өлгерә. Кем икән ул? Миннән нәрсә кирәк бу тәрбиясез, оятсыз, әрсез күзләргә? Бер мизгелдә алар ачулы, явыз, мәрхәмәтсез күренәләр, шунда ук аларга самими җылылык сирпелгәндәй була.

Рәхмәтләр әйтелеп, чәчәк бәйләме, истәлек бүләкләр тапшырылып, халык таралгач та тынгысыз күзләр хуҗасы урынында калды. Менә ул торып басты, рәт арасыннан чыгып, акрын атлап трибуна ягына юнәлде. Чәчләре шәмәхә төскә буялган, уртача буйлы, аркылыга җәелә төшкән, юантык ханым икән серле күзләр хуҗасы. Таныш булмаган инсани затка сәгатьләр буена текәлеп карап утырмыйлар дип эченнән тегене әрләп алып, профессор юантык ханымга игътибар беләнрәк карады. Зиһенен ярдәмгә чакырды. Тик аны кайда, кайчан күргәнлеген, бу сак һәм, шул ук вакытта елмаюлы күзләрне хәтеренә төшерә алмады. Кичке ашау-эчү өчен җаваплы бәндәләр дигән карарга килеп, Әмир кәгазьләрен, китапларын, тәнкәләрен коңгырт портфеленә тутыру белән мавыкты.

—Танымадыгыз бугай, профессор,—дигән гадәти мөрәҗәгать аны кинәт укол кадагандай сискәндереп җибәрде. Тавыш ана таныш тоелды. Дөресе, сүз-хәрефләрнең әйтелеше, сөйләмнең моңы күптән яңгырамаган, онытылып барган көй төсле якын булып китте. Кешенең тавышы тәнне кебек картаюга тиз бирешми икән. Ә күзләр? Бу күк зәңгәрлеген кая, кемдә күрде икән. Жетелекләрен югалтсалар да, үтә күренмәле, болын чәчәгенә охшаганнар икән бу күзләр. Мәгәр исенә-ятенә төшерә алмый. Склероз исемле зәхмәтнең җимергеч көче шундый вакытларда үзен сиздерә торгандыр инде.

Күзләре, тавышы таныш кебек, ә бөкрәя башлаган карчык бөтенләй ят, күргән-күрешкән кешесе түгел. Шунысы хак.

—Туган авылыгызда күптәннән булганыгыз юкмы? Гатаулла абый белән Хәдичә апа исән түгелләрдер инде?

Каян белә икән бу минем туган якны, әти-әнинең исемен дип, Әмир уйларга да өлгермәде, ханым сүзен дәвам иттерде.

—Яралы бармагыгызны бәйләгән шәфкать туташын оныттыгызмы? Хәтерләмисездер шул, күпме вакыт узган, сулар кирегә акса да, яшь гомерне кире кайтарып булмый.

Музейдан вакытлыча алып торган борынгы акчаларын учына кыскан

килеш, профессор тораташтай катып калды. Аның яшьлек мәхәббәте, тормышын чәлпәрәмә китергән Сәвия түгелме соң бу хатын? Ханымны таныгач, профессорның йөрәген татлы сулкылдау кисеп узды.

—Сәвия мин, Әмир, заманында син яратып, гашыйк булып йөргән мишәр баласы булам.

Профессор, ниһаять, телгә килде:

—Сәвия,... Чынлап та син заманында безнең авылны бизәгән шәфкать туташымы? Ничек килеп чыктың бу якларга?

Ханым сораугa туры җавап бирмичә:

—Картайган, танымаслык хәлгә килгән дисеңме?

Археолог аны багалмасыдай алсу йөзле, тирә-юньгә бәхет нуры сирпеп торган зәңгәр күзле, тал чыбыгыдай гәүдәле кыз итеп хәтерләвен, һаман шул үзгәрешсез хәлендә төшләренә керүен, бер шагыйрь сүзләре белән әйткәндә: "сыгылмалы горур буй сынган", барысын да картлык галәмәте, хәрабәләр алыштырган дисеңме? Үзеңдәге шундый ук үзгәрешләрне күрмисең, иң дөресе, күрәсең килми шул.

Әмир үзенең гөнаһлы уйларын яшерергә теләп, начар шөгыльдә тотылган баладай хис итеп:

—Вакыт берәүне дә аямый шул. Барыбыз да Җир-анабызга бурычны түлибез, табигать үзе биргән яшьлекне, матурлыкны хәтердә генә калдырып, кире ала, безне мәңгелеккә әзерли,—дип, очрашу киеренкелеген йомшарту юлын эзләп, урынсыз фәлсәфәгә кереп киткәнен сизми калды. Ми бүлеп чыгарган уй-истәлек дулкынын, йөрәктән иңгән хисне аңлыйсы, бәялисе бар иде. Көтелмәгән очрашу. Барысына вакыт кирәк, ә ул—юк. Үткерлеген югалтмаган зәңгәр күзләр сүзне дәвам итте:

—Бик зур галим булгансың. Телең телгә йокмый. Дөрес, элек тә сүзгә кесәгә кереп тормый идең. Халкыбызның бөек үткәнен инләп, гаҗәеп олы тарихлы милләтнең киләчәге булырга тиешлеккә ышандырдың. Уңышсыз мәхәббәтебез сине юлдан яздырмаган, хәер, күпкә әйбәтрәк кыз тапкансыңдыр әле. Ир-ат халкының бу яктан да мөмкинлекләре киңрәк. Шундый олы кешегә син дип эндәшүемә үпкәләмисеңдер? Хәтерлисеңдер: кулга-кул тотынып, төн ярып, йолдызлар санап авыл буйлап атлаганда, мәхәббәтебез ялкыны сүрелеп, язмыш Сак-Соклар кебек як-якка ташласа да, дус булып калырга, очрашканда бер-беребезгә "син" дип эндәшергә сүз бирешкән идек. Кая ул наив чаклар...

Үткәннең вак-төяген дә, әлбәттә, Әмир хәтерли иде, шунар да сонга калудан курыккандай, башын чайкарга ашыкты.

—Бернәрсәне дә онытмадым, Сәвия,—дип профессор сәхнәдән залга төште. Кул ишарәсе белән ханымны янына беренче рәткә чакырды. Текәлебрәк карагач, Әмир бик шыксыз күренгән, ярлы гына киенгән карчыкта элеккеге гүзәлләрнең гүзәле Сәвия чалымнарын шәйли башлады. Күз төпләренә бетми торган сөрем сөртелеп, битен, муенын төрле тирәнлектәге җыерчыклар каплаган булса да, яшьлектә Әмирне акылдан шашарлык дәрәҗәгә җиткергән күзләр үткер зәңгәрлекләрен саклаган. Кечтеки мине дә йөзне бизәвен дәвам итә. Күз, тавыш кебек үк, картаюга тиз бирешми. Кеше узган гомер җилләренә буйсынып, үзгәрсә дә, яшьлектә чәчрәп торган сыйфат-билгеләрен, үткән матурлыкны танырлык дәрәҗәдә булса да, саклый икән.

Заманында яшь, тук болан баласыдай урынында тәк кенә басып тора алмаган Сәвияне дә вакыт җиңгән, арзанлы иннек-кершән яккандай, үз билгеләрен тәннең барча ачык җиренә индергән. Уйламаганда, урман юлыннан кинәт аяк астыннан очып килеп чыккан кош кебек, көтелмәгән очрашу үзенчә кызык та, сәер дә иде. Беренче мәхәббәтенне, икесе дә утка

эләккән күбәләкләрдәй гыйшык ялкынында көерелеп, гомерләрен бергә уздырырга тиешле кешене читкә тибәрү, битараф булып кылану килешмәс. Язмышы ничекләр булып бетте, бу тарафларга кайчан һәм ни өчен килеп эләкте икән бичаракаем? Өлгергән көнбагышны хәтерләткән сары башын гел ярым ачык ишеккә тыгып, кулы белән чакыру ишарәләре ясап торган университет проректоры гына тынгы бирми. Аны да аңлап була, тырышып әзерләткән ризыклары, чәйләре суына торгандыр, өенә ашыгасы бардыр. Кунак килә дә китә, һәркемнең көйләнгән үз тормышы. Сәвия белән очрашуны башка көнгә күчерәсе булыр. Бу күрешүдән күңел җәрәхәтләре генә ачылмасын. Яшьлек хаталары өчен ул житәрлек түләде кебек. Ана да җиңел булмагандыр. Яраткандыр. Юкса, археология фәненнән ерак кеше аның чыгышын шулай игътибар белән тыңлап утырмас иде. Шул ук вакытта Әмирнең бәхетсезлекләренең яшерен серенә, символик мәгънәсенә төшенәсе, кайбер нәрсәләрне ачыклыйсы килә. Күбрәк аның хатасы, кемгәдер артык ышануы аркасында ахмакларча аерылышканнан соң Сәвия бәхеткә тарды микән? Әмирнең олы, керсез мәхәббәтен кем аяк астына салып таптады? Аның тулы бәхеткә дәгъва итә алмаган гомер кичерүендә кем гаепле?

Күңел чоңгылларында мәңге күтәрелмәскә, йөрәкне талкымаска, онытырга дип күмелгән истәлекләр хәтәрләнеп башын калкытты. Үткәненнән киемнән тузан каккан кебек кенә арынып булмый икән шул. Хатирәләр җанны сагыш һәм шатлык белән берьюлы сикертә ала икән.

Бу көтелмәгән, күз алдына китерүе кыен очрашу адәм баласын янә бер сынап карау өчен кирәктер, тормыш кояшы офык артына төшеп барганда да Хак тәгалә балаларын янә бер кат тикшерә, фани дөньяда сират күпере аша уздыра торгандыр. Яшьлек мәхәббәтең белән болай гына аерылышырга ярамый, бүген сөйләшеп бетереп тә булмый. Кунак хуҗаның ишәге диләр, кабул итүчеләр пырдымсызлана.

—Сәвия, иртәгә минем иртәнге сәгать уннан тарих факультетында бер пар лекциям бар. Уникеләр тирәсенә шунда килеп чыга алмассыңмы?

—Пенсионер кешенең вакыты күп. Килермен,—дип ханым яше мөмкинлек биргән дәрәҗәдә тиз-тиз атлап чыгып та китте.

Әмир университет җитәкчелеге белән кизү өчен генә утырды, тамагыннан рәтләп ризык үтмәде, мангаеннан борчактай тир бәреп чыкканчы, әллә ничә чынаяк чәй эчте. Авызларына аракы эләккәч, өйгә ашыгуларын, хатыннарының усал карашларын онытып яшьләр белән озаклап утыруны мәгънәсез һәм кирәксез санап, кунакханәгә озатып куюларын үтенде. Ял итү, тиз генә йокыга китү турындагы татлы хыяллары барып чыкмады. Күптән йоклаган хатирәләрне уятмаска иде дә бит, вакыты белән ми безнең ихтыярга буйсынмый. Вакыйгалар өй бүрәнәләре төсле берсе өстенә берсе өелә-өелә, кинодагы шикелле аның күз алдыннан узды. Берничә еллык гомерне искә алу өчен төн җитте. Бәхетсезлекләренең серен белгән Сәвия дә төнен шул ук халәттә, йокламыйча уздырды.

***

Югары уку йортына эләкмәгәч, шул көзне үк Әмирне хәрби хезмәткә яраклы дип таптылар һәм ул Мурманск шәһәренә флотка эләкте, студент булу бәхетенә ирешә алмаган адәм баласы диңгезче киеменә гәүдәсен төрде дә СССР исемле ясалма империянең старостасы дип үртәп йөртелгән (Сталинның адәм баласыннан каһкаһәле көлүе булгандыр инде) кешенең фамилиясен йөрткән, ягъни "Калинин" крейсерында һәр узган көнне, атнаны, аннан айны, елны санап хәрби диңгезче вазифасын үтәүгә керешге. Беренче мәлне туган як аеруча сагындыра, һәр минуты, очрашуга соңга калып килгән кызны көткәндәй, бик акрын уза икән. Дәрьяның саф һавасы,

судан искән жиле дә жирсүне баса алмый. Балачагында Әмирне юкка гына алсу жилкәнле кораб төшләренә кереп йөдәтмәгән булып чыкты. Портта кыска вакытлы тукталышларны исәпкә алмаганда, экипаж күп вакытын су өстендә чайкалган "тимер әржәдә" уздыра. Крейсер иксез-чиксез су белән чолганып алынган хәрәкәттәге утрауны хәтерләтә. Ә бер елны кыш иртә килеп, Мурманскига барып житә алмыйча, боз катламы арасында кысылып калып, кышны крейсерда уздыралар. Боз өстен каплаган кар салкыннан энже-мәржәннәрдәй ялтырап, күзне камаштыра. Дөньясында үзгә мохит, башка манзара юк кебек. Тирә-юнь авыл егете Әмиргә бушап калган колхоз кырын да хәтерләтеп куя.

Палубадан текәлеп озак карап торсаң, ап-ак бозлы кар күнелгә кара шом кертә, дөньяның фанилыгына ышандыра. Ятаклар аслы-өсле куелган бүлмәчеккә төшсәң, шул ук таныш йөзләргә, озынча кылыч, төерчекле бәрәнге борынга, нәселле этнеке төсле тырпаеп торган яисә башка ябышкан колакка, табигать биргән төсен отыры үзгәртми торган өлгергән борчактай соры, күк йөзе төсле зәңгәр күзләргә, хатын-кыз турында тәмсез мәзәк сөйләргә җайланган чапылдык авызларга юлыгасың. Һәммәсе мәңге онытылмаслык булып бавырда, бөердә, күздә утыралар. Салкын боз өстендә туган авыл, мунча себеркесе исе, таң әтәче, усал этләре, чишмә-сулары белән аеруча еш искә төшә. Шул мизгелләрдә туган якның кадерен, тәмен аңлый башлыйсың икән. Крейсер китапханәсенең китап-журналлары кат-кат укылды. Хәрәкәтсез крейсерның палубасы пычранмый, бүлмәләргә тузан кунмый. Эшсезлектән акылдан язар идең: ике нәрсә коткара. Берсе—шахмат уены, икенчесе—шигырь язып маташу.

Рифма сырлавы да аптыраган үрдәкнең күлгә арты белән чумуы кебек кенә бер шөгыль иде анысы. Әмир әүвәл бер-берсенә охшаш сүзләрне төзеп чыкты, шулар арасына халык җырларыннан күңеленә сеңгән сынландыруларны өстәде, үз күңеленә дә ягымлы гына җөмләләр килеп төшкәләде. Туган теле җанына ана сөте белән кергән татар кешесе яшьлегендә йә гашыйк булгач, хисләр басымына түзә алмыйча, шигырьдә көчен сынап карамыйча калмый торгандыр. Җырлый белмәгән чын башкорт юк, диләр бит. Бездә тезмәгә тартылу дәртен, вакытын кая куярга белми интеккән, кайгысын, шатлыгын, табигый моңын көндәлек дәфтәренә теркәп барган шәкертләр заманында җанга, канга сеңеп, буыннан-буынга, атадан-балага күчеп килүче бер фалдыр. Ничек кенә булмасын, бер китаптан бөек сүз остасы Шиллерның "шагыйрь ул—бердәнбер чын кеше", дигән гыйбарәсен укып, Әмир үзенә шундый юаныч табуына ифрат шатланды, үзенең бу мавыгуын аклады. Тик язганнарын берәүгә дә укымады (бөтен крейсерына бер татар баласы аларны кемгә укысын), соңыннан беркемгә күрсәтмәде, җан җылылыгын салган юанычларын ертып та ташламады.

Крейсер командасы Әмирне кызыксыну белән кабул итте. Көнбагыш төшләре арасына эләккән кабак орлыгы кебек иде татар егете.

Беренче мәлне яшь арыш башагыдай чәчле егетләр: "урысча исемең ничек була, Амир—Александрга туры килә, без сине Саша, Сашок дип атыйк", дип башын катырдылар. Соңгы олы орышта катнашкан әтисенең хушлашкан кичне тәкрарлаган сүзләре келт итеп исенә төште. "Улым, исемең матур, җинел, мәгънәле, урысчага килештереп, бозып әйтергә рөхсәт итмә. Бер дилбегәне йомшартсаң, төрлечә төрләндерү-болгандыру, ахыр үртәүләр китәчәк. Гади урыс үзен дөнья кендегенә санап, миен кыймылдатырга яратмый. Эреләнүнең, башка халыкларны кимсетеп карауның, кешегә санамауның бер чагылышыдыр дип уйлыйм".

Әтисе әйткән сүзләр бер дә зиһененнән чыкмады. Җавабын "фәнни" дәлилле итеп әзерләп куйды.

—Әмир, Амир, Эмир ханнан, сезненчә императордан, патшадан кала дәүләттә икенче кеше булган. Еш кына гаскәр башында ул торган. Тәржемәдә олы, бөек шәхес дигән сүз. Гарәп Эмиратын, гарәп Александры диеп әйтмиләр ич,—дип иренмичә аңлатты.

Әмир сезненчә олы князь була дип өстәмәкче иде, тыелып кала белде, элегерәк татарларны “князь” дип ирештереп йөргәннәре исенә килде. Кушамат тагып куярлар. Ул зәхмәт бер ябышса, ат коерыгына укмашкан кырмавык кебек, тиз генә котылам димә. Ярый әле хезмәттәшләренең тарихтан белемнәре чамалы икән.

Шулай да крейсер туган авылын түгел, әни әйтмешли, гыйфләт йокысына тарырга ярамый. Авылда да әле урамнарны, кызларны бүлешкән югары, түбән оч малайларын күз унында тотарга туры килә иде. Ә биредә илнең төрле почмагыннан жыелган, төрле холыклы әзмәвердәй егетләр. Ихтыяж булганда, юри шахматтан оттырганда дустанә кылансалар да, үзенне гел уяу тоту, кирәкмәгән вак-төяк низагларга катнашмау хәерлерәк икәнлегенә Әмир тиз төшенде. Аеруча крейсер бозлар арасында кысылып калган чорда, үгезлек көчне чебенгә сарыф иткән, хәрәкәтсез, чарасыз халәтләренә ачулары чыккан, бер төрле боткадан сарулары кайнаган, дәртләрен кая юнәлтергә белмәүдән баганага сикерергә әзер матрослар юк сәбәпне бар итеп бәйләнергә генә торалар. Берсе Әмир “бәхетенә” салынган балдак булды. Чем кара чәче, өлгергән карлыгандай күзе, кинчә бите берүк тамырдан—кыпчак нәселеннән икәнлеген аңламаган, үзен бөек милләтнең вәкаләтле вәкиле дип санаган хохол егете Досенко “чәченне кырып бирим, без сине гололобый татарин дип кенә атарбыз” кебек бәйләнүләре белән Гатаулла улының тенкәсенә тиде, тәмам гажиз итте. Әмирне очратканда Досенконың бите маска кигәндәй мыскыллы көлүгә жайлаша да куя. Әүвәл Әмир гаепле кешедәй, әллә инде сабыр төбе саф алтын дипме, хохол егете белән очрашмаска тырышты. Чучкага йомшаклык күрсәтсән, түренә кереп утырыр диюләре шулдыр инде. Теге зәхмәте күзгә калалган кылчык, һәр почмакка утыртып куелган карачкы кебек көтелмәгән тарафтан авызын иләктәй ерып килеп чыга да, шул ук сүзләрен кабатларга керешә: “гололобый татаринга риза булмасан, гололобый хан, князь дип эндәшербез. Чәченне кырдыр!”. Эт өрер, бүре йөрер дип Әмир бу юлы да Досенкога жавап бирмичә, усал карашын ташлап узып китү белән чикләнде. Башына төрле уйлар килде: “Ничек әле бу адәм актыгы мина сагыз кебек ябышырга булды сон? Ана начарлык эшләгәнем, рәнжетерлек сүз әйткәнем юк. Каян килә кешеләргә шундый явызлык, әшәкелек, бер милләт баласының икенчесен күрә алмавы. Диннәрнең төрле булуы сәбәпчеме? Алай дисән, Жир шарындагы барча диннәрдә тату яшәргә, башкаларны рәнжетмәскә, байлыгынны ярлылар белән бүлешергә өндиләр түгелме сон? Сизеп торам, ул малай мине шәхсән яратмаудан тилерми. Халкымны кабул итми, үз милләтен, динен өстен куя. Әллә үзен өстәрәк утыручы берәрсе котыртамы? Бәс, шулайга китсә, яхшылык белән аңламаса, явыз төрттерүләрен дәвам итсә, чарасын күрергә туры килер”,—дип Әмир күнеленә беркетеп куйды.

Кеше күнеле пыяла—саксыз кылансаң уала шул. Әмир татар холкына хас булганча, Досенконың бәйләнүләренә түзде-түзде дә, бер мәлне үзе дә көтмәгәнчә низагка чик куйды.

Ул көнне көндезге ашка кичегебрәк дәштеләр. Матрослар палубада жыелып, ашханә ачылганны көтеп торганда, көтеп алынган тансык күчтәнәч кебек авызын ерып Досенко килеп чыкмасынмы! Әмирнең янына килеп, “дусларча” култыклап алгандай итеп, тавышын башкалар ишетелерлек итеп чыгарып “чәченне кырдырып, үз табигый хәленә кайтырга вакыт, зыялы кешеләр кебек йөрмә” дип, әйтеп салмасынмы. Мондый мыскыллауга Әмир

түзеп тора алмады, каны ак күбекләрен сикертә-сикертә табадагы көнбагыш мае кайнап чыккан хәлгә килде, ачуы аяк табаныннан битенә, башына менде һәм егет үзен хәтерләмичә диярлек, бар көчен яшьли физик эштә ныгыган кувалда чаклы йодрыгына күчереп, аз гына артка чигенеп, төртмә тел хуҗасының ияк астына шәпләп тондырды. Уеннан уймак чыгасын көтмәгән хохол егете башы белән тимер идәнгә барып төште. Соң чиккәчә кызган Әмир бер сугу белән генә чикләнерлек дәрәҗәдә түгел иде. Торырга маташкан мескеннең өстенә сикерде, кулы белән янакларын, янтавын дөмбәсли башлады. Палубада кабер тынлыгы урнашты. Кәмит көтеп елмаешып торган матрослар әүвәл югалып калалар, аста чалкан яткан кешенең авызыннан күбекләр килә башлагач, исләренә килеп, Әмирне корбаныннан каерып алалар. Борыныннан шарлап кан аккан Досенконы юыну бүлмәсенә алып китәләр. Әмир бер мизгелгә ни булды соң әле бу дигәндәй, тораташтай катып тора да, өстен каккандай итә һәм ашыгыч эше калгандай, эре-эре атлап ашханәгә кереп китә.

Тыныч, сабыр Гатаулла улының чыгырдан чыгып, котырынып алуының бүлмәдәшләре генә белә торган янә бер сәбәбе бар иде. Матросларга өр-яңа куныччлы ботинкалар өләштеләр. Ул көнне Әмир искесен киеп бетерим дип, яңа аяк киемен идәнгә мендәре янына куеп, нарядка китә. Кичен кино булырга тиеш иде. Әмир көязләнеп, яңа ботинкаларын кия. Шунда ук ике аягы да носки аша җеп- җүеш булганны сизә.

—Нәрсә бу? Кайсы хайваны минем ботинкаларга су салган?—дип, урысча сүгенеп җибәргәнен сизми дә кала.

Бүлмәдәшләре белән дус яшиләр. Араларында гәүдә ягыннан иң тазасы, гер күтәргәндә күренгәнчә, иң көчлесе Әмир. Анардан азмы-күпме шөллиләр дә. Матрослар "мин түгел", "билләһи, минем эш түгел", "мин беркайчан андый пычрак нәрсәгә бармыйм дип", баш тартырга ашыктылар. Берсе килеп, ботинканың берсен кулына алды, борынын җыерып, "сасы су" дип, аны идәнгә ташлады. Димәк, кемдер Әмирнең аяк киеменә бәдәлен агызган. Тикшерә, уйлана торгач, төштән соң Досенко дигән матросның вакытлыча кечкенә урындыкларын алып торуы исләренә төште. Әмир барысын да аңлады. Аның көтмәгәндә сугыш чукмарына әверелүенең бер һәм төп сере шул иде.

Гатаулла улы берничә көн үзен чакырырлар, сораштырырлар, әрләрләр, бәлки, берничә көнгә салкын карцерга утыртып куярлар дип борчылып, эченнән аңлату, аклану сүзләрен әзерләп йөрде. Бу гамәлен хуплагандай, аны беркем дә чакырмады, шелтә бирмәде, шик-шөбһәсе акрынлап онытылды.

Досенко иптәшкә йодрык "килеште": шул көннән алып ул, еланнан сакланган куян кебек, Әмирдән качып ук булмаса да, күзенә чалынмаска тырышып йөрде. Әхмәдиевка хохол малаеның "татарлар юморны аңламыйлар икән", дип сөйләнеп йөрүен генә житкерделәр. Ләкин адәм баласына һәр адымы, хәрәкәте, кыланышы өчен ахыр чиктә бер түлисе була икән, бу орышның кайтавазы шактый вакыттан соң көтмәгәндә килеп чыкты.

Бик житди хәрби уен көннәре иде. Ике крейсер дошманны "эзәрлекләп" бара. Иртән аяз гына күренгән көн төшкә таба кинәт бозыла да куя. Күк йөзендә анда-санда гына күзгә чалынган ала-кола болытлар куера башлыйлар, шагыйрь әйтмешли, "чалбар кияләр". Төньяктан искән жил, файдалы эш башкаргандай, тизлеген арттыра барып, котыптагы шикелле, котырына ук башлый. Көләч дәрья чыраен сыта, жыерчыклары дулкынга, ак ялга әверелә, дөя төкерегедәй ак күбекләр һавага, биеккә күтәрелә, нәрсәгәдер ярсуы чыккандай океан юлында очраган һәр нәрсәне, шул

исәптән "Калинин"ны да тозлы суында коендыра, палубаны көймәдә йөзеп йөрерлек хәлгә китерә.

Әмир хезмәт иткән олы, мәһабәт баһадир крейсерга ышыкланып, анардан күп тапкырга кечерәк һәм, әлбәттә инде, көчсезрәк кораб килә иде. Элек силуэты рәшә кебек кенә булса да шәйләнгәләп алгаланган, матрослар әйтмешли, дәрья котырына башлагач, "малыш" юкка чыга.

"Калинин" капитаны крейсерны артка чигереп, "энесен" эзли башлый. Бәләкәч артык еракта калмаган булса да, үзен сәер тота. Зур суга эләгеп язмышына ризалашкан йомычка кебек, үзен күмеп-күмеп киткән дулкыннар ихтыярына буйсынып, тиле көчкә үзе белән теләсә ничек уйнарга ирек бирә. "Малыш"нын ярдәмгә мохтажлыгы, идарәсен югалтканлыгы якты көн кебек ачык. Шул арада олы крейсерга SOS хәбәре килеп житә. Ләкин аңа ничек, ни рәвешле ярдәм итәргә? Ул хәтлесен бер Алла гына белә торгандыр дип уйлый "калининдагылар".

Тәжрибәле диңгезчеләр, уйлана торгач, һәлакәткә юлыккан объектны бау белән олы крейсерга тагып куеп, тартып барып кына була дигән нәтижәгә киләләр. Палубада тимер култыксага тотынып басып торуы да ифрат кыен чакта әлеге гамәлне ничек башкарырга? Ялгыш кына кулны ычкындырсаң, дулкын үзеңне бәрә дә ега. Капитан үзе, радист жирле элемтә чаралары аша экипаж әгъзаларын бу авыр һәм куркыныч шөгыльгә алынырга чакырып карадылар. Үзе теләп алынган кеше табылмады. Премия, яна кием-салым, спирт кебек вәгъдәләр өстенә ил алдындагы бурыч, намус, ярдәмчеллек турындагы үгет-нәсихәт комга сеңгән су гамәлендә калды. Берәүнең дә үзе теләп фани дөнья белән араны өзәсе килми иде.

Ватан дошманы белән өркетеп булмаганда боерык илә генә кешене үлемгә жибәрүе кыен шул. Туган ил, Сталин өчен дип дошман амбразурасын каплаган ахмак еллар узып киткән икән. Кемнеңдер кинәшен тыңлапмы, үз акылы житепме, капитан эфирга яңа жим ташлады:

—Шуна алынган һәм башкарып чыккан матроска өч атналык ял бирелә. Юлы түләнә.

Океан гүләвен шау-шулы дию пәриләре туена тиңләп сәндерәсендә яткан Әмирне хужанын соңгы сүзләре сискәндереп жибәрде: "Сон, әти-әнине күреп килергә мөмкинлек туа түгелме соң?" Шунда ук адәм баласы ышанмастай хыялына үзе үк каршы төште. "Юк ла, башкарып чыгарлык эш түгелдер. Палубага күтәрелүгә, үзеңне дулкын бәреп егачак, әле бит ыргаклы арканны алагаем көч белән күршегә ыргытасы... Бушлай сыр капкында гына була, диләрме әле". Әмма тирәндә, ан төпкелендә утырган шайтан аны котыртуын, миенә үзенә муафыйк фикерен салуын дәвам итте. "Әтинең үзе ясаган балын эчеп, урман һавасын сулап, әнинең бәрәңге пәрәмәчен сыек каймак белән тәмләп кайтсаң, шәп булыр иде. Картлар күпме яши бит әле, тозлы су һавасын иснәп, үзләрен күрми дә калырсың". Соңгы фикер Әмирне күз иярмәс тизлек белән жылы ятагыннан сөйрәп төшерде һәм палубага ташлады. Саклану чараларын онытып жибәрә язган иде. Йөзләп кеше арасыннан син генә әти-әниеңне сагынган мәми авыз икәнсең дигәндәй, аждаһадай ыжгырып килгән дулкын аны чак кына аягыннан бәреп екмады. Тимер култыксага таянып өлгерде. Шуңа ук тотына-тотына палубаның арткы өлешенә китте. Тәнендәге жиңел киемнең секунд эчендә соңгы жебенә чаклы юешләнеп, лычма суга манчылуын әйтеп торасы да юк. Сәгать икеләр тирәсе генә булса да, берсен-берсе кысырыклый, сикерешә-котырына килгән дулкыннар яктылыкны каплап, тирә-якка кара пәрдә элгәннәр.

Бәлагә тарган крейсер, качыш уйнагандай, бер күренә, янә югала, "Калинин"га якынаебрак китсә, көчле өермә үги баланы тибәргәндәй, аны

җәһәт кенә читкә алып ташлый. Әмир үзе өчен бер хакыйкатьне ачыклады: крейсерлар якынлашкан мизгелне, мылтык мүшкәсенә объектны туры китергәндәй, эләктерү зарур. Палуба буенча, судан үрмәләп килеп, капитан ярдәмчесе матроска ыргаклы арканны ташлады, мәңгелеккә саубуллашкандай, Әмиргә карап алды да, кире чигенде. Бер кулы белән тимер култыксага тотынып, уңына юеш бауны алып, крейсерның арт кырыена килеп, егет үткен күзле сунарчыдай бәхетле минутны көтә башлады. Аның ниятен сизеп алып, хупламагандай, дуамал көчкә ия, баш бирмәс дулкыннар аны тозлы суында коендыруын дәвам иттеләр. Бер ташкын артыннан икенчесе килеп өерелгәнче туган күз ачып йомарлык вакыт эчендә, яшен тизлеге белән, чыбыркы селтәгәндәй кизәнеп, Әмир арканның тимерле башын чак кына сизелеп-күренеп алынган кечкенә крейсер ягына ташлады. Аның бурычы ыргакны күршенең тимер рәшәткәсенә эләктерү иде. Калганын бәлагә тарган экипаж әгъзалары башкарыр. Беренче ташлау уңышсыз чыкса да, алынган эшне башкарып чыгарга күнеккән үҗәт егет чигенергә җыенмады, дулкынның ыжгырып килү һәм чигенү вакытларын чамалап, швартов бавын ыргытуын белде. Куркыныч шөгыле белән булашып, үзенең өшеп теше тешкә тимәвен, киемнәрендәге тозның шытырдап катуын да сизмәде. Юештә сүс бау авырая, хәрәкәт итүе кыенлаша бара. Ыргак ташлаулар арасы бик озакка—мең елга сузылгандай тоелды. Бу хәтәр эшнең барып чыгуына, хәтта үзенең исән-имин калуына шикләнә башлагач, палуба янтаеп, арттагы крейсерга якынаеп китте, шул мәлдә Әмир соңгы җегәрен уң кулына туплап, бауны унынчымы-унберенчеме тапкыр ташлаганда, ыргак тиешле урынына барып төште, егет хәле бетеп, палуба идәненә егылды, шулай да су эченнән эчкәрәк шуыша алды, шуннан аны сөйрәп диярлек алып киттеләр. Бу—күрше крейсерның һәлакәттән котылуы дигән сүз иде.

Әмиргә бу егетлеге шактый кыйммәткә төште. Иптәшләренә таянып, көч-хәл белән каютасына житеп егылган егет берничә көн саташып, кызышып, өшеп аунап ятты. Ашыйсы килми, күңел болгана. Авырту, сызлау чигәдән башлап аяк бармаклары эченә хәтле төшә. Яшьлек һәм күңел тынычлыгы җитди салкын тиюне җинделәр. Ул өскә күтәрелгәндә инде дәрья тынган, тыныч су өстендә кояш көлтәләре күңелләрне кытыклый, югары баллы шторм булмаган да диярсең. Саф һава үпкәләренә, тән тукымаларына тулып, Әмирнең кәефен күтәреп җибәрде.

Һәлакәткә тарган крейсерны исән-имин килеш портка китереп җиткерүләре турындагы хәбәр күңеленә хуш килеп, авыр фәннән бишле алган баладай, йөзенә җинүче кыяфәте инде. Капитанның үзен чакыртып алып рәхмәт әйтергә ашыкмавына сәерсенеп, эченнән аны шелтәләп, эрерәк атларга тырышып, хуҗа янына күтәрелде. Озын буйлы, кипкән балык кебек чандыр гәүдәле, итләч борынлы капитан аны ачык йөз белән каршы алды.

—Батырыбыз килә. Терелеп җиттеңме? Куркытып алдың. Рәхмәт сиңа, Әхмәдиев, булдырдың! Чын егет икәнсең.

Кабул ителгән тәртип буенча, Әмир, үрә катып, уң кулын баш янына күтәреп:

—Советлар Союзына хезмәт итәм,—дип, ботинкаларын шапылдатып алды.

Булачак мактау сүзләренә дулкынланып, кызуланып бүлмәгә килеп кергән матрос почмакта журнал актарып утырган, кашлары кара болыттай асылынып торган, "бровеносец" кушаматлы партия комитеты сәркатибенә игътибар итмәгән иде. Әмир аның ягына борылып исәнләште дә, вәгъдәнең ничек, ни рәвешле үтәлеше турындагы сүзне көтә башлады. Рубкада сәер тынлык урнашты. Әмир телгә килде.

—Иптәш капитан, мине кайчан отпускага җибәрерсез икән? Ике атнадан портка кайтабыз ди бугай?

—Әхмәдиев, без парторг белән шул хакта сөйләшеп утыра идек әле. Синең кыюлыгыңны, ил алдындагы бурычыңны үтәвеңне хуплыйбыз! Шул ук вакытта матроска бәя биргәндә, уст..в таләп иткәнчә, без мәсьәләнең төрле ягын исәпкә алырга тиешбез. Иптәш Әхмәдиев, син тәртипне бозгалыйсың икән, матрос Досенконы рәнҗетүең турында партия җитәкчесе әле генә бәян итте. Егетне кыйнап үтерә язгансың ич. Чак аерып алганнар. Димәк ки, "Александр Матросов" крейсерына ярдәм итеп син бурычыңны гына түләгәнсең.

Зур коңгырт күзле колга капитан күп сүзле адәм иде. Сөйләшмичә, аңлашмыйча мөһер сугучылар белән эш итүе кыенрак. Өстә утыручы андый кеше хаклымы, түгелме, анысын уйлап бетермичә үк, кырт кисә дә куя, бетте-китте, башыңны кашы да чыгып кит.

Якыннарын күреп кайтуны хәл ителгәнгә санаган Әмир мондый борылышны көтмәгән иде. Аптыраш катыш сискәнүдән бер мәлгә өнсез калды. Ни өчен икәнен ачыштырмыйча, кечкенә буйлы, кешегә беркайчан туры карамый торган, диңгез суы төсле, йөгерек күзле, кара янып утырган парторг ягына кискен борылды, әмма аның карашын тоту хыялына ирешә алмады. Тегенең йөзенә иллә ваемсызлык, битарафлык төсмере чыгарырга тырышып утыруы сизелә. Ләкин алдында басып торган кара тут йөзле, тыгыз гәүдәле чибәр егетне ил дошманыннан битәррәк күрә алмавы астан, бавырдан, бөердән, нерв күзәнәкләреннән күтәрелгәне сизелеп тора, ун як битендәге кара төерчеге йолдыз төсенә кергән. Коткы җиленең кай тарафтан искәнлеге аңлашыла. Менә каян килгән икән бу "кыюлык" һәм мәкер Досенко иптәшкә. Кәҗә койрык күтәрә дип, сарык та койрык күтәрә, дигәннәре шулдыр инде. Явызлыкны партия әһеле оештырып ята икән. Менә кемне дөмбәслисе булган. Әмирнең үпкәсе үтмәс ризык кебек тамагына тыгылды. Үзен, теге вакыттагы кебек, тозлы сулы усал дулкын коендыргандай булды. Димәк ки, Әмирнең ял турындагы татлы хыяллары чәлпәрәмә килә, вәгъдәләргә ышанычы уылып төшә. Ни булса шул булыр дип, суда батып яткан кеше саламга ябышкандай, тавышының калтыранып чыгуына гарьләнеп:

—Иптәш капитан, мин тормышымны куркыныч астына куеп, күрше экипажны, хөкүмәт малын коткарып калдым. Вәгъдәгез булмаса, сезнең сүзгә, абруегызга ышанмасам, бу хәтле хәтәр эшкә алынмас идем. Көчкә исән калуым Сезгә мәгълүм.

"Болай ук шаярту кирәкмәс иде",—дип өстәмәкче булган иде дә, анысы артык булыр дип, тукталып кала алды. Шаярту түгел иде бугай мондый борылыш.

—Батырлыкны эшләдең. Рәхмәтемне әйттем, тагын кабатлый алам. Тик без мәсьәләгә төрле яктан килергә тиешбез, дидем. Партия оешмасы секретаренең үз фикере бар,—дип, ярдәм эзләгәндәй, парторг ягына борылды. Янәсе, ул нәрсә әйтер.

Тегесе торып басты. Утырганда буйга кыскалыгы бик сизелмәсә дә, кыска аякларына баскач, тагын да кечерәеп, утырган урындыгына аз гына югарырак булып калды. Сөзгәк сыерга Ходай тәгалә мөгез бирми шул. Табигать үзен тавыш белән рәнҗетмәгән. Сүзләре җиз быргыдан ингәндәй көчле чыгып, бүлмәне яңгыраттылар. Күңел тарлыгын тавышы эчендә яшерә торган адәм икәнлеге күренеп тора.

Озынрак күренергә теләпме, сүзләренә мәгънәлелек, саллылык өстәргә ниятләпме, аяк үкчәсенә күтәрелебрәк:

—Сугыш чукмары Әхмәдиевнең урыны төрмәдә. Без монда демократия

уйнап вакыт уздырабыз. Кыскасы, мин каршы. Бу—партия оешмасы сүзе,—дип урынына барып утырып, янә журналын кулына алды.

Җавапсыз калдырса, оттырасын аңлап, Әмир парторг ягына борылып:

—Башка милләт кешесен мөселман булганы өчен рәнжеткән, адым саен мыскыллаган өчен Досенконың түшенә орден тагыгыз алай булгач. Ул сезнен яктан яклау тапканга шулай азынган.

Аны партоешма секретаре котыртып ята икән дип өстәмәкче иде дә, вакытында тыелып, сүзләрне үзендә калдырды. Әлегә артыгы кирәкмәс. Болай да аңлашылырлык әйтелде. "Татлы тел аю биетә, усал сүз аждаһа китерә"—дигән борынгылар сүзен исенә төшереп, бәхәсне артык куертмаска булды. Әти-әнисен күрү турындагы мөкатдәс хыяллары дошмани кьяга бәрелеп, кырпак бозга төртелеп чәлпәрәмә килермени?

Парторг Әмир сүзләрен җавапсыз калдыра алмады. Аның абруена шәүлә төшерәләр ич.

—Досенко киресен сөйли. Тиктомалдан, көтмәгәндә, коллектив алдында китереп сукты, аяктан егып буа башлады,—ди.

Парторг яклау-хуплау көтеп, капитан ягына борылып сөйләде. Вакыйганың нинди юнәлештә үсүен әйтүе кыен иде, шул урында бүлмәгә салынып төшкән озын мыеклы, киң җилкәле казак Войтек дед-өлкән механик килеп керде һәм сөйләшүдә катнашкан кешедәй:

—Батырыбызны ялга озатырга җыенасызмы? Хуп, хуп. Өстәмә орден бирергә кирәк әле аңа. Бирәү дә булдыра алмаганны башкарды да чыкты,—шулай диде дә, нәрсәдер исенә төшкәндәй, чыгып та китте.

Әмир, допинг алган спортчы төсле кыюланып, һөҗүмгә күчте.

—Хәрби капитан да сүзендә тормагач, бу дөньяда нинди дөреслек була алсын, ди. Ике әйберне бутамаска иде. Ял итеп кайтыйм да, гаепле булсам, җәзасын бирерсез, зинданга озатырсыз,—диде, әрсез кәҗә кебек үҗәтләнеп.—Мин партияле кеше түгел, шуны истә тотыгыз.

—Бәлки, шулай итәрбез дә,—диде капитан читтән килгән ярдәмгә шатланып һәм матросның кыюлыгын хуплап.—Матрос Әхмәдиев, өч атнага ялга кайтырга әзерләнегез.

Парторг ягына борылып, бу кыюлыгын аклагандай, "Александр Матросов" крейсерының капитаны да кичә үзләрен коткарган егетне бүләкләүне сораган, аны күрәсе килүен әйткән иде дип өстәүне кирәк тапты.

Көтү сәгатьләре, көннәре бик акрын узса да, кадерле вакыт килеп җитте. Әмир вак-төяк күчтәнәчен алып, Казан тарафларына чыгып китте. Ярты юлга китереп житкергән автобус, очраклы машина, тәпиләп атлау һәм, ниһаять, туган авыл, туган йорт... Әти-әнисе, туганнары тупланган яшәү урынының кызыгырлык жире, башка татар авылларыннан аермасы да юк кебек. Ике кечтеки инеше, берничә чишмәсе, урманнан яулап алынган уңдырышсыз туфрагы... Дөрес, халыкны киендергән, жылыткан, жиләк-жимешкә, чабата-чыптага кинәндергән, карак узаманнар качырып тоткан, кызыл, ак партизаннарны бердәй күреп яшергән куе кара урманы бар. Сугыш елларында ул халыкны ач үлемнән саклап калды, дисән дә зур хата булмастыр. Шунда туып-үскән кешегә авыл якын һәм газиз. Яманны күрмәгән яхшының кадерен белмәс, дигәндәй, Әмир дә айлар буе су эчендә чайкалган "тимер әрҗәдә" утырмаса, авылының, туган ихатасының илаһи көчен тоймас, аңламас иде. Муртаеп беткән сарайлары, почмакка эленгән колмаклы, кычытканлы каен себеркесе, сүс, йон исләре төшләренә кереп, борыннарын кытыклады шул.

Әмир, дулкынлануын басарга тырышып, биек агач капканың келәсен җебеннән тартып күтәреп, эчкә үтте. Житкән егет кечкенә кызыл бозауны сарайга куып маташа. Капка ачылган тавышка борылды. Башына

түбәтәйдән аз гына зуррак койрыклы чүпрәк баш киеме элгән, аклы-каралы сызыклы майкасы күренеп торган таза гәүдәле кешегә мул кара чәчле, алсу чырайлы, яшәү көче ташып, мул куллары кыска жинле күлмәген тәртеп торган житкән егет карап тора. Әмир: "күрше мазардыр бу, нишләп йөри ул безнен йортта",—дип тә уйлап өлгермәде, егет бозау белән мавыгуын калдырып, "абый кайткан, нихәл" дип, теленә салынып, анын өстенә килеп сикерде.

—Наил, син түгелме соң ? Кай арада үсеп життен? Әни өйдәме?—дип, сорау артыннан сорау тезә-тезә, кул-аяклары белән кочып алган энесен өстеннән төшерергә маташты. Ул түгел, "ят кеше нишләп йөри безнен йортта? Ахыр чиктә монда кем хужа?" дигәндәй, тамагыннан бас чалымнары индерә-индерә, оясыннан кара соры зур эт килеп чыкты. Бик теләмичә генә абыйсыннан аерылган Наил маэмайны тәртипкә чакыра башлады.

—Чомбе, Чомбе, шаулама, үзебезнен кеше. Бар, әнә, Анжеликаны каравылла, чебешләрне эләктермәсен,—дип болай да өрәсе килеп тормаган этне читкәрәк этәрде.

—Чомбе—диктатор, ди. Ә Анжеласы кем була инде анын. Минем заманда бу ерткычларнын берсе дә юк иде. Тәмам баегансыз.

—Анжеласы бик үткен кара мәче. Үзара сугышалар да, дуслашалар да. Син армиягә китүгә эти бик ямансулады. Аракы, ачы бал белән юксынуын баса алмагач, күрше урыс авылыннан икесен дә бер көнне алып кайтты. Үзен беләсен, ул бит сәясәтче. Гәжитне кулыннан төшерми. Исемнәрне шуннан тапты. Әни генә әйтә алмый, һәр чакыруында янача эндәшә. Барыбер йөгереп киләләр үзләре,—дип сөйләнә-сөйләнә, башлаган шөгылен онытмыйча, кызыл бозауны вак бүрәнәле сарайга кертеп бикләде.

Шул арада кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә өйдән әниләре килеп чыкты, кабалануыннан сөртенеп, чак кына абынып егылмады. Татар гадәтенә хилафлык китерәм дип уйлап тормыйча, улын кочаклап, аркасыннан озак итеп сөйде.

—Балакаем кайткан икән. Исән-имин. Юлларын авыр булгандыр инде. Сине күрер көннәр дә бар икән,— дип, улыннан аерылып, чит-ят киемнән алдында басып торган таза, мәһабәт гәүдәле, дулкынланып торган конгырт кыска чәчле, кин мангайлы ир булып житешкән кешегә текәлеп карады. Күкрәк астында йөрткән улы икәненә инанды бугай, шатлык хисе тышка бәреп чыгу юлын эзләде, күзләре яшь белән мөлдерәмә тулды, үтә күренмәле ак карлыгандай эре бөртекләр бит жыерчыкларын үтеп, иреннәргә барып житте. Шатлык яше дә тозлы була икән. Тормыш газапларына тын гына түзгән ананын бөтен кыяфәтенә берьюлы сагыш, мон, наз, сөенеч нурлары инде.

Ындыр кебек зур йортта аралашып торган арада атлы арбасына утырган этиләре кайтып керде. Хатыны кебек улын кочаклап, балавыз сыгып тормады. Ике кулын биреп күрешге дә:

—Бөтенләйгә кайттынмы, Әмир. Әллә ялга гынамы, ә?—дип, сүзне эшлекле сораулардан башлап жибәрде. Матроска этисе бирешкән, картайган, ябык гәүдәсе тагын да кечерәеп калгандай тоелды. Тавышы элеккечә көр икән.

—Ничек әле сине Чомбе йортка кертергә булды? Рөхсәтсез берәүне дә якын китермә дип әйтеп калдырган идем. Өченче ай хатын юк. Әниен борчыла, мине бимазалый. Ә сина хоть бы что,—дип сөйләнә-сөйләнә атын тугара башлады.

Әмир, гаепле кешедәй, "ялга жибәрәбез дигәч, кәгазь пычратып тормадым, ә аны хәл итү сузылды", дип анлатма бирүне кирәк тапты.

Әтисе сүзендә кырыс кыланса да, соры күзләрендә дөнья вакчыллыгыннан өстен шәфкать һәм ирләрчә сөю нуры балкый иде. Гатаулла абзый уенын-чынын кушып сөйләргә яратуы, көтелмәгән чагыштырулары, борчак сибәргә маһирлыгы белән үзенә бер кеше иде. Шул ук вакытта авыл халкы аны каршыдагы пожарка янында домино уенындагы осталыгы өчен түгел, ә ярдәмчел булуы, олы-кеченең хәленә керүе, кайгысын, шатлыгын уртаклашырга һәрвакыт әзер торуы, тиешле киңәшен бирә, юата белүе өчен ярата иде. Кеше күңеле таш түгел, җылы сүзгә мохтаҗ, дип яши иде атаклы умартачы, бал кортларының якын дусты, киңәшчесе, сердәше.

Юан юкә бүрәнәләрдән эшләнгән, өч бүлмәгә бүленгән, агач исе күңелне сафландырып җибәрә торган чиста өйгә үттеләр. Әмир чантасын бушатып, энесенә атаклы моряк майкасын бирде, өлкәннәргә бүләкләрен өләште. Матур чәчәкле күлмәген киеп өлгергән әнисе олы якка чыгып, сабыйларча гөнаһсыз күз карашы белән улын иркәләп ала да, янәдән аш-су бүлмәсенә йөгереп кереп китә, шул арада өстәлен әзерли башлый. Казанда быгырдап кайнаган ит бүлмәне тәмле исләр, яшәү көче белән тутыра. Шул арада түр башына хуҗа булып, бабаларыннан калган атаклы җиз самовар килеп утыра, ирләр очрашуында мәҗбүри гонсыр "чуаш малае" өстәл кырыенда урынын ала, ачы бал кувшины да килеп утыра.

Әмирнең градуслы эчемлек белән күптәннән, армиягә озату мәҗлесеннән соң мавыкканы юк иде. Хәзер дә үзендә андый ихтыяҗ тапмады. Әтисе аның чәркәсенә коярга әзерләнгәч, рюмканы киң учы белән каплады.

—Кирәкми, әти. Туган авылның саф һавасыннан исереп киттем әле.

Ата кешенең мәҗлестәшен югалтуга аз гына корымы коелса да, ул улының гамәленнән (эченнән кыланышыннан дисә дә, матросның эчмәвенә аны кәҗәнен кәбестә яратмавына ышандыру кебек үк кыен нәрсә иде) канәгать калды. Атаның шатлыгы йөзенә чыкты.

—Соң дингез-дәрьяда һава начармыни? Анда сез гел исереп йөрисездер алайса? Ә палубаны швабра белән капитан үзе җыештырамы?

Әти кешенең төрттергүен житдигә алмыйча Әмир:

—Тозлы су һавасы исертми, әти. Ну зиһеннәрне ачып җибәрә.

Ана бәхете бүлмәне үзенә бер нур белән бизи. Күгелҗем күзле, чит кешеләр янында утыргандай авызын ак кәшәмир яулык очы белән капларга онытмаган әнисе, башка берәүгә дә игътибар итмичә, морякны кыстап-кыстап ашата.

Тиктормас энесе Наил гел сүзгә катнашып, өлкәннәрне бүлдереп, үзенә игътибар таләп итеп утыра. Әмир аны да сөйләшү үзәгенә тартырга була.

—Ну, Наил, укулар ничек бара? Гел бишлегә укыйсыңдыр инде.

—Абый, заманалар үзгәрде. Программалар катлауланды, бишлеләр борча кебек житезләнде, бик тоттырмыйлар, нечкә муеныннан эләктереп алам дигәндә, шуаларда да чыгалар.

Әмир өлкәннәр житдилеге белән:

—Эленке-салынкы укысаң, сиңа да югары уку йорты тәтемәс. Минем кебек дингезләр айкап йөрү көненә калырсың.

Наил башын кашып алгандай итә дә:

—Мин авыл хуҗалыгы институтына юл тотарга булдым. Әти районнан направление алып бирәм, ди. Ижау үпкәләмәсен инде,—диде, абыйсына төрттереп.

Сәясәтче-умартачы әтисен күбрәк флот хәлләре, хәрби әзерлек, туган илнең чикләрен саклау, дошмани көчләрнең торышы кызыксындырды.

Икенче көнне әнисенең теше-тырнагы белән каршы килүенә карамастан, Наил абыйсын утын ярырга, урам якка алып чыкты. Бу шөгыльгә бик теләмичә алынса да, Әмиргә тора-бара кызык булып китте. Шимбә көн

булу сәбәпледер инде, халык урамда, читтән кайткан, таныш булмаган кешеләр дә шактый күренә. Өч ел эчендә авыл халкы шактый үзгәргән. Яннарыннан узып баручы кешеләр турында Наилдән сораштыра, ачыклый торды. Тик тегенең талканы коры:

—Каян белеп бетерим мин барыгызны да, кайтасыз да китәсез. Китәсез дә, тагын да әйләнеп кайтасыз,—дип, ялгыш сүгенү сүзен үк ычкындырып җибәрде.

Учакка ягарга әнисенә җайлырак булсын дип пүләннәрне сул кулы белән бастырып тотып яра башлаган иде, бер мәлгә онытылып китте, энесенең пырдымсызланып ямьсез сүз ычкындыруы тәэсир иттеме, осталык җитмәдеме, балта баш бармакның өстен шактый тирән умырып алды. Әмирнең "фу, шайтан" дип кычкыруы булды, зиндан ишеге кинәт ачылып, тоткын иреккә йөгереп чыгарга ашыккандай, куе кызыл кан тышка ыргылды, матросның чалбарына эләкте, утынлыкны манчыды. Тычканга үлем, мәчегә көлке, диләр. Энесе бу хәлгә мөнәсәбәтен шундук бәян итте:

—Булдыра алмасаң, тотынмаска иде, балта швабра түгел ул сина.

Күгелҗем күзләреннән тәрәзә аша нур сирпеп торган әниләре кулына шырпы белән чүпрәк тотып, галошларын өстери-өстери килеп тә чыкты. Халык медицинасында кабул ителгәнчә, чүпрәкне яндырып, ярага, шарлап агып яткан канга төтен җибәрде, янәдән өйгә йөгерә-атлый кереп, "ай, улым, харап иттең бармагыңны, юк белән маташмасан" дип, йод сөртеп, булдыра алганча бәйләп үк куйды.

—Бармагыңны гел өскә каратып тор. Наил улым, йәтегез, фильширга. Сәвия апаң яхшылап бәйләп куйсын. Хөкүмәт кешесе бит.

—Утын яру тагын миңа калсын дип юри эләктерден бармагыңны,—диди Наил Әмирне авылның кыл уртасына оялган медпунктка алып китте.

Егерменче гасыр башында, татар мөлкәте күтәрелеп алган бер чорда авыл бае Шакир Бурнашев акчасына төзелгән, кызыл кирпечтән салынган бер катлы, хәзерге нәфес котырынган дәвердә таш мунча кебек кенә калган бина янына килеп җиткәч, энесе бик җитди итеп юллама-киңәшен бирде:

—Мин может көтеп тормам. Алдан кисәтеп куям: селәгәеңне агызып, кызга сразы гашыйк була күрмә. Мондый гүзәл туташның мона чаклы авылыбыз чирәмен таптаганы юк иде, диләр. Егетләр хәйлә белән, кайсы юри бармагын йә башка җирен кискәндәй булып, медсестра янына эләгергә, тиз генә аннан чыкмаска тырышалар. Тик бераздан барысы да шампан бөкесе кебек дуфкумга атылып килеп чыгалар. Син дә шундый хурлыкка калма.

Кызыл буявы төсен югалткан такта баскычтан күтәрелгәнче, Әмир гаҗәпсенү катыш аптырап, отыры ямьсез ак хәрефләр белән кызыл чүпрәккә төшерелгән "Медпункт" сүзенә карап торды. Ул бу язманы укыдымы, мәгънәсенә төшендеме—кәҗәнең афиша укуы гына булдымы—әйтүе кыен. Шул мизгелдә аның күнелен билгесез киеренкелек тудырган дулкынлану, хәтта борчылу ялмап алды. Кызның чибәрлеге турында энесенең уенычыны катнаш сафсатасы гына эчке дөньясына баллы шом салмагандыр инде. Язмышы шунда дисәң... Үзен тынычландырырга тырышып, эре-эре атлап коридорны узды, сорыга буялган ишекне төртеп ачып эчкә үтте. Агачтан салынган өйләр арасында тыштан мәһабәт күренсә дә, ташпулатның эче әлләкем түгел икән. Як-якта берәр тәрәзә елмаеп тора, дарулар тезелгән пыяла шкаф, кечкенә өстәл һәм берничә урындык кына бизи бүлмәне. Уң якта ак тукыма белән бүленгән авыруларны кабул итү почмагы шәрехләнә. Ишек шыгырдауга өстәл артында утырган туташ язуыннан аерылып, кергән кешегә җәһәт кенә күтәрелеп карады да, башлаган җөмләсен төгәлләүне мәгъкүл күрде. Өстендәге халаты төсле үк чиста, кәгазьдәй ак чырайлы,

конгырт чәчле, килешле борынлы кыз икән, әнисе әйтмешли, фильшер дигәннәре.

Кыз янәдән игътибарын кергән кешегә юнәлткәч, Әмир аның алгарак чыгып, ымсындырып торган тулы иреннәрен, өлгергән алмадай кызгылт янакларын, бигрәк тә зур, фирүзәдәй зәңгәр күзләрен зиһененә сеңдереп калды.

—Мөмкинме сезне борчырга?—диде, ачык якасыннан матрос майкасы күренеп торган егет, тавышының капитан бүлмәсендә сөйләшкәндәгедәй калтыраныбрак чыгуына оялу катыш гарьләнеп.

—Рәхим итегез!—диде назлы тавыш.—Ни булган безнең кунакка?—дип дәвам итте кыз ак, тигез, юеш тешләрен күрсәтеп алып.

—Энекәшкә утын ярышкан идем. Балта белән бармакны эләктердем. Ярасы тирән түгел кебек тә. Барыбер иркәләнергә булдым, ярдәм сорап сезгә килдем,—дип аңлатма бирде, тавышына тулы битарафлык төсмере индерергә тырышып.

—Авыл эшен оныта башлагансыз. Үтмәс балта кул кисәр, диләр. Белмәгән хезмәткә алынганда саграк булырга кирәк,—диде кыз, сүзенә инә кыстырып. Күзен туташның нурлы йөзеннән аера алмаган егет шаяртыбрак әйтелгән җавапны хәерлегә юрады.

—Сез дә минем энекәш сүзен кабатлыйсыз,—диде моряк үпкәләгәнрәк тавыш белән.

Шәфкать туташы аяз күк йөзедәй зәңгәр күзләрендә нур уйнатып алды да, егетнең сүзләренә игътибар итмичә:

—Хәзер бармакны иплән бәйләп куярбыз. Хәдичә апа канны туктаткан инде. Безгә артык мәшәкать тә калмаган,—дип, Әмиргә күтәрелеп карамаска тырышып, ниндидер сыекча сөртеп, өй чүпрәген бинтка алыштырып куйды. Кызның йомшак, назлы куллары бармакларына тиюгә Әмиргә рәхәт булып китте, киселгән җирнең сызлавы басылгандай булды. Тик йөрәге генә аңа буйсынмыйча, ашыгыч шөгыле бар кешедәй, тыпырчынып тибә башлады. Шәфкать туташының янында басып торуы матдәнең җанлы кыйпылчыгын шулай дулкынландырды бугай. Әмирнең конгырт күзләре тик тормады, кызны өйрәнүен дәвам итте, ап-ак маңгаены, карлыгач канатыдай кыйгач коңгырт кашларны, озын керфекләрне, килешле борынны, кабартмадай ымсындыргыч иреннәрне, уртасында кечтеки чокырчыклы иякне инләде, илаһи матурлыкны хуплады, төпсез коедай күзләр эчендә эреп, югалып калгандай булды. Авылыбызны шундый нәзакатьлелек бизәгәнне бармакны эләктермәсән белми дә калыр иден. Дан балтага! Үзенә мен рәхмәтләр укып, дәреслеккә юл яручы дип музейга тапшырырсын! Адәми зат гомер бакый хәләл яртысын көтеп-эзләп яши, диләр бит. Минем язмыш йомгагымның башы шунда булса?

Су дәрьясы чиксезлегендә гизгәндә тезгенсез хыял гына мондый матурлыкны иҗат итә алгандыр. Илаһи нәфислек туган авылыбызда яши икән ләбаса. Бәлки, Әмиргә генә шулай тоеладыр. Озын-озак сәфәрдә йөреп, ниһаять, коры җиргә аяк баскан дингезчегә шыксыз хатын-кыз да оҗмах фәрештәсе булып күренә, диләр. Аннан килеп, туган якта йолдызлар да яктырак, әнинең кадерләп тоткан җиз табагына охшаган ае да җанга якынрак була. Юк, бу күз алдануы гына түгел. Икенче яртыбыз вәкилләрен күргәне бар ич аның. Шәфкать туташы табигать тудыра алган гүзәллек алдында тез чүгәрлек. Безләргә, бар байлыгы тозлы су ияләренә тәтемәс шул ул. Артыннан ымсынып йөрүчеләр бихисап, ди бит Наил. берәр әрсезенең кармагына капкандыр инде. Ул арада бармак белән алышбирешен төгәлләгән гүзәллек телгә килә.

—Туегыз әле булмагандыр. Анарчы төзәлер. Хушыгыз,—дип кыз, егеткә

чыгып китәргә мөмкин дигәнрәк ишарә ясап, килешле чүгәләп, тар шкафында актарына башлый.

Егет бар әрсезлеген теленә күчерә:

—Туенда тоткарлык булмас иде дә, балдак кидерерлек кызы гына юк.

—Авылыгыз районда ин зурысы, кызлар күп, берәрсе табылыр,—дип шәфкать туташы Әмир ягына әйләнеп тә карамыйча, шөгылен дәвам иттерә. Юк-бар белән башны катырып торма, юлында бул диюедер.

Моряк бик теләсә дә, урыныннан кузгала алмады. Шул мизгелдә аңа киләчәк язмышы хәл ителәчәктәй тоелды. Зәвыклы, нечкә күнелле кыз икәне сизелеп тора. Тәвәккәл таш яра дигәндәй, Әмир беркадәр ясалма кыюланып, янәдән тавышының калтыранып чыгуына гарьләнеп, сүзне ялгарга омтылыш ясады:

—Безнең авылда сездәй чибәр кызлар туа белмәгән шул. Андыйлар читтәрәк яши икән. Гафу итегез, эшегезне бүләм инде. Сез күрше авылларның берсеннәнме?

—Юк, мин еракттан.

Сүзне дәвам итәргәме-юкмы дип уйланып торганнан соң, өстәп куйды:

—Чистай медучилищесын тәмамлагач, сезнең авылга эшкә җибәрделәр. Үзем ул яктан, авылыгызда икенче ел инде,—дип, чүгәләгән килеш башын егет ягына борып, бер мизгелгә генә Әмирне күз нурының көлтәсендә коендырып алды. Тыгыз гәүдәле, куе дулкынланып торган коңгырт чәчле, киң маңгайлы, куна тактасыдай киң күкрәкле, ихтыяр көченә ишарә ясап, алгарак чыгып торган иякле хәрби дә кызларга ошамаслык түгел иде. Шул рәвешле сүзләре ипле генә ялганып китәргә торганда, ишекне шакып та тормыйча бүлмәдә шомырт агачыннан матурлап ясалган таякка таянган, гәүдәсе сорау билгесен хәтерләткән карчык пәйда булды.

—Кем, Сәвия кызым, мина теге, каһәрнең исемен оныттым, даруны апкайтам дигән идең? Апкайталмадыңмы әле? Башым үтереп сызлый. Түзеп булса да, авыртуына чыдавы кыен.

Әбекәй сөйләнә-сөйләнә үзен буш урындыкка урнаштырды. Үзе шикелле үк чакырылмаган кунакның озакка кергәнлеген чамалап, Әмир дә уң кулын ишек тоткасына салды.

—Рәхмәт сезгә ярдәмегез өчен. Янәдән бәйләтергә ничә...—Авызыннан чак кына, сәгатьтән керим сүзе коштай очып чыкмады—көннән соң әйләним?

Әбигә кирәкле даруны эзләргә керешкән шәфкать туташы "бәлки инде кабат керүнең кирәге дә булмас, ярагыз тирән түгел", дип, егетнең янәдән бу тирәдә йөрүен өнәмәгәнен сиздереп куйгандай тоелды дәрьяны җингән дингезчегә. Кызның кыска халаттан чыгып торган тулы балтырларыннан, тез асты чокырчыкларыннан күзен авырлык белән аерган егеткә:

—Сау булыгыз,—дип, җәһәт кенә чыгып китүдән башка юл юк иде.

Энесе Наил "өйгә кайта торам" дисә дә, кызыксынуын, бәлки әле көнләшүен үк җинә алмыйча, әрсезләнеп, урамда көткән.

—Кайтып утын яра торсаң, файдалырак булыр иде. Юлны синнән башка да табар идем әле,— дигән шелтәне Наил үтә күренмәле колак яфрагы аша гына уздырып җибәрде.

Үз оясында бәләкәй көчек хәтта арысланнан курыкмый шул. Теленә шайтан төкергән энесенең җавабы әзер:

—Медсестра бармагынны эшкә яраксыз дип кисеп ташларга уйлап, рәнҗетә калса, ярдәмгә әзер булып тордым. Күзеннән күрәм, гашыйк булгансың. Тик ул сина карамас. Генерал, һич югында әфисәр йә капитан булсаң иде хет. Синдәй матрослар, ефрейторлар аның ишек төбендә әрдәнә-әрдәнә өелеп яталар. Берсенә дә карамый.

Үзеннән нәрсәдер торган шикелле кызның кырыслыгын хуплап ук куйды: “Молодец тути”.

—Телең ачылып китте әле, малай актыгы. Үзең яшерен утта янып йөрмисеңме икән?

—Минем өчен карт инде ул, минем вкуста да түгел,—диде Наил эре генә, юл өстендә яткан ташны тибеп очырып.—Әнә нинди әрсез яшьләр үсеп килә.

—Аракы эчә, тәмәке тарта белгәннәрме?

—Авыл кызлары тәртиплерәк әле. Дөресен әйт әле, иптәш матрос, Сәвия апаны күргәч, тәнең каз тиреседәй кабарып чыктымы?

Әмир чын-чынлап ачуы килеп:

—Житте. Телеңә салынма. Иртә өлгергәнсең, абзыкай. Мин синең яшьтә азып-тузып, кызларга күз салып йөри алмадым, печән чаптым, урман кистем, сине бактым.

Туганнар ярым шаярып сөйләшә-сөйләшә өйләренә кайтып житкәнне сизми дә калдылар. Егетләрне әтиләре елмаеп каршы алды.

—Әниегез барын сөйләде. Балта үзе белән шаярганны яратмый шул. Ихласларга гына баш бирә.

Кан юллары агач тамырын хәтерләткән кулын алга сузып, Әмирнең бинт уралган бармагына күрсәтә-күрсәтә көләргә үк тотынды. Тик аның сүзләреннән, ирештерүеннән мөлаемлылык, аталарча ярату бөркелеп тора иде. Шул арада өйдән изге жан—әниләре атылып килеп чыкты. Төртмәле телле ир-ат женесеннән аермалы буларак, ул Әмирнең ярасын житди кабул иткән.

—Ничек, улым? Бик сызлап бимазаламыймы? Юк белән мавыкмаска, ял итәргә ие. Бармагыңны медсестрабыз ничекләр килештереп бәйләп куйган. Мишәр кызы булса да, бик тырыш, тыйнак, уңган булып чыкты. Авылыбызның бәхете бар икән. Сәвияне үзендә яшәткән әби үзен мактап бетерә алмый. Үз гумеремдә мондый кырт иткән баланы очратканым юк иде, дир. Үземне өрмәгән жиргә утыртмый, дир.

—Әллә инде сиңа килен кирәк,—дип бүлдерде хатынын Гатаулла шаянрак тон белән. Әмма житди жавап алды.

—Кирәк тә булыр. Ничә ир-атка бер үзем. Шарун дигәнегез дә сезнен заттан,—дип түгәрәк тормышыннан канәгатьлеген яшереп тормыйча, шатлык күз яшьләрен яулык чите белән сөртә-сөртә өстәл әзерләргә өйгә юнәлде. Хәдичә апа дөньяның олы проблемалары тирәсендә баш ватмыйча, кешелекнең илаһилыкка омтылырга тиешлеге хакында уйланмыйча, үз гаиләсе—ире, балалары, йорттагы маллары белән аралашудан ләззәт, бәхет табып яши белә иде.

Улы Әмир генә Сәвияне күргән сәгатьтән тынычлыгын югалтты. Ятса да, торса да халаты төсле ак йөзле, коедай төпсез күзле кыз бөтен матурлыгы белән күз алдыннан китми интектерде. Көненә берничә тапкыр ул беренче сөйләшүләрен искә төшерә, булачак очрашуларында ни-нәрсә әйтәселәрен күңел шәрифләреннән уздыра. Әтисе кулыннан узган ачы балны бер-ике стакан жибәргәч, гайрәтләнеп китеп, күңеленнән кыз белән шактый кыю гәпләр корып ала, йөрәген биләгән хисләре турында сөйләп бирә, чәчләреннән сыйпап, шәфкать туташының нәфис кулын киң учына ала. Ачы бал пары очып бетү белән кыюлыгы да кими, өмет чаткылары учак күмерләре төсле берәм-берәм сүнә, хыялый сәрхүшлеге өчен үзен ахмак, тиле бәрән орлыгы ашаган тинтәк дип әрли, эттән алып мәчегә сала. Мич башында гел ымсындырып, үзенә чакырып торган мичкәдән янә бер чәркәне үзенә бушаткач, күңеленә тагын талымсыз рәхәтлек белән бергә кыюлык инә.

Икенче көнне үк яралы бармагын тикшертеп, янадан бәйләтү теләге көчле булса да, егетлеге җитмәде, яхшысынмады, юкка борчып йөрисез дип әрләп чыгарудан шикләнеп бармады, түзде. Ул көн ана ифрат озын вә монсу тоелды, дөньяда егерме бер ел яшәп, шулай бимазалап узган кояшлы көнне хәтереннән таба алмады. Июнь аенда көчләп ураза тоттырып, "кияш пайуын та паер, ну пес пулмапыс" дип, башка вакытта бик кадерле яктылык шәменең урман артына төшүен, сүнүен көтеп зарыккан чуаш көненә кала язды. Ярый әле, әтисе эштән иртәрәк кайтты. Атын туарып, улы янына баскычка килеп утырды.

—Йә моряк, яллар ничек уза? Туйдырмадымы әле? Корабын сагындырмыймы?

Әмирнең "әйе", "юк" кебек җавапларын тыңлап тормыйча, тышкы ишек ягына борылып, хатынынннан кичке ашнын әзерлеген белеште һәм сүзен дәвам иттерде.

—Улым, теге вакытта Ижауга укырга керә алган булсаң, може яхшырак булыр иде дә, болай хет дөнья күрәсең, дәрьялар иңлисең, безнең авылда кемгә тәтегән әле мондый бәхет.

—Ар кардәшләрнең шомартуына карап кына ким-хур булмадың әле,— диде Гатаулла абзый озынча, тирән сырлар бизәгән маңгаеннан фикер кысып чыгаргандай маңгаен уып.—Алтын җирдә ятмас, яхшы исем югалмас. Безнең авылдан флотка син беренче эләктең. Ялга да кайтардылар үзеңне. Значитсы начар хезмәт итмисең. Дингезләрне, океаннарны иңлисең, авыл халкының төшенә дә кермәгән дөнья күреп йөрисең.

Әмир үз шәхесе турындагы гәпнең озаккарак китүен өнәмичә, сүзне башка юнәлешкә кертергә булды.

—Хезмәт хакын, әти, вакытында түлиләрме?—дигән сорау бирде.

—Акча турында сөйләргә яратмыйм, улым. Вакытында түләсә дә бик аз чыга шул.

—Соң таләп итегез, сорагыз, үзәккә язызыз, тавыш күтәрегез.

Гатаулла агай улына сәерсенеп, гаҗәпләнеп, рәнҗеп карады. Бу аның малай шаяртамы, әллә берни аңламыймы яисә дингездә озак йөзеп, зиһен шөрепләре бушаганмы диеп фаразлап куюы иде бугай.

Гатаулла абзый бармаклары белән бу юлы башын кашып алгандай итте дә, мәгънәле итеп кулын селтәде.

—Әй улым, син өч ел су өстендә чайкалып, тормыштан аерылып барасың тегелме? Бу гамәлнең файдасыз икәнен аңламыйсыңмы?

Уйланып торгач, Әмирнең күңелендә мәңгегә уелып калган җөмләсен чыгарды:

—Үзебез сарык булгач, көтүченең Сарбай булуы гаҗәп тегел.

Шул арада өстәленә бар нигъмәтен тезеп өлгергән ана өлкән улын күгелҗем коңгырт күзләренең нурында коендырып, барысын чәйгә чакырды. Ул да булмады, капканың урам ягында, өстәлгә япканда әнисе эш кушмасын дип махсус көтеп торгандай, тимер келәне шартлатып күтәреп, бусагада ерык авызлы Наил күренде.

—Әни, шыпырт кына, миннән качырып, абзыйларны сыйларга уйладыңмы? Барып чыкмас, минем борын японский, тәмле ризык исен бер чакрымнан сизә.

Гаилә әгъзаларының барысын тигез күргән ана, әлбәттә, бу төр шаяртуны кабул итми.

—Юк, юк. Наил улым. Төпчегем. Синнән башка ничекләр ризык тамактан үтсен, ди. Тузга язмаганны. Синең кулга каласы. Әйдә, тизрәк кулларыңны ю да, утыр.

Бик мөһим эшен оныткандай, аш-су бүлмәсенә кереп чыкты да, Наилнең

йортка юынырга китүеннән файдаланып булса кирәк.

—Күкрәк астымда йөрткәндә үк Наилнең шук малай буласын сизгән идем.

Үзендә ирләрнең сораулы күз карашын тоеп, әйтимме, юкмы икән дип, икеләнеп торгандай итте дә:

—Бертуктаусыз укшытты,—дип ярып салды.

Әмир берәүне дә, игътибарын жыеп, чын-чынлап тынлый алмый. Йөрәген билгесезлек тырный, әнисе Наил белән интеккәндәге төсле, укшыта. Кыз аны тәмам гипнозлады. Нәрсә булды аның белән. Чибәррәк кызларны да күргәне бар ич, бер дә болай чәч төбеннән дым чыкканы юк иде. Әмир үзен тынычландыру өчен кызның житешсез якларын эзләргә керешә. Колаклары кечерәк булып, башына ябышып торалар түгелме? Яннан караганда, авызы маймылныкы кебек алгарак чыгып тора. Нәкъ шул мизгелдә шул иренне суырып үбеп аласы килә. Наил шайтанның кызны үтереп мактавы психикага китереп бәрде бугай.

Иртәгегә кадәр ничек түзәргә, таң атып, әни көтүне кугач та, әле кояшның муллалар тавы өстенә менеп атланганына тикле көтәсе була. Хөкүмәт оешмалары, аерым алганда медпунктлар эшләрен ник шулай соң башлый икән? Чирнең акылы юк, ул сиңа сәгатькә карап килми. Авыруларны тугыздан гына кабул итә башласыннар имеш, тузга язмаганны. Әнә крейсерда нинди тәртип, сәгать алтыдан да калмый швабраңны тотып палубага чыгасың. Вакыт адәм баласын тынламый шул, ашыкмый да, туктап та тормый.

Үз жае белән, ямьле иртә ялындырып кына булса да, килеп житте. Бармакны күрсәтү, нәрсәдер сөрттереп бәйләтү сылтавы Әмирне серле кыз янына, кара бай төзеп калдырган таш ихата янына сөйрәде. Тиктомалга йөрми ич, житди йомышы бар. Әнә ашын ашаган яшен яшәгән әбиләр дә юк йомышны бар итеп дару тирәсендә әйләнә. Бәхетсезгә жил каршы дигәндәй, Сәвия эш урынына кереп, кирәкле даруларын алып, үзләре йөри алмый торган авырулар янына киткән, жыештыручы апа аңлатканча, шуннан бульнискә, райүзәккә юл тотасы икән. Әмирнең сөмсере коелды, тәне бер тунды, бер кызышты, ул үзен дөньяда иң бәхетсез кеше итеп тойды. Ул мишәр кызы турында уйламаска, өйдәгеләргә берни сиздермәскә кирәк. Авызын тулы кан булса да, кеше алдында төкермә, диләр түгелме соң?

Әмир иптәш кызга чүт кенә булса да ошаганмы, юкмы, белгән юк, теге вакытта күз карашын сирпеп тә ваклашмады. Берәрсе югары белеме белән масаеп эләктерер әле үзен. Хатын-кыз бәхетнең дипломда гына түгел икәнен аңламый шул. Бер күзәнәкле халык.

Эленке-салынкы гына атлап, бар дөньясын әрләп, үзен, мәхлукны кызганып йортка килеп керүгә, энесе килеп чыкты һәм ирен читенә үртәүле-кинәле елмаю чыгарып, сөенечен әйтеп салды: Әмирне мәктәптәше Фоат туган көненә чакырган икән. Сүзенә мәгънә салып өстәде.

—Медсестра да булырга тиеш, ди. Килерме, юкмы анысы билгесез. Ну, чакырылган.

—Причем монда медсестра, малай актыгы. Аның мәжлескә килү-килмәве мине борчымый,—диде Әмир. Мөмкин кадәр кырысрак булырга тырышса да, тавышының калтыранкыбрак чыгуын тойды.

—Соң шул Сәвия түти аркасында бар тынычлыгыңны югалтканыңны сизеп, күреп торам абзыкай,—дип, Наил аны үртәргә үк керешә.

—Ычкын моннан шайтан таягы. Капканың теге ягына барып төшәрлек итеп берне тондырырмын.

—Тота алсаң, сугып жибәр,—дип, дугасыман сызылып киткән кара

кашларын хәйләкәр уйнатып, Наил урамга чыгып йөгерде. Башын кече капкадан тыгып, болай дип өстәде:

—Көпә-көндез барып куя күрмә! Сина ышансан. Кичке сәгать сигезгә чакырдылар. Түземсезлеген чыраена чыккан.

Ходай Тәгалә үз балаларын бер дә кызганмый инде, сынауларын җибәреп кенә тора. Кичкә чаклы ничек түзәсе инде тагын. Әтинең ачы балы вакытны кыскартырга ярдәм итсә генә. Бал мичкәсе янына касә белән килгәннең әни бер дә хупламый шул, камыр изгәндә, бәрәнге әрчегәндә күзләре гел шул якта. Аның кәефен кырасы килмәү дә аңлашыла.

Иптәш егете каршы урамда гына тора икән. Бүләккә киелмәгән матрос майкасын алып, сигезгә үк атылып барып керсәң дөрес аңламаслар дип уйлап, ярты сәгатькә сонарып, Фоат исемле сабакташына юл алды. Кызлар-егетләр вакытында килгән, җәмгысе унбишләп кеше җыелган икән. Бүлмәдә хушбуй исе, яшьлек дәрте, тир тәме. Әмир ир-ат заты белән кул биреп күрешеп, сиздермичә, җәһәт кенә бер почмактарак пышылдашып торган кызлар ягына күз салды. Күңел күзе белән "аның" юклыгын сизенгән Әмир маңгай күзе белән дә шуңа инанды.

Әмир уенча, букетка матур, төрле төсле үләннәр җыелган, әмма араларында таҗ булырдай чәчәк юк, аның бәйләмдә җитешмәгәнлеге сизелеп тора.

Тәбәнәк буйлы, кин җилкәле, таза беләкле Фоат: "Ун минут көтәбез дә утырышабыз. Фельдшер кызыбыз әле генә районнан кайтты. Хәзер килеп җитәр."—диде. Чыннан да, хуҗа сүзен әйтеп бетерүгә, аның фикерен хуплагандай ишек ачылды, роза чәчәге кебек балкып, бусагада Сәвия туташ пәйда булды. Бүлмә киңәеп киткәндәй, яшьләрнең йөзләренә якты нур сирпелгәндәй тоелды Әмиргә. Кыска җиңле ак кофтасы, кара итәге, кызыл ташлы колак тәнкәләре, муенындагы нечкә алтын чылбыры матурлык алиһәсен бизәп торалар. Егетләр ягына борылып, җиңелчә баш кагуы белән исәнләште дә, кызлар төркеменә кушылды. Бер ел эчендә авыл яшьләре белән танышып беткән бугай, бик җиңел аралашып китте. Әмир ничек утырганнарын, нәрсә ашаганнарын, ни-нәрсә сөйләгәннәрен хәтерләми диярлек. Зиһене чуалды, йөрәге урыныннан кубардай булып ярсыды. Яхшы түгел икәнен аңлаган хәлдә дә, күзләрен шәфкать туташының шампан шәрабы капкалагач алсулык типкән ак йөзеннән, кофтасын төртеп торган күкрәгеннән аера алмый интекте. "Каян килеп чыккан бу каһәр кызый безнең авылга, бөтен тынычлыгымны алды, ялымны тәмугка әйләндерде, болай ярамый",—дип үзен әрләп, тәртипкә чакыруның да файдасы тимәде. Кызып житкән мәҗлескә рухи азык кирәк була башлады. Фоат ялындырып тормыйча, сыздырып гармун уйнап җибәрде. Яшьләр Сәвиянең җырлавын сорый башладылар. Күрәсең, чибәрлегә өстенә кызның андый сәләте дә бардыр. Беркая язылмаган, әмма татар авылларында кабул ителгән гадәт буенча, Сәвия ялындырган булды. "Бәлки, безнең кунагыбыз, матрос җырлый торгандыр",—дигән булды (эт күңеле бер сөяк дигәндәй, егетнең эченә җылы керде, димәк, ул аны хәтерли, кешегә саный) һәм гармунга кушылып җырлап җибәрде. Тавышы матур, ягымлы дию генә Әмиргә аз, ярты дөреслек тоелды. Көмеш кыңгыраудай чыңлый, зәңгәр биеклекләргә алып менә, таң җиле кебек назлы, иркә иде аның тавышы. Кызның гади авыл җырлары Әмир күңелендә гаҗәеп нечкә хисләр уятты, берүк вакытта бәхет дингезенә дә, тирән упкынга да ташлады. Мишәр кызлары тупасрак була, аларга моң хас түгел дип ишеткәләгән иде Әмир. Нахак сүз икән. Шул мизгелдә егет үзенең чын-чынлап гашыйк булганлыгын аңлады. "Кашың кара, буең зифа, юк килмәгән җирләрен" сүзләре Сәвиягә нисбәтән чыгарылгандыр әле.

Кызны, Әмирнең сөенеченә, тагын сорап җырлаттылар. Аннан соң

биюләр, тансылар башланды. Әмир, башкалар чакырырга өлгергәнче дип, ашыга-кабалана шәфкать туташының каршысына килеп, кулын күкрәгенә куеп, баш ымы ясады. Калтырануын басарга тырышып, кулын кызның биленә салды, кулын кин учына алды, аның җыры белән соклануын әйтергә ашыкты. Тавышын, моңын, үзен чын сәхнәдәге кебек тотуын мактауга мөкиббән китмичә, кыз гади генә итеп:

—Бармагыгыз ничек? Төзәләме? Сызлап интектермиме?—дип белеште.

"Сыерыгыз көтүдән вакытында кайттымы"—кебегрәк бик кизү килеп чыкты.

—Бүген эшегезгә сугылган идем, бәйләтермен дип. Районга китеп өлгердегез.

Кыз биюдән туктап: "Йәле, күрсәтегез ярагызны, шешмәгәнме", дип, егетнең баш бармагын сул кулына алып, уны белән тикшерә үк башлады. Нәфис куллардан җылы дулкын агымы Әмиргә күчте, егеткә илләм рәхәт булып китте, ирексездән күзләрен йомып алды.

—Бармагыгыз төзәлә. Куркыныч нәрсә юк.

—Куркынычы йөрәккә күчте шул, аны кыса.

Кыз берни аңламаганга салышып, табиблык хезмәткәрләредәй җавап бирде.

—Нәрсә булды? Чәнчиме, ике яклап китереп кысамы, күкрәк турысыннан басамы?

—Әлегә үзем дә тәгаен әйтә алмыйм. Авыртуы хак,—диде егет.—Мәхәббәт түгелме икән дип куркам. Кыз көлеп: "безнең медпунктта анысыннан дару юк",—диде.

Шул арада музыка тынды. Ак танец игълан иттеләр. Әмир биюгә чакыру көткән арада, шәфкать туташы тотты да хуҗаны—Фоатны уртага чакырды.

Әмирнең жанында кайнаган хисләрне анлапмы, сизәргә теләмичәме, Сәвия үзен бик гади, барча егетләр белән тигез тотты. Егеткә көне буе тәкрарлап йөргән: "Рөхсәт итегез озата барырга, шунда бәгырьнең ничекләр авыртуын әйтермен"—җөмләсен кызның үтә күренмәле, алсу колакларына ирештерү өчен шактый тырышырга туры килде.

Шәфкать туташы мондый тәкъдимнәрдән, кинаяле, нөктәле сөйләшүләрдән туйган бугай.

—Сез дә, иптәш матрос, шул ук бәйләнчекләр, бер күрүдә гашыйк булучылар нәселеннән икән.

—Йөрәгем чын-чынлап әрни, сызлый, пошкыра...

Соңгы сүздән кыз, бит очларына ике ямьле чокырчык чыгарып, көлеп җибәрде, ләкин җавап фикерен сүзгә төрмәде.

Музыка тынды. Дингез кузгалыр алдыннан була торган тынлык урнашты. Яшьләрнең күбесе, шул исәптән Сәвия дә, "иртәгә эш көне", дип кайту ягын кайгырта башладылар. Әмир шәфкать туташы янына кеше азрак яктан килеп:

—Сөйләшкәнчә, мин Сезне озата барам,—дип пышылдады.

Кыз сөрмәле күзләрен аңа төбәп, йөзенә аптырау галәмәте җәеп:

—Вәгъдә биргәнемне хәтерләмим. Булса, вино йогынтысыдыр.

Әмма күз карашының елмаюлы самимилеге кызның ризалыгы турында сөйли иде. Егет шунда гына игътибар бирде: кызның сабыр тыныч холыклы булуына ишарә ясап, уң як кашы янәшәсендә генә мине бар икән. Кечтеки генә ходай бүләге болай да матур йөзенә аерым бер нәзакатьлек өстәп тора иде.

Урамга чыккач, егет кызны култыклап алырга булган иде, тегесе йомшак кына "кирәкмәс, авыл әле йокламый, миңа монда яшисе" диде. Сәвиянең йөрүе дә аккошларныкы шикелле матур, ыспай һәм горур икән. Күбәләктәй җиңел гәүдәсен озын, төз аяклары сизми дә диярлек. Сүзне ничек һәм

нәрсәдән башларга белми, акыллырак күренәсе иде дип уйланып барса да, зиһененә рәтле-башлы фикер килмәгәч, Әмир турысын ярып салырга ниятләде.

—Беләсезме, Сәвия, сезне күргәннән бирле бөтен тынычлыгымны җуйдым.

—Мин сезгә бернинди начарлык та эшләмәдем кебек. Бармагыгызны медицина таләпләренә китереп бәйләдем.

—Турысын әйтәм алайса. Язмыш сызган әйләнеч, сикәлтәле юллар аша сезне таптым. Сезнең өчен исән калдым.

—Уф аллам, куркыттыгыз,—диде кыз сүзне һаман шаяртуга борып.

—Мин сезгә бер күрүдә гашыйк булдым бугай.

—Бугаймы, әллә чынлапмы?—диде кыз кинаяле сөйләшү юлыннан чыгарга теләмичә.—Бугай—украинча үгез дигәнне аңлата кебек.

—Мине шундый тиле җан иясенә тиңләвегез түгелдер бит,—диде егет үпкәләгәнрәк тавыш белән. Рәнҗегән кеше гел хаклы. Әмир кызның кинәт ычкынган сүзләреннән унайсызланып калуыннан файдаланып, биюдәге кебек, кулын кызның эчкә тартылып торган биленә салды.

—Тынычланыгыз, матрос иптәш. Әйттем бит инде. Мин дәүләт эшендәге кеше. Урамда кочаклашып йөрү килешеп бетмәс. Бер соравым бар. Сезнең авылда барча егетләр шулай бер күрүдә канаты ялкынга эләккән күбәләктәй мәхәббәт утында яна башлыйлармы?

—Авылның барлык егетләре өчен мин җаваплы түгел. Алайса минем дә сезгә соравым бар.

—Рәхим итегез.

—Сезнең белән күпләр мәхәббәттә аңлаштымы инде, сер булмаса?—диде егет ирен читен аска төшереп.

—Шактый булды, егетем. Һәрхәлдә үз-үзенә кул салу дәрәҗәсенә җиткәннәрә (күбрәк тел белән инде) арасында сез беренче түгел. Танышырга сәбәп эзләп бармак кисүче сез беренче.

Әмир кызның сүзләрен җитдигә алды. Чигәсенә менгән ачудан колагы шаулый башлады, чәч төпләреннән тир бәреп чыкты.

—Сез... Сез нәрсә... Медпунктка килү өчен бармагын кискән дип уйлыйсызмы әллә? Балта бармакны умырып алганчы авылыбызда килмешәк... шундый тәрбиясез шәфкать туташы барын белми дә идем. Сезнең дөньяда барлыкны сизми калсам, дөньям тынычрак булыр иде—диде, нахакка рәнҗетелгән баладай авызын турсайтып, коңгырт күзләренең чакма ташыдай ялтырап алуын кыз күреп өлгермәде.

—Ярый, ярый, кызмагыз! Шаярып кына әйтәм. Кер күтәрмисез икән,—дип, егетнең кайнар көч бөркеп торган кулына кагылып алды.

—Кешенең авырткан сөяленә басарга сезгә кем рөхсәт итте?—дип, Әмир кызуын дәвам итте.

Кызый исә берни булмагандай, җыйнак авызын ерып, рәхәтләнеп көлүен белде. Кинәт ниндидер ашыгыч эше исенә төшкәндәй, җитдиләнеп китте.

—Әмир, сез миңа охшыйсыз. Бу—мәхәббәтме, түгелме—әйтә алмыйм. Шул сүзне әле берәүгә дә әйткәнем булмады. Хәзергә хушыгыз. Ике йорт аша безнеке. Әбием мине йокламыйча капка төбендә каршы ала.

—Күрсә ни. Кешенекен урламыйбыз ич. Карале, сез гел шулай соңарып кайтасызмы, төн уртасында, әбиегезне интектереп.

Кыз ай яктысында егеткә текәлеп, нидер күрергә теләгәндәй карады.

—Егеткәем, сез бик көнче кеше булырга охшыйсыз. Көнчеләр заманасы узды. Минем медицина хезмәткәре икәнне онытмагыз. Авылыгыз зур. Халык чирләми тормый.

Егет нәрсәнедер ачыкламакчы, яшерен-батырын йөрү килешми, безгә

барыбер бергә буласы дип фикерен дәвам иттермәкче иде, ул авызын ачкан арада чибәркәйнең ак кофтасы еракта иде инде.

"Әмир, сез мина ошыйсыз" дигән гыйбарәне, ярату-яратмауда шикшөбһәне ничек аңларга икән? Бу сүзне ул хәрби хезмәттәге затның, ялга кайткан кешенең күңелен күрү, озатып куйган өчен рәхмәт әйтү, ахыр чиктә, бәйләнчек чебеннән тизрәк котылу өчен генә әйтмәдеме икән?

Медпункт янында егетләр әрдәнә булып өелеп яталар дигән Наил фикере раска чыкса, кыз артыннан чапкынлап заяга вакытын гына уздырса? Зиһен ярдәме белән кызга мөнәсәбәтенә тәнкыйди караш булдырырга тырышса да, аяклары, гәүдәсе, теләге аны тыңламыйлар, һәммәсе берьюлы хис колларына әйләнәләр дә куялар. Хайвани тойгыларга бирешәсе түгел дип, рухын ныгытырга, эчке мөстәкыйльлеген сакларга ниятләсә дә, дөнья ул дигәнчә генә бармый икән шул, икенче көнне илаһи көч аны ихтыярсыздан кызыл кирпечтән салынган ихата кырына күтәреп алып килсә, ни күрсен, урындыкларның берсендә туры сызыклы олы кара кашлы, сөзгәк күзле, куе тубалдай бөдрә чәчле Ленар исемле укытучы егет бүлмәдә хуҗаларча җәелеп утыра. Әмир бүлмәгә килеп керүгә, кул биреп күреште дә, шәфкать туташы ягына борылып:

—Алайса, Сәвия, сөйләшкәнчә. Кабат исеңә төшереп тормыйм,—дип, әле генә үстерелә башлаган кәттә мыегы аша гына "сау булыгыз" сүзен кысып чыгарып, тиз-тиз генә атлап чыгып китте.

Әмир ни әйтергә, нәрсә юрарга белмичә урынында таптанган арада бүлмә хуҗасы ифрат ягымлы, җылы һәм үз итеп:

—Нәрсә әллә бармак һаман авыртамы? Ярагыз төзәлгән диярлек. Янәдән бәйләп торасы да юк.

—Йөрәк авыртуга түз алмыйча килгән идем дә, Сәвия, соңаргганмын шикелле.

—Йөрәккә карвалол бик килешә. Рәхим итегез,—дип кыз юри җәһәт кыланып, пыяла шкафтан кечкенә коңгырт шешәне алып, ача ук башлады.

Өйрәтелгән попугай кебек егет үзенекен тәкрарлады.

—Сонга калдым бугай. Карвалолны эчүчеләр табылган кебек. Минем йөрәк чирен дару гына баса алмас шул.

—Ленар абыйдан көнләшәсез түгелме? Көнләшерлек тә шул. Югары белемле. Явыз, усал үгез кебек сөздереп караулары ни тора, күлмәк төймәләренне ычкындыра башларсын,—диде кыз, юри Әмирне ирештереп.

—Ә миңа анын күзләре еланныкы төсле салкын тоелды,—дип җавап бирде Әмир. Бу мизгелдә ул юморны кабул итәрлек хәлдә түгел иде. Җен ачулары чыкты. Теге вакытта хохол малаена китереп бәргәндәге кебек бармаклары йодрыкка җыелды. Ярсуын баса алмыйча, тышка атылып чыкты. Анын артыннан ук кечкенә баскычта кыз күренде.

—Моряк иптәш, сез галәмәт кызу канлы кеше икәнсез. Кире керегез әле. Уйнап сөйләгәнне аңламадыгыз мыни? Ленар абый машинасы белән районга, больницага бер авыруымны алып барырга ризалашты.

—Уеннан уймак чыга, диләр. Мин ни уйларга белмим,—дип, мыгырданамыгырдана, Әмир кире бүлмәгә керде, кинәт кыюланып китеп, ак халатлы, ап-ак тәнле кызны кочагына алды. Мондый борылышны көтмәгән кыз әүвәл үзе дә егеткә бер мизгелгә генә елышып алды, әмма бик җәһәт исенә килеп, кайнар тәнне иплән кенә читкәрәк этәрде.

—Нишлисез сез? Тәрәзәләр ачык, мин эш урынында. Безне дөрес аңламаслар. Теләсәгез, кичен клубка килегез.

Шул көннән яшьләр кичләрен бергә уздыра торган булып киттеләр. Буш сүзләрдән башлап, яшәү мәгънәсе турында фәлсәфи темаларга күчеп, бу газаплы, авыр тормышта изге хис-мәхәббәт кенә бар, ул гына кешене

яшәтә, хайваннар дөньясыннан аерып куя кебек олы фикерләргә килеп чыгып, яшьләр йолдызлык үз канатына алган авылны аркылыга буйга инләделәр, хистән мәхрүм, салкын ай күзәтүендә йөрделәр дә йөрделәр. Кәлимәләрнең иң матурлары әйтелде, зифа рухи хисләр ургылды, вәгъдәләр бирелде. Кин текә маңгайлы, җәлпәк борынлы, юка иренле, алгарак чыгып торган иякле, моңсу күзле егеткә битараф булмаса да, кыз морякны тирәнгә җибәрмәде, хәер, Әмир үзе дә тәртип саклады, кызның чиядәй татлы иреннәрен тәмләүдән, кин учын билгә салудан узмады. Андый татлы мизгелләрдә кыз тәненең кайнарлыгы егеткә күчте. Гадәттә аз сүзле Әмир, теле озак ачылмыйча торып, кинәт сөйләп киткән һәм шул шатлыктан сүздән туймаган сабый кебек сөйләде дә сөйләде.

—Сәвия, син минем беренче һәм соңгы мәхәббәтем. Әлегәчә берәүгә дә эч серләремне сөйләгәнем юк. Энем Наил синең матурлык турында сөйләүгә үзеңне күргәнче үк гашыйк булдым.

—Бик ышанасы килә,—диде кыз моңсу гына.—Ирләр—йөрәген, хатын-кыз—тәнен тиз генә ачмаска тырыша. Ә син ихластан сөйлисең кебек. Бу газаплы кыска тормышны мәхәббәт кенә бизидер.

—Ә син минем күңел музыкамны аңларга тырыш, ул дингездәге ураган кебек астан күтәрелә. Син янымда басып торганда, мин утта пешкәндәй булам, аягыңа егыласым, итәк читеңне үбәсем килә. Мине мәҗнүнгә санап, көләрсең дип кенә тукталып калам. Вакыты белән шулай тиз кабынган мәхәббәтемнән куркам, үземнән шикләнәм, сине бар дөньядан көнләшәм.

Әмир йөрәгеннән кайнап чыккан сүзләрен тәлгәш-тәлгәш уеп салды. Гамәли хезмәт кешесе Сәвиягә егетнең сүзләре купшырак тоелса да, ул аңа ышанды, җанында җавап хисләре уянды. Шул мизгелләрдә Әмирнең йөрәге ашкынып типте, башы әйләнде, рухы гакылның теге ягына чыгып киткәндәй булды. Бу наз икесенә дә тансык иде. Күзләрендә сөю-сәгадәт нурлары балкыды.

Санаулы көннәр тиз үтә. Егет армия хезмәтенә китәсе вакытны әллә юри, әллә мәхәббәте белән артык мавыгып онытып ук җибәрә. Кичләрнең берсендә Әмир язылышып, ир белән хатын булырга тәкъдим кертә. Сәвия аның тәкъдимен шаяртуга борды.

—Ашыкмыйк әле, Әмир. Хезмәтеңне тәмамлап кайт. Булачак дошманыңны паспортыңа яздырырга ашыкма, ди торган иде укыганда фатирда торган апа. Муеныбызны ефәк богауга тыгарга өлгерербез.

—Нәрсә дигән сүз инде бу, матурым. Гаилә кешеләре бер-берсенә дошман булып чыгамы? Әти-әнием мисалында мин болай әйтмәс идем. Гаҗәп логика.

Шәфкать туташы фикерен ачыклап, тәфсилләп аңлатып торуны кирәк тапмады.

—Кайтканыңны өзелеп көтәрмен, ышан миңа.

Әмир барабан каккан кебек түбәгә шыбырдап яуган яңгырга уянып китте. Табигать биргән вәкаләтләренә дәгъва итеп, көз җәйне кысрыклый башлаган вакыт килеп җиткән иде. Ял срогының бүген соңгы көне, ягъни ул 30 нчы августта крейсерда булырга тиеш. Болай да теләр-теләмәс кенә авылына җибәргән капитан, бигрәк тә аның җил баклы, дошмани урынбасары—партия оешмасы секретаре, хезмәт срогын озынайтып үчне алачаклар, һәрхәлдә зинданга ук озатмасалар да, кәҗә маен чыгарачаклар. Әмир хәрбиләрчә бик тиз җыенды, мәгъшукасы, туганнары белән тиз генә саубуллашып, көнендә барып житәр кешедәй, чыгып та китте. Әтисе аны озата барырга алынды. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, район үзәгеннән тимер юл тукталышына бара торган автобуска соңга калдылар. Тегесе дә уч иткәндәй зәңгәр төтене белән урамны мул сасытып, күз алдында китеп

барды. Әмир ачыргаланып, үрле-кырлы сикерсә дә, урман тынычлыгы иңгән әтисе, фажига ясамыйча гына әйтеп куйды.

—Ходай ни язганны адәм баласы күрергә тиеш, улым. Мачтага асып куймаслар әле. Китү хәстәрен әүвәлрәк кайгыртасың булган. Гыйшык-мыйшык шулай итә шул, юк ихтыярыңны сындыра. Фани дөньяда һәр нәрсә өчен түлисе була.

Уйланып торгандай итте дә, фәлсәфи йомгагын хәйләкәр генә төгәлләп куйды: "Өйләндем, диярсең".

Кунарга әтисенең иске танышына керделәр. Түгәрәк битле, борын тишекләрен дә каплый алмаган мыеклы, баш түбәсе банка капкачы хәтле генә пләшле, гәүдәгә таза абзый аларны җылы каршылады. Әмирнең хәтеренә иң кереп калганы хуҗаның кәкре танавы булды. Сирәк очрый торган күренеш. Аны мең кеше арасыннан тиз генә танып була. Юлчылар чишенгән арада, кибет төенчекләре күтәреп үзенә караганда яшь, житез хәрәкәтле, төтен чәчле, ягымлы күкрәкле хатыны кайтып керде. Әтисе алып кергән шайтан суы янында, Әмирнең теле ачылып китте, әтисенең дустына хезмәтенә соңарып баруы, татар баласын өнәп бетермәүләре турында хискә тиярлек итеп бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Кемгә зарланасын белгән икән. Хуҗа кеше—Салих абзыйның хатыны районның загс бүлеге хуҗасы булып чыкты. Егетнең аяныч хәлен дөрес бәяләп, ярдәм итәргә алынды.

—Яратып йөргән кызың бармы?

Әмир Сәвияне ничек атарга белмичә:

—Яхшы танышым, дөресе, ошатып, озаткалаган ахирәтем бар.

—Шәп,—диде абзый пләш башын тирләгән учы белән сыпырып.— Авылыгыз кызымы?

—Юк, читтән килгән. Безнең авылда медсестра булып эшли.

Салих ни өчендер кызның фамилиясен сорарга итте. Матрос Сәвиянең фамилиясеннән хәбәрдар түгел иде. Саф мәхәббәт өчен аның әһәмияте юк иде шул. Әмир зур коңгырт күзләрен исерә башлаган әтисенә текәде.

—Әхмәдиева,—диде тегесе, бер тын белән үз фамилияләрен кысып чыгарды.

—Шаяртма әле, әти, соңарган өчен мине рәшәткә артына озатулары, хезмәт срогын озайтулары мөмкин.

Тегесе керфекләрен дә какмыйча, муенын катырып куйган килеш:

—Соң бит мин аны безнең фамилиягә кучкән килен дип саныйм инде. Кыз фамилиясе Ишбулатова кебек хәтеремдә калган.

Сүзгә кәкре ияк кушылып китте. Кызмача ирләр гадәттә мәрхәмәтле вә мәрәүвәтле була.

—Әгәренки, егетем, сине кыса башласалар, тот та телеграмма сук. Мин "Әхмәдиев фәлән-фәлән көнне язылышты" дип җавап бирермен. Капитанның фамилиясен әйтеп калдыр.

—Казаринов Илья Григорьевич.

—Булды, үзбәкләр әйтмешли, хуп мәйле. Хатынны гына ялганга күндерү җинел булмас. Бик принципиальный ул минем. Кәрәзле бал ярата. Жылы Оренбург шәле алып бир дип тенкәмә тия. Әйдәле, Гатаулла кордаш, чәркәләргә азрак кой әле шайтан суын.

Шулай сөйләшеп, бер-берсен макташып утыра торгач, таң сызылып, саба җиле килеп ишеккә шакыганын да сизми калдылар. Йокының юкә балыдай татлы булуы турында әйтеп тә торасы юк. Бу юлы Әмир автобуска өлгерсә дә, поездына соңарды. Крейсерга килеп житкәндә, ул нәкъ ун көнгә үз файдасына ялгышкан булып чыкты. Рапорт язарга да өлгермәде, Әхмәдиевнең сонга калуын гына көтеп утырган, үзгә шөгыле булмаган шикелле, аны берничә сәгатьтән капитанга чакырттылар.

Хужа бүлмәсенә курка-курка кереп, үкчәләрен шакы-шокы китереп, кулын түгәрәк кәпәченә тидереп алды.

—Матрос Әхмәдиев үз вазифаларын үтәргә килеп житте.

—Үтәмичә торсаң, ни булыр. Сонга калган өчен саботаж дигән матдә белән төрмәгә озатуга яисә хезмәт срогынны бер елга озайтуга ничегрәк карыйсың, матрос иптәш?—диде капитан ваемсыз гына, сигарасын пышнатуны дәвам итеп.

—Сонаруның гадәттән тыш житди сәбәбе бар, иптәш капитан.

—Туган илне саклаудан баш тартуга яисә кичегеп килүгә сәбәп үлем генә була ала,—диде капитан тавышына өркетү төсмере иңдерергә тырышып. Күзләренең энәләре белән егеткә кадалды.

—Мәеткә охшамагансың. Тазарып, матураеп киткәнсең, киресенчә.

—Мин гаилә кордым, өйләндем,—диде егет, загс хужасы иренең—кәкре танауның вәгъдәсен исенә төшереп.—Мәшәкате күп булды.

—Ярый, хуш. Раслау кәгазьләренне күрсәт, шуннан соң хәл итәрбез. Хөкем документларына карап чыгарырлар,—диде колгасар капитан, йомшара төшкәндәй булып, уң кулын алга сузды.

—Язылышу таныклыгымны үзем белән алмаган идем шул, иптәш капитан, югалыр дип куркып өйдә калдырдым,—диде матрос уңышлы ялганлавына шатланып һәм шул мизгелдә гүзәл Сәвияне рәсми хатыны буларак күз алдына китереп. Кинәт авызына жыелган төкерекне йотып жибәрде.

—Ун көнгә сонга калгансың. Шул вакыт, ягъни ун көн эчендә телеграмма белән өйләнүенне рәсми оешмалар расласын!

Мәкерле фикер эзләгәндәй, капитан олы башын селкетеп ала да, өстәп куя.

—Телеграмма печать белән беркетелгән булсын. Хатынынның биредә язылганнарны раслыйм дигән имзасы да торсын! Аңладыңмы?

Әмирнең килешүдән башка чарасы юк иде. Бик озаклап, тирләп-пешеп телеграмма әзерләде. Ишбулатованың да "мин Әхмәдиевнең хатыны" дигән имзасы булырга тиешлекне дә искәртте. Берсен әтисенә жибәрде, икенчесен загс хужасының иренә юллады. Жавапны шактый көтәргә туры килде. Сәвия әүвәл бу темага сөйләшүдән "бөтенләй баш тарта, аннан соң Әмир үзе шундый үтенеч белән үземә мөрәжәгать итсен, аның чынында нәрсә уйлаганын белүе кыен, буш сүздән тун тегеп булмый", дип, Гатаулла абзыйны кат-кат тискәре жавап белән борып жибәрә.

Әти кеше янәдән шәфкать туташы янына килә.

—Кызым, синнән мин Әхмәдиевнең законлы хатыны дигән жавап килмәсә, малайның киләчәге бик хөрти булачак. Аны төрмәгә ябачаклар. Безнең илдә төрмәгә эләккән кешенең киләчәге юк. Рәтле эшкә алмыйлар, үстермиләр. Син укыган кеше, боларын миннән яхшырак беләсең.

Гатаулла картның зиндан турындагы сүзләре кызга тәэсир итте бугай, дулкынланып, бармакларын аралаштырып алды, сул як күзе тартышып куйды. Абзый тагын да житдирәк тәкъдим кертә.

—Сәвия сенелем, ул сине ярата, бер елдан хезмәтен бетереп кайткач, тәки-тәк сина өйләнәчәк. Менә шул телеграммага раслау сүзенне әйтеп, кулыңны куй да, яшәргә безгә күченеп үк кил. Калганы минем забута. Иртәгә ат белән әйберләренне кереп алырмын,—дип ярып сала. "Әмиргә бал кашыгы белән кабып йотарлык хәләл жефет әзерләп куйсам, шатланыр гына. Дөрес, армиядән котылуга укырга китәм дигән анты бар. Белемнәрен бергә күтәрерләр".

—Аллага тапшырдык алайса, Гатаулла абзый. Жаваплылыкны өстегезгә аласыз. Улыгызны чыннан да яратам. Мин риза. Давай, кәгазегезне. Кая

кул куясы? Печатьне үзегез авыл советында суктырырсыз.

Мишәр кызы чая Сәвия иртәгә киләсе атны көтеп тормый, әйткән сүз—аткан ук дип, ике чемоданга сыйган бар мөлкәтен күтәреп, шул ук кичне Әхмәдиевләр йортына никахсыз килен булып төшә. Гатаулла улын "өйләндереп" куюы турында, телеграммалар белән үрсәләнеп йөреп, хатынын, Наилне кисәтергә өлгерми. Ярый әле үзе өйдә туры килә. Чемоданнарын күтәреп йортларына шәфкать туташы килеп кергәч, Хәдичә апа белән Наил өнсез калалар. Гатаулла хатасын төзәтергә ашыга.

—Онытып җибәрә язганмын. Карчык, Наил, кунакны каршы алыгыз! Бу кыз безнең килен, Әмирнең хатыны Сәвия булыр. Сезгә таныш кеше.

—Хәерле кич, исәнмесез,—ди шәфкать туташы, чемоданнарын җиргә куеп, салынып төшкән иреннәргә, ямшәеп калган битләргә игътибар итмичә.—Гатаулла абый, сөйләшкәнчә, мин Сезгә ышанып килеп җиттем. Әмирне сездә көтәргә булдым.

—Соң ни, бит... Әмир солдатка китте. Үзеннән башка ничек була инде ул,—ди ана кеше кулларын кая куярга, үзен ничек тотарга белмичә.

—Беләм, Хәдичә апа,—ди Сәвия.—Ул авылда чакта ук кулымны сораган, язышып, бергә торырга тәкъдим ясаган иде, мин ул вакытта икеләнеп тордым. Хәзер телеграмма аша хатыны булуымны сораган. Менә ул кәгазь. Мин аның тәкъдименә риза булдым, сөекле улыгызны төрмәдән коткарып калу өчен бу хәтәр адымны ясадым. Киләчәк язмышыбыз кайсы юлдан китәсен бер Алла гына белә. Чәчемне Әмир белән бәйләргә халь кылдым. Башка ир-егетләр борчымасын дип, Гатаулла абый тәкъдиме белән яшәргә сезгә күчеп килдем. Барыбер кешедә торам.

Наилгә нәрсә ана, диңгез тубыктан, үгез егылса—ит, арба ватылса утын. Ана исә шатланырга да, кайгырырга да белми, йөрәге туктап калгандай тоела.

Бу мажараның гаепле кешесе Гатаулла кулларын җил тегермәне канатлары кебек як-якка җәеп:

—Токле аягың белән килен,—дип, Сәвиянең чемоданнарын түргә кертеп куя. Гадәттә сүзгә саран умартачының бер ачылып китсә, бигрәк тә үзен йә гаепле, йә җаваплы сизсә, шактый озын-озак сөйли торган гадәте була. Ул бик тәмләп Әмирнең ифрат четерекле хәлгә эләгүе, Сәвия турында бик аз белсә дә, аның затлы нәселдән икәнлеге, бик яхшы укуы, табигатьтән килгән акылы турында тәмләп сөйли.

Ирне Алладан кала икенче илаһи зат, буйсынырга тиешле абруй санаган, чын татар хатыны Хәдичә түти, Гатаулла нотыгын тәмамлауга күзендәге аптырау катыш сыкрануны шатлыкка алыштырырга тырышып, Сәвиягә кытыршы кулларын суза.

Менә шулай шәфкать туташы язмыш уены беләнме, артык беркатлылыгы аркасындамы, киләчәген билгесезлеккә тапшырып, Әхмәдиевләр гаиләсе әгъзасы булып китә. Аның яңа өйдәге статусын беркем белми, мәгәр гаилә әгъзалары аны кабул итәләр, "кызым, апа" дип яратып эндәшәләр. Сәвия үзе дә ягымлы сөякле иде. Аның һөнәре дә Хәдичә апага ярап куйды. Хатын-кыз авырмыйча тормый, һич булмаса чирне уйлап таба.

Хәдичә апа кызлы булды. Иркәләнеп зарланды, көн аралаш кан басымын үлчәтте, рәхмәтен әйтергә онытмыйча, Сәвия биргән ак, соры төймәләрне авызына капкан булып, зәңгәрсу халатының зур кесәсенә шудыра торды.

Авылда чакта Сәвиягә башы-аягы белән гашыйк, анардан башка яши алмастай хис ихтыярына бирелгән Әмир "хатынлы" булу хәбәрен әүвәл шаярту кебегрәк кабул итә. Аннан чиксез шатлана. Берничә көннән сөенеч гаҗәпләнү катыш аптырау, югалып калу, ашыккан өчен эчтән әтисен әрләү белән алышына. "Ничек шулай килеп чыкты соң әле. Гатаулла карт үз

өстенә кубрәкне алган. Өйләнешү турындагы хәбәр капитанны алдау өчен генә кирәк икәнне, минем әле укыйсы барын онытттылармы барысы да? Мине әтием көчләп өйләндергән булып чыга түгелме соң? Язылышу, гаилә кору турында сүз кузгалткач, Сәвия ничек кыланды, ашыгуның нигезендә берәр могҗиза йә мәкер ятмыймы? Медпункт тирәсендә сырпаланып алгандыр да, мина кияүгә чыгарга булгандыр. Черт с два, моряк абзан андый арзанлы капкынга эләкмәс". Шул уйларыннан, үзе күз алдына бастырган манзарадан эсселе-суыклы булып китте. Күңелен билгесез көчкә үпкә, каргыш, әче өзгәләнү кебек хисләр биләде. Шикләнү тойгысын куарга тырышты. Шул мизгелдә кызның татлы иреннәрен, яңа күпереп чыккан камыр кебек йомшак, хуш исле тәнен искә төшереп, калтыранып куйды, теләге уянды. Кызны чын-чынлап ярата бит ул. Нигә икеләнеп торырга? Үзе теләп безгә күчкән. Ул Сәвиянең үзенә, әти-әнисенә аерым-аерым хат язды, энесенә җингәсенә күз-колак булырга боерды.

Вакыт үз мәңгелек шөгылендә, һәркем аша үтә дә тора. Гел шомартып, алдап яшәгән хөкүмәт бу юлы сүзендә торды, хәрби хезмәткәрләрне вакытында, хәтта бераз алданрак өйләренә таратты. Шулар арасында тизрәк туган авылына кайтып сөеклесен кочагына алу хыялы белән шашынган Әмир дә бар иде. Ул район үзәгенә, дөресрәге, автобус станциясенә килеп төште. Туган авылы тарафларына кайтучы машина белешә башлады.

Килгән-киткән йөк, берән-сәрән күренгәләгән җиңел машиналарны белештерә торгач, Әмирнең күзенә көлтә чәчле таза ир гәүдәсе чалынды, аны каядыр күргәндәй тоелды, хәтерендә таныш-белешләрен барлаган арада "бөдрә чәч" якынрак килеп, ана үзе эндәште.

—Ба, безнең авыл егете—моряк дисәм, ялгышмыйм кебек. Сәлам, сәлам,—дип ике кулын берьюлы Әмиргә сузды. Бәхетле мосафир рәхәтләнеп күреште.

—Авылга кайтышмы, бөтенләйгәме? Хезмәт срогынны тутырдыңмы диюем.

Бөдрә чәче бүрек кигәндәй күпереп торган кешенең исеме келт итеп исенә төште: укытучы Ленар бит.

—Әйе, бөтенләйгә кайтуым. Безнең авыл ягына баручы транспорт эзләп йөрүем.

—Ә мин үземнең иске "Москвич"ым белән. Теләсәң, алып кайтам. Мәктәп эшләре белән РОНОга килгән идем. Берәрсе авылга кайтырга аптырап йөрми микән дип, вокзалга кагылдым. Бәхетен бар икән, егет,—дип сөйләнә-сөйләнә, Әмирнең бер чемоданын кулына алып, читтәрәк торган машинасы кырына алып китте.

Чын-чынлап куанган, бәхетле йолдыз астында тууына ышана башлаган Әмир йөртүченең ничектер күңелен табу турында баш ватты. Укытучы кеше авылдашыннан акча алмас, майка бүләк итсәң, житди булмас, башка кызыклы нәрсәсе юк та кебек. Әтисенә дип алган коньягы бар ич. Гатаулла карт ул эчемлекне бик өнәми. Сугыштан соңгы елларда халыкның тенкәсенә тигән кандала исе килә, ди. Хакыйкый ачы балы яшәсен.

Авылдашлар районны калдырып, газиз туган якларына элдерәләр. Җәйге ямьле көн. Кояш Миләшле урманы артына төшү җаен алган. Әмир колхоз, мәктәп хәлләрен сораштыра, күргән-белгән кешеләренең язмышы белән кызыксына. Бөдрә чәч ачык, күңелле адәм икән. Сорауларга бик теләп, тәфсилле җаваплар бирә, авыллары күренеп торган кәҗәләр тавына житкәч, куаклар ышыгына машинасын куеп, Ленар очрашуны билгеләп үтәргә тәкъдим кертә, ул гына да түгел капот өстенә бер ярты аракы, ипи, сыр кебек кабымлыклар да чыгарып куя. Әмир, бер дә кызганмыйча, биш йолдызлы коньягын шуларга куша. Берәр чәркәне күтәреп куйгач, Ленар

күптән күрешмәгән дустын очраткандай, Әмирне тирән серләре уртасына алып кереп китә. Укытучы егет ярты ел элек өйләнеп караган икән дә, гаиләләре оешып житмәс борын таркалган. Бердән, күрше авылдан алып кайткан хәләл жефете ару кыз булып чыкмаган, икенчедән, үжәт, үзсүзле, гел үз туганнарын кайгырта торган хатын икән. Элеккеге хәләл жефетенә тискәре бәя биргән укытучы егет, чәркәләрне тикшереп торуны онытмыйча, гомумән хатын-кыз затына бәя бирүгә күчә:

—Элеккеге ышанычлы, ирнең авызына карап, баш өсте дип, анын һәр теләген үтәп, буйсынып яши торган хатынны хәзер көндез чыра яндырып эзләсән дә, таба алмассын, юк алар. Кая киттеләр шундый затлы татар хатыннары дисең инде, Әмир дус. Аларны Совет власте ирләр белән бер үк хокук биреп бозып, азындырып бетерде. Тынламауларына, каршы әйтүләренә генә чыдар идең әле, женси яктан азынуларына түзәрлек түгел. Элек ирләр хатын-кызга бәйләнсә, хәзер озын чәчләр үзләре ирләрне аулый, пәрәвезләренә эләктерү жаен карый.

Йөртүченең күп сөйләвен якын итүгә юрап, килешеп, сүзгә керешеп китмичә, "әйе, шул", "шулайрак шул" кебек гомуми сүзләрдән узмаган Әмир, тиешле тапкан жөмләсен кыстырып куярга булды.

—Мин андый азгын хатыннар портовый шәһәрләрдә генә очрыйлар дип уйлый идем. Ул калаларда женси азгынлыкның чәчәк атуы аңлашыла. Таза, яшь, айлар буена су өстендә интеккән, назга сусаган ирләрне эзләп, сез әйткән бозык, тотнаксыз озын чәчләр шул якка агыла. Хатын-кызны сагынган ирләр акчасын кызганмый.

—Татар авыллары да портовый шәһәрләрдән калышмый,—дип, бөдрә чәч Әмирнең сүзен хуплый.

—Әллә андыйлар безнең... үтә күренмәле авылыбызда да очраштыргалыйлармы? Мин дүрт ел флотта хезмәт иткән арада халык шулай үзгәреп өлгерде микәнни?—дип Әмир йөзенә гажәпләнү, аптырау төсмере чыгарырга тырышып сорап куя.

Ленар әйтимме икән, юкмы икән дип уйланып-борчылып торгандай була, кинәш-табыш сорагандай озын бармакларын куе бөдрә чәченә батырып ала.

—Кәефенне бер дә бозасым килмәгән иде. Дуслар арасында сер булырга тиеш түгел. Без инде дуслар бит, ийеме? Авыр булса да дөресен әйтсәм, үпкәләмә?!

—Йә, әйт, әйт,—ди Әмир кигәвен тешләгән аттай пырдымсызланып.

—Синең кызыннымы... хатыныңнымы чит ирләр белән күргәләгәннәр, шулай ук армиядән кайткан бозау Илгизе белән чуала дип ишеткән идем. Колхозда бригадир булып эшли, бар нәрсә анын кулында. Мотоциклда гына йөри. Аннан килеп, үзең беләсең, ачык капкага кем кермәс!

Бу сүзләр әле генә сөеклесен кочагына алу турында хыялланган Әмирнең бөтен өметләрен чәлпәрәмә китерде: башына күсәк белән китереп тондыргандай булды, күз аллары караңгыланды, шөбһә зиһенен чуалтты, Ленарның гөманын шик астына алырга зиһене, көче житмәде. Күзләренә мең төрле сорау, ышану-ышанмау, икеләнү, әрнү, газап, сагыш кебек хисләр берьюлы бәреп чыкты.

Димәк, Әмирнең бәхетле гаилә тормышы турындагы татлы хыяллары бәллүр савыт төсле ватылды, ышанычы жимерелде, яшәүнең яме, тәме бетте, йолдызы сүнде. Кайнар хисләргә төрелгән, гөнаһсыз мәхәббәте балкыган көннәр үткәндә калган икән, аны сатканнар, алыштырганнар, жир суалчаны төсле изгәннәр.

Бөдрә чәч сүзләренең нәтижәсен көткәндәй Әмирнең йөзенә текәлеп карады, ә үзе иреннәрендә шайтан сыбызгы сайратты, күзләрендә зәһәр

ялкыннар биеде. Әмир боларның берсен дә сизәрлек, анларлык хәлдә түгел, рухы зиһененең аргы ягында иде.

Акылына килеп, Ленарга күтәрелеп караса, Әмир ихласлы, ялганны күтәрми торган, балаларныкыдай самими күзләрне күрде. Алар алдый алмый, аларга ышанмый мөмкин түгел иде. Шуннан соң исә Ленарның күзендә хәйләкәр төлке балалары биеде.

Ленар Әмирдәге кискен үзгәрешне күреп, сизеп, бу бәндә мина сугып җибәрә күрмәсен дип шөлләп куйды. Берни белмәгән гөнаһсыз Әмир кулын пычратмады, тик хәбәрченең якасыннан алып, "әгәренки бу сүзләрең гайбәт, яла икән, үпкәләштән булмасын", дип кенә әйтә алды.

Тагын эчтеләр. Әмирне аракы да, аңа алмашка килгән коньяк та алмады. Ленар, мәкер җәтмәсен үрә барып, кичке якта медпункттан башка ирләрнең дә кереп чыккалаганын күргәннәр, шунда җыештыручы Нурҗиһан апа күрше авыл ветврачының шул тирәдә чуалганы турында сөйләгән дип, лепелдәвен дәвам итте.

—Киттек, житәр,—диде Әмир үзе өчен үк ят тавыш белән. Егетнең тизрәк өйгә кайтасы, Сәвиянең күзенә карап, араларын өзәсе, бу газаплы-сагышлы халәттән котыласы килде. Калган юлны сөйләшмичә уздылар. Һәркайсының үз кайгысы, үз хәсрәте иде.

Менә туган өй бинасы, капкасы күренә. Әмирнең күңелендә гадәттә туган йорт янына якынлашканда кабына торган шатлык хисенә урын юк. Чөнки анда чит-ят кеше, фәхеш ханым яши. Аның кем икәнен сизмичә, ничек аны яратып, иркәләп, бәгырем, мәк чәчәгем, дип өзгәләнеп йөрде икән?! Оятсыз хатын тозсыз аш кебек шул. Ахмаклыкның чиге юк диләр, дөрестер. Капка янында чемоданнарын алып, төшеп калды. Ул үзенең кайту вакытын якынча гына әйткән иде, шуңар да аны, өйдә астыртын гына әзерлек барса да, берәү дә капка төбендә каршы алмады. Келә хәбәренә әнисе белән Сәвия йөгереп чыктылар. Капылт кайтып төшсә дә, көткәннәр икән. Газиз һәм иң ышанычлы җан иясе әнисен кочагына алгач, Әмирнең бөтен тәне буенча җылы хис йөгерде. Муенына ташланырга әзер, очрашу шатлыгыннан битенә алсулык йөгергән Сәвия ягына борылып, коры гына:

—Исәнмесез,—дип уң кулын сузды. Әмирнең күзләрендә, йөзендә шәфкать нуры, назга, иркәләүгә урын юк иде. Аны-моны сизмәгән Сәвия "иренең" кулын учларына алып, ул ятканча сыйпарга уйлаган иде, Әмир кулын җәһәт һәм шактый дорфа тартып алып, әнисе ягына борылды:

—Әти эштәме әле? Наил кайда бутала?

Сораулар: "Төркиядә төрекләр яшиме?" кебек кизү белешүләр иде. Әмирне беркем борчымады, берәү дә кызыксындырмады. Аның өчен дөнья, тереклек мәгънәсез боламык иде.

—Нишләп әле йортта басып торабыз. Әйдәгез, өйгә керик, камырым да әзер. Хәзер килен белән өстәлне өлгертербез. Чумбы, кит әле моннан, аяк астында буталма.

Әнисеннән ояла, яхшысынмый торгандыр дип фаразлап, берни аңламаган кыз Әмирнең кечкенәрәк чемоданын эләктереп, аякларының гер асып куйгандай, авыраеп китүләрен тоеп, өйгә юнәлде.

Шул арада сөенечне сизгәндәй әтисе, аның артыннан ук Наил атылып кайтып керде, дөнья белән аш өстәле тәмам түгәрәкләнде. Тик түгәрәк җир шарының бер чите убылып төшкән, бар гаеп Әмирдә иде. "Хәләл иренең" тотышында, үзенә нисбәтән сәерлек сизсә дә, әлегә берни аңламаган, ата-анадан гадәти читсенү, татар тыйнаклыгы дип фаразлаган Сәвиянең Әмир янындагы урындыкка килеп утыруы булды, тегесе өстәлнең аргы ягындагы эскәмиягә чыгып чүмәште һәм "сезнең исәнлеккә, күрешү хөрмәтенә" кебек сүзләрне генә теш арасыннан кысып чыгарып, чәркә

арты чәркә ачы бал чөмерә башлады. Бер ел элек егетләр асылы, инсафлы, зыялы Әмирне алыштырып җибәргәннәр, миен, йөрәген башка якка әйләндереп куйганнар диярсең. "Төннәр ката мәңгелек мәхәббәте, бер күрүдә Фәрһад, Мәҗнүннәр кебек акылдан язарлык кимәлдә гашыйк булуы, мәңге бергә булырга, бәхетле гаилә вәгъдә итеп, таң сандугачыннан уздырып сайраган егет шулмы соң, әллә үзем ычкына башладыммы? Мөгаен, тагын да көчлерәк мәхәббәте Сәвияне аның йөрәгеннән кысрыклап чыгаргандыр, ә ул дивана сарык юк-бар телеграммаларга, Гатаулла картның тасма теленә ышанып, кичләрен клубка чыкмыйча, имеш-мимешкә урын калдырмыйча, йомыкый кыз хәлендә яшәп, ярык тагарак янында утырып калды түгелме?"

Аш-судан соң, бернидән хәбәрдар булмаган, улыннан күзен ала алмаган ана, риясыз гадилек белән:

—Балалар, сезгә йокы урынын алгы бүлмәгә җәям. Мунчам да өлгерә, теләсәгез, юынып чыга аласыз. Әмир юлда бик талчыкмаган булса. Үзегезгә карагыз. Наил, син безнең белән, олы бүлмәдә ятарсың.

Зиһененнән бәйләнчек чебен кебек хыянәт сүзе китмәгән Әмир, кискен рәвештә урыныннан тора-торышка:

—Мин сарай башында, печәнлектә йоклыйм,—дип бер мендәр, юрган күтәреп, туктатып, тотып калмасыннар дигәндәй ашыга-ашыга чыгып та китте. Өйдә киеренке тынлык урнашты. Барысына ифрат кыен булып китте. Һәркем үзен гаепле санады. Яшьләр арасыннан үткән кара мәче өйдәгеләрне телсез калдырды. Гатаулла абзый белән Наил Әмир артыннан чыгып киттеләр. Иң кыены, әлбәттә, килмешәк килен Сәвиягә иде. Иреннәре ачудан, рәнҗүдән дерелди, кашлары тартыша, бит алмалары тимгелле кызыллыкка баткан шәфкать туташы бүген зөфаф төне уздырырга тиешле бүлмәдән чемоданнарын алып чыкты да, идәнгә ташлап, шунда ашык-пошык туйга дип тектергән күлмәкләрен, башка киемнәрен ничек туры килсә, шулай тутыра башлады. Ул барысын аңлады. Әмир белән борчаклары пешмәячәк. "Вәт, дура, набитая дура, умартачы картның сүзенә, үгетенә ышанып үземне рисвай иттем, хурлыкка калдырдым". Берни аңламаган, аптырашта калган ана, илереп:

—Нәрсә булды, кызым, сезгә? Ни дип тиләрәсез?

—Мина берни булмады, Хәдичә апа. Сезне анам кебек күреп ихтирам иттем. Улыгызның тәмле теленә ышанып, аны җәзадан алып калыйм дип, үземне төрмәгә бикләп, яшьлегемне әрәм итеп җилкуарыгызны көттем. Җаныма, тәнемә түгел, кулыма да ир-ат затын якын китермәдем. Үземне Әмир өчен саклавым иде. Мин, тиле, мескен бер бәндә булып калдым. Газизегез барысы өчен рәхмәтне өздереп әйтте. Хушыгыз,—дип, кулларын кая куярга белми аптырап, тораташтай басып торган ананың иненә нәфис бармакларының очын тидереп алды да, шул ук ике чемоданын тотып, тол хатын толымнарын сүтеп җилкәсенә салган кара төнгә чыгып югалды. Сагыш, үкенечкә күчеп, ачы төер булып бугазына тыгылды, капканы япкач, тозлы яшьләр күзеннән битенә коелды. "Килен"нең соңгы сәламы капка келәсенең ыңгырашып, гадәттәгедән ямьсезрәк тавыш чыгарып урынына утыруы булды. Бу йорт Сәвиядәй чибәр кызны беркайчан да күрмәячәк иде.

Күңелләре белән фаҗигане сизенсәләр дә, әле нәрсәнедер төзәтә алуга ышанган, тәртә дулап ат булмас, дип мәсьәләне гадиләштергән, Сәвиянең җәһәт кенә җыенып бөтенләйгә чыгып китүен күз алдына китерә алмаган Гатаулла белән Наил кесә тулы өмет белән Әмир янына күтәреләләр. Төннең салкынча булуына карамастан, өстенә ябынмаган, матрос киемнәрендә шабыр тирдә яткан егетнең күзләре хәтәр ялтырый. Ата кеше сорап тормыйча сүз ала:

—Ни кылануың бу, улым? Мин берни аңламыйм? Нәрсә житми сиңа,

ник рәнҗетәсең сабыйны? Үзенне өтермәдән алып калган, мина ышанып безгә күчеп килгән, әниенне, мине, Наилне якын күргән Сәвияне нинди намусын җитеп рәнҗетәсең?

Яна туа килгән гаилә өчен үзен җаваплы сизгән Гатаулла астына утын өстәлә торган кайнаган казан кебек кызганнан кыза барды.—Исеменне теленнән төшермичә, бисмилла урынына кабатлап көтте, яшьләр белән аралашмады, беркая чыкмады, никахлы тол хатын кебек, әниенне тәрбияләп яшәде. Үзеннең соравың буенча, ул телеграммага кул куйды, ЗАГС кәгазе өчен кәкре танау мине күпме сауды, әле балы, әле акчасы, тактасы, хатынына кыйммәтле шәле... Барысын да үзем генә беләм.

—Сез берни белмисез,—диде Әмир, торып утырып.—Өеңдәге хәлне күршеңнән сора икән, ачык авызлар, бер кызны да саклый алмагансыз.

—Нәрсә булган Сәвиягә, нинди гөнаһысы бар?

—Ул башка ирләр белән чуалган, шактыен куенына алган.

—Дөрес түгел абыем, чеп-чи ялган, гайбәт. Үзем шаһит, Сәвия апа берәү белән дә очрашмады, чыгып та йөрмәде,—диде Наил ихластан.

—Сезне алдау аңа берни тормаган. Ул төннәрен авырулар янына барам дип чыгып киткәләгән. Аның кая барганын кем белгән. Үзенә бер бина, анда теләсә нишли ала. Күргән кешеләр сөйләде, сүз тәмам,—дип, Әмир арты белән үк борылып ятты.

—Аз булса да, үз акылың булсын икән. Адәмне сүз, дөньяны җил боза, диләр. Дөрес икән,—дип сүзен бу юлы ерактанрак башлады Гатаулла.—Нахакка рәнҗетәсең кеше баласын. Сине өзелеп көтте, рәхмәтең шул булдымы. Мондый багалмасыдай чибәр кызны гомереңдә күрәсен юк. Нарасыйны кыерсытып, үзен дә бәхеткә тармассың. Болай кылансаң, ул гафу итмәс, яшьлеге, чибәрлеге бар, үз горурлыгы үзенә җиткән. Иң кыен, мескен хәлдә калган кеше мин, ит яхшылык, көт явызлык,—дип сөйләнә-сөйләнә, лапас башыннан төшеп үк китте.

Әмир, бик теләсә дә, дөрес карар кабул итәрлек хәлдә түгел иде. Ул Ленардан миенә сеңгән гайбәт кырыннан чыга алмыйча:

—Утсыз төтен чыкмый. Берәүне дә күрәсем, яшисем килми,—дип йодрыклары белән печәнне изә башлады.

Энесе Наил абыйсын ялгыз калдырмаска булды, ялварулы тавыш белән үз дәлилләрен Сәвия апасы файдасына китерә-китерә печәнлектә йоклап киткәнен сизми дә калды. Араларына алдан уйланылган мәкер кермәгән булса, Әмир адәм балаларын күпме фаҗигагә алып килгән көнчелек хисенә үзен җиңәргә, кешелеген юкка чыгарырга ирек куймаса, бүген үз гомерләрендә иң татлы таңнарны аттырасы яшьләр һәркайсы үз уен уйлап, язмышны каһәрләп йокысыз төн уздырдылар. Үз гомерләрендә иң ачы булып күңелләренә кереп калган ачы төнне керфекләрен кушмый каршыладылар. Бәхетсезлекләренең башы иде бу.

Сәвия элек яшәгән әбисенә кайтып егылды. Яшь белгечләрне эшкә җибәргәндә ерак Сармабаш авылын сайлавына үкенде, "Әй, Ходаем, ник мине хәсрәт утларына салдың, кешелек алдында рисвай иттең",—дип, чәчрәп чыккан яшьләренә буылып, талымсыз төшләр күрә-күрә иртәнге якта гына черем итеп алды.

Әмир күңеле, сүрелмәгән хисе белән Сәвиянең кире кайтуын теләде, үзен ярым йокы баскан килеш аның белән саташты, гафу үтенде, өнендә шуны теләде, әмма миенә сеңгән рәнҗүен җиңә алмады, гаепне каршы яктан эзләде. Берни аңламаган, хәбәрдар булмаган Сәвия дорфалыгы, үзен тәрбиясез тотуы, рәхмәтле була белмәве өчен егетнең алдына килеп тезләнүен теләде, шул хакта хыялланды. Ике яшь йөрәк бер-берсен көтеп, җитди адымны каршы якның ясавына өметләнеп, гомерлек афәтне сизенеп,

аны булдырмау чарасын күрергә кодрәтләре житмичә, һәлакәт упкынының туймас авызына тәгәрәделәр.

Тормозы тотмыйча таудан аска киткән машинаны туктатуы кыен булган шикелле, Әмир белән Сәвия мәхәббәте сары сагыш юлын үтеп, кара нәфрәткә, бер-берсен күрә алмауга күчте. Тирә-юньдә бөтен дөньясы үзгәрде. Үзен Сәвия каршында гаепле сизгән Гатаулла карт эшендә, кортлары янында тоткарлануны артыграк күрде, Наил житдиләнде, абыйсы белән шаярып түгел, гомумән сөйләшмәс булды. Улын күгелжем күзләренең нурында коендырудан ләззәт тапкан Хәдичә апа, елмаймый, көлми, ачуын маллардан ала торган булды. Дөрес, ул үз вакытында өстәлен әзерләп, киемнәрен юып, мунчасын ягып торса да, Әмир әнисенең үзенә нисбәтән кискен үзгәрүен тоярга мәжбүр иде. Улын фанатикларча ярату битарафлык белән алышынды. Әнисенең елап туктагач, көрсенеп йөрүенә түзә алмаган Әмир:

—Житте сиңа үз-үзеңне бетереп йөрергә, гаеп Сәвиядә, котә белмәгән,— дип әйтеп салды.

—Улым, син андый матур, унган, ышанычлы кызны беркайчан таба алмаячаксың. Безнең нәселгә Алла бүләге иде ул.

Бик авырлык белән, сыкранып булса да, тавышына көр интонация иңдерергә тырышып, Әмир:

—Бер дә борчылма, әни, үзенә аннан да гүзәлрәк Казан килене алып кайтырмын,—дип әнисен тынычландырырга тырышты.

—Авыл халкы алдында рисвай иттең. Хурлыгын, языгын кая  куярсың. Көтүдән ялгыш кергән сарыкны йорттан куып чыгарган кебек, мескенкәемне кара төндә өеңнән чыгарып жибәр инде. Сине мәкерле дошман бутаган, әни әйткән иде, диярсең. Күр дә тор! Явызлык бер ачылыр. Тик язмышыгызны гына төзәтә алмассыз! Соң булыр. Ахырзаман житә торгандыр инде...

Аш-су бүлмәсе белән маллар арасында йөреп, бер караурда бик гади күренгән Хәдичә ханым тормышны, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне шактый тирән аңлавын күрсәтте. Теләсә кайсы адәм баласында кирәк вакытта философ уяныргa мөмкин икән.

—Көнчелек—иң начар гадәтләрнең берсе. Чөнки андый кешенең каны бозыла, ул хатынынннан түгел, ә үзеннән шикләнә. Андый кешеләрне еш кына бәхет әйләнеп уза. Безнең нәселдә атаң ягыннан да көнчелек галәмәте шулкадәр яман тамыр үрләткән зат юк иде кебек. Берәр бабаң шундый булгандыр инде,— дип, Әмирне аптыраштa калдырып, кара бозауны сарайга куа башлады.

Әмир, туңу катыш кызышып, көннәр буе печәнлектә ятты. Аракы пары жинеп йокымсыраган арада теге вакыттагы кебек өстенә ак башлы, ачулы дулкыннар сикергәндәй булды. Куркып уянып киткән мәлдә тормыш ана мәгънәсез, кирәксез тоелды, аның үләсе, һич югында "Калинин" крейсерына китәсе килде.

Үз гаебен аңлый алмаган Әмир әүвәл өендә, нигездә хәл белгән булып, бушлай баш төзәтү хыялы белән йөргән ялкау, хөрәсән ир-ат даирәсендә буталды, аннан үзен кулга алып, университетка керү имтиханнарына әзерләнә башлады, монда китаплар житешми дигән сылтау белән Казан тарафларына чыгып китте.

Хәдичә апа Сәвияне сагынганда, "киленле" чордан сакланып калган дару төймәләрен халат кесәсеннән түр өстәленә бушатып, шуларны кат-кат санап утыруда юаныч тапты, әйтерсең лә,  алар жанлы һәм шәфкать туташын алыштыра алалар.

Сәвиягә килгәндә, аның өчен яраткан, тынгысыз хезмәте саклану,

онытылу чарасы булды. Көйсез әбиләре, чирле бабайлары янына, ялгызлыктан, хәсрәттән качып, көненә икешәр-өчәр тапкыр житез аякларында очып килеп китә торган булды. Тик күптән түгел кешеләре газиз йорт яныннан үтәргә туры килгәндә, урамның каршы ягына чыгып, күзләрен чатырдатып йомып, жәһәт кенә узып китәргә тырышты.

Ә вакыт туктапып торуны белми, алга хәрәкәтен дәвам итә, шул арада бер яралар төзәлсә, икенчеләре ачыла.

Ишеккә көз шакый башлаган көннәрнең берсендә, район үзәгенә барып, дарулар алып кайтасы бар, бәлки, шунда үзенә эш урыны да белешер дип уйланып утырганда, Сәвиянең ниятеннән хәбәрдар булгандай, бүлмәгә тирләп-пешеп Ленар килеп керә.

—Сәвия Идрисовна, исәнмесез. Сезгә йомышым да юк кебек, мин райүзәккә чыгып китәргә торам, анда берәр эшегез юкмы? Башкарып кайтырмын.—Бөдрә чәчнең жыештыручы апага күчтәнәчләр биреп, шәфкать туташының һәр адымыннан хәбәрдар булуын башына да китермәгән кызый, риясыз гына:

—Эш дигәннән, үзем автобуска чыгарга торам. Йомышларым бик күп жыелган,—ди.

Шуны гына көткәндәй, егет кулларын бөркет канатларыдай як-якка жәеп:

—Киттек минем белән. Медсестрабызны рәхәтләнеп алып та барам, алып та кайтам. Бер-беребезгә ихластан ярдәм итү—жир йөзендә яшәүчеләрнең бурычы,—дип, Сәвия юлга әзерләнеп беткәнче сайрый.

Икәүләп барасыларын белгән диярсең, авылдашлары күзәтеп күз нурларын әрәм итмәсен дип, Ленар машинасын урам якка түгел, ә бинаның кеше йөрми торган почмагына куйган. Хужа кеше, итагатьлелек вә зыялылык үрнәге күрсәтеп, ишекне үзе ачты, фәрештә кереп утыргач, чабу кысылмасын дигән булып, кызның итәген рәтләп, ин башын жинелчә сыйпап алырга онытмыйча, "барысы да о'кэй, тәртип булыр" дип, сөйләнә-сөйләнә машинасын кабызды.

Юл буенча бөдрә чәч мәктәп хәлләре, укучыларның елдан-ел дәресләргә начаррак әзерләнүләре турында сөйләп, мәзәкләр кыстырып куярга да онытмыйча, кызның күңелен күреп, көлдереп барды. Тел байлыгын биргән икән табигать үзенә. Тирән күзләре иркәләү, яраргa тырышу, әйтелмәгән мон бөркеп тора. Төп сүзенә, серенә керешәсе килеп, дулкынланганы, интеккәне сизелә.

—Мина ниндидер житдирәк хәбәр әйтмәкче буласыз кебек... иптәш,—ди кыз, жинелчә генә аның терсәгенә орынып.

—Дөресен әйтсәм үпкәләрсез, мин гаепле булырмын дип куркам.

—Мин инде язмышның төрле борылышларына әзер,—ди кыз көрсенеп.—Әйтегез, мин туры сүзгә мохтаж.

—Әмирнең үзен сәер тотышының серенә төшендегезме?

—Хикмәт тә шунда. Мин берни аңламыйм. Баш миенә берәр нәрсә булганмы?

—Юк, акылы үз урынында. Тик... хезмәт иткән шәһәрендә үлепләр гашыйк булган. Һәм өйләнгән, бу көннәрдә хатыны кайтып төшәргә тиеш, ди. Сина мөнәсәбәттә шулай кылануы, кара янып, эчеп йөрүе ике ут арасында калуы белән жинел анлатыла. Мина хатынының ифрат матурлыгы, күкрәк шәрифләренең ымсындыргыч муллыгы турында юл буе такылдап кайтып, колакларымны чынлатып бетерде. Мин үзем гайбәтне, кеше тормышына кагылуны яратмыйм.

Ленар алдындагы кечкенә тәрәзәдән сүзләренең туташка тәэсирен яшертен-орынтын гына күзәтеп барды. Машина эчендә давыл алдыннан

була торган киеренке тынлык урнашты. Гыйнвар кары кебек агарынып киткән кыз куллары белән битен каплады. Бөдрә чәч йөзенә курку галәмәте чыгарды, машинасын шып итеп туктатты.

—Мина, бәлки, бу хакта әйтәсе булмагандыр. Ир-атка бер-берсен сату килешми. Сезгә ихласлы, чын дусларча мөнәсәбәтем турысын әйтергә кушты. Беләсезме, намусым алдауны, мәкерне күтәрми.

Сәвия үзен бик тиз кулга алып:

—Сезгә күземне ачкан өчен чын күңелдән рәхмәт. Нигә ул мина турысын әйтмәде. Аңлаган булыр идем. Бала-чага кебек ирен турсайтып, сөйләшмичә, анлашмыйча, төрле почмакларга басып, үпкәләшеп йөрүдән кемгә файда!! Һәрхәлдә, егетләрчә түгел дип саныйм.

Кыз шактый гына уйланып торганнан өстәп куя:

—Әмир, ни әйтсәң дә, намуслы кеше икән. Бозык ир булса, берни булмагандай, гомер буе ирем өчен саклап килгән байлыгымны алып, өйләнгәнлеге турында соңыннан гына әйтсә, ни кылыр иден. Мине төп башына утыртырга бөтен мөмкинлеге бар иде. Ни булганын әйтергә кыюлыгы гына житмәде. Дөресен ярып саласы, Сәвия, менә шулай килеп чыкты, гафу ит дисә, мин дә болай каңгырып йөрмәс идем.

—Мин шулай итәр идем,—диде укытучы иптәш мактанып алырга җай чыгудан файдаланып.—Нәрсәсен яшереп торырга.. Булган, булган... Кеше башыннан уза торган хәл.

Бу сөйләшүләр кызның ярасын саркытып, тоз сибү булып, күз алдында кызыл шәүләләр биесә дә, ул үзен кулга алып, хастаханәгә, даруханәгә кереп, бар йомышларын үтәде, сөйләшелгән жиргә үз вакытында машина янына килеп житте. Ленар, "эшләрен бетереп", күптәннән көтеп тора икән.

Тәкъдиме дә әзер.

—Көне буена йөгереп йөреп, ачыгып беттек, ресторанга кереп тамак ялгап алыйк.

Кызның да ашыйсы килүе табигый, каршы килеп баш катырмады. Ленар район үзәге ресторанды мөмкинлегеннән чыгып, тәгамнар, шампан шәрабы алды. Руленә сылтау итеп бөдрә чәч үзе эчмәде, иреннәрен генә чылатып утырды, әмма ләкин шәфкать туташын ифрат тырышып сыйлады. Тегесе язмыш сынавы киеренкелегеннән алҗыган иде, туарылып, нерв дилбегәләрен бушатып, рәхәтләнеп эчте, ап-ак битенә кызыллык кунды, ясалмарак чыкса да, елмайды, тотышына табигыйлек төсмере индерергә тырышып утырды һәм йомшап китте, гомере буена үкенәчәк хата эшләп ташлады.

Сәвиянең рухи һәм физик халәтендә туган үзгәрешне сизеп алган Ленар иркәләп кенә аның бармакларын учына алды, бөгелеп, кызның кулына дәрт кайнап торган иреннәрен тигезде. Кызны өрмәгән жиргә утыртмаска, күтәреп кенә йөрергә әзер ир иде бу мизгелдә Ленар.

—Сәвия, йөрәгемнән чыккан бер сүз әйтсәм үпкәләмәссезме?

—Әйдәгез, икене,—диде кыз көлә-көлә.

—Мин бит сезгә беренче күрүдә үк гашыйк булдым, шуны әйтергә оялып, Әмирдән көнләшеп яшәдем. Хисләрем басылмасмы дип өйләнеп тә карадым, юк булмый. Бер атнадан өемнән куып чыгардым.

—Ул боламык турында исемә төшермәгез. Үзен дә, исемен дә ненавижу,—дип нәфис куллары белән өстәлгә төя башлады.

Эчкә батып торган күзләрендә өмет чаткылары кабынган Ленар, илһамланып китеп, урындыгын йөртеп кызга якынлашты.

—Сез, Сәвия, барыбер аны яратасыз?

—Юк, инде яратмыйм, әйттем бит, женем сөйми, күрә алмыйм,—диде ярым исерек кыз, үҗәтләнеп, иреннәрен авыртканчы тешләп.

—Вакыт үзенекен итәр, мине дә бәяләрсен, яратырсың әле... Бигрәк тә минем тәкъдимне кабул итеп, мина тормышка чыксаң.

—Сине дә яратмыйм. Үземне дә яратмыйм... Беткә ачу итеп тунны янган мичкә ыргыткандай, беренче хатынынны куып чыгаргандай, тиз генә аерылышмаска вәгъдә бирсәң, тәкъдимеңне кабул итәм. Формально үзем дә икенче тапкыр кияүгә чыгам бит инде. Кыз булып калсам да.

Бөдрә чәч урындыгыннан сикереп торып, шатлыгыннан бөтен дөньяны кочагына алырдай булып, кызның беләнә кулын сала.

—Ашыкма, абзыкай, өлгерерсен,—дип Сәвия дәрте кабынган ирдән читләшә, кулын алып куя.

—Сөйләшеп бетерәсе хәлләр күп әле. Туярсың. Ни өчен тәкъдимеңне кабул итүемне анлатыйм. Бу арада Мөсәгыйть Хәбибуллинның "Кубрат хан" романын укыдым. Чибәр кыз Аппак Кубратка яратмыйча, бичарадан ни чара дигәндәй, кияүгә чыга. Бергә көн итә, балалар үстерә башлагач, ирен якыннанрак танып-белгәч, ул Кубратка чын-чынлап гашыйк була. Безнең белән шундый могҗизага ышанам. Синең белән чәчемне бәйләсәм, өч шартым булыр, шуларны карышусыз үтәргә сүз бир, ант ит.

Ленар күндәм укучы кебек аягына басты, янәдән урындыгына чүмәште.

—Йөз дә бер шартына риза, сөеклем.

—Юк, өчәү генә. Беренчесе—никах укытып, язылышкач, шул сәгатьтә үк авылдан чыгып китәбез, җәһәннәм читенә алып китсәң дә риза. Икенчесе—мин көндезме, читтән торыпмы—укырга керәм. Каршы килмисең. Синеке кебек үк минем югары белемем булырга тиеш. Өченчесе—тора-бара ин мөһиме булып китүе бар—яратмыйча кияүгә чыгуымны теләсә нинди шартларда... хәтта үлгәндә дә искә төшермисең. Ул хакта сөйләшмичә гомер итәбез, балалар үстерәбез, кунаклар җыябыз, биибез, җырлыйбыз...

Беренче ике шартны җинел кабул итсә дә (соңыннан күз күрер), өченчесен тынлаганда Ленарның көнләшү кытыгы уянды, чырае сытылды, ирлек горурлыгы рәнжеде.

—Сез мина бөтенләй битарафмы? Бер тамчы гына булса да ошамыймы?

Кинәт айнып киткән кыз житдиләнде:

—Мин ошамыйсың димәдем. Салкын ай кебек битараф булсам, биредә ләчтит сатып, язмышымны кулына тапшырып утырмас та идем. Ярый житте, юлга чыгыйк.

Булачак ирнең бер фикере калган икән әле.

—Син укырга кереп, балабыз туса, аны кем карар?

—Анысы, иптәш, минем хәсрәт булыр. Медик икәнемне онытма. Җае чыгар, балабызны приютка тапшырмабыз.

Шул көнне кичен егет ашыга-ашыга мулла белән никах турында килешеп, авыл советы рәисен сыйлап, майлап, өч көн эчендә рәсми хатынлы булды. Кабалануының сере аңлашыла. Кыз кәҗәләнергә, сүзеннән кире кайтырга, Әмирнең имтиханнарын биреп, авылга кайтып төшеп, мәкерне сизеп, оеша килгән дөньяны бутап ташлау ихтималы бар. Алдауны, хәрәмләүне сизсә—йодрыгын ходка җибәрүе ихтималын көн тәртибеннән алып ташларга ярамый.

Ленар белән Сәвиянең язылышып, кая киткәннәрен беркемгә әйтмичә, билгесезлеккә гаип булулары турында хәбәрне студентлык хыялын тормышка ашырган Әмиргә энесе Наил житкерде. Булачак тарихчыга таныш лапас печәнлегендә сабыйларча үксеп-үксеп жылаудан башка чара калмаган иде. Хатасын аңласа да, чын дөреслекне әле ул тиз генә белмәячәк. Әмирнең якынча кайсы көннәрдә кайтасын атасыннан белешкән Ленарның атна-ун көн буенча "көндәшен" каршы алырга вокзалга чабып, Сәвиянең ирләр белән чуалуы турындагы сөйләк-гайбәтне үзе уйлап чыгарып, ике гашыйкны

бер үк дәрәҗә-алым белән алдап, йөрәкләрен бутап, хәйлә аша морадына ирешүен берәү дә белми. Бу хакта дөреслекне Әмир утыз елдан соң гына тыңлаячак. Тик терсәкне сыйпап булса да, тешләп, үткәнне кире кайтарып булмый шул.

***

...Икенче көнне Сәвия ханым килешенгән вакытта Әмирне университет коридорында каршы алды. Профессор да эшләрен төгәлләп, озата йөрүчеләреннән шома гына котылып куйган иде. Күптән күрешмәгән кешедәй, Сәвиянең кулын учларына алып, ипләп кенә кысты, күзләренә тутырып карады. Таныш-белешенне озак еллар күрмичә торсаң, ул бик нык бирешкән, юанайган, күзләренең нуры тоныкланган, ирене сәлперәеп аска салынып төшкәндәй тоела. Элеккеге якының белән аралашып, сөйләшеп-серләшеп, зиһенләшеп киткәч, ул сиңа яшьрәк күренә башлый, әңгәмәдәшең тормыш низагларына артык бирешмәгән, сөйкемле чалымнарын саклый алган дигән фикердә урнашасың. Әмирдә бүген Сәвия шундыйрак тойгылар уятты. Кичә бетәшкән карчык үзгәргән, бүген ул профессорга җыйнак гәүдәле, ягымлы йөзле, үткер зәңгәр күзле урта яшьләрдәге ханым кебек күренде. Әллә инде яшьләрчәрәк киенеп, ялтыравык алкаларын, кул һәм муен чылбырларын тагуы тәэсир иткәнме, һәрхәлдә яшьлек мәхәббәтеннән аклык, пакьлек, яктылык сирпелеп торгандай, үзе дә шул аура эчендә иңеннән басып торган картлык галәмәтләрен селкеп ташлагандай тоелды.

Әмир ханымны бер тәрәзәле тар бүлмәгә алып кереп, студент эскәмиясенә үз янына чакырып утыртты.

Күрешүнең башында ук Әмир үзен гомере буенча борчыган соравын бирергә җөрьәт итте:

—Яраткан кешегезгә тормышка чыгып, сез бәхетле гомер кичергәнсез инде, Сәвия ханым?

Хатын җавап бирергә ашыкмады. Бәхетне аны яшереп булмый, ул булса, адәм баласының барча күзәнәкләренә матур күбәләктәй куна, йөзенә, күзләренә сүнмәс нур бөрки. Сәвиянең, киресенчә, күз карашлары тоныкланды, борын төпләренә кара күләгәләр төште. Бугазына ачы төер кадалды.

—Үлгәннән соң тәүбә юк,—диләрме әле.

—Нигә шундый пессимизм, төшенкелек?—Без яшибез ич әле! Ходай тәгалә күпме гомер биргән, шуны үтәсе булыр. Хәзер һәр бирмеш якты көнгә сөенеп яши белергә кирәк.

—Без бит, Әмир әфәнде, бу фани дөньяда иң бәхетле кешеләр булырга тиеш идек.

Тегесе шуннан да әһәмиятле соравы булмаган кеше төсле үҗәтләнеп үзенекен тугылады:

—Шулай да, Сәвия, син бәхетлеме?

—Сигез ел төрмәне һәм ялгыз картлыкны бәхет дип санасаң, олы Рәсәй илендә миндәй "бәхетлеләр" аздыр дип уйлыйм, Әмир Гатауллович.

Урынсыз һәм уңышсыз төпченүен аңлап, Әмир ирексездән телен тешләде, таяныч эзләгәндәй, почмаклы сакалын сыпырып алды.

—Бәхет төшенчәсенә әле берәүнең дә тулы җавап бирә алганы юк. Һәм барча адәм баласының күңеленә хуш килгәне табылмастыр да. Тыныч, ипле, уртак мәхәббәткә корылган гаилә тормышы, шуны татымаган кешегә җирдәге оҗмах тоела торгандыр дип уйлыйм. Минем тормыш юлымны озак итеп, ваклап сөйләсәң, үзе бер романга җитәрлек. Үз гомеремдә чын-чынлап бер кешегә генә гашыйк булдым. Ул—син идең. Ахмак булып сезгә

күченеп хур булдым. Бәхетсезлегем шуннан башланды. Мәхәббәтем хәсрәтле, юлсыз булып чыкты. Үпкәләүдән, рәнҗүдән, чарасызлыктан, сина үч итеп, Ленарга яратмыйча кияүгә чыктым. Мин куйган шартларнын берсе нигезендә авылдан тиз генә чыгып киттек. Зиһенен кыскармаган булса, алары сина билгеле. Без Ижауга барып урнаштык. Мин медицина институтына укырга кердем, кичләрен эшләдем. Балага уздым, аны табарга ниятем иде. Безгә әле пычрак чүпрәк-чапрак белән чәбәләнергә иртәрәк, кеше өендә яшибез, үзебезгә фатир булдырыйк, укуынны да тәмамлыйсы бар дип, туачак балабызны Ленар көчләп диярлек алдыртты. Ир сүзеннән чыкмый торган вакытым иде әле. Биргәннен кадерен белмәдегез дип, Ходай тәгалә бүтән бала бирмәде.

Тумаган баласы турында искә алу ханымнын күзләрен чылатты, Сәвия битен куллары белән каплап, тын гына елап алды.

Акрынлап тынычланды һәм янәдән сүзен дәвам иттерде:

—Биология укытуын ташлап, Ленар милициягә эшкә урнашты, бер ел эчендә фатирлы булдык. Мин институтны тәмамлап, терапевт булып эшли башладым.

Арбанын алды кайда барса, арты шунда булырга тиеш дип, иремә ярарга тырыштым, Ленардан гел унай сыйфатлар эзләдем.

—Син ана тора-бара гашыйк та булгансын әле,—дип Әмир көнләшкәндәй итеп сүз кыстырды.

—Кирәк булганга, тормыш итү өчен ярату бардыр, ә мәхәббәт ул, Әмир бөтенләй үзгә нәрсә. Кеше өчен дөньяда мәхәббәттән дә газиз хис юктыр. Андый мәхәббәт кешегә бер генә бирелә икән. Табигать кешегә матурлыгын тутырып бирсә, бәхетен төерле итә икән. Ленар янәшәсендә төп хисем ялгызлык, дөньяда яшәүнен мәгънәсезлеген тою булды. Ирем дә миннән суынды. Мәхәббәт—учак кебек, аны икен дә жылытып тормаса, тиз сүнә. Иремнен табигате, фигыле бозыла барды. Минем яклаучым юк иде. Ул бик азгын, кабих кеше булып чыкты. Шулай килеп чыгасын жиденче тоемым белән сизенгән идем, тик синнән үч алу хисе жинде. Ахыр чиктә бу усаллануым үземнән көлү булып чыкты. Анадан кыйшык туганны тезгә салсан да турайма с диләр, дөрес икән. Мин ярарга, гаилә тормышыбызны ипле генә алып барырга тырышкан саен, Ленар холыксызлана, юк-барга бәйләнә торган булып китте. Үзен сизенгәнсендерме, юкмы, бәгырьгә төшкән низагнын сәбәпчесе син иден.

—Минем ни катнашым булды икән сезнен бәхәсләрдә?—диде профессор.—Сезнен этле-мәчеле торуыгызда,—дип әйтмәкче иде, тыелып кала алды.

Ханым, кулындагы кулъяулыгын бармакларына чорный-чорный, сүзен дәвам итте:

—Мине яратмыйсын, һаман Әмирен турында уйлыйсын, мина кияүгә дә ана үч итеп кенә чыктын дип, һәр көнне диярлек бер үк балык башын чәйнәвен белде. Чамадан тыш күп эчә башлады. Дуслары, хезмәттәшләре белән кәефләнеп кайтса бер хәл иде, ә ул эштән сон өйдә салу гадәтен алды, максат куйгандай, мине дә көчләп эчертә башлады. Үзе егылган бала еламас, дип тешләремне шыгырдатып кысып булса да түздем, аны да сакларга, эчермәскә тырыштым, аракысына сулар кушып, төрле чаралар күреп карадым. Көнчелеге түзеп булмас хәлгә житте. Шулай интегә торгач, нигә кадеремне белмәгән бу юньсезгә үземне әрәм итим дип, аерылып китәргә уйладым. Гариза бирдем. Бу хакта әйткәч, ул курыктымы, акыл кердеме шунда, гафу үтенде, алдыма килеп тезләнде, төзәлергә шанс бир дип ялынды, ялварды, миннән башка яши алмавы, эшеннән куачаклары турында сөйләнде. Сүзендә торды кебек. Эчүен ташлады, өйгә вакытында кайта башлады. Мине бүләкләргә коендырды. Тыныч яшәү хыялым гамәлгә

ашкандай булды. Мин аерылу турындагы гаризамны кире алдым. Ит күрмәгәнгә үпкә тансык, диләр. Тик минем гаилә бәхете турындагы хыялым таш идәнгә төшеп ватылган бәллүр савыт кебек берничә көннән үк чәлпәрәмә килде. Фаҗигале язмышым мине сагалап торган икән.

Бер кичен Ленар кызмача кайтты. Өстәлгә ике шешә аракы чыгарып куйды. Миңа стаканын тутырып салып бирде. Иреннәремне тидереп, стаканны өстәлгә куйгач, "мин салып биргән аракыны эчәргә җирәнәсеңме, Әмирнең кулыннан агу да эчәр идең әле", дип йөгереп барып пистолетын алып килде, шалтор-шолтыр китереп, корып, ашамлыклар арасына өстәлгә урнаштырды. Коралга күрсәтеп, миңа күз кысып алгандай булды һәм беренче тапкыр үткән тормышыбызда ни-нәрсә булганны сөйләп китте.

—Абзаңдагы акыл Министрлар советына житәрлек. Ник дисәң, берьюлы өч ахмакны төп башына утырттым. Гатаулла карттан Әмирнең кайчан вокзалга кайтасын белешеп, атна буена шунда чаптым. Сөйгәнеңне каршы алдым. Очраклы очрашу дип уйлап, шатланды, мескен, коньягын чыгарып куйды. Бераз салып алгач, мин аның колагына сине ирләр белән чуалды, бозау Илгизе белән үзем күрдем, ачык капкага кем кермәс дигән информацияне бирдем. Ул тинтәк, минем ялганга ышанып, сине куып чыгарды. Әмир хезмәт иткән җирендә өйләнгән, дигән хәбәрне үзем уйлап чыгарып, синең колак шәрифләренә җиткердем. Шул рәвешле тутый кош үзе куеныма килеп керде. Ул—син идең.

Ленар җинүче кыяфәте белән түр башында ыржаеп утыруын белде.

Үз-үземне белештермичә, алдымда торган бер стакан аракыны эчеп куйдым да, урынымнан сикереп торып, "син кабахәт, җирәнгеч мәкерче",—дип өстенә киттем. Ул ысылдап:

—Менә сиңа пистолет. Корылган, шул ыргакны гына үзеңә тартасы,—дип пистолетын миңа сузды. Мин, үземне белештермичә, коралны аңа төбәп атып җибәрдем. Шартлау... пистолет кулымнан сикереп төште. Үзем дә идәнгә егылдым. Пуля Ленарның йөрәгенә тигән. Хезмәткәрләре җирләделәр. Миңа ун ел бирделәр. Сигезен утырып кайттым. Эшкә урнаша, фатир таба алмыйча интектем. Инде менә хәзер пенсиядә,—дип тәмамлады Сәвия сүзен, моңсу гына көрсенеп.

—Ә син ничек, Әмир? Күрәм, зур галим, абзый кеше, абруйлы зат булгансың. Минем кебек, бердәнбер гомереңне заяга уздырмагансың.

Үткәненә хәтер канатында булса да әйләнеп кайтасы килмәсә дә, Сәвиянең фаҗигале язмышында үзен гаепле сизгән, хәтта тетрәнгән Әмир үзе турында сөйләми калдыруны дөрес булмас дип тапты. Чынында аны да бәхетле тормыш кичергән кешеләр рәтенә кертү кыен иде.

—Дөресен әйткәндә, Сәвия, әүвәл сине көттем, мәҗнүннәрчә, иреңне ташлап мине эзләп табарсың дип саташып яшәдем. Аннан сиңа, шәүләңә булса да, охшаган кызны эзләдем. Шул арада яшем утызга житте. Ирләр хатынсыз яшәргә тиеш түгел дип, синең кайтасына өметем учактагы соңгы күмер кебек сүнгәч, елмаебрак караган бер кызга тоттым да өйләндем. Шартын китереп яшәп киттек. Хатыным бер малай, бер кыз алып кайтты. Фатирлы булдык. Балаларыбызны үстергәндә инглизләр тәҗрибәсенә таянмадык, каеш кулланмадык, бик иркәләп тәрбиядә тоттык. Улыбыз кыек юлдан китте. Мәктәпнең өлкән сыйныфында ук эчә башлады, укырга да, эшләргә дә теләмәде, төркемнәргә иярде һәм ... үзен Петербургтан табут белән алып кайтырга туры килде. Кызыбызны башлы-күзле иткәч, аналары аның янына күчеп карады. Анда озак тора алмады, янәдән минем кырга кайтты. Балалар һәрвакыт, һәркайда ата-ана янына сыя. Тик әти-әни генә балалар учагында бик җылына алмый. Буыннар арасындагы бәйләнешнең берьяклы булуы аталар-балалар арасындагы мәңгелек

конфликтны китереп чыгара да инде. Бала ата-анага кирәк, соңгылары бала өчен өстәмә, кирәксез йөк.

Кызыма Сәвия дип исем биргән идем. Хата җибәргәнемне сонарып аңладым. Исемен әйткән саен син искә төшәсең, таныш чалымнарыңны, төпсез коедай тирән зәңгәр күзләреңне эзли башлыйм. Күксу соры күзләргә төртеләм дә, кәефем кырыла. Хәзерге халәтең нинди дисәң, бөтен юанычым, шатлыгым, кайгым—яраткан фәнем. Җәй буе экспедициядә булам, кышын очрашуларга йөрим. Өемә кайтасы килми. Хатын белән читләшеп беттек. Уртак сөенечләребез юк диярлек. Оныклар килгәндә генә бер гаиләдәй берләшеп алабыз. Оныта язганмын. Сине соңгы сулышына чаклы сагынган, юксынган кеше әни, ягъни Хәдичә апаң булды. Әти белән Наил сине оныттылармы, юкмы, әйтә алмыйм, тик артык искә төшермәделәр. Иратның табигате шундыймы, мине кызгандылармы, белмим. Әни сине рәнҗеткән өчен мине тәки гафу итмәде. Йөрәк өянәге белән бик тиз дөнья куйды.

Бөтен барлыгын фәнгә багышлавы, шуннан юаныч, ләззәт табуы турында артык бәян итүне кирәк санамыйча, Әмир үзен борчыган сорауны бирде.

—Ленар хаклы булган. Мин—ахмак. Сәвия, бик үтенсәм, алдына тезләнсәм, мине гафу итә алыр идеңме? Синең чаклы ук булмаса да, мин дә бурычны түләдем. Сөю-сөелүсез тормыш—тормыш түгел икән.

Ханымның әле һаман да озын керфекләреннән үтә күренмәле тамчылар битенә тиеп, Сәвиянең бармакларын тоткан Әмирнең кулларына тамды.

—Кулыбызга алтын бөртеге кебек килеп кергән бәхетне саклап кала алмауда беренче чиратта мин гаепле, Сәвия, син дә кияүгә чыгып ашыктың, минем акылга килгәнне бераз көтәсе идең! "Ашыккан кыз иргә барса да—мантымас"—дигән мәкаль бар безнең якта.

Сәвия бик озак эндәшми торды. Бу бәхәскә керешеп, үзен аклап, Әмирне яманлап маташудан ни файда. Икесенең дә ашлары ашалган, яшиселәре яшәлгән. Кояшның офыкка төшеп батасын гына көтәсе калган. Шуңа күрә, гафу итсә дә, кирегә сукаласа да, узган гомерне кайтарып булмасын ул аңлый иде.

—Узган болытны күз белән генә тотып, ә үткән тормышны хәтер белән генә иңләп була, Әмир. Гомер, кояшлы яңгыр кебек, бик тиз үтә икән шул. Сизми дә каласың. Хөкемчебез—Ходай Тәгалә. Җир йөзендә бит әле үз мәхәббәтен бөтенләй тапмаган кешеләр дә була, ди. Без алардан бәхетлерәк,—дип ханым сыктану, үкенү катыш елмаерга тырышты. Елмаюы, фаҗигале әрнеш сыман чыкты. "Адәм сөйләр, язмыш көләр"—дип юкка гына әйтмиләрдер.

*2004.*



**Ирек Сабиров**

## УЙ ЯРЫНДА, УЕЛ БУЕНДА...

**Троицк каласына багышлап**

**Уй ярында таң шәуләсе уйный,
Таң сәламли Уел буйларын...
Шул таңнарда ерак гасырларга,
Тарихларга оча уйларым.
Тәңрем ихтыяры белән, ахры,
Шәһәребез шулай урнашкан:
Мәчетләргә төшә тәүге нурлар
Алсуланып чыккан кояштан.**

**Сокландырып бу дөньяның
Фәкыйрен дә, баен да,
Таң нурлары җем-җем итә
Мәчетләрнең аенда.**

**Таңнар ата, мөэминнәрне өндәп
"Тәңребездән иңгән бәхеткә":
Татар тыкрыгыннан, әкбәр әйтеп,
Мөселманнар бара гаеткә.
Чиратлашып мәңге алмашына
Кышкы көртләр, җәйге чәчәкләр.
Изгеләрнең кабер ташларында
Балкып сүнә соңгы шәфәкъләр...**

**Кичке шәфәкъ яулый Уй буйларын,
Моңсулата Уел суларын.
Хак Тәгалә үзе яктыртамы
Халкыбызның язмыш юлларын?—
Изгелеккә Раббем соклана күк,**

---

Ирек САБИРОВ (1950) *— шагыйрь; "Яшим", "Аваз", "Манзара" һ. б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Чиләбе өлкәсе Яман Елга шәһәрендә яши.*

Гөнаһларга, гүя, көрсенә.
Көн башлана Татар тыкрыгыннан,
Татар зиратында көн сүнә...

Сокландырып бу җиһанның
Фәкыйрен дә, баен да.
Таң нурлары җем-җем итә
Мәчетләрнең аенда.

***

*Безне ерак, ерак ыргытканнар...*
*Кайта-кайта хәлләр калмады.*
Харрас Әюп

Туган яктан ерак китсәк тә без,
Югалмадык әле дөньяда:
Тегендә дә сынатмаган идек,
Кеше булып калдык монда да.

Монда матур айлы кичләре дә,
Таңнары да балкып яктыра,
Тик барыбер Убса урманнары
Төнлә төшкә кереп чакыра.

Без бит Казан арты егетләре!
Күк ишелеп, җирләр упса да,
Бер кайтырбыз әле Мәмдәлләргә,
Бер кайтырбыз әле Убсага!

## Гармония

Безнең фани дөньябызга илаһи бер моң ия,
Бу гаҗәеп могҗизаның исеме—гармония.

Ансыз булмас иде Җирдә мәхәббәт тә, нәфрәт тә,
Игезләрдәй булыр иде ләззәт белән михнәт тә.

Йә кычкырып елар идек, язмыш мәзәк күрсәтсә.
Йә шаркылдап көләр идек—төшкән чакта хәсрәткә.

Бу серле моң тәэмин итә гаиләдә берлекне,
Шуңа күрә дәвам итә Җир йөзе—тереклекне...

Әнкәм назы, әткәм сүзе, сөйгәнемнең күзе ул,
Ахры инде—гармония Хак Тәгалә үзе ул.

Парлап, сайрап гомер итсен Җирнең бар җан иясе,
Яшәсен лә бу Җиһанның бөек гармониясе!

## ALMA MATER

Тәннәр яшәп тузды...
Кайттык, килсә дә көз:
Шушы йортта узды
Яшьлек көннәребез.

Монда кайнап торды
Иҗат, сәнгать, фәннәр;
Балкып, ямьнәр бирде
Шәмдәлләрдә шәмнәр.

Ул чак без заманга
Булдык бик мөкиббән...
Әйдә, керик, монда—
Шул ук яшьлек микән?

Монда ямьнәр бирә
Шул ук шәмнәр микән?
...Ә, юк! Шәмдәл генә...
Шәмнәр янып беткән.

## Сынамыш

Кырыс холык, аз сүзлелек
Гаделләргә хас була,
Артык татлы телле кеше
Ялганга һәвәс була.

## Мавыксаң...

Узган заманнарны әрли-әрли
Күрми калмыйсыңмы бүгенне?
Еш борылып артка карый-карый
Мәтәлүең мөмкин түгелме?

## Сайлаулар алдыннан

"Тиздән тормыш рәтләнер,—ди,—
Сизәсезме—яз исе?"
...Тиздән, имеш... Минем исә
Бүген килә яшисе!

## Бүгенге ил

Юк дилбегә, юк авызлык:
Кылмаганны кыл әйдә!
Йә фахишлек, йә явызлык:
Юк бүтән юл Рәсәйдә.

## Адәм баласы

Якасыннан каптырса да
Әҗәл ташлаган ыргак,
Бер аягы гүрдә аның,
Берсе... бии тыпырдап!

## Заман

Тел шартлатып алдашабыз:
Көязләрне—матур дип,
Тыйнакларны—куркак диеп,
Оятсызны—батыр дип.
Ни кылырбыз, җирне, үрчеп,
Риялылар тутыргач,
Чын матурлар,
Чын тыйнаклар,
Чын батырлар юк булгач?

## Концерт

Без ашкынып килгән идек бер сөйкемле җыр көтеп;
Нигә болай каркылдыйсың, козгыннарны өркетеп?

## Картлык

Кисеп бетерелгән урмандагы
Исән калган ике агач без:
Көрештек тә, бергә куаныштык,
Бу дөньяда ялгыз калгач без.

## Язмышлар

Затсыз булып туган—затсыз яши,
Холкы мескен булган—гел байгыш.
Җаен сокландырган чәчәкләрнең
Соңгы көннәре дә—сокланггыч.

## Йөрәк

Көннәр буе йөзем көләч минем:
“Дусларым—дим,—җирдә терәгем!”
...Төннәр буе сызлый—рәнҗүләрдән
Тишкәләнеп беткән йөрәгем...



# Луиза Янсуар

## ОФЫКЛАРГА ТАБА ЙӨГЕРӘМЕН...

### Таллар

Таллар бии Мишә ярында,
Көмеш-якты нурга коенып.
Төн яшерә кинәт күзләрен,
Оялыпмы? Әллә... тыелып?
Бәхет төне—ул бер мизгел тик!—
Күкрәгендә—ымнар, ырымнар.
Әле җанда гына бөреләнгән
Туар Моңны тыңлый болыннар.
...Таллар бии Мишә ярында,
Карашлары өтә бәгырьне.
Пышылдый күк алар "җан сорап":
"Без Җырыңа күчәр Хәтерме?
Без Җырыңа күчәр Хәтерме?!."

### Җайдак җыры

Ялларыңа нинди моңнар үрә,
Нинди серләр сөйли төн җиле?
Яулар кичтек бергә, юллар кичтек,
Җаннан газиз күрәм мин сине.

Туган туфрак сулышын тоясыңмы?—
Тоташ дәрттән тора адымың.
...Күз алдымда—сылуым, сөйгән ярым,
Ә син, атым, кемне сагындың?!

Дошман гына мәкер-уй кормасын,
Эх, кайтырбыз таңда, җил куып!
Каршыларга чыгар газиз кавемем
Батырларын, җанкай, ил булып...

Ялларыңа нинди моңнар үрә,
Ниләр көйли туган як җиле?
Утлар кичтек бергә, сулар кичтек.
Җаннан якын күрәм мин сине!

---

Луиза ЯНСУАР — *шагыйрә; "Күзен ача умырзая", "Мин күкләргә кайтам" исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Әрнү

Офыкларга таба йөгерәмен,
Табанымны яра камыллар.
Далаларны урап кайткан җилме,
Җавап сорап, җанга кагыла?

Учак эзләрендә калган көл дә,
Хәтер ярындагы гөл дә мин!
Язмыш күзләренә карап сөйлим
Җанны күпме әрнү телгәнен.

Күпме җөйләр барын—ялганмаган,
Сулкылдавын янә Үткәннең.
Тамырларга иңеп... моң агыла,—
Бәхил түгел җаны кемнәрнең?!

...Лачын булып җәйсәм канатларым,
Кунар иңнәр тапмыйм... Кайларда?!
Ялгыз атлар чаба томырылып
Иңрәп торган моңсу далада.

Тере Хәтер булып ташлар ята,—
Йөрәкләргә күчкән һәр өне.
Ташлар телсез түгел, җаннар өнсез.
Тетрәп калка ташның бәгыре...

Киләчәктән урап кайткан өнме,
Җавап эзләп, җанга сарыла?!
...Хәтер ярларында... Моң чайпала,
Ак болытлар күктән агыла...

## Төнге фәрештә

Иңнәремә килеп кулын салды,
Пышылдады: "Күтәр канатың!
Җил дә узмас ят юллардан атлап,
Аякларың күпме канаттың.

Йөрәгеңә күтәрдең Җир зарын,
Учың белән сөрттең яшьләрен.
Тик башканы котә синнән Дөнья,
Көтә... яшен булып яшьнәвең!.."

Һәм югалды, болытларны ярып,
Чыклы эзләр сибеп үләнгә.
Шул мизгелдән—йөрәгемдә күкрәү,
Ярсуларга юк чик, йөгән дә.

Яза йөрәк Хәтер елъязмасын,—
Җил тәкъдире аңа юралган.
Язмышымның җырлы тәгәрмәче
Мең яшенгә-утка уралган.

Ул яшеннәр, балкып, уяу итәр
Беркөн хәтта котып бозларын!
...Тоям таңда изге фәрештәмнең
Бәхетеннән елап узганын...

## Сер

Дулкыннарның күкрәгендә нинди сер?—
Тылсымлы өн булып җанны назлый гел.
Йә тамчы—җыр булып сибелә учларга,—
Илһам көчем җитәрме аны кочарга?

Түзә алырмы моң шавына йөрәгем?
Алтын бишек—офыкларга төбәлдем...
Гомерләрнең агышында нинди сер?!—
Дулкын булып айкап тора җанны гел...

## Җиңелү

Бии-бии үрли ялкын йөрәгемә...
Бар әфсеннәр көчсез, ялварулар—юкка!
Яңгыр толымнарын сүтеп таратсам да,
Корбан гына булыр дөрләп торган утка.

Әверелер көлгә—үргән богауларым,
Салкын бозлар эреп, китәр җаннан Кыш та.
...Елап-көлеп очам, Сөю, кочагыңа,—
Яңа колың да мин, иркен җуймас кош та!..

## Учак

Бу учактан күпме утлар алдым,
Күпме моңнар күмдем көленә...
Тыны белән җанга кагылыр ул
Менгәндә дә соңгы үремә.

Дәшәр: “Ятим калган ялкыннарым
Кемнәр йөрәгенә сыеныр?
Еллар күкрәгенә дәртле хисем
Нинди сурәт булып уелыр?!.”

Яланаяк узган безнең эздән
Шау гасырлар атлый, көй сузып...
Шул учакка кайтыр беркөн җаным
Бакый дөнья аша—юл узып!..

## Талпыну

Чишмәләр йөгерә диңгезгә...
Җан кала талпынып, ымсынып,—
Күкләрне колачлап иңләгән
Ирекле кош чагын юксынып.

Ә Диңгез бер иңрәп, бер елап,
Бер көлеп сарыла кыяга,—
Шаулардан арыган йөрәген
Телиме... таш итеп тоярга?!

***

Йөрәгең кыямы, диңгезме?
Ул минем йөрәккә игезме?
Гомернең үлчәме ни безгә?!
Хыяллар—бизмәндә. Тигезме?

Хисләрең өермә—давылмы?—
Иң яшерен кылларга кагылды...
Язмышым җебенә уралып,
Наз сорап, учларга сарылды.

...Йөрәгем кыямы? Диңгезме?
Дулкыннар дулкынга игезме?!.

## Тынгысыз җан зары

Диңгезләргә китеп адаштым мин,
Үз-үземнән качтым! Дөньядан!
Яулык болгап калды сылу ярым
Мине җылыта алмас тын ярдан.
Болын гөлләреннән үргән хәтер
Кабат дәште илгә, нигезгә.
(...Кызган, Тәңрем, җанның упкыннарын
Туфрак белән капла, тигезлә!..)
...Әллә Хыял чакыра мине, тетрәп,
Әллә... Үлем әйди үзенә?
Балкып янган төсләр, тоныкланып,
Томан каплый кинәт күземә.
Мәңге шулай айкалырмы йөрәк,
Кайдан эзлим насыйп соң ярны?!
Хыял алдар...
Бер китәрмен төсле
Ятим итеп Җирне... Дөньяны...

***

Сөю кошым
Күкрәгеңне
Читлек түгел, бишек иткән.
Без узасы серле юлны
Кояш үзе нурдан чиккән.

Син кисәтмә:
"Чиксезлекнең
Читләре бар, чиге..."—диеп.
Йөрәгеңнең Моң-кылларын
Тетрәндерсен хисләр—биеп!

Юк, уфтанма:
"Офыгымда
Уйның соңгы балкыш..."—димә.
Сөю кошым учларыңны
Күмгән ләса шигъри җимгә!

## Хушлашу

Сине, ахры, җырым сихерләгән—
Саф, гөнаһсыз хисләр ташкыны.
Мин тибрәнгән биеклекне эзләп,
Йөрәккәең Күккә аштымы?

Сине, ахры, җаным ымсындырган,—
Үреләсең, каплап күзләрең.
Кояш булып иңсәм учларыңа,
Ялкынына бар бит түзмәвең.

Шуңа китәм, йөзеңә дә бакмый,
Үз офыгым анда, үз Күгем.
...Отып кал да серле моңнарымны,
Ап-ак карлар булып яу бүген!..

## Көз уза...

Көз уза,
Юлларда дымлы эз калдырып.
Хисләрне
Яфрактай туздырып, яндырып.

Төш гүя—
Йолдызлы сукмаклар чакыра.
Китикме,
Адашыйк Хыяллар чатында?

Чү, йөрәк,
Ул кадәр ярсыма, талпынма!—
Көз уза,
Җаннарны салып ач ялкынга...

***

Инешем!
Ярларга тулып,
Ташымас, ахры, күңелең.
Төпләргә иңгән сагышны
Күзләрең аша күрдем.

"Күкләр дә әллә саеккан?!—
Моңнарым җитми барып..."
Тын гына тибрәнгән өнең
Йөрәкне үтте ярып.

Инешем!
Дулкынга кушылып,
Саф җырым башлыйм әле.
Син түгә алмаган сагыштан
Бер—үзем ташыйм әле!



## Рифә Рахман

## ЧИКЕРТКӘ

ХИКӘЯ

Клавдия Петровна күрше карчыгы белән чәйләп утырган жиреннән, эшләрем күп дигән сылтау белән, көндәгедән иртәрәк кузгалды. Акрын гына, бер-бер уйда кыяфәттә каталарын киде, кулындагы таягын авырлык белән йөртеп, үз ихатасына юнәлде. Күңелендә бер моңсулык иде аның.

Ахирәте Матрена Павловнаның шәһәргә күчеп китәр көннәре житкән дә хушлашу чәенә чакырган булып чыкты. Чәй янында сүз ялганмады. Бер-бер кызык хәлнеме, яшьлекләренме исләренә төшерергә теләп тырышсалар—күңелләренә моңсулык килде, алдагы елларга берәр эш планлаштыра башласалар—күз төпләренә яшь бөялде. Ул хакта сүз башладылар, бу хакта—йә очына барып чыга алмадылар, йә әлеге хәлләрнең бер килешсез ягы исләренә төшә дә, сүзне ник башлаганнарына үкенеч хисе биләп куя иде. Ахырда, Алла кушса, күрешербез, бергәләп жәйләр жәйләрбез әле дип, үзләрен берни булмагандай тотарга тырышып, тыныч кына саубуллаштылар.

Карчык, тимер күтәрмәне көч-хәл белән бавыннан тартып, чоланга үтте дә бер мәлгә тын калды. Йорттан кыштырдаган тавыш-мазар ишетелмиме дип колакларын шомартып торганнан соң, ярымжимерек ишекне сак кына ачып, йорт эченә атлады. Искергән обойның каерылып торган кәгазьләрен көннәр буе кыштырдатып шаярган, өстәл аягын кимереп теш чарлаган Петя йөгереп каршысына килер дип көткән иде—күренмәде.

Клавдия Петровна карты Афанасийдан калган, инде ботаклы буыннары да шомарып беткән таяк белән идән тактасына суккалап карады, тавыш ишетелмәде. Аннан сул кулы белән ишек янагына тотынды да бераз гына читкәрәк китеп, инде үзе хәтлек кенә калган жинел таякны да зур авырлык белән генә күтәреп, ишек өсләренә төрткәләп алды. Петя жавап бирмәде.

Аш өстәле торган аралыктадыр, минем белән качышлы уйнамакчыдыр дип, карчык, каплап торган чаршауның бер кырын ачып, мич буена узгач,

Рифә РАХМАН —*шагыйрә; «Керфекле тәрәзәләр», «Күзләрең төймәләнсә» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

шатлыгыннан елмаеп куйды. Җыерчыклар арасына сеңеп беткән, пешмәгән ике шомырт шикелле күрәнсу күзләреннән сөенеч шәүләсе узды. Клавдия түтекәй утырмага киткәндә, сөт чөмереп калган Петя, көтеп арыганмы, идәнгә сузылып яткан да йокыга киткән иде. Аны уятмаска тырышып, карчык кергән юлыннан берьяклы йортның түренә чыкты. Өстәлдә улы Костядан килгән хат ята. Ул аны инде әллә ничә тапкыр укыган, ахирәтенә дә укытасы килә, әмма үзе дә чәйгә чакыргач сүз башларга бер сәбәп булыр дип, әлегә сер итеп саклый иде.

Зәңгәр-күк тамырлы куллары, дер-дер килеп хатка үрелде. Карчык, олаеп тапкангамы, тормышына чиксез шатлык өстәгән улының ягымлы сүзләрен сеңдергән кәгазь битләрен алып, юллар арасына да качкан җан җылысын тоярга теләгәндәй, башта—бер, аннан икенче битенә куйды.

—Ах, Костя, Костя, кадерлем минем,—диде ул,—кулыңа мылтык тотып, Әфган тауларын кичкәндә дә онытмагансың мине. Ком-таш арасында бер йотым суга тилмереп ятканда да, әниең турында уйлагансың. Рәхмәт, ай рәхмәт, балакаем. Анаң янына тизрәк кайтыйм дип, күпме михнәт кичкәнсеңдер... Ватанга чын сакчы үстереп биргән икәнмен!

Клавдия Петровнаның, шул вакыт кунакка кайтачак улына тансык ризыклар әзерләмәгәне исенә төште. Хәер, келәт матчасына каклаган каз эленгән, тырыска җимерек лапастагы утын әрдәнәсе астына чуар тавыгы көн дә салып торган йомыркалар җыелган. Быел кура җиләген дә киптереп тормады, алдагы елдагысы да ашалмаган. Сакаллы сыеры—затлы нәселле "Маня"сы кичкенә алюмин бидонны тутырырлык сөт бирә. Иткә җәй көне шәһәрнең, суыткычлы йортларында да кытлык диләр. Талон белән, аена дүртәр йөз граммлап кына бирәләр, имеш. Итсез дә сыйларлыгы бар. Анысын солдат паегында татыгандыр әле. Беленен пешерер, кәҗә сөтеннән маен язар.

Май дигәннән, искергәнен Петяга ашатып бетерергә кирәк. Абыйсы кайткач, ана да кунак ризыгыннан өлеш чыкмый калмас.

Ата тычкан Петяны Клавдия Петровнага әле генә чәйдә булып кайткан Матрена Павловнаның оныгы бүләк итте. Шәһәр йорты подвалыннан иптәш малайлары белән тотып алган мескен җан иясен карчыкның усал килене фатирларында асрарга теләмәгән. Клавдия Петровна йортындагы тычканнарның барысын тәбе куеп тотып бетергән иде инде. Ни дип әйтергә дә белмәде, ахирие кыш шәһәргә киткәндә, иптәш тә булыр дип, үзендә калдырды.

Йортка үз күсе-тычканыңны ияләштерсәң, башкаларныкы килми дигәннәре рас, ахрысы. Шул көннән бирле ник ят бер тычкан идән астыннан өскә күтәрелсен. Хәер, карчыкның читкә ташып ашарлык артык ризыгы юк, булганы да исә чәчелеп ятмый.

Клавдия түти Петяны яңа савып алынган кәҗә сөте белән бик тиз кулга ияләштерде, икенче елны җәй җәйләргә кайткач, Матрена Павловна алырга керсә дә, ул ана ияреп тормады. Үзен идәннән үрелеп алган карчыкның ишеккә дип борылуын күргәч, кулын кинәттән бик каты тешләде дә, сикереп төшеп, карават астына шылды. Авыртудан күз читләре аска авышса да, ахирие түзде, чериләмәде, хәтта сиздермәде дә. Бердәнбер күршесен үпкәләтүдән куркыпмы:

—Дуслашкансыз да икән, ярый инде, бергәләп яшәгез, күзен тагын сина кертәсе булыр иде юкса,—дип куйды.

Клавдия Петровна, шуларны уйлый-уйлый, мич буена күз ташлады.

—Ах, Петя, Петя, нишләп һаман йоклыйсың? Абыең кайтам дип хат язган, ул болай тик яткырмас сине. Сез хәзер өйдә ике ир-кеше булачаксыз. Каралтыны рәтләрсез, лапас түбәсендәге имән кайрыларын такта белән алмаштырырсыз, болдырны да терәүдә тотарга ярамас.

Кояш баеп килә иде. Клавдия Петровна ут яндырырга булды, әмма челтәрләп ясаган тәрәзә пәрдәләрен дә тартып тормады: бу тирәдән барыбер һичкем үтми.

—Кояш баеганда черем итү бер дә яхшыга түгел. Чәйләп алырмындыр, ахрысы, сина да өлеш чыгар,—дигән булып, карчык кабат мич арасына узды. Картларча шаяртмакчы идеме—таяк очы белән сак кына Петяның койрыгына төртте, үзе йонсыз колакларына карады.

—Әллә колагын да селкетми инде юньсезкәй,—диде Клавдия түти, инде аркасына ук катырак та төртеп. Чыелдау түгел, Петя селкенмәде дә.

Карчык эшнен нәрсәдә икәнлеген шунда гына аңлады. Петя жан тәслим кылган иде.

Нишләргә дә белмичә, беравык дәшми торганнан сон, карчык белештермәстән:

—Урыны жәннәттә булсын,—дип куйды. Күзеннән тәгәрәгән бер тамчы яшьне кара яулыгынын бөгәрләнеп беткән почмагы белән сөртеп алды.

Иртән, кояшнын беренче нурлары туфракка төшү белән, Клавдия Петровна алма бакчасына чыгып, таяк очы белән, карты Афанасий утырткан әнис төбенә Петя сыярлык кына кабер чокыды. Тезләнгән килеш, капчыклап бәйләнгән алъяпкычыннан алып, шул уемга салганда, әрекмән яфрагында хәл алып торган чикерткә карчыкның иннәренә сикереп менде.

Тычкан да Алланын жан иясе бит дип, белгән догаларын укый-укый өенә таба киткән карчык үзенә яна иптәш алып кайтканлыгын сизмәде әле. Тыштан кергәндә, чолан өстәленнән каклаган каз кисәкләрен, әчкелтем миләш суы тутырылган шешәне эләктерде. Әйберләр тоткан килеш, ишекне ничек ябарга белмичә, бер урында таптанып торганнан сон, куйгач, ачык ишектән кире чыгарга булды. Карчыкнын жилкәләрендә сәяхәт иткән чикерткә шул арада аш өстәленә кунаклап өлгерде.

Күнел юаткычын сонгы юлга озату унаеннан хәзерләнгән каты-токылы табын артында Клавдия түтинен үзеннән башка һичкем юк иде. Чикерткә әйберләр арасында сикеренгәләп йөрде дә, нәрсә кабарга инде дигән кебек, канат-кулларын угалап аваз чыгарып алды:

—Пе-тя!—дип үзе белән таныштырырга тели иде, гүя.

Карчык өстәлнен тавыш килгән почмагына караса—ана нәп-нәни, яшькелт-соргылт жан иясе текәлгән.

—Әллә, Ходаем, Петянын жаны мунча чыршыгы булып кайткан инде?!

Карчыкнын бармаклары, үзләреннән-үзләре көч алгандай, житез генә төртенеп куйдылар:

—Иисусе...

Чикерткә шым калып карап торуында булды.

—Кил, Петя, ризыктан авыз ит,—диде карчык һәм мич буеннан икенче стаканны алып чикерткә каршысына куйды. Аннан үзенә салынган миләш суынын яртысын сак кына буш савытка агызды.

—Синен ризалыгың өчен булсын!

Карчыкнын чикерткә белән шул рәвешчә сөйләшеп утыруын берәү күрсә, исәрләнгән мәллә бу кортка дип уйлар иде, әлбәттә. Ходай кушуы белән, авылнын бу очында икенче өй иртән шәһәргә китеп барган Матрена Павловнаныкы, ул да бу төндә ут элмәгән иде.

Чикерткә, инде үзен хужа итеп тойгандай, стакан ырмавына менеп утырды һәм, андагы суны татып карар өчен, егылмаска тырыша-тырыша, башын аска иеп маташты.

—Ой, Петенька, чыннан да, син икәнсен ләбаса!—диде карчык тагын, инде үз күзләренә үзе ышана башлагандай. —Китеп тә өлгермәден, сагынып кайтканчын да. Карчыкнын мәңгелеккә кипкән күзләрен кинәт яшь

каплады. Ул, әчке бер сызлану катыш шатлык белән, буыла-буыла елады.

—Петя, мин сиңа урынны үзем яныннан—мич башыннан бирермен. Костя абыең кайтса, сәкедә йоклар. Ул әле яшь—кызлар кочаклап җылыныр чагы. Менә безнең гомер ахырына якынлашып бара. Син мине кабат ташлап китмәссең бит? Күзләрем йомылганда, янымда булырсың, ишетсен колагың.

Ишетепме-ишетмичәме, мич җылысына кинәнеп алган чикерткә кошларны узарга теләгәндәй сайрарга тотынды.

—Йортта чыршык булгач, радионың да кирәге калмады,—диде карчык, бер мактаныч тоеп, аның йортында моңа кадәр радио-телевизорлар гөрләп утырган. —Менә Костя абыең гына кайтсын... Минем малай әйбәт тә угыл инде. Илгә сакчы үстергәнмен бит, әй! Син көн дә шуның хөрмәтенә җырларсың, яме, Петенька?! Кайтсын гына, әле пичнең дә янасын, күзгә төтен кертми торганын чыгарырбыз, тәрәзәгә ефәк челтәрләр алып эләрбез. Ул, бик күп акча белән кайтырмын, авыл кызларын күзли тор дип, амәнәт әйткән безгә. Синең күз минекеннән үткеррәк инде дә... Улың язмышын кеше кулына тапшырырга ярыймыни? Минем улым ул гынамыни?!

Клавдия Петровна йортының түрендә ике рәсем бар. Берсеннән, бәйрәм көннәрендә, шәмнәр яктысыннан Гайсә пәйгамбәр үзе карап тора. Бүген дә ул моңсу күзләрен карчыкның үзенеке кебек сары йөзенә төбәгән. Икенче почмакта, бер үк төсле кутәртмә өстендә—улының фотосы. Рәсемнән солдат киемендәге егет карый, кулларын терсәктән бөгеп, бармакларын маңгаена терәгән. Фотоның астына зур хәрефләр белән: "Ватан өчен гомеремне дә кызганмам",—дип язып куелган.

—Игелексез җаннарга, минем улымның гомерен ут астына куйганнарга тәмуг яныйдырмы инде...—дип өстәде.—Аллам сакласын, дөньялыкта хаталансалар да, алар да кеше баласы лабаса. Аллага шөкер, менә минем Костя сугышка тәре тагып китте, тәре тагып кайтыр. Әле киткәндә, әйткәнне-ниткәнне көтеп тормады, чиркәүгә барып, изге суын да алды. Изге сулар сакласын инде угылкаемны.

Карчыкка Костяның рәсем читләрен бизәкләгән челтәр бүген никтер ошамады. Тегеләй тартты, болай—барыбер дә күңеленә хуш күренмәде. Аннан, шул турыда онытырга тырышыпмы, чын динне белмәгән мөселманнарны кызганыпмы:

—Ходай ярлыкасын үзегезне, теге дөньяда туры юлны аңлатсын!—дип куйды. —Менә минем Костя—Аллага шөкер, христиан.

Клавдия Петровнаның кайгы белән башланган көне тагын улын көтү шатлыгы белән тәмамланды.

Костя кайтасы көн төрле сәбәпләр белән ерагайган саен ерагая барды. Көз дә үтте, кышлар да ахырына җитте. Озын төннәрдә, әле мич каршысында, әле мич башында Петенька белән алар һаман батыр солдат хакында гына гәп кордылар. Җилнең чолан ишегенең бавыннан тартуын да, моржа башында улавын да, киртә кырында үскән карт тупылның төндә сыкрануларын да Костяның ишектән керүенә, урамнан аваз салуына фаразладылар. Егет исә кайтмады да кайтмады...

Петя шул арада үсте, күзләре тагын да зураеп китте, тавышлары тагын да яшелләнде. Ул кай ягы беләндер җәй буе симертелеп, яшь бикәчләр артыннан йөгерә башлаган калай әтәчкә охшаган иде. Карчык аны кулларына алып үчтекиләргә, учларыннан өреп бер стенадан икенчесенә кадәр сикертергә гадәтләнде, йортның тагын бер хуҗасына тәмам ияләште.

Карчыкның өмете инде өзелде дигәндә, авыр чемоданнарын күтәреп Костя кайтып төште. Күрешкәч, тиз арада өстәл хәзерләрмен дип еллар буе хыялланган Клавдия түткәй олайган, ирәйгән, чибәрләнгән бу егеткә үзе дә, онытылып, гашыйк кызлар күзе белән карап торды.

Кичен аларнын сөйләшеп сүзе бетмәде. Костя алып кайткан күчтәнәчләрне ашап туя алмадылар. Мондый кадерле кунакны карчыкнын тагын да ныграк хөрмәтлисе килә иде. Берни дә уйлап тапмагач, ул үзенен жылы мич башын бер төнгә Костяга биреп торырга булды.

Ниһаять, утлар да сүнде, йокларга да яттылар, тик Костянын гына керфекләренә йокы эленмәде. Ул каты солдат караватына күнеккән, әнисенен биек ястыкларында анын башы әйләнә сыман тоела иде. Житмәсә, төн уртасында әллә каян гына мунча чыршыгынын сайраганы ишетелә башлады. Бер сәгать түзде егет, ике сәгать. Торып ут яндырырга батырчылык итмәде, бар нәрсәне болгатып, теге чикерткәне эзли башлады. Карчыкнын учларында биеп кенә яшәгән Петя, кунак абыйсынын ни кылырга жыенганын белмәгәнгә, кул аркасына сикереп менде дә тагын да шәбрәк сайрарга тотынды.

—Аһ, мур кыргыры! Әле син ун дошманнын башына житкән батырдан да батыррак булмакчымы?! —Костя инде бернинди ачусыз-нисез генә, шаярткан бер кыяфәттә, икенче кулы белән чикерткәне “Шап!” итеп кысты да, жан тәслим кылганын белгәч кенә, төшеп мич учагына атты.

—Әнием дә тынычлап йоклар, мина да ял ярыйдыр,—дисә дә, инде йортка тан яктысы үтә башлаган, йокы да каядыр китеп барган иде.

Костя Клавдия түтинен кәжә сауганын, мичкә якканын, өстәл әзерләгәнен, йомшак тавыш белән табынга дәшкәнен көтте. Карчык исә, нидер югалткан шикелле, мич тирәсендә әйләнгәләп йөрүендә булды.

—Петя, Петя!—диде ул бераздан, эче пошканрак тавыш белән. —Петя, дим, чык инде, төне буе яныма килмәден, кайда йөрисен сон? Кунак абыен торганчы, су эчерим үзенә.

Бу сүзләрдән аптыраишта калган Костя, мич башыннан сикереп төшеп, әнисенә карап тора иде.

—Нинди Петя? Син ишегалдында чагында һичкем дә кермәде. Бу өйдә качарлык урын бармыни?—диде ул бераздан.

—Нинди Петя дип... Минем өйдәшем инде. Дустым, якыным дисән дә була. Чикерткә...

—Әллә мин берәр бала-чагамы дип торам. Чикерткә эзләр дип кемнен башына килер? Үтердем мин аны, әнкәй, мичкә аттым!—диде Костя, көлә-көлә.

—Үтердем? Мичкә... —Клавдия карчыкнын күз алдыннан карангы шәүләләр йөгергәндәй булды, ул да түгел, алар барысы да чикерткә, тычкан балаларына әверелделәр дә ике аякка басып биешә башладылар. Мичкә аркасы белән терәлгән карчык, инде берни дә анламый башлагач, әкрен генә мич буйлап шуып төште. Анын сулышы ешайган, күзләре аларган иде. Костя тиз генә су, дару каптырды, көчле беләкләренә алып, карчыкны сәке өстенә илтеп яткырды, коргаксыган кулларыннан, итсезләнгән битендә тырпайган аксыл алмаларыннан үпте.

—Мин киткәнче терелә күр, әнкәй...— диде ул, еларга житешеп. —Исән-сау килеш, хәер-догада кал инде, әнкәй.

—Киткәч? Син кабат китәсен дәмени?!. Кем белән яшәргә мина, Костя? Әйт, кем белән?

Солдат егет дәшмәде. Ул әнисенә хезмәт срогын тагын да озынайтканын әйтергә дә оныткан иде. Үзенен дә күзенә яшь килде.

—Юк, юк, китмәм,— диде ул бераздан, әнисе тынычлансын өчен генә.

Клавдия Петровнанын итсез беләкләре суынганнан-суына кебек тоелды, күзләренен мәгънәсе югалганнан-югала барды. Бераздан ул:

—Петя янына ал мине, Ходам!—диде дә сонгы тынын алды. Чукынырга дип жыелган бармаклары, өлгерә алмыйча, таралып борын турысында тырпайдылар...

*Василий Макарович Шукшин—халык арасында актер буларак та, эдип буларак та, башкалардан аерылып торган олы талант иясе. Ул рус телен искиткеч әйбәт белеп иҗат итүче, телнең бөтен байлыгын оста кулланучы прозаик иде.*

*Бу тәрҗемәне мин кульязма хәлендә игътибар белән укып чыктым. Тәрҗемәче, авторның образлы, үтемле сүзләр белән тасвирлавын тулаем аңлап эш иткән, авторның кинаясен, кыек атып, туры тидерүен дөрес бәяләгән. Чыннан да, "Бүреләр" дип аталган әсәрдә ерткыч җанварлар гына сурәтләнми, бәлки игътибар үзәгендә—кешеләр: каената белән кияү. Ач бүреләр яңь-яшь колхоз атын ботарлап ташлыйлар; әмма алар, ичмасам, тату. Кешеләр исә, хикәянең башыннан алып ахырынача, үзара чарпалашалар, хәтта әле тел чарлау белән генә чикләнмичә, бер-берсенең бугазына ябышырга әзерләр. Әнә шул ике аяклы бүреләрнең холкын тулысынча аңлаган, хикәядә бәян ителгәннәрне генә түгел, бәлки әле авторның җаны сыкраганны юл араларыннан, күңел күзе белән күрү бәхетенә ирешкән тәрҗемәче, һичшиксез, әдәби әсәрнең рухи кыйммәтен укучыларыбызга түкми-чәчми китереп җиткерер. Моңа минем иманым камил.*

*Бу тәрҗемә, гәрчә Фәния Шәрәфетдинованың "Казан утлары" укучыларына тәкъдим ителгән беренче эше булса да, әдәбият "табасында" беренче генә "коймак" түгел. Моңа кадәр дә ул тәрҗемә өлкәсендә уңышлы гына эшләп килде. Бу очракта да сынатмас, дип ышанам.*

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**

# Василий Шукшин

## БҮРЕЛӘР

ХИКӘЯ

Якшәмбе көнне ачы таңнан Иван Дегтярев янына каенатасы Наум Кречетев килеп керде. Әле картлыкка бирешмәгән, сөйкемле генә, елгыр һәм хәйләкәр абзый ул. Иван каенатасын өнәп бетерми. Наум да кызын җәлләп кенә, Иванның кыланмышларына түзеп тора иде.

—Ни хәлләрегез бар?.. Һаман йоклап ятасыңмыни?—диде Наум, кера-керешкә үк сүз башлап. —Их-ма! Болай булсаң, Ванечка, теге дөньяга да йоклап калырсың инде.

—Анда барырга ашыкмыйм әле мин.

—Ашыксаң да зыян итмәс иде... Әйдә, тор әле. Утынга барып кайтыйк. Бригадирдан ике ат сорап алдым. "Майларга" туры килде-килүен, ярар инде, чукынып китсен! Утыны да кирәк бит.

Иван, тагын бераз ятканнан соң, торып, сөйләнә-сөйләнә киенергә тотынды:

—Яшьләр ник шәһәргә китә дип беләсең? Чөнки анда норманы үтәдеңме, син—үзеңә үзең хуҗа. Кешегә ял итәргә ирек бирәләр ичмаса. Монда—Алла каргаган диярсең, көн дә юк, төн дә юк. Якшәмбе дә юк.

Иванның хатыны Нюра да сүзгә кушылмый түзә алмады:

—Утынсыз калыйкмыни инде алайса? Ат сорап биргәнгә рәхмәт әйтәсе урында, киреләнеп торган буласың.

—Шәһәрдә дә эшләргә кирәк,—дип куйды каената.

—Кирәк инде анысы. Тик мин рәхәтләнеп җир казырга да китәр идем. Җан тирләрең чыкканчы бер эшлисең дә, аннары кайгы-мәшәкатьсез рәхәтләнеп яшисең. Өеңә суы да, җылысы да кергән.

—Бер караганда, өйгә су кертү әйбәт нәрсә инде ул үзе. Ә икенче яктан—начар: аннары син бөтенләй йокы чүлмәгенә әйләнер идең. Йә ярый, киттек әйдә.

—Ашап аласыңмы?—дип сорады Нюра.

Иванның әле ашыйсы килми иде. Наум, кызыксынып:

—Кичтән эчкән идең мәллә?—дип сорап куйды.

—Дөп-дөрес, галиҗәнап әфәнде!

—Һе-е… Менә бит хикмәт нидә. Ә син, өйгә су кергән, водопровод, дисең… Әйдә, китик булмаса.

Күк йөзе чалт аяз, ап-ак карның кояшта җемелдәвеннән күзләр камаша. Урманда ниндидер ят, сәер тынлык хөкем сөрә.

Барасы юллары шактый озын, егерме чакрымлап булыр. Агачны якын-тирәдән генә кисәргә рөхсәт итмиләр.

Наумның аты алдан кузгалды:

—Шайтан алгыры!.. Утын эзләп урманнан урманга бар инде,—дип зарланып алды ул.

Чана табанының салмак кына көйләп баруыннан Иван йокымсырап китте.

Урман ызанын үтеп, ачык уйсулыкка төшкәч, акрынлап тауга күтәрелә башладылар. Тау башында яңадан, күгелҗем стена булып, урман тотына.

Менеп җитәбез генә дигәндә, ни күрсеннәр: юлдан ерак та түгел, урманнан чыгып басканнар да атлыларны сабыр гына көтәләр—бүреләр!

Наум атын туктатты. Үзе дә сизмәстән, акрын тавыш белән, сузып кына:

—Анаңны-ы…—дип сүгенеп куйды. —Котырыннармыни, тезелешкәннәр!

Иванның аты, яшьлеге белән куркып, артка чигә башлады, шулчак бер аягы тәртәнең тышына чыгып китте. Иван, кирегә борылмакчы булып, дилбегәне селкеткәләп караса да, бичара ат, хырылдап, бер урында тыпырчынып тора, тәртә аша аягын алалмый иде.

Ул арада бүреләр түбән таба кузгалдылар.

Наум, түземсезләнеп, Иванга кычкырып җибәрде:

—Нәрсә мыштырдыйсың инде?!

Иван, чанасыннан сикереп төште дә, этеп-төртеп, көч-хәл белән, атны тәртә арасына кертте. Ярый әле үзе чанасына авып өлгерде—ат, баскан җиреннән үк кисәк борылып, алга ыргылды.

Наум инде шактый ераклашкан, үзен-үзе белештермичә, бар көченә:

—Талыйла-а-ар!—дип акыра-акыра, атын чыбыркылый.

Бүреләр, соры йомгаклардай иплән кенә түбәнгә тәгәрәделәр—атлыларның юлын кисәргә чамалыйлар.

Наум һаман:

—Талыйла-а-ар!—дип илерүен белә.

“Әллә “ычкына” башлады инде бу?!—дип уйлап алды Иван. —Кем талый? Кемне?”

Сәер бер халәт кичерәләр болар—хәвефле үзе, шул ук вакытта галәмәт кызык та. Ләкин тиздән кызыкларның эзе дә калмады. Көләсе килми иде инде. Бүреләр юлга төшеп җиткәннәр, чанадан йөз адым чамасы гына арттарак, җепкә тезелгәндәй, куып киләләр. Чана үрәчәсенә чытырдап ябышкан Иван алардан күзен дә алмый.

Киң күкрәкле, өтек танаулы зурысы иң алдан элдертә. Аңардан чанага хәтле егерме-утыз адым гына калып бара. Иванның бүреләрне болай ук якыннан күргәне юк иде әле. Шуңа күрә ул аларны, зуррак этkә охшаганнардыр, дип йөри иде. Хәзер аңлады инде, бүре—бүре шул, чын ерткыч икән! Иң явыз этне дә соңгы мизгелдә, куркытыпмы, юмалапмы, туктатып калып була. Ә бу көйгән танауны үлем генә туктата алачак. Ырылдамый, куркытып маташмый. Түгәрәк сары күзләре белән туп-туры карап, корбанын эзәрлекләүне белә.

Иван чанага күз төшереп алды—берәр таяк кисәге дә юк ичмаса. Балталар икесе дә каената чанасында. Калдык-постык печән бар да, кулында чыбыркысы бар.

Наумның: “Талыйла-а-ар!”—дип кабат акырган тавышы өстәлгәч, Иван чын-

чынлап куркуга төште. Өер башы, атка сикерергә чамалап, чананы урап уза башлады... Иван сул кулы белән чана кырыена тотынган көе бераз күтәрелә төште дә өер башлыгына чыбыркысы белән шәпләп берне сыдырды. Моны көтмәгән бүре юлыннан тайпылды, тешләрен шыкылдатып, читкә сикерде. Арттан килүчеләре, туктый алмыйча, аның өстенә өелеште. Бер мәлгә бөтен өер бергә укмашты. Башлык, ачуланып, бүреләрнең әле берсен, әле икенчесен тешләп алды. Аннары, яңадан алга чыкты да тиз арада чананы куып җитте. Иван тагын калкынды, тагын берәрне эләктерергә иде исәбе. Тик бу юлы инде бүре чананы ерактанрак әйләнеп үтте. Ә берсе, хәтта өердән аерылып, чананың икенче ягына төште.

Иван чыраен сытты... "Беттем. Әҗәлем шушы икән!"—диде ул тешләрен кысып.

Наум әле дә булса атын чыбыркылый. Менә ул борылып карады. Киявенең камалышта калуын күргәч, ялт итеп башын кирегә борды.

—Талыйлар!

—Атыңны тыя төш, әткәй! Балтаны бир!

—Талыйлар!

—Тый атыңны, котылабыз!.. Атыңны тый, дим, хайван!

—Син аларга бирәр нәрсә ташла!—дип үкерде Наум.

Өер башы инде ат белән тигезләшкән, сикерергә җыена. Арттагылары да яп-якын: аз гына соңладың исә, чанага "очып" менәчәкләр. Иванның ыргыткан бер уч печәненә бүреләрнең исе дә китмәде.

—Әткәй дим, эт җан, тый атыңны, балтаны ыргыт!

—Ванька!.. Тот, ыргытам!..—дип, ниһаять, Наум балтаны юл кырыена ташлады.

Иван, чанадан сикереп төшкән хутка, балтасын эләктереп алды. Арттан ажгырып килгән өч бүре сискәнеп читкә каерылды һәм аңа ташланырга әзерләнеп, адымнарын акрынайтты. Нәкъ шул мизгелдә башлык, аяк астында кар катысын тоеп, ат өстенә сикерде. Коты алынган ат, юл кырыена авышып, көрткә чумды. Чана әйләнеп капланды, түшлек каешы шартлап өзелде. Камыт бугазын китереп кыскач, ат мескенкәй, тәртәләр арасында бәргәләнеп, хырылдый башлады. Ул арада икенче яктагы бүре, астан һөҗүм итеп, үткен тырнаклары белән атның корсагын аерып төшерде. Калганнары да корбанга ябырылды.

Минут эчендә, бишесе бер булып, әле җаны да чыгып җитмәгән атны ботарлый, пар бөркеп торган күгелҗем-кызыл эчәкләрне күз камаштыргыч ак кар өстендә сөйрәп йөртә һәм канәгатьлек белән ырылдыйлар иде инде.

Бу хәлләр шундый коточкыч тиз булып узды ки, хәтта өндәге маҗара икәненә ышануы да кыен. Иван, балтасын кулына тоткан да, комсызланып сыйланып ятучы бүреләргә карап, исен җыя алмый басып тора. Өер башы, түгәрәк сары күзләре белән бораулагандай, адәми затка төбәп-төбәп карап алгалый...

Шушы тантаналы оятсыз караш Иванны дөньяга кайтарды. Ул, балтасын күтәреп, җан ачысы белән бар көченә кычкыра-кычкыра, бүреләр өстенә ташланды. Тегеләр, канлы авызларын ялаштырып, теләр-теләмәс кенә читкә тайпылдылар. Алар шулчаклы тырышып, мавыгып ялманалар—балталы кеше алар өчен әллә бар, әллә юк. Өер башы гына, игътибарын киметмичә, туп-туры карап тора. Иван, дөньядагы иң әшәке сүзләр белән сүгенә-сүгенә, балтасын селтәп, башлыкка таба юнәлде. Тик, бүре урыныннан кузгалмагач, Иван да туктарга мәҗбүр булды.

—Сез җиңдегез,—диде ул.—Тыгыныгыз, хәшәрәтләр!

Аннары Иван, ботарлап ташланган ат ягына карамаска тырышып, авылга таба атлады. Шулай да, артына борылып карамый түзмәде. Кызганудан җаны әрнеде, бөтен күңелен каенатасына карата ачу биләп алды һәм ул, тиз-тиз атлап, авылга таба юл тотты.

—Күрмәгәненне күрсәтәм әле мин сиңа, юха елан! Котылып кала идек бит, атка да берни булмас иде. Куркак җан!—дип, ачуына чыдаша алмыйча, үзалдына сөйләнеп барды Иван.

Наум киявен борылышта көтеп торган икән. Аны исән-сау күреп, чын күңеленнән сөенде ул:

—Исән икәнсең! Аллага шөкер! —Ни дисәң дә, аны вөҗданы газаплый иде.

—Исән!—диде Иван, кара янып. —Син дә исән икәнсең!..

Наум, кияү тавышында усаллык төсмерен тоеп, шикләнеп куйды. Алай-болай булса, дип, чанасына ук менеп утырды.

—Нишли тегеләр?
—Сиңа сәлам әйттеләр. Куркак җан!..
—Син нәрсә? Нигә җикеренәсең әле?
Иван чанага якынлашты:
—Җикеренеп кенә калмыйм, тотып кыйныйм әле мин сине.
Наум, атына чыбыркы белән сыптырып, тизрәк китү ягын карады. Иван аның артыннан ыргылды:
—Тукта! Тукта, хөрәсән!
Наум аның саен атын ныграк куалады. Хәзер инде бөтенләй башка ярыш башланды: кешеләр бер-берсен куа.
—Тукта дим мин сиңа!
—Саташкан!—дип кычкырды Наум, аңа каршы.—Ник каныгасың миңа? Тилердең мәллә? Минем ни гаебем бар?
—Ни гаебем бар, имеш?!. Ычкына идек без, ә син хыянәт иттең!
—Ни сөйлисең?! Ычкынырсың алардан, бар!
—Юха елан! Акылга утыртам әле мин сине! Качып котыла алмассың, тукта яхшы чакта! Хәзер кыйнасам, үзеңә ояты азрак булыр. Барыбер ярам, кеше алдында булса да. Кемлегеңне сөйләп тә бирәм... Яхшылык белән тукта!
—Хәзер, туктады ди! Тот капчыгыңны!—диде Наум, атын чыбыркылый-чыбыркылый. —Әрәмтамак... Башка бәла булдың инде бер!
—Тыңла сүземне—тукта! —Иванның инде сулышы кысыла башлады. —Үзеңә җиңелрәк булыр: хәзер тукмыйм да беркемгә берни әйтмим.
—Син ыштансыз иблисне, кешегә санап, гаиләбезгә керттек. Ә хәзер миңа балта белән кизәнәсең! Оятың бармы бераз, юкмы?
—Башта тотып ярам әле, кемнең ояты барын-югын аннары тикшерербез. Тукта!—Иван, ярыйсы ук артта калгач, куып җитә алмаслыгын аңлады да адымга күчте. Алай да, каенатасы артыннан:
—Барыбер табам мин сине, беркая киталмассың!—дип кычкырып калды.

Иванның өендә кеше юк иде. Ишектә йозак эленеп тора. Йозакны ачып, эчкә керде дә, шкафта актарынгалап, кичтән калган аракы шешәсен тапты. Салып, бер стакан эчкәч, туп-туры каенатасы йортына китте.
Ишегалдында тугарулы ат тора иде.
—Өйдә-ә...—дип куйды Иван, канәгатьлек белән. —Менә хәзер арт сабагын укытам мин аның.
Ишекне төртеп караса—бикләнмәгән. Ә ул, бикле булыр дип уйлаган иде. Аның килүен көтеп торганнар икән: өйдә хатыны, каенатасы һәм милиционер утыра иде. Милиционер, елмаеп каршы алды:
—Нихәл, Иван?
—Алай икә-ә-н... Алып та килдеңмени?—дип битәрләде Иван каенатасын.
—Алып килдем, алып килдем! Тамак төбеңне чылатып өлгердеңме соң әле?
Иван урындыкка утырды да:
—Җибәрдем бераз... Сүз ялгансын өчен...—дип куйды.
Нюра гасабиланып сикереп торды:
—Нишләвең инде бу, Иван? Шаштың мәллә?
—Әтиеңне акылга утыртмакчы идем. Кеше булырга өйрәтәсе бар.
Сүзгә милиционер кушылды:
—Ташла әле, Иван. Бәхетсезлек булган инде, ярар. Икегез дә курыккансыз. Кем белгән бит аны, шулай килеп чыгар дип. Бернишләп тә булмый—язмыш инде ул.
—Без икәүләшеп җиңел генә котыла ала идек. Мин алар белән берьялгызым калдым бит...
—Соң мин сиңа балта ыргыттым лабаса? Син сорадың—мин ыргыттым. Тагын ни кирәк инде?
—Әлләни күп тә түгел: кеше булуың гына кирәк иде. Ә син шыр җибәрдең. Арт сабагыңны укытмый калмыйм барыбер.
—Кайдан килгән укытучы! Маңка... Шыр ялангач килеш, әзергә-бәзер, йортка килеп керде дә, янап маташа бит әле. Җитмәсә, ризасызлык белдерә әле ул, водопроводыбыз юк, имеш!

—Эш анда түгел бит, Наум,—диде милиционер. —Водопроводның ни катнашы бар монда?!

—Авыл тормышы начар имеш, аңа! Шәһәрдә рәхәт!—дип, зәһәрләнеп дәвам итте Наум. —Ни пычагыма өстерәлеп кайттың соң алайса? Зарланып йөрергәме, халыкны Совет властена каршы котыртыргамы?

Иван, гаҗәпләнүеннән, сикереп үк торды:

—Эт икәнсең!

Милиционер да аягына басты.

—Җитте сезгә! Киттек, Иван…

Наум һаман тынычлана алмый иде әле:

—Синең кебек котыртучыларны, беләсеңме, кая тыгалар?

—Беләм! Бәкегә, баштүбән…—диде Иван һәм каенатасына таба бер адым атлады.

Милиционер, Иванны култыклап, өйдән алып чыгу ягын карады.

Урамга чыккач, туктап, тәмәке кабыздылар.

—Кара әле, паразит түгел диген син аны!—диде Иван, исе китеп. —Мине гаепли бит җитмәсә!

—Ташла әле шуны!

—Юк, мин аны кыйнарга тиеш!

—Үзеңә эләгәчәк бит аннары. Бер шакшы аркасында…

—Кая алып барасың инде мине?

—Әйдә, бездә кунарсың. Бераз суынырсың да. Бәйләнмә. Соңыннан үзеңә кыен булуы бар.

—Ул бит… Нинди кеше ул, ә?

—Ярамый, Иван, ярамый! Хаклыгыңны йодрык белән исбатларга калгач, булмый инде ул.

Алар, сөйләшә-сөйләшә, милиция бүлегенә юнәлделәр.

—Ник тегендә генә кыйнамадың соң?

—Куып тота алмадым шул! —Иванның тавышы үкенечле иде.

—Менә бит… Хәзер—соң инде, хәзер ярамый.

—Ат җәл.

—Җәл дә соң…

Озак кына дәшми бардылар. Шактый барганнан соң, Иван туктап калды:

—Җибәр син мине, ә? Нишләп ятыйм инде анда якшәмбе көнне?! Курыкма, тимим мин аңа.

—Барыйк әле, барыйк. Ахыры начар булмагае. Сине җәлләп әйтәм. Шахмат уйнап утырырбыз… Шахмат уйный беләсеңдер ич?

Иван кар өстенә тәмәке төпчеген төкереп ташлады да, яңасын эзләп, кесәсенә тыгылды:

—Беләм.

***Фәния Шәрәфетдинова***

*тәрҗемәсе.*



## Гөлзада Әхтәмова

# ГАЛӘМ, ДӨНЬЯ, ТОРМЫШ МӘГЪНӘЛӘРЕ

### Өермәләр

**Өермәләр, көчле өермәләр!—**
**Буйсындыра азмы язмышны...**
**Аның тырнагыннан исән-имин**
**Бу дөньяда сирәк калышлы...**

**Өрмәләр, көчле өермәләр!**
**Сайлап микән ала үзенә?**
**Карата ул көчләп газиз җанны,—**
**Буйсындыра дәһшәт күзенә.**

**Өермәләр, көчле өермәләр!**
**Бөтерелеп, гүя, яшәдем...—**
**Күңелдә бар бер горурлык хисе:**
**Каршы килеп мин дә яшьнәдем.**

**Өермәләр, көчле өермәләр!**
**Баганасы буең җитмәслек...**
**Галәм, Дөнья, Тормыш мәгънәләре**
**Бер гомергә сыеп бетмәслек.**

### Вакыт

**Вакыт һәрчак үзгәрүчән:**
**Йә тиз уза, йә—әкрен.**
**Мизгелләр кушылу көчен**
**Үзенчә тоя һәркем.**

Гөлзада ӘХТӘМОВА – *шагыйрә; "Йөрәгемдә яшен", "Мәхәббәтле иреннәр", "Зәңгәр хыял" һ. б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Алабугада яши.*

Шатлыкта һәрчак ашыга,
Үтә дә китә генә.
Кайгыда исә үз итеп
Ябыша итәгеңә.

Көтүләр озак тоела,
Минуты еллар кебек.
Һәм вакыт үзенчә сынап,
Торадыр синнән көлеп.

Чәчләргә бәсләр кундыра,
Битләргә эзләр сыза.
Төрлечә үткән вакытта
Бербөтен гомер туза.

## Истә!

Бер хәтерсез халык җирдә булмас инде,
Булса әгәр, бер эше дә уңмас иде.

—Истә, истә!—дибез, гүя ядәч кулда,
Оттырмаска инде безнең исәп алда.

Истә, истә! Йөрәкләрдә сагыш уты,
Күз яшьләрен халкым ничә гасыр йотты.

Иделкәем дулкынлана ил-җиремдә,
Суларында аккан башлар хәтерендә.

...Истә, истә Сөембикә һәм Үтәмеш!..
Тарих битләрендә ята бар үткән эш.

Буыннардан-буыннарга күчә хәбәр,
Онытылмый фаҗигале хәвеф-хәтәр.

Истә, истә! Шәһитләргә дога кирәк.
Шул догадан тынычланыр, бәлки, йөрәк...

И мөкатдәс, и кадерле туган илем!
Кайгылардан арынырмы күңел күгең?..

## Кашкарыйлар

Гомер көзләренә керелсә дә,
Кашкарыйлар мине үз итә.
Кашкарыйлар үскән гөлбакчамда
Авыр көннәрем дә тиз үтә.

Кашкарыйлар—сабыр, чыдам гөлләр,
Салкыннарга озак түзәләр.
Җәйге гөлләр сулып бетсәләр дә,
Кашкарыйлар һаман гүзәлләр.

Төнлә кырау тимәгәнме, диеп,
Таң атуга күзлим аларны.
Кашкарыйлар—җәйдән калган бизәк,
Дәртләндерә моңсу уйларны.

Гомер күзләренә атласам да,
Йөрәгемдә җәйге кичләр бар;
Кашкарыйлар көнләшерлек сөю—
Мәңге кырау төшмәс хисләр бар.

## Хәбәр

Хәлең ничек?
Бик беләсем килә.
Артык кызыксынам, билгеле.
Синең хакта һәрбер хәбәр—шатлык.
Аны ишетүе күңелле.

Синең хакта һәрбер хәбәр—тансык,
Тик соңгысы гына булмасын,
Соңгы хәбәр—соңгы сулышың булып,
Күңелкәем генә тулмасын.

Без аерым. Аерым да түгел:
Хәбәрләр бит уртак серләләр.
Галәмнең бер олы йомгагына
Уралгандыр безнең сөюләр.

## Хуҗабикә мин түгел

Синең йортың матур икән,
Курчак өе кебек җыйнак.
Байлыгың да юк, булганы—
Үзең кебек сабыр, тыйнак.

Белдем инде
Менә шунда
Үтәр синең картлык көнең.
Яшьлегеңнән сәлам алып
Килүче мин бары—бүген.

Бакчаңда гөлләр елмая.
Дулкынлана нечкә күңел:
Бу хуш исле сиреньнәрнең
Хуҗабикәсе мин түгел...

Уңган икән, җитез икән,
Чибәр икән киленнәрең.
...Нәкъ синеке кебек калын
Оныгыңның иреннәре!

## Үтте инде

Үтте инде яшь һәм чибәр чаклар.
Гомер җиле барын тараткан.
Ләкин йөрәк һаман сөеп тибә,
Мин барыбер әле яратам.

Алсу томан аша килгән хатлар
Укылдылар бар да ачылып.
Яшәү көче биргән ул хыяллар
Һаман әле ала очынып.

Үтте инде яшь һәм чибәр чаклар.
Гомер күзе үзен сиздерә.
Тик шулай да гүзәл мизгелләре
Хыял диңгезендә йөздерә.

Ап-ак томан аша салкын яңгыр
Айныттыра татлы уйлардан.
Мәхәббәтнең, ләкин очкыннары
Күтәрелә әллә кайлардан.



# Вячеслав Ар-Серги

## БУ—БОРЫНГЫ ҺӘМ МӘҢГЕЛЕК ДӨНЬЯ

### Ай кызы

Күккә бактым—әллә күзгә күренә,
Айда бер кыз су алып кайтып килә.

Оча белсәм, очар идем янына,
Әйләнер идем, шәт, сөйгән ярына.

Күз төбендә әче яшьләре тагын—
Иреннәрен киптерер иде аның.

Көянтәсе, буйсынып мәхәббәткә,
Иңнән иңгә күчәр иде, әлбәттә.

Бер үзенә бик күңелсездер аңа.
Кем бар йөзен ай суында юарга?

Бергә булсам, мин дә инде шул суны
Эчә-эчә мактар идем ул кызны.

Ах! кызганыч—шулай булыр иң соңы—
Миңа язмас Айның татлы бу суы.

Мизгел көтми, яшерен, кысып тынны,
Очар идем, ташлап бу ятагымны.

...Мөмкин түгел, янымда йоклый—әле
Кичә генә миңа су китергәне...

### Аю биюе

*(Кыйланчык кәләш җыры)*

Шундый оятсыз! Артымнан калмый һич тә!
Йә өненә, йә дәшә печәнлеккә.

Вячеслав АР-СЕРГИ (1962) – *Удмуртиянең халык язучысы, шагыйрь, тәрҗемәче, күпсанлы китаплар авторы. Ижауда яши.*

Шундый сыйлады татлыдан, туйганчы,
Акчасын түккәндер әле бер капчык...

Җырлыйм, дидер, минем тәрәз төбендә
Аю булып үкерә төннәремдә.

Биегәндә аю кебек кочаклый,
Оялуларымнан үләм, шул чакны!

Анам биргән туфлиемнең үкчәсе
Актарылды, инде хәзер нишләсе?

Җонлач аю! Тик татлы кочак кына!
Культуралы булса иде чак кына?

...Кәкре аяк, кая күзең тондырдың?
Үз өеңә алып китче? Сындырдың!

Минем белән кеше булып китәрсең—
Мин булмасам, мөгаен, дим, бетәрсең!

## Джоконда

*(Күзгә күренү)*

Әнә ул—каршыңа килә, йөзеп кенә атлап,
Югалган илаһилыкны нәкъ илаһи саклап...

Янәшәсеннән изелгән трамвай да үтә,
Хәтта җил дә юл биреп ташлана бит читкә.

Бәндәләр алга ашыга, аяк өсте йоклап—
Сумкаларда көнлек хәсрәт тутырылган шыплап.

Ә барыбер һәммәсендә яшәргә тырышлык—
Башлар пеләш. Ә күкрәктә, җаннарында бушлык.

...Мәнсезләр иле өстеннән атлап килә ул. Әйе!
Аны күреп мәнсезләрнең ага селәгәе...

Берсенә игътибар итми атлап узмасынмы!—
Күлмәк табангача. Үзе сүзсез. Үзе гүзәл сынлы.

...Бу калада яшәп ята йөзләп төрле милләт.
Урыс телендә сөйләшеп, үз теле юк иләт.

Кичә ир-ат булганнары белми хәтта атын:
Үз туганы туган түгел, туган, имеш хатын.

Милиция басып тора, әнә, тукталышта.
Аңлапмы, аңламыйчамы, аваз бирә:—Тукта!

Тик тавыш тамактан чыкмый, чыга эчәгедән.
(Баш үлеп авырта әле һаман кичәгедән).

Ә ул уза горур атлап, иңнәр кагып кына.
—Кем буласың?
—Джоконда!
Сержант әле аңламыйча тора.

Ә ул китеп бара җиңел генә, йөзеп кенә атлап,
Югалган илаһилыкны үз-үзендә саклап.

## Синнән башка

Без китәрбез, бу борынгы һәм мәңгелек дөнья калыр.
Безнең кабер ташы
Мүк белән капланыр.

Безнең өстә ап-ак каен шаулар, үсәр өянкеләр.
Көз килер дә... яфракларны сибеп,
Матурлыкны сөйләр.

Күке авазы да каберлектә гомер санап үтәр.
Аның авазын да өзеп, бер көн
Кыш патшалык итәр.

Нәүмиз калганнар да килеп елар. Елар—бездән соң да...
Тик син булмассың шул инде
Алар арасында.

Шәм дә янып бетәр.
Кемнең бармагына мае тамар?
Ут-ялкынның соңы булыр алар.

Ут калтырар
Әтәч кикригедәй,
Соңга калып, тәмам
Соңга калып янар.

## Әрнү

Бер сүз дәшми
Бергә басып тордык—
Бөдрә чәчең шаян җил тарый.

Үлән сары,
Урман—яфрак яңгырында иде.
Ә чын яңгыр коя—туктамый.

Кыш та керде,
Ә без гел дәшмәдек.
Гел дәшмәдек, елга бозланды...
Кар да төште.
Төнге салкын суык
Безнең сүзсезлектән сызланды.

Исем китте,
Сүзләр кая китте?—
Сиңа әйтелмәгән сүзләрем...
Күктә очкан җыр иде бит алар,
Ишеттем мин аны,
Эзләдем.

Әйтелмәгән сүзләрең дә, бәлки,
Язмышыңны шулай кыладыр.
Ул нәфрәт тә,
Мәхәббәт тә булып—
Иң соңыннан әрнү буладыр.

Сүзсезлек тә узмый
Сүзсез генә...
Әрнүләр дә узмый эзсез генә.

***Мөдәррис Әгъләм***
*тәрҗемәләре*

## Мөхәммәт Гали

# ПОЖАРНЫЙЛАР

I

Мин белә килгәннән бирле, елнын елында безнең әти Шәфыйк бабай белән бергәләп каравыл ала.

Безнең авылның каравыл өендә искереп беткән бер насос, ике мичкә, өч багор, биш-алты көрәк, бер-ике балтадан башка бернәрсә дә юк. Халык ярлы, авыл кечкенә булганлыктан, әллә ничә елдан бирле җимерелеп ята торган каравыл өен төзәттерергә дә җәмәгатьнең хәленнән килми. Җитмәсә, узган ел игеннәр начар булганлыктан, авыл расходлары өчен халыктан иманага кушып җыела торган мир акчасы да җыелмаган. Расходка акча кирәк. Олы урамнан чыга торган зиярат башындагы күпер дә җимерелгән, тегермәнче тегермәнне дә будырмый, ди. Волость ямщигы ялларга да акча килеп сораганнар, мөгәҗи келәтенең дә түбәсеннән яңгыр үтә башлаган...

Менә шуларның һәммәсенә бик тиз генә акча кирәк булган да, беркайдан да таба алмагач, старостаның әйтүе буенча, җәмәгать каравыл өендә тора торган бердәнбер атны сатып та җибәргән. Инде хәзер: "Каравыл алган кеше үзе ат куйсын",—дип әйтәләр икән.

Менә безнең әти белән Шәфыйк бабайга аяк астыннан килеп чыккан кайгы!

Безнең әти узган ел көз, кыш ашатып чыгарга печән дә, салам да юк, дип, чаптар бияне сатып, аның урынына, ат орлыгы калса ярар, кечкенә тамак булыр, дип, икенче яшькә чыккан гына калган кырыкмыш тай алып калдырган иде. Аны бу ел сабан тырмасына да җигәрлек түгел. Инде Шәфыйк бабайның гомер буена аты булганы юк.

Әти аптырады.

—Инде нишләргә кирәк, быел да бит каравылны башка кешегә ычкындырмыйсы иде,—ди.

Әни әйтә:

—Юкка борчылма, атасы, аңа карап ачка үлмәбез әле, сине бит быел десятник тә итеп билгеләгәннәр, ике көймәнен койрыгын берьюлы тота алмассың,—ди.

Әтинең аласы килә, минем дә ике ел рәттән җәйнең җәй буе, әтиләр эштә йөргәндә, каравыл өенең сәндерәсендә йомшак печән өстендә пожар каравыллаган булып, Шәфыйк бабайның яшь вакытта башыннан узганнарын һәм әкият сөйләгәннәрен тыңлап ятканнар искә төшә дә, бер дә каравылны чит кешегә ычкындырасы килми. Үз-үземә эчтән генә: "Быел да каравылны без алсак, тагын шулай күңелле булыр иде бит",—дип куям.

Бервакытны безгә, йөгереп, тирләп-пешеп, таякка таянган Шәфыйк бабай килеп керә.

—Гыйлаҗи! Кырыкмышыңны каравылга куярга риза буласыңмы,

җәмәгать җыенында халык җәй буена акчалата егерме сум, биш арба ботак утыны, көзгә ун пот арыш бирергә булды. Сукыр Исмәгыйль белән Әсфәндияр акчалата утыздан кимгә риза булмыйлар, җәмәгать аны кыйбатсына,—ди.

Әти әйтә:

—Мин бик риза булыр идем дә, Шәфыйк абзый, кырыкмышка җәмәгать риза булмас. Алай-болай ут-күз булуы бар бит,—ди.

—Кешегә караганда түбән бәягә алучы булгач, җәмәгать риза була инде ул, әллә ничә елдан бирле авылда бер кара мунчаның да янганы юк бит әле, ник риза булмасын, тик мине генә каравылдан калдырма, анысын мин үзем рәтлим инде,—дип Шәфыйк бабай кулларын селеккәләп чыгып та китте.

## II

Халык сабан чәчәргә чыккан көнне без Шәфыйк бабай белән каравыл өе янындагы лапаска кырыкмышны илтеп бәйләдек.

Шәфыйк бабай кыштан туңып калган мичкәләрдәге бозларны чаба, насос куйган, багорлар, баскычлар төягән арбаларны рәтли; мин, лапас түбәсенә менеп, Шәфыйк бабай белән икебезгә кич кунарга урыннар әзерлим, кырыкмыш кырт-кырт итеп утлыктан печән ашый.

Шулай итеп, без өч "пожарный" бик ныклап пожар сакларга керештек. Шәфыйк бабай өенә дә кайтмый:

—Элек көнне үк ташлап китәргә ярамас, кеше-фәлән килүе бар,—ди.

Кич була, кояш байый, эңгер-меңгер житә...

Көндезен көн кояшлы, матур, җылы булуга карамастан, кичен суыта. Шәфыйк бабай белән без чикмәннәргә төренеп утырабыз.

Көне буе сабан сукалап, җир сөреп, арып-талып кайтуларына карамастан, каравыл өе ачылганны ишетеп, төрле яктан безнең янга авыл егетләре җыелалар. Аларның кайсы тәмәке тарта, кайсы салмак кына көйгә гармун уйный, кайсы авыз эченнән генә, моң гына итеп гармун көенә көйләп утыра. Шәфыйк бабай аларга:

—Нихәл, егетләр, җир юеш түгелме, калакка балчык сыланмыймы?—ди.

Егетләрнең кайсы: "Юеш әле, ике-өч көнсез сукаларга ярамый",—ди. Кайсы: "Бик кибешкән инде, ярый",—ди. Кайсыберсе аты йөрмәүдән, кайсыберсе, көне буе йөреп, җирен таба алмый кайтудан, кайсылары чәчәргә орлык житмәүдән зарланалар.

Шулай итеп, без, ястүгә мәзин азан әйткәнче, алар белән сөйләшеп утырдык та, аннан соң Шәфыйк бабай:

—Бар, кайтыгыз инде, егетләр, иртәгә иртә үк сезнең дә эшкә барасыгыз бардыр, безнең дә йокы килә башлады,—дип аларны лапастан чыгарып җибәрде.

Алар киткәч, Шәфыйк бабай белән лапас түбәсенә менеп, печән түшәп, өсләргә чикмәннәр, туннар бөркәнеп яттык.

Шәфыйк бабай каравылны эләктереп калганга куана:

—Аз булса да, аның акчасы килеп тора бит, көзгә игеннәр уңса, арышы булыр, аның өстенә имананы ярты гына түлибез. Әле дә ярый Исмәгыйль белән Әсфәндиярга ычкындырмадык. Алар байлар бит, алган булсалар, бер ат урынына ике ат та куйган булырлар иде,—ди.

Мин аңа:

—Барыбер йокы да килми, әкият сөйлә әле, бабай,—дим.

Ул:

—Әкиятне башка вакытта сөйләрмен әле, мин сиңа хәзер яшь вакытта үземнең Кара диңгез ягында күмердә эшләгәннәрне, солдатта йөргәннәрне,

Гөлсәхип әбием белән бергәләп Җаек буенда алпавытларга урак урып, печән чабып йөргәннәрне сөйлим,—ди.

Бабай, уналты яшьтән башлап, солдатка алынганчы, үзенең Кавказ ягында, Кара диңгез буенда күмер эшләгәннәрен, анда күргән азапларын, шуннан солдатка алынып китеп, ун елга якын Себер ягында солдат булып йөргәннәрен, аннан кайтып, Гөлсәхип әбигә өйләнүен, аның белән бергә тора башлагач, көнкүрешләре бик артык начарланып киткәнлектән, җәяүләп Җаек суы буена барып, анда алпавытларга урак урып, печән чабып йөргәннәрен берәм-берәм бик озын итеп сөйләп бирде.

Бабайның сүзләрен бик җентекләп тыңлап яттым; үземнең дә аның кебек йөрисем, аның кебек дөнья күрәсем, мәшәкать чигәсем килә башлады.

Кырыкмыш лапаста һаман да кырт-кырт иттереп бик салмак кына печән ашый. Югары урамда бер эт "һау-һау" килеп бертуктаусыз өреп тора. Ул арада бер-бер артлы таң әтәчләре дә кычкырырга тотындылар.

Без дә:

—Йоклыйк инде, иртә торасы булыр,—дип, бабай белән бер чикмән астына кереп, кочаклашып йоклап киттек.

III

Мин, йокы арасында берөзлексез сыерлар мөгрәгән, сарыклар кычкырган, казлар кыйгаклаган, үрдәкләр бакылдаган, әтәчләр кычкырган, тавыклар җырлаган, кырыкмыш кешнәгән тавышларны ишетеп, шулар белән саташып ятам.

Бабай мине уята:

—Тор, тор, улым! Кояш чыккан инде, халык көтү куа, кырыкмышың да кешни, әчәсе килгәндер, ахры!—ди.

Мин яткан урыннан сикереп тордым да үземнең бабай белән бергә каравыл өе лапасының сәндерәсендә ятканлыгымны күреп, шатланып киттем. Кыш буе тар гына, тәбәнәк кенә өйнең мич башында йоклап килгәнлектән, бүген үземне мондый иркендә күрү дөрестән дә минем өчен зур бәхет иде. Шатланмаска да мөмкин түгел.

Торгач та, миңа беренче эш—кырыкмышны эчертергә кирәк. Аңар атланам да инешкә төшеп китәм.

Көн бик матур, кояш та күтәрелә башлаган. Яшь кызларның, яшь киленнәрнең кайсы көтү куа, кайсы инештән су китерә, ирләр сабаннарын, сукаларын шалтыратып кырга китәләр. Бөтен авыл кайный...

Кырыкмышны эчертеп менәм дә, өйгә кайтып, чәй эчеп киләм. Ә бабайга инде Гөлсәхип әби өеннән китереп кенә ашата, кайтса, әллә нигә бер чәйгә генә кайтып килә ул.

Бабай көнне тик кенә уздырмый, шөшлесен алып, бүкәнгә утыра да чабата ясарга керешә.

Миңа да әйтә:

—Син дә тик кенә, уен артыннан йөреп кенә, көнеңне уздырма, улым, эшкә өйрән, менә шул чабата ясарга гына өйрәнсәң дә ярар. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дигәннәр борынгылар, үсеп буйга җиткәч, анысы да кирәк булыр,—ди, мине үз янына чабата ясашырга утырта.

Шулай итеп, бабай белән безнең көннәр бер-бер артлы бик күңелле генә узалар. Минем өйгә дә кайтасым килми, малайлар белән уйнарга да артык ихлас юк. Лапасны бик әйбәтләп каравыллыйбыз, кырыкмышны бик шәпләп ашатабыз. Әти рәтләп килеп тә карамый, туры килгәндә, кешеләргә ара-тирә генә:

—Минем малай да эшкә ярый башлады инде,—дип мактангалап та алгалый.

## IV

Гөнаһ шомлыгына каршы, беркөнне кичкә кырын бабай, лапаста мине генә калдырып, ике-өч чакрымлык күрше авылдагы бер кибетчегә үзенең ясаган чабаталарын сатарга дип киткән иде. Әти, берәүдән ат алып, кулалмашка сукага киткән. Мин бабайның чабатасын тезеп утырам, кырыкмыш яткан жиреннән печән кыштырдата. Көн жиләсләнеп, болытлап, бозылырга торган төсле.

Күнелем нидер сизә. Кырыкмыш та пошкыра, тезә башлаган чабатаны бер кырыйга ыргытып бәрдем дә, кырыкмышка атланып, инешкә су эчертергә киттем.

Кырыкмышның аркасыннан сыйпап, сызгыра-сызгыра су эчертеп ятканда, миннән ерак түгел, инеш буенда, яна чыккан каз бәбкәләренә чирәм ашатып, аларны саклап маташа торган безнең күрше Гөлйөзем әби:

—Ай, бәбкәм, харап булдык! Карасана зинһар: Дәүлиләрнең өй түбәләреннән бөркелеп кара төтен чыкты!—диде дә каз бәбкәләрен ташлап йөгерде.

Артыма әйләнеп карасам, исләрем-акылларым да китте: ни күзем белән күрим, Дәүли абыйларның өй түбәләреннән, яңа кайнаган казаннан чыккан бу төсле булып, бөркелеп-бөркелеп, кара-кучкыллы, ямьсез, шомлы төтен чыга.

Кырыкмышның авызын судан тартып алдым да, тезген очы белән берне бик каты итеп сугып, бөтен көч белән чаптырып үзебезнең лапаска кайтып киттем.

Мин, лапаска кайтып житеп, кырыкмышны читәнгә бәйләгәндә, әлеге кара төтен арасыннан багана шикелле булып ялкын сузылып чыкты. Көчәеп бара торган жил ялкын баганасын Хәйриләрнең салам түбәләренә аударды да, күз ачып йомганчы, аны ут камап алды. Янәшә салынган ике йорт минут эчендә ут туфаны эчендә калдылар.

Чыр-чу, тавыш, кычкырыш купты...

—Ут баррр!!! Янабыз!! Пожар!!.—дигән йөрәккә төшә торган ачы, ямьсез тавышлар минуты белән бөтен авылны чолгап алдылар.

Халык ары да, бире дә йөгерә, ләкин ник йөгергәннәрен, кая барганнарын берсе дә белмиләр, һәммәсе дә каушаганнар.

Нишләргә белмичә аптырап, мин дә халык артыннан шунда йөгердем.

Яна башлаган өйләрнең берсенең тәрәзәсеннән ике хатын берьюлы бәреп чыктылар. Алар артыннан шул ук тәрәзәдән, берсе артыннан берсе, самавыр, сандык, түшәк, ястык шикелле йорт әйберләре ташлана башлады. Шул нәрсәләр арасында жиргә бер яшь бала да килеп төште. Аның артыннан ук тәрәзәдән, су урынына агылып, бик ямьсез кара-кучкыллы ялкын да бәреп чыкты. Тәрәзәдән ургылып чыга торган куркыныччлы ялкын туфаны арасыннан, сакаллары, чәчләре көйгән, битләре пешкән, күлмәгенә ут кабынган бер ир кеше жиргә ташланды.

Жил көчәйгәннән-көчәя бара. Көчле жил ут дулкынын ары да, бире дә бәреп уйната башлады. Ут чыккан өйләр тирәсенә жыелган халык та, бу дәһшәтне күреп, үзләренең йортсыз-жирсез, бернәрсәсез калуларын уйлап, бик тиз арада гына һәммәсе дә үз өйләренә таралып беттеләр. Янучыларга читтән ярдәм күрсәтерлек бер кеше дә калмады.

Ул арада барча каралты, өй түбәләренә кулларына чиләкле су тоткан кешеләр менеп тә бастылар. Арбаларга төялгән, болай ташланган сандык-савыт, түшәк ястык, самавыр, комган кебек йорт әйберләре, ашлыклы капчыклар белән урамнар тулып калдылар. Күп урыннарда ул нәрсәләрне карарга куелган бала-чага, карт-коры, яна башлаган йортлардан очып

чыккан тавык-чебеш һәм ыгы-зыгы килгән халык дулкыны моннан ун гына минут элек зур тынлыкта яткан авылны тәмам кайнап торган казанга әйләндерде.

Мин тәмам аптырап, каушап калдым. Өйгә кайтыргамы, лапаска барыргамы, монда ут янында басып карап торыргамы—белмим. Шулай да лапаста бабайның юклыгын белеп, алай-болай кырыкмышны алып китмәсеннәр, дигән уй белән, мин тиз генә лапаска йөгереп кайтам. Кайтсам, ни күз белән күрим: биш-унмы кеше лапас тирәсенә жыелганнар да минем кырыкмышка камыт киертеп, аны насос арбасына жигәргә маташалар. Мин тиз генә йөгереп бардым да:

—Чү, ни эшләтәсез аны, аның әле тырмага да жигелгәне юк бит!—дип кырыкмышның тезгененнән тоттым.

Каушау катыш ачудан күзләре кызарган сары сакаллы бер кеше, миңа бик ачуланып карап, сүгенеп:

—Ул кырыкмышны монда күрсәтергә куйдыгызмыни, жигәргә дә ярамагач, кайда Шәфыйк карт, кайда атаң, бар, тизрәк ат китер, дуңгыз малай!—дип йодрыгы белән бик каты итеп минем жилкәгә берне кундырды.

Аның артыннан тагын берсе килеп:

—Шундый жилле-давыллы көнне, ут чыкканда, каравыл өен ташлап китәләр бит, үзләрен тотып утка ташларга кирәк!—дип миңа тагын берне сугып жибәрде.

Берсе килеп аягы белән мине аркага тибеп екты.

Бер кеше килеп:

—Егетләр, сез баладан үчне алмагыз, ул бернәрсә дә белми бит, менә аның атасы белән Шәфыйк картны, монда китереп, бик әйбәтләп кенә пешерергә кирәк. Алганда ялынып-ялварып алалар, ә менә хәзер кирәк вакытта үзләре юк,—дип мине артык кыйнарга тегеләргә ирек бирмәде.

Ирекле-ирексез минем күзләрдән яшь атылып чыкты.

Ул арада теге кешеләрнең берсе:

—Әнә, әнә, үләт кыргыры карт үзе кайтып килә!—дип, әлсерәп-пешеп, биленә чабаталарын кыстырып, йөгерә-йөгерә кайтып килә торган бабайны күрсәтте.

Бабайны күрүгә, барысы да, насос арбасына жигелеп ята торган кырыкмышны ташлап, Шәфыйк бабай өстенә ташландылар. Тиз генә аны әвереп тә алдылар. Бервакытны бабайны, бичараны, кирәкме-кирәк салалар да егалар, салалар да егалар...

Ул арада ут рәттән биш-алты йортны чолгап алды.

Бүрек кадәре бер ут кисәге, жил белән очып барып, икенче урамдагы бер өйнең түбәсенә төште дә ул да яна башлады.

Бу дәһшәтне күреп, бабайны кыйнаучылар да, тиз генә килеп, насос арбасына жигелә башлаган кырыкмышны янадан як-яктан жигеп бетерергә тотындылар.

Бичара бабайның башы, бите кан булган, шулай да ул, яткан урыныннан торып, насос арбасы янына килде.

Кырыкмышны жигеп бетерүгә, биш-алты кеше берьюлы насос арбасына менеп бастылар да, дилбегә тоткан берсе кырыкмышның биленә зур күсәк белән бик каты итеп берне сукты. Бичара кырыкмыш бөгелеп китте. Бер киерелеп алып карады да арбаны кузгата алмады.

Шуны күргәч, үземнең аркамның авыртуы да онытылып китте, бер яктан, бичара бабайны кызганам, икенче яктан, кырыкмышны...

—Кырыкмыш белән бабай бәхетсезлегенә каршы керешкәнбез икән бу эшкә,—дим.

Ул арада насос арбасына төялгән кешеләр тиз генә арбадан төштеләр

дә, "ахры болай булмас" дип, авыл янганны күреп, ашыгып-ашыгып сукадан кайтучы берәүне, ай-ваена куймыйча, атын туктатып туарып алдылар һәм насос арбасына китереп җиктеләр. Берсе кырыкмышны янга җикте.

Атлар җигелеп беткәч, тагын да баягыча төялеп, бөтен көчләре белән атларны кыйнап пожарга киттеләр. Алар артыннан дүрт-биш кеше арбалы су мичкәсен, аннары багорлар, баскычлар төягән арбаны тартып алып киттеләр.

Бераз гына баргач та, насос арбасының күчәре сынды, бер як тәгәрмәче чыкты. Менә тагын кешеләр арттан ияреп бара торган бабайга килеп ябыштылар.

Берсе:

—Монарчы шул арбаның күчәрен дә алмаштырмагач, тәгәрмәчен дә ныгытып куймагач, нишләп кенә торасың соң син монда, мур кыргыры карт!—дип бабайның колак төбенә берне сукты.

Икенчесе:

—Менә монда насосның көпшәсе дә ярылган, сиртмә төпләре дә күгәреп, йөрмәскә әйләнгән, карт дуңгыз!—дип бабайга аягы белән типте.

Арттан мичкә тартып килүчеләрдән берсе, тиз генә йөгереп килеп:

—Мичкәң кыршау аткан, юл буенча суы агып килә, ник аны карамадың?—дип бабайга тагын берне сугып җибәрде.

Тагын бабайны әвереп алдылар...

—Утка ташларга кирәк!—диләр.

Мин тагын нишләргә дә белмичә аптырап калдым.

Ул арада элек яна башлаган йортлар яртылаш янып күмергә әйләнделәр, ут авылның башка урамнарына күчте. Җил утны бөтен авыл өстендә уйнатып йөри...

Шуны күреп, безнең насос тирәсендәге кешеләребез дә кайсы кая—үз өйләрен сакларга таралып беттеләр.

Без, бабай белән икәүләп, көне буе сукада йөреп арыган, талган бичара атка һәм кырыкмышка карап, шаккатып калдык.

Баштанаяк канга баткан бичара бабай, күзләрен мөлдерәтеп:

—Булмый инде миннән, улым, син теләсәң нишлә, минем басып торырлык хәлем калмады инде...—диде дә юл кырыенда яшәреп чыгып килә торган чирәмгә барып егылды.

Арбаның күчәре сынуга, тәгәрмәче чыгуга, бабайның хәлдән таеп егылуына карамастан, ут авыл өстендә сикергәләп, уйнаклап йөрүендә дәвам итә.

Мин әтине эзләдем—таба алмадым, ул качкандыр инде. Монда килсә, бабайны кыйнагандай кыйнап ташларлар, дип куркам.

Нишләргә дә белмәгәнлектән, мин урам уртасында торган насос арбасына аякларымны бөкләп менеп утырдым да, авылның ике урамы баштанаяк янып чыкканчы, хәйран булып карап тордым.

Бер-ике сәгать кадәре вакыт эчендә, илле-алтмыш йорт янып күмергә әйләнгәнче, безнең янга килеп караучы да булмады.

*1923*

## Искәрмә

Мөхәммәт абый Гали хикәяләренең башламында ук бер үзенчәлек сизелә—әдип укучыга ипләп-җайлап, үз итеп эндәшеп куя. Монда вакыйганың ничек үстереләчәге тәгаенләнмәсә дә, сүзнең нәрсә турында барачагына пөхтә ишарә бар.

Менә "Чәчүлек сукканда" исемле хикәянең башы: "Ел яңгырлы килгәнгә, арышны вакытында урып булмады. Шуңа күрә чәчү дә соңга кала язды". Ярдәмче фигыль буларак килгән шушы "язды"да җир кешесенең хафалануы да, авыр хәлдән чыгуы да (тик боларны әсәрне тулаем укыгач беләсең) искәртелә. Яки югарыда сез укыган "Пожарныйлар" дигән хикәянең беренче җөмләсенә игътибар итик: "Мин белә килгәннән бирле, елның елында безнең әти Шәфыйк бабай белән бергәләп каравыл ала". Монда "каравыл ала"га—"пожарныйлар" булуга ("пожарныйлар" сүзе хикәядә куштырнакларга алынган) басым ясала. Шуннан соң гына әдип вакыйганы, үзәк юлдан тайпылмыйча, пөхтә талантына хас булганча, пөхтә итеп үрә. Һәм без бу хикәядә әле әкиятләр тыңлау яшендәге малайга, гомер итеп тә рәхәт күрмәгән бабайга, кырыкмыш тайга мәгънәсез кешеләрнең бер көндә кылган мәрхәмәтсезлеге (иң киме) шаһиты булдык кебек.

Мөхәммәт абыйга, гомумән, үзен тотышында, сөйләшендә, кешеләр белән аралашуында, хәтта йөрешендә пөхтәлек хас иде, әйбәт тәрбияле булуы беренче күрүдә үк сизелә иде. Аның белән танышлыгым еш очракта өлкән кешене олылап исәнләшүдән, аның башкалар белән әңгәмәсен яки лекциясен тыңлаудан узмаса да, Мөхәммәт абыйны шундый олы зат итеп хәтеремдә саклыйм. Ул тыныч холыклы, эшчән кеше иде, аңардан тәрбияле горурлык бөркелә иде. Шулай—төпле гыйлем ияләренә, тәрбияле кешеләргә шапырыну, буш сүзлелек ят лабаса.

Мөхәммәт Гали (Мөхәммәт Вәли улы Галиев) 1893 елның 24 мартында Татарстанның хәзерге Балык Бистәсе районындагы Олы Юлга авылында мулла гаиләсендә туган. Авылы мәктәбендә, Саба төбәгендәге Сатыш, Казандагы Күл Буе, Оренбургтагы "Хөсәения" мәдрәсәләрендә укый. 1931 елда Казан университетының география факультетын тәмамлый. Яшьлегендә рудникларда, нефть промыселларында эшли. Беренче бөтендөнья сугышында Австрия якларынача, Румыниягәчә барып җитә.

Октябрь революциясеннән соң, авылында һәм Казанда укыта, төрле газеталар редакцияләрендә корректор, әдәби хезмәткәр, секретарь була. Беренче хикәяләре 1914 елда басыла. Аның пьесалары, Каюм Насыйри турында тәмамланмаган романы, әдәбият тарихы буенча күләмле мәкаләләре, Г. Тукай, Г. Камал, Ш. Камал турында истәлекләре бар. 1945 ел ахырыннан вафатынача (1952 елның 6 мае) Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр була һәм кульязмалар бүлеген җитәкли.

...Егерменче еллар хикәяләрендә бер нәрсәне тою-күрү кыен түгел—әдипләр тормышыбызның тайгак юлга томырылып кереп китүен яшертенлек белән булса да чагылдырганнар. Кайберләрен теркәп кенә узыйк: Гомәр Толымбайның "Мәртәт Гыйбай" (1925), Мәхмүт Галәүнең "Яшәсен ипи белән суган!" (1928), Г. Газизнең "Эчке эмигрант" (1929) исемле хикәяләрендәге һәм Мөхәммәт Галинең шушы хикәясендәге күпләр инде тайгак юлда кешелек сыйфатларын югалтып өлгергәннәр. Совет системасының нинди булып әвереләчәгенә ишарәләр М. Галинең "Базарчылар" дигән хикәясендә дә турыдан бәрмичә, чукларсыз тел белән көчлерәк тә тасвир ителә.

"Пожарныйлар" исемле бу хикәя Мөхәммәт Галинең "Сайланма әсәрләр"еннән (Татарстан китап нәшрияты, 1964 ел) алынды. Шуннан соң аның китаплары чыгуын хәтерләмим. Бәлки, хәбәрдарлыгым чамалыдыр. Ялгышсам, гафу.

**Мәгъсум ХУҖИН**

**Илдус
Садыйков**

## ЙӨРСӘҢ КҮРЕРСЕҢ, КҮРСӘҢ БЕЛЕРСЕҢ

Беренче зур сәяхәтемне мин Төркия дәүләтенә барып кайтудан башладым. Мәрхүм әтием әйткән сүз хак булып чыкты: "Улым, дөньялар үзгәрер әле ул, халык бераз булса да иркен сулыш алыр. Бу көннәрне сез, яшьләр, шәт иншалла, күрерсез... Син төрки халыкларның бердәнбер мөстәкыйль дәүләте булган Төркиягә бару чарасын күр. Анда—Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Йосыф Акчура кебек бөек милләттәшләребезнең каберләрен зиярәт кыл. Безнең мөһаҗирлеккә дучар булган туганнарыбызны, дусларыбызны, бәлки, әле эзләп таба да алырсың..." Әтием аларның рәсемнәрен дә күрсәтеп, исемнәрен дә әйткән иде. Әлбәттә, әтиебезнең бу сүзләрен мин аның васыяте итеп озак еллар сакладым.



*Күңелгә бик якын бу җир...
Төркия, кунакчыл Алания шәһәре.*

1991 елның язгы бер матур көнендә Алмаз Алиев исемле бер батыр егетебез Төркиягә җилкәнле көймәләр белән барырга тәкъдим итте. Озак уйлап торырга вакыт юк иде. Күнелне сәяхәт романтикасы биләп алды. Чөнки яшьлектә мин җилкәнле көймә спорты белән дә шөгыльләнгән идем. Гаилә рөхсәтен алып, тәвәккәлләргә булдым.

Без, 14 кешедән торган бер төркем сәяхәтчеләр, Идел-Дон каналын кичеп, август аенын ахырында өч көймә—"Багира", "Идел", "Энже" белән шаулы Кара диңгез дулкыннары аша Төркия ярларына юл тоттык.

Өч көн, өч төн 5-6 баллы дуамал диңгездә чайкалганнан соң, 1991 елның 5 сентябрендә, Босфор култыгын узгач, ягымлы кояш нурларында балкып, иртәнге

азан янгыратып, безнен каршыбызда гүзәл Истанбул пәйда булды.

Бу, әйткәнемчә, Төркия туфрагына беренче тапкыр аяк басуым иде. Шуннан соң бирегә күп тапкырлар, ел саен диярлек киленде. Шуларның берсе, 2003 елда баруым турында тәфсиллләбрәк сөйләмәкчемен.

Озаграк күрешми торсак, дусларым шалтырата. Өченче ел да шулай булды. Дусларым, Ак дингез ярлары сезне көтә, дип хәбәр салдылар. Чакырганда бар, куганда кайт, диләр бит. Тәвәккәлләдем инде. Чөнки берничә ел рәттән, ничәмә ничә мәртәбә чакырып та бара алмаган идем. Бик тә мөһим эш белән мәшгуль идем. Ул да булса күп балалы һәм аз керемле гаиләләрнең балалары өчен хәйрия пансионаты ачу иде. Һәм бу "Ак өмет" дип исемләнгән пансионат 2002 елда ачылды. Ачылышына Татарстан Президенты да килде һәм рәхмәтен белдерде. Изге эш эшләгәнсез, дип, Төркиядәге аркадашларыбызны хуплады. Бу иске бинада евроремонт эшләре өчен ике ел ярым вакыт сарыф ителеп, бөтен чыгымнарын Төркиядәге дусларыбыз тоткан иде. Халык дипломатиясе ысуллары белән шактый күп эшләр майтарып була икән бит. 55-60 бала урамның начар шаукымыннан аерылды. Алар дәүләт мәктәбендә укып, пансионатта яхшы шартларда өстәмә дәресләр алып, киләчәктә илнең чын намуслы гражданнары булырга әзерләнәләр...

...Истанбул һава аланында мине ике дустым каршы алды. Берсе (Мозаффар әфәнде) хәтта Иске шәһәрдән килеп житкән иде. Берничә көн Истанбулның гүзәл мәчетләрен, тарихи урыннарын, урамнарын, базарларын тагын бер тапкыр күреп хозурлангач, мин юлымны Анталия каласына дәвам иттем.

Ак дингез ярына урнашкан бу кала хәзер инде безнең илдән дә күпләрнең ял итә торган урынына әйләнде. Монда безнең татарларыбыз да яши. Бу баруымда шәһәрнең үзәк урамнарының берсендә татар музыкасы янгырамагач, бик ямансу булып китте. Чөнки безнең милли көйләрне үзенең кибетендә уйнатучы дустым Бәхсәт Акташ Измиргә күченеп киткән. Бәхсәт әфәнде бик оста һөнәрче—зәркән (ювелир). Татар музыкасын янгыратып, моңаеп кына утырмый иде ул. Үз моңын ишетеп кергән һәрбер татар белән таныша һәм үзенең кунаклар кенәгәсенә теркәп тә куя иде.

Айлы матур бер кичтә дингез ярында урнашкан чәй бакчасында дуслар белән гәпләшеп, чәйләп утырганда берсе: "Татарстан Президенты да биредә ял итә, аны да чәй мәжлесенә чакырсак, килер идеме икән?"—дип сорап куйды. Шаярту түгел икәнен абайлап, җавап бирдем. Кунак чакыру—изге эш. Ләкин ял итүче кеше күбрәк үз мохитендә, үз ихтыярында калырга тели. Ә инде ял итүче кеше Президент дәрәҗәсендәге рәсми зат булса, аның ялының да үз тәртипләре бар.

Иртән уянып киткәндә, Хәмзә һәм Мостафа әфәнделәр хәләл җефетләре белән килеп тә җиткәннәр иде. Иртәнге ашны ашап, без юлга чыктык. Барасы җиребез—Алания шәһәре.

Алания Анталиядән 380 чакрым чамасы ераклыкта, көнчыгыш тарафта урнашкан. Юлыбыз шактый озын, дингез ярлары буйлап барасы, матур табигать күренешләрен күзәтеп әйтеп бетермәслек сәгадәт кичерәсең. Төркиядә юллар әйбәт, төзек. Нефтьләре, битумнары үзләрендә чыкмаса да, киң асфальт юллар әллә кайларга илтә. Чиста, зур, матур автобуслар, төрле машиналар (төрекләр "араба" диләр) көне-төне 100-120 чакрым тизлек белән элдерәләр генә. Хәрәкәт тантанасы бу! Юл полициясе дә бик күренми үзе.

Машинабыз шактый тизлектә барса да, без ашыкмадык. Юл буйлап тезелеп киткән кафе-рестораннарга тукталып, су коенып, бакчаларда җиләк-җимеш ашап кәефләндек.

Табигатьнең гүзәл хәзинәсе—Гөрсу ташкыны ярсып-ярсып таудан атылган бер җирдә туктап, балык тоттык, аны кыздырдык...

Төрле илләрдән килгән сәяхәтчеләрне кунакчыл кабул итә белгән илләр үзләренең казналарын тулыландыралар. Һәм иң мөһиме, үз халкының мәдәниятен, гореф-гадәтен, тарихын башка халыклар алдында ким-хур булмаслык итеп күрсәтергә тырышалар. Төркия бу өлкәдә дә алга киткән ил. Кая гына барма: Измирның "боз тавы"; Памуккаланың тоз таулары, күлләре; ак ташлы, байлар ял итә торган Бодрум; борынгы Бурса; Беләжек калалары, хәтта кечкенә генә Османия дигән татар авылы,—

боларның барсында да теләсә кем гаиләсе белән килеп ял итә торган урыннар күп. Бирелә исерек кешеләр, болагайланып, акрып-бакрып җырлаучылар, сүгенүчеләр юк. Һәрхәлдә, минем күргән булмады. Халык бер-берсен ихтирам итә. Яшьләр өлкәннәргә ярдәмчел.

2003 елның җәендә Чистайда яшәүче дустым кунакка чакырды. Машинасы белән борынгы дәүләтебезнең башкаласы булган Биләргә алып барды. Татарстанда да матур җирләр бар ла ул безнең. Төрекләр әйтмешли, "чок гүзәл" бу манзараны күреп "чок мәмнүн олдык" ... Яшеллеккә күмелгән таулар, саф сулы челтерәп аккан чишмәләр, махсус ял итү урыннары—болар барсы да күңелне шатландырды. Бөек Чулман аркылы салынган күперне кичеп, асфальт юлдан 2-2,5 сәгатьтә барып җитеп, рәхәтләнеп ял итәргә була. Килгән кунакларны шул матурлык белән ләззәтләндерү—үзе бер куаныч. Ләкин шунысы бар—өстәлләрдә тезелеп киткән аракы шешәләре, стаканнар, дуңгыз итеннән пешерелгән шашлыклар күңелне рәнҗетә. Изге бабаларыбыз җирендәге кирәкмәгән шау-шу, тәртипсезлек кәефне җибәрә. Ә инде үзләре артыннан чүпләрен җыеп китә белмәгән сансыз вә мәгънәсез ял итүчеләрне күреп йөрәк тагын әрни.

...Аланияга кич кенә барып җиттек. Биредә мине яңа танышларым бик матур итеп каршы алды. Бераз танышып сөйләшкәннән соң, тагын машинага утыртып, бормалы юллар үтеп, тау башына урнашкан бик матур йортка алып килделәр. Ахшам ашы табыны шул йортның зур бер залында әзерләнгән иде. Төркиядә кунакны сыйлый да, хөрмәт итә дә беләләр. Аштан соң мәйвә бирелә, анда нәрсә генә юк: йөзем, кавын-карбыз, алма, армут (груша), мусс (банан), инжир, портакал (әфлисун), кактус алмасы һ. б.

Алания—Төркиянең мусс (банан) бакчасы. Чөнки үзенчәлекле, кечкенә, баллы-татлы мусс биредә генә күпләп үсә. Шунысы кызык һәм күңелле: һәрбер табын аерым бер җирдә әзерләнә, мәсәлән, мәйвә табыны зур ачык террасада әзерләнде. Аннан искиткеч матур табигать күренеше ачылган иде. Күк йөзендәге ай үзенең көмеш юлын диңгез өстенә элеп куйган да, әйтерсең лә, сәяхәтчеләрне ерак юлга чакыра. Ә кичен Алания шәһәре, бихисап нурлар сибеп, йөзек кашындагы бриллиант кебек, төрле төсләр белән уйный.

Иртән моңлы азан тавышына уянып, якындагы мәчеткә иртәнге намазга киттек. Мәхәллә мәчетендә утызлап кеше бар иде. Намаздан соң алар барсы да килеп күрештеләр, хәл-әхвәл белештеләр, сәфәремдә хәерле юллар теләделәр. Мәчеттән кайтуга, иртәнге ашны хуҗалар йортның чәчәккә күмелгән җиләк-җимеш бакчасында әзерләгәннәр иде. Төркиядә табында ашык-пошык ашау юк. Барсы да салмак хәрәкәт итә, ләззәтен белеп ашыйлар.

Чәй эчкәндә Аланиядән соң мин Иске шәһәргә, аннары Анкарага, аннан соң Истанбулга һәм Мәскәүгә очачагымны белдердем. Аланиядә ике-өч кенә көнгә калуымны һич хупламадылар. Сез кадерле кунак, кимендә бер атна-ун көн торсагыз, сезгә хөрмәтебезне күрсәтә алырбыз, сезнең өчен махсус ял программасы да төзеп куйдык, диделәр.

Яңа дусларым—Латиф, Хилми, Хөсәен белән беренче барган җиребез каберлек булды—дусларымның ата-анасы, әби-бабалары каберләрен зиярәт кылдык. Без ошбу изге эшне ихлас күңелдән үтәдек. Аннан соң әлеге өч бертуган мине үзләренең бакчаларын күрсәтергә алып киттеләр. Бакча дигәннәре ул безнең өч сутыйлы җир түгел икән. Ул чын мәгънәсендә Бразилия сериалларында күрсәтелә торган фазенда булып чыкты. Бу бакчада үстерелгән банан, алма, йөзем һәм башка җиләк-җимешләр хәтта башка илләргә дә сатыла икән.

Алания—борынгы шәһәр, анда тарихи һәйкәлләр бик күп. Бу шәһәрне 19 гасырның азагы һәм 20 гасырның башындагы феодал Алания дәүләте белән бутарга кирәк түгел, чөнки ул вакыттагы аланнар, Хазар каганатыннан аерылып, Төньяк Кавказның үзәк бер җирендә яшәгәннәр. Төрле халыкларның бөек күченү чорында нинди генә элемтәләр, бәйләнешләр булмагандыр... Борынгы таш диварлар, кальгалар, биналар тирәсендә йөргәндә чал тарих тавышын ишеткәндәй буласың, аның тирән һәм серле сулышын тоеп, кешелек дөньясының гасырлар буйлап үткән юлын күзаллыйсың.

Сәяхәтебез көннәренен берсендә, бормалы тау юлларын үтеп, Алания шәһәрен биек тау башында урнашкан кальгадан күзәттек. Бу искиткеч күренеш иде. Уч төбенә сыярдай булып кечерәйгән шәһәр зәңгәр дингез кинлегендә йөзә торган корабка охшаган иде. Чыннан да, Алания ярның дингезгә очлаеп кергән жиренә, ягъни борынга урнашкан. Шушы без менгән биек тау башыннан батыр туристлар парашют белән сикерәләр. Алар, әкияттәге бөркет кошы кебек акрын гына очып, дингезгә килеп төшәләр, анда аларны махсус катер җыеп йөри. Мин дә сикереп карамакчы идем, ләкин дуслар бу теләкне хупламадылар...

Кичен, таулардан кайткач, без шәһәр башлыгы урынбасарына чәй мәҗлесенә чакырулы идек. Рәсми даирәләрне Алания белән Казан арасында туризм һәм сәүдә багланышлары мәсьәләсе кызыксындыра икән. Казан турында видеокассета бүләк иткәч, алар аны шунда ук карап, күп кенә сораулар да бирделәр, һәм үзләре дә бүләккә Алания турында диск бирделәр...

Арабага, ягъни машинага кереп утыргач, аркадашларның өлкәне, Латиф әфәнде, әйтеп куйды: "Илдус әфәнде, хәзер без Яшел Койгә барабыз, сезне шундагы кунак йортыбызда калдырырбыз"...

Тагын кичке дингез ярлары буйлап җилдерәбез. Аланиядән бер 40-45 чакрым узгач, без теге Яшел авылга килеп тә җиттек. Иркен, матур һәм бай җиһазландырылган йорт күңелгә бик хуш килде. Хуҗалар миңа йортның бүлмәләрен күрсәттеләр һәм, әлбәттә инде, чәй бүлмәсендә чәй табыны әзерләнгән иде. Бераз чәйләп, сөйләшеп утыргач, аркадашлар: "Сез, ял итүче кеше күбрәк үз ихтыярында булырга тели, дигән идегез. Шуны исәпкә алып, без сезне бирегә алып килдек. Төрек авылында ял итеп карагыз әле, ошамаса тагын Аланиягә алып китәрбез",— диделәр.

Төркиянең кайсы гына җирендә булсагыз да, нәкъ Тукай әйткәнчә, сезне иртәнге намазга "бик матур моңлы азан" уята. Әлбәттә инде, Төркиядә азан үзенә бер төрле мәкам белән әйтелә.

Ләкин, ни кызганыч, Яшел Кой авылындагы беренче иртәмдә мин каты йоклаганмын. Иртәнге азанны йокы аралаш ишеттем, төш күрәм дип торам... Чынлап уянуым кесә телефоным тәкатсез, дерелди-дерелди шалтырагач булды... Иске шәһәрдән Ихсан Танатар дус шалтыратып, хәл-әхвәл белеште: "Без сине көтәбез, кайчан киләсен?"—диде. Мин Ак дингез буенда 5-7 көн ял итәргә калачагымны белдердем. Ул да бу планны хуплады һәм: "Алай да бик озакка калып безне онытма, көтәбез",—дип хушлашты... Тиздән ишек шакыдылар... "Керегез, рәхим итегез!" Ишек ачылды һәм елмаеп тора торган көләч йөзле ир-ат: "Әфәндем, и сабахлар! Ничек йокладыгыз? Сезне иртәнге табынга чакырабыз",—диде. Аш бүлмәсендә бу пансионатның хуҗалары, мөгаллимнәре җыелган иде. Таныштык. Аштан соң пансионатның хуҗасы Мостафа әфәнде бу матур, дингез буена урнашкан, бай җиһазландырылган бинаны күрсәтте һәм, бинаның югары, өченче каты сезнең карамакта, диде. Анда йокы бүлмәсеннән тыш зур һәм кече зал, китапханә, юыну бүлмәсе, душ, солярий, ачык һәм ябык террасалар бар иде. Иң кирәклесе, рухны күтәреп, бөтен җан вә тәнне кинәндергәне—ул, әлбәттә, искиткеч матур табигать, зәңгәр дингез, зәңгәр күк киңлекләре иде. Ә җылы кояш нурлары юмарт һәм назлы итеп иркәли... Минем шатлануымны күреп, Мостафа әфәнде сорап куйды: "Чок, име?" "Чоктан чок!",—дидем.

Төркиягә беренче килүемдә истә калганы шул: бик күп кешеләр, хәтта яшь балалы хатыннар да тәмәке тарта иделәр. Бер мәҗлестә бу турыда әйткәч, миңа ханымнар җавап итеп: "Ә сездә хатыннар аракы эчә..."—диделәр. Дөрес сүзгә җавап юк! Соңгы баруларымда шуны абайладым, тәмәке тартучылар шактый азайган, һәрхәлдә, автобусларда иркен сулыш алып була. Күрәсең, ул бәла безгә күчкәндер, бездә бит соңгы вакытларда аракы эчүче хатын-кызларга тәмәке тартучылары да өстәлде. Япь-яшь кызлар яшерми-нитми тәмәке көйрәтә, аты-юлы белән сүгенә, наркотиклар куллана хәзер. Болардан нинди ана чыксын, ничек сәламәт бала тусын инде?!..

Бакчаны күрсәтеп бетергәч, Мостафа әфәнде бер автомобиль янына килде дә. "Бу араба сезнеке, менә ачкычлары,—дип, миңа бирде.—Теләсәгез, үзегез йөртегез,

кирәк булса, шоферны чакырырбыз",—диде. Мин: "Ә полиция туктатса, җәзасын кем түләр?"—дигәч, ул елмаеп: "Иншалла, берни булмас",—диде...

Үзем генә калгач, мин тирә-җирне карап, авыл белән танышмак булдым. Авыл дигәне хәзерге заманча төзелгән ике-өч катлы коттеджлардан тора иде. Октябрь ае булса да, көн эссе иде. Мин, авыл белән танышуымны хәзергә тәмамлап, диңгез кочагына чумарга булдым. Пансионат комлыгында берничә генә кеше, берүзем бер диңгез. И кинәндем инде йөзеп, чумып. Көннәрем күбрәк шулай шифалы диңгез кочагында үтте: балык тотып, акваланг белән су асты дөньясына чумып...

Бигрәк шәп нәрсә инде кесә телефоны! Кая гына барма, кесәдә бөтен дөнья белән элемтә тотарга әзер, кечкенә генә, бака кабырчыгы сыман бер тартма. Кирәкле төймәсен басуың була, ул сине кирәкле кешең белән тоташтыра да куя.

Кичләрен террасада утырып, диңгездә кояш баеганын карап монайганда кесә телефоны шалтырап, уй-хисләрдән айнытып җибәрә. Дөньяның әллә кайсы почмагыннан сине дусларың эзләп таба... Шулай итеп, кечке якта телефон аша сәяхәт итү тагын үзенә бер күңелле шөгыль булып китте: Америкада, Канадада, Алманиядә, Австралиядә, Япониядә һ. б. илләрдә яшәүче дусларым белән телефон аша күпер салып, хәл-әхвәл белештек. Күрешеп-сөйләшкәндәй булдык.

Анталиядагы һәм Аланиядагы дусларның "сюрприз" дигәннәре коры сүз генә түгел иде. Зур зәвекъ белән җиһазланган залда телевизордан 400-450 программа карап була. Мондый мөмкинлек махсус спутник тәлинкәсе аша булдырыла.

Каналларның барысын да диярлек күзәтеп чыктым: Италия, Франция, Греция, Испания, Кипр, гарәп илләре, Төркиянең үзенең генә 10-15 программасы көне-төне эшләп тора. Ләкин, ни кызганыч, Татарстан программасы юк. Рөхсәт сорап, сәбәбен аңлатып, түбәгә менеп киттем. Спутник тәлинкәсенең диаметры, ЛМБ (конвертор) параметрлары гомуми стандартларга килә иде. Рессиверны да (TV радиоалгыч) ТНВ параметрларына көйләдем. Ә Казан программасы күренмәде. Сәбәбе билгеле, тәлинкәнең азимут юнәлешен үзгәртергә (спутникка каратырга) кирәк иде. Бу шактый төгәллек таләп итә торган эш һәм аны, махсус прибор кулланганда, тиз башкарып була... Шактый маташкач, "Яңа гасыр" программасының сурәте пәйда булды. Ул кичне без дуслар белән бик кызыксынып татарча тапшыру карадык. Төрек дуслар сезнең тел безнеке белән айны икән бит",—дип әйтеп куйдылар. Татар тапшырулары рус теленә күчкәч, алар нигә болай башка телдә сөйли башлауны һич тә аңламадылар. Чөнки бөтен дөньяда милли тапшырулар аерым каналда алып барыла. Хәтта дәүләтчелеге булмаган көрдләрнең дә үз спутник каналы бар. Иртәнге сәгатьләрдә кыска дулкыннарда эшләүче радио аша мин Татарстан программасын тыңладым. Шунысын да әйтеп китмичә булмый, Татарстан радиосы, "Яңа гасыр" каналы үзләренең нинди ешлыкта, кайсы вакытта эшләвен тапшыру азагында кабатлап әйтми. Ә бу бит чит илләрдә яшәүче милләттәшләр өчен бик мөһим.

Бирелә "Азатлык" радиосын да тыңлыйлар. Мәсәлән, 6 октябрьдә иртән "Азатлык" "Кара болак" фаҗигасе (Чиләбе өлкәсендә милләттәшләребезнең радиациягә дучар булуы) турында бик тә мөһим тапшыру ясады. Радиодулкыннар—дәүләт чикләрен үтеп керә алган, милләтне туплый торган илаһи көч бит ул. Хәтеремдә әле, 90 нчы елларның башында "Азатлык" радиосын ябалар икән дигән хәбәр таралды... Без, бер төркем милли хәрәкәт вәкилләре, бу хәбәрне ишеткәч, "Юк, "Азатлык" радиосы, татар телендә кыска дулкында бөтен дөньяга сөйләүче бердәнбер (ул вакытта) радио буларак, ябылмасын",—дигән таләп куелган мөрәҗәгать белән чыктык. Алай гына да түгел, 1992 елда мин Америкага барып, Сан-Францискода яшәүче татарлар белән бәйләнешкә кереп, Равил Салиәхмәт ярдәмендә конгрессмен Томас Лантос белән очраштым, мөрәҗәгатебезне аңа тапшырдым. Шөкер, "Азатлык" радиосы әле дә азатлык дулкыннары тарата.

Кая гына барсам да, мин төрле радиотелевидение тапшырулары белән кызыксынам. Шул исәптән, Төркия дәүләтенең элемтә системалары белән дә азмы-күпме танышырга туры килде. ТУДЕВ оешмасының радиотелевидение мәгълүмат чараларын тикшергән бер комиссиядә катнашып, чыгышымда Төркия радиосының татарча программаларын булдырырга дигән тәкъдим керткән идем. Минем

тәкъдимне хуплап кабул иттеләр һәм тиз арада Төркиядә кыска дулкында эшләүче, татарча сөйли торган радио барлыкка килде...

Яшел Кой авылын карап бетергәч, мин, машинага утырып, Алания белән Анталия арасындагы авылларны, шәһәрчекләрне, базарларны күрмәк булдым. Бу мавыктыргыч сәяхәт мина ошап китте. Чөнки үз иркендә булып, гади кешеләр белән очрашып син үзен дә сизмәстән алар мохитендә яши башлыйсын, тормышнын чын хәрәкәтен тоясын. Көтмәгәндә-уйламаганда кызыклы кешеләр белән танышасын. Шулай бер көнне, Анталиядән кайтып килгәндә, диңгез ярынын бик матур жирендә туктап, су керергә булдым. Рәхәтләнеп су коенганнан сон, магнитоланы жибәреп, күләгәдә үзем яраткан татар халык көйләрен тынлап хозурланганда яныма могтәбәр бер кеше килеп сәлам бирде. Мәрхәбәгә—мәрхәбә! Бер мәл дәшми торгач, ул: "Әфәндем, бу нинди музик була?" дип сорап куйды. Бу сөаль мина нәкъ Габдулла Тукайнын "Әллүки"ендәге кебек янгырады. Чак кына: "Бу көй була "Әллүки"—дип әйтеп куймадым. Ләкин магнитоладан башка көй агыла—Исмәгыйль Һилалов мандолинада татар көйләрен башкара иде. Чал чәчле бу әфәнде утырырга рөхсәт сорады. Әлбәттә, мин, кунакчыллык күрсәтеп, ана элегрәк урын тәкъдим итәргә тиеш идем. Ул килеп утыргач, музыканы туктатмакчы идем дә, ләкин ул, юк, тынлыйк дип ишарә ясады. Музыка уйналып беткәнче без бер-беребезгә дәшмичә генә монландык. Бу мәһабәт кешенен зәнгәр күзләрендә энжедәй яшь бөртекләре күренде. Концерт тәмамлангач, без таныштык. "Минем исемем Рамазан,—диде ул,—әтием Әхмәт Самарлы, Казан татарларыннан атаклы сәүдәгәр иде һәм бик матур итеп Италиядән алып кайткан мандолинада уйный иде,—шулай дигәч, ул күз яшьләрен сөртеп алды.—Әйдәгез, минем яхтага керик, минем сезне кунак итәсем килә". Мин магнитоланы туктатып алып куймакчы идем дә, Рамазан әфәнде: "Алыйк үзебез белән, тагын музик тынларбыз",—диде. Аккош сыман сылу яхта безне, бишектәге кебек тирбәтеп, тагын музыка дәрьясына кертеп сагышландырды. Ул арада Рамазан әфәнде үзенен фотоларын күрсәтте. Баксаң, ул зур корабларда капитан булып хезмәт иткән икән. Ә хәзер—әмәкле, ягъни пенсионер, шушы зур гына яхтада сәяхәт итә. Бодрумнан Аданага, өенә кайтып барышы икән. "Бодрумда булганым бар, бик матур шәһәр",—дип, мин дә үз хәл-әхвәлләремне сөйләдем... "Әйдәгез, Адана шәһәрен дә күреп китәрсез, минем өемдә кунак булырсыз, сезне, Казан татарын күреп, чок мәмнүн булдым",—диде. Суыткычтан зур карбыз чыгарып, кисеп жибәрде... Ул Казан, Татарстан хәлләрен сорашты. "Казан турында әтием күп сөйли иде, хәзер дә әле анын мандолинасы, китаплары миндә саклана",—диде. Рамазан әфәндене татарчасы шактый яхшы, һәрхәлдә, Казанда яшәүче кайсыбер татарларныкыннан арурак. "Казанга 2005 елда 1000 ел тула, рәхим итегез",—дидем. Үземнен "Яшел Кой"дә үткәргән радиотелевидение эксперименты турында сөйләдем, һәм татар радиосын кыска дулкында тынлап, "Яна гасыр" телевидение программасын спутник аша карап булуын анлаттым. Ул шунда ук яхтасындагы спутник телевизорын кабызды, ләкин мин биргән "Яна гасыр" параметрлары һәм "тәлинкәсенең" параметрлары туры килмәде: анын антеннасынын диаметры бары 90 см., ә иң кимендә 1,20 м. булырга тиеш. Рамазан әфәнде: "Ярый, мин аны өйгә кайткач көйләрмен",—диде.

Саубуллашканда мин яна танышыма теге кассетаны бүләк иттем. Рамазан әфәнде: "Бу минем өчен кәтелмәгән бүләк, өемә әтием рухы кайткан кебек булыр",—диде. Мин китеп барганда, ул, бөтен көченә Сәйдәш маршын янгырата иде...

Рамазан әфәнде Аданага барырга бик кыстаса да, бара алмадым. Иртәгесе көнне Аланиягә барып, анда атаклы пансионатта шәкертләр белән очрашырга тиеш идем... Пансионат житәкчесе Мөхәммәт әфәнде бик үтенеп сорады, көтә... Әле кайтышлый тагын бер жиргә кереп чыгасы бар. Иске шәһәрдән шалтыратып, мин тора торган авылдан ерак түгел Татарстаннан килгән егетләр барлыгын әйткәннәр иде. Дөресерәге, алар каникул вакытында төрле жирләрдә эшләп азрак мая туплыйлар да, Төркия университетларын тәмамлыйлар икән. Эзли торгач, таптым берсен, Тәлгать исемлесен. Танышып, хәл-әхвәл белештек. Татар яшьләре-шәкертләре дөрес юлда. Трай тибеп, аракы эчеп йөрмиләр. Берничә телдә иркен сөйләшәләр, кешеләр

белән матур мөгамәләдә, фикерләрен анлата beләләр. Төркиядә яшәүче татарлар аларны аталарча кайгыртып тора. Ресторан, кибет хуҗалары аларны эшкә бик теләп алалар, һәм безнең егетләр дә тормыш тәҗрибәсен шулай узалар.

Иртәгесен, Аланиядагы шәкертләр белән очрашуга килгәндә, пансионатның зур залы яшьләр белән шыгрым тулган иде. Очрашуның эчтәлеге ирекле булса да, төп тема шул Татарстан инде. Аның тарихы, сәнгате, географиясе, икътисады, халкы, көнкүреше. Белгәннәремне ике сәгать ярым сөйләдем. Казан һәм Татарстан турында видеофильм да күрсәтелде һәм сорауларлар дә бик күп булды.

Төркиядә автобуслар көне-төне юлда. Халык гел йөрешеп, аралашып тора, һәм бу хәл илнең икътисады үсүенең бер билгесе инде. Юллар төзек, автовокзаллар исә үзенә күрә бер культура һәм сәүдә үзәге дә. Өр-яңа автобуслар халыкка югары кимәлдә хезмәт күрсәтә. Юл бәяләре арзан дип әйтмәс идем. Шулай ук кайбер көнкүреш әйберләре, азык-төлек тә бик юнь түгел. Мәсәлән, сарык итенең килосы 7-10 доллар тора. Инфляция дә үзен сиздерә. Әмма халык яңа сайланган дәүләт җитәкчелегенә ышаныч белдерә. Чөнки, ни әйтсәң дә, Төркия хәзер икътисади үсеш юлында. Төркия дәүләтенең Америка гаскәрләрен Иракка үз территориясе аша кертмәве халыкта хуплау тапкан. Бу дөрес сәяси адымны ясаганда дәүләт җитәкчелеген Европа берлегенә кабул ителмәү мөмкинлеге дә куркытмаган...

Төнге автобуста сәяхәт итүнең рәхәт ягы да бар. Эссе түгел, юлда хәрәкәт тә азрак. Әлбәттә, карап барып булмый, ә менә йоклап була. Һәр 2-3 сәгатьтән соң автобуслар 15-20 минутка зур тукталыш ясыйлар. Шул арада автобусларны шампуньләп юалар, юлчылар кафе-ресторанда ашап-эчеп ала. Һәрбер тукталышта диярлек кечкенә генә мәчетләр бар, теләгән кеше кереп намаз укый. Китү турында игълан ясап, юлчыларны барлап чыккач, юлны дәвам итәләр. Шунысы ошады, юлда барганда кулны-битне сөртеп, чистарынып алыр өчен учка лимон суы тамызып чыгалар. Аннары чәй-кофе, су, әйрән, кока-кола ише нәрсә сайлап, кекс яки печенье белән тамак ялгап аласың.

Шулай 9-10 сәгатьлек юл узып та китте. Иртәнге яктылыкта Иске шәһәр күренә башлады. Шәһәрнең автовокзалы бик шәп, заманча итеп эшләнгән. Андагы кибетләр, билет кассалары, кафе-рестораннар, хәтта бәдрәфләр дә зәвекъ белән эшләнгән. Кечкенә, унайсыз Казан автовокзалы белән чагыштырсаң, әллә ничек оялып, гарьләнеп китәсең.

Автовокзалга кереп өлгермәдем, телефон тавыш бирде. Ачсам, таныш тавыш: “Илдус абый, сез кайда, без сезне каршы алырга килдек”. Аланиядән шалтыратканнар, югыйсә каршы алыгыз дип борчырга теләмәгән идем. Ул арада Мозаффар дус үзе дә пәйда булды. Арабага утырып тиз арада шәһәр үзәгендәге отельгә барып та життек.

Иске шәһәрнең яңа ир балалар пансионаты белән танышып чыгудан башланды беренче көнем. Мин 1997 елның язында Казан шәһәре башлыгы Камил Исхаков җитәкләгән дәүләт делегациясе белән килгәндә бу бина әле салына гына башлаган иде. Ә хәзер патша сараеннан бер дә ким түгел. Пансионатның җитәкчесе Хәсән бәй әйтүенчә, мондагы ике йөзләп ир бала мәктәпләрдә, университетларда укып белем һәм тәрбия ала, шул исәптән, дини белем дә. Мондый пансионатлар Төркиянең бөтен шәһәрләрендә дә бар. Аларның эшчәнлеге җәмгыятькә яшь буынны инсафлы, белемле инсаннар тәрбияләү белән файдалы. Һәм шунысы әһәмиятле, пансионатлар дәүләт бюджетына түгел, җәмгыяте хәйрия хисабына булдырылалар һәм тотылалар..



*Иске шәһәрдәге балалар пансионаты.*

Ә биредә торып яшәүче балалар бер тиен дә акча түләми... Безнең мәгариф оешмалары нигәдер пансионат системасына әһәмият бирми, өйрәнми. Ә бит бу система бөтен дөньяда хупланды. Безнең шартларда, аз керемле, хәтта фәкыйрьлектә булган гаиләләр үз балаларын тиешле дәрәҗәдә укыта-тәрбияли алмаган вакытта, мондый пансионатлар булдыру безгә дә лаземдер...

"Казан культура дәрнәге"—Иске шәһәрдә яшәүче татарларның үзәге, офисы ул. Биредә мине иске танышларым, дусларым көтә иде. Шыгрым тулы бинада кемнәр генә юк: Ихсан Танатар, бертуган Яфайлар: Ихсан, Орхан, Доган; Кенан Иделле, Вахит Ирдан һ. б.. Туганнарча, кочаклашып күрештек. Сагынылган, күптән күрешкән юк иде бит, телефоннан сөйләшү генә күреп сөйләшүләрне алыштыра алмый шул инде. Актык килүем, әйткәнемчә, 1997 елда булган иде, алты еллап вакыт үтеп тә киткән. Ул вакытта булган хәлләрне дә искә төшереп, видеофильм карадык. Аркадашлар Казан шәһәренең башлыгы Камил әфәндене жырлавын бик яратканнар. Әйе, ул вакытта, җәмәгатьчелек белән очрашу кичәсендә, Камил әфәнде бик рухланып, матур итеп "Әниемә" дигән җырны башкарган иде.

Иске шәһәр урамнары буйлап барганда үзгәрешләр күп күренде. Беренчедән, шәһәр трамвай транспортын булдырырга керешкән. Җир тетрәү күп кенә бәлаказа китергән. Яна йортлар, гипермаркетлар, төрле биналар, төзек юллар шәһәрне матурлый, үзенчәлекле итә, ямь кертә. Зилзилә Ихсан Яфайның да йортына зыян китергән, ул хәтта яна йортка күчәргә мәҗбүр булган.

Иртәгә ял көне, шуңа күрә без озаграк йокларга дип килештек. Ләкин шулай да сәгать 9 дан да калмыйча, өч-дүрт машина белән сәяхәткә чыгып кирәргә булдык. Барасы юлыбыз шактый ерак: Иске шәһәр—Сагут—Беләжек. Барышлый Османия дигән татар авылына да кереп чыгарга ниятләдек. Иске шәһәрдәге аркадашларның күбесе шул авылда туып-үскән. Бу якларга килгәндә минем Османия авылына бармыйча кире киткәнем бер-ике мәртәбә генә булды бугай. Биредә үзенчәлекле авыл тормышы. 1896 елда беренче татарлар шушында килеп урнашалар. Бу турыда зираттагы кабер ташлары да сөйли. Әлбәттә инде, хәзерге заманда яшәүче уллары, оныклары үзләренең әти-әни, әби-бабаларының тормышы турында хатирәләр саклыйлар һәм горурланып сөйлиләр. Бу тарихка кергән мөһаҗирлек турында Фатима Озкан чыгарган "Osmaniye TATAR AGZI"( Ankara, 1997) дигән китап шактый кызыклы мәгълүмат бирә. Беренче тапкыр Османиягә без бер төркем туристлар булып 1995 елда килгән идек. Безне бик җылы каршыладылар һәм кунак иттеләр. Татар моңы ул көнне бөтен далага таралды. Ак сакаллы абзыйлар борынгы, без ишетмәгән җырларны илһамланып башкардылар. Җәләй абзый аккордеонда борынгы көйләр уйнап моңланды. Ул чагында мин дә, булдыра алган кадәр, аккордеонда борынгы татар халык көйләрен һәм хәзерге заман көйләрен уйнап күрсәттем. Шулай, татар кая барса да гармун таба, күз яшьләре сыгып моңлана, хисләнә, сагына, тарихын барлый инде ул... Исемдә, беренче баруда Якуб абзый горурланып үзенең фермер хуҗалыгын күрсәтеп йөрде: иске генә булса да, комбайн, трактор һәм башка җир эшкәртү машиналары ишек алдына төзәтелеп, майлап куелган иде. Аерым бер бүлеп алган җирдә—сыерлар, сарыклар, кәҗәләр, кошкорт. "Ничә баш сарыгың бар?"—дип сорагач, хуҗа кеше: "Бер 800 ләп бардыр",—диде.

Беренче булып ерактан авыл мәчете күренде. Без Османиягә килеп җиткәндә азан тавышы яңгырый иде. Намаздан соң андагы мәхәллә инсаннары белән очрашып, сөйләшеп алдык. Авыл башына килеп, анда утыртылган агачларны карадык. Беренче килүемдә әле бу агачларны утырту турында сөйләгәннәр генә иде, ә хәзер инде алар урман булып җиткән. Бу игелекле эш дәвам итә. Авылда яшәүчеләр дә, шәһәргә киткән авылдашлары да агачлар утырту белән ихлас күңелдән мәшгульләр. Әйткән сүз—аткан ук, диеп эш итә алар. Моннан йөз ел элек, аларның ата-бабалары килгәндә тирә-юньдә урман шаулап үскән. Тора-бара хуҗалыкка, көн-күрешкә кирәк булган агачлар киселеп беткән. Аларның балалары, оныклары үз бурычларын кайтарып, ата-баба истәлегенә урманны кабат тергезергә сүз куешканнар. 2004 елда алар тагын 700-800 төп төрле-төрле агач утыртачаклар. Табигать шартлары биредә бездәгедән үзгәрәк. Туфраклары да Әлмәт, Азнакай якларындагыдай кара-кучкыл

түгел, җәен эссе дә, шуна күрә сугару мәсьәләсе бик мөһим. Җәмәгатьчелек, авылныкылар һәм шәһәрнекеләр, бергәләшеп махсус җайланмалар эшләп, суны җир астыннан, тирәннән суырталар. Авыл тормышы кайда да җинел түгел. Монда да тырышырга-тырмашырга, тир түгәргә кирәк икән шул. Йорт, абзар, каралты-кура бут ташыннан, саманнан эшләнгән, түбәләр кызыл чирәп белән ябылган. Корылмаларның эчендә—чисталык, пөхтәлек. Күп йортларда хәзерге заман җиһазлары, заманча техника казанышлары бар, телевизордан спутник аша бөтен дөньяны карыйлар. Тәбәнәк түгәрәк өстәл тирәсендә, аяк бөкләп, йомшак мендәргә таянып утырып, татар кешесе монда да үзенең ризыгын ашап ләззәтләнә. Ин мөһиме, кайсы йортка керсәң дә—якты чырай, такта чәй. Бу килүемдә Османиядә яңа, заманча итеп төзелгән йортларны күреп шатландым. Димәк, авылдан китүчеләр генә түгел, кайтучылар да бар. Дөресен әйткәндә, мин, шәһәрдә туып үскән зат, авыллы кешеләрдән әзрәк көнләшеп тә куям. Чөнки аларның табигать бишеге булган туган авыллары да, авылдашлары да бар. Ә шәһәрдә күршедә торып та берберсен белмәгән адәми затлар яши. Урбанизация корбаннары шул без!.. Хәер, алар да бит шулай ук авыл кешеләре.

Иске шәһәр белән Бурса каласын тоташтырган киң юл буйлап безнең арабалар тагын чаба. Сөйләшә-сөйләшә барып, Согут шәһәренә килеп җиткәнне сизми дә калганмын. Таулар арасындагы тигезлеккә урнашкан бу кала әллә кайдан, тау башыннан ук күренеп тора. Аклы-кызыллы таштан эшләнгән, кызыл эшләпә кигән сыман чирәп түбәле йортлары, мәчетләре яшеллеккә күмелгән нәни шәһәр үзенчә, ашыкмыйча гына яшәп ята кебек. Ләкин бу кечкенә шәһәрнең зур тарихы бар. Музейлар, тарихи һәйкәлләр биредә атлаган саен. Күргәннәрне сөйли, яза китсән, ул үзе бер зур китап булыр иде. Мәсәлән, биредә Эртугрул Газиның кабере, мәчете, музее бар. Бу—тарихи шәхес, галим кеше, анын исеме белән тарихта күп нәрсәләр бәйләнгән. Анын исемен безнен Казандагы татар-төрек лицее да йөртә. Согут шәһәре борынгыдан Төркия дәүләтчелеген булдыру, ныгытуда бик зур роль уйнаган. Шуна күрә дә ел саен биредә барлык мөстәкыйль төрки дәүләтләр күләмендә олы бәйрәм, жыен үткәрелә. Заманча җиһазландырылган зур стадионда төрки дәүләтләрнен җитәкче әһелләре, халык вәкилләре катнашында фольклор концертлары уздырыла. Бөтен шәһәр, безнеңчә әйтсәк, Сабан туе мәйданына әверелә.



*Иске шәһәрдәге иске һәм яңа дуслар арасында. Сулдан уңга: Ихсан Яфай, Вахит Эрдел, Мозаффар Үзтөрек, Илдус Садыйков, Орхан Яфай, Сәрвәт Байкал, Ихсан Танатар.*

Сәяхәтебезнең ахырында безне Согут районынын башлыгы Али Ихсан Су кабул итте. Шәһәр турында язылган бик матур китап-альбом һәм рәсемле тәлинкә бүләк итте ул. Минем Татарстаннан икәнемне белгәч: "Мин сезнең дә киләсе елга бу зур бәйрәмгә килүегезне телим һәм чакыру җибәрәчәкмен",—диде.

Шәһәрдә һәм бу төбәктә сәнәгать тә үсеш алган. Мәрмәр эшкәртү, керамика заводлары җир астыннан чыккан кайнар су кулланалар. Авыл хуҗалыгы терлекчелек, җиләк-җимеш үстерүдән гыйбарәт. Базарлар гөрләп эшләп тора. Халык сәүдә итә, хезмәтенең файдасын күрә.

Термаль суны альтернатив энергия чыганагы итеп куллану аерым хуҗалыкларга да, дәүләт күләмендә зур файда китерә. Төркия шәһәрләрен, авылларын карап үткәндә дә йорт түбәләрендәге су җылыткыч системаларга игътибар итәсен.


Фотоэлементлар ярдәмендә кояш нурларын эшкә жигүче мондый системалар кояшлы Төркиядә генә түгел, хәттә Швеция, Финляндия кебек кояш аз карый торган илләрдә дә бар. Ә жил көче белән әйләнә торган, хәзерге заман технологиясе белән эшләнгән "жил тегермәннәре"—электр генераторлары Германиядә, Англиядә һ. б. цивилизацияле илләрдә барлык электр энергиясенең 15-20 процентын бирә. Газ генераторлары тирестән-чүптән газ эшләп чыгарып, бу газны фермерлар гына түгел, хәтта шәһәр транспорты да куллана. Ә бездә нигәдер меңләгән гектар чәчү жирен, болын-басуларны су астында калдырып, Түбән Кама ГЭСының куәтен арттырмакчы булалар. Голландия үзенең жирен әз генә булса да зурайту өчен аны диңгездән көрәшеп ала, ә без изге жиребезне үзебез суга батырабыз!

Сәяхәтебезнең бүгенге соңгы ноктасы—Беләжек шәһәре. Борынгы ефәк сәүдә юлы бу шәһәр аркылы да узган. Биредәге кемпинглар яңартылган, автомобиль юллары һәм тимер юл, тарихи һәйкәлләр туристларны дәшеп тора. Гел үсә, матур, жыйнак, чиста шәһәр бу.

Безнең татарларны кайда да үз итәләр, хөрмәт күрсәтәләр, чөнки алар үзләренең хезмәтләре, гаделлекләре белән шөһрәт казанган. Беләжек шәһәренең вәлие Айхан Чевикның безне кабул итүе шул хакта сөйли. Айхан әфәнде: "Иске шәһәрнең Казан белән тугандаш шәһәрләр булуы турында ишетеп беләм",— диде һәм уртак эшләр майтарырга әзер икәнен сиздереп: "Беләжек шәһәре дә Иске шәһәрдән ерак түгел..."—дип өстәде.

Иске шәһәргә кайтканда вакыт шактый соң иде. Шуна да карамастан, бераз туктап чәй эчкәннән соң, Вахит дус: "Әйдәгез, егетләр, мунча керәбез",—дип, отельнең аскы катына алып төшеп китте. Мунча нәтижәсе шул, иртә белән телефоннан уятмасалар, ихтимал, төшкә чаклы йоклаган булыр идем. Тиз генә киенеп урамга чыкканда "Мерседес" инде килеп туктаган иде. Утырып, Ихсан дусның (заводына) киттек.

1995 елда килгәндә Ихсанның эш урыны кечкенә генә, берничә эшче хезмәт куйган бер мастерской иде. Яна заводны беренче чираты салынгач күргәнем булды. Ләкин бу килүемдә мин шаккаттым, шатландым һәм дустым Ихсан белән горурландым. Менә ул татарның Форды! Форд та бит машина төзәтә торган кечкенә генә мастерскойдан башлаган. Кесәсендә бары 5 ме, 10 мы доллар булган диләр... Ихсанга да әтисе байлык калдырган: акыл, фәһем һәм эштән курыкмау. Ул да шул Османия авылында туып-үскән, авыл хезмәтендә чыныккан. Укыган, тырышкан-тырмашкан, һәм нәтижәдә менә нинди эшләр башкара хәзер! Өр-яңа, заманча төзелгән бина, компьютер ярдәмендә идарә ителә торган программалы станоклар, югары квалификацияле инженерлар, эшчеләр... Катлаулы детальләрне төрле илләр (Франция, Италия, Германия) заказ биреп, ошбу "TANATAR KALIP" фирмасында эшләтүне кулайрак күрәләр... Бер тапкыр ул зур басымлы пресс юллап миңа да мөрәжәгать иткән иде. Ләкин безнең Русиядәге бюрократия—һәрбер эшкә таяк тыгып гайрәтне жибәрә торган бер Алла каргаган система бит ул. Германиядән, Италиядән һ. б. илләрдән кайтартты Ихсан әлеге пресс-станокларны, һәм хәзер үзенең сыйфатлы эшләре белән төрле дөньякүләм күргәзмәләрдә катнаша, ала, сата, халыкка эш урыннары булдыра. Эшчеләргә медицина ярдәме күрсәтә, заводта ашата-эчертә, яхшы итеп үз вакытында хезмәт хакын да түли. Тәгәрәп бара эше! Шулай булсын өчен ул зур тырышлык куя, ижтиһат итә. Үзе дә, гаиләсе дә рәхәттә яши. Жәмгыять тә олы ихтирам күрсәтә үзенә. Көченнән, мөмкинлегеннән чыгып, Ихсан үз ярдәмен "Татар культура дәрнәгенә", Төркиягә килеп укый торган татар шәкертләренә дә күрсәтә. Ә бездәге теге олигарх диган байлар һәм алай димәгәннәре дә, дәүләт казнасыннан



*Ихсан Танатар заводы.*

урлап, халык байлыгын сатып баючыларның берсе дә, Ихсан кебек, үз тырышлыклары белән түбәннән күтәрелмәгән бит. Ялган белән урлау осталыгын эшкә җигеп, партия оешмасы аркылы югары урыннарга эләгеп сәнәктән көрәк булганнар чутсыз бит хәзер. Шуңа күрә дә мантый алмыйбыз без.

Машинасына утыруга Ихсан дус татар музыкасын уйнатып җибәрә. Ул офисында интернет аша Казан тапшыруларын тыңлый, концерт, җыр, мәзәк тыңларга ярата. Үзе дә бик оста итеп, көлмичә, мәзәкләр, шаян шигырьләр сөйли. Гомумән, зыялы, кабилиятле, самими һәм булдыклы шәхес ул. Машинасында барганда кайчакта кызыклы сораулар биреп куя. Бер заман болай ди: "Илдус абый, менә бу язманы тыңлыйм, кайбер сүзләрен һич аңлый алмыйм. Мәсәлән, нәрсә ул "зараза", "теща", "сволочь" дигән сүзләр?" Сизеп торам, ул инде әллә кайчан бу сүзләрне сүзлектән карап белгән. Ләкин, башка мохиттә тәрбияләнгән кеше буларак, эчке рухы, намусы моны һич тә кабул итми. Кыскасы, мондый мәзәк буламыни, дип, сорау үзенә үзе үк җавап бирә...

Ихсан Танатар турында язуым аны мактарга теләгәннән түгел, әлбәттә. Ул үзе дә, зур эшләр майтарса да, гади кеше булып кала белә. Османия авылыннан чыккан барча мин белгән кешеләр хакында шундый ук җылы сүзләр әйтә алыр идем. Мәсәлән, шул ук Әмин Сакмар, Ихсан Яфай, Кенан Иделле, Бәхсәт һәм Әхмәт Акташлар һ. б. Бу дөньяда алар барысы да үз урыннарын тапканнар, хезмәт итеп, мул тормышларын булдырганнар. Җәмәгатьчелек алдында абруй казанган инсаннар алар.

Төркиягә барган саен мин яңа танышларым арасында тагын татар кешеләрен күреп шатланам. Ихсан Танатарның заводы белән янәшә урнашкан "ENZET" фирмасының завод җитәкчесе Мостафа Башгол әфәнде белән таныштым. Ул юл хәрәкәтен тәртиптә тоту өчен кирәкле билгеләр чыгара, төрле куркыныч-хәвефле эшләр өчен махсус киемнәр, җайланмалар җитештереп, бөтен дөнья кулланучыларына сата.

Иске шәһәр зур сәнәгате, халык куллануы товарлары җитештерүе, медицина өлкәсендәге уңышлары, азык-төлек фабрикалары, атаклы Анадолу университеты белән, музейлары һәм тарихи һәйкәлләре белән (бер Сәет Гази музее, мәчетләре генә дә ни тора), табигатьнең матурлыгы, кешеләрнең кунакчыллыгы белән туристларны, кунакларны үзенә җәлеп итә. Бу шәһәрдә мин үземне нәкъ Казанга кайткан кебек хис итәм. Әлбәттә инде, шундый яхшы дуслар булганга күрә.

Бу тарихи җирдә безнең татар мөһаҗирләре үзләре өчен генә түгел, киләчәк буыннар өчен дә яшәргә, иҗтиһат итәргә уңай шартлар, тугандаш халык һәм ил тапканнар. 1997 елны безнең дәүләт делегациясе Иске шәһәр белән Татарстан башкаласының—бөтен дөньядагы татарларның кыйбласы Казанның тугандаш калалар булуын рәсмиләштереп кайтты. Ә бу эшнең башында халык дипломатиясе торды.

1995 елда без, "Ватан" җәмгыяте һәм Бөтен татар иҗтимагый үзәге вәкилләре, газетадан укып, шуны белдек: имеш, бер төркем Иске шәһәр кешеләре Казанга килергә телиләр икән, әмма ләкин юлга акчалары юк икән... Тиз арада элемтәгә кереп, милләттәшләргә чакыру җибәрдек һәм менә Әмин Сакмар җитәкчелегендәге алты кешелек делегация Казанга килеп тә җитте. Алдан сөйләшкәнчә, һәрберебез берәр кунакны өебезгә алып кайттык, мөмкин булган кадәр кунак итәргә тырыштык. Берничә көн торгач, без аларны, автобусларга утыртып, Татарстан буйлап сәяхәткә алып киттек. Чаллы, Әлмәт, Азнакай якларын урап кайттык. Кунакларыбыз бик тә мәмнүн булдылар.

Санаулы көннәр үтә торды. Китәсе көн дә килеп җитте.

Мине Анкарага озатырга автовокзалга дуслар-кардәшләр тагын да күп булып килгәннәр. Кочаклашып, кул болгап хушлашып аерылыштык. Казанның 1000 еллыгына килербез, Аллаһы боерса, дип, кабат очрашу насыйп булсын дип калды алар.

Анкарага мин Гали Акыш чакыруы буенча барам. Чөнки аның "Исемдә калганнар" дигән истәлекләр китабын тәрҗемә итеп, рус телендә чыгарырга иде ният. Дөрес, инглиз, татар телләрендә басылып чыкты инде ул. Татар телендәгесенең бик күп хаталар белән басылуы кызганыч. Шуның өчен рус теленә тәрҗемәсен

төрек, инглиз телендәге тулыландырылган вариантлар буенча эшләргә кирәк дип таптык. Гали абзый яна, без күрмәгән фотографияләр дә бирәсе иде.

Иске шәһәр, Алпу, Беликово, Сиврихисар (Хужа Насретдиннның туган шәһәре, биредә анын кабере, юл читендә анын ишәккә атланган бик кызык һәйкәле) инде артта калдылар. Тиздән офыкта Анкара да күренә башлады. Ул—Төркиянең башкаласы, анда безнең бөек, мәшһүр милләттәшләребез яшәгәннәр. Гаяз Исхакый, Садри Максудилар бу дәүләтнең сәясәтендә, тормышында катнашып, тарихка үз өлешләрен керткәннәр. Ишетүемчә, Садри Максудины, хәтта Төркиянең Президенты итеп тә сайламакчы булганнар...



*Гали Акыш (уңда) үзенең 93 яшьлек абыйсы Газиз белән.*

Иртәгесен, Гали абыйның өенә машина җибәреп, аны мин тора торган йортка алып килделәр. Гали абый чын зыялы кеше, бик матур итеп киенгән, муенындагы модный галстук (төрекчә—карават) аны яшәртеп тә җибәргән сыман. Актык мәртәбә без анын белән Германиядә, Мюнхен шәһәрендә очрашкан идек. Мюнхенга баруның бик мөһим сәбәбе булды. Гали Акыш үзенең китапханәсен һәм архив материалларын Татарстанга бүләк итте. Шушы зур бүләкне (анда нәрсә генә юк иде: тарихи китаплар, журналлар, газеталар, документлар, аудиовидео материаллар) тарихчы профессор Искәндәр Гыйлажев белән бергәләп, тәртипкә салдык. Аннары 500 кг чамасы авырлыктагы йөкне мин Казанга алып кайтырга тиеш идем. Һәм бу төрле дипломатик каналлар аша башкарылды. Хәзерге вакытта ул әйберләр Татарстан дәүләт архивында саклана. Гали Акыш бу эш өчен кабат рәхмәтләрен әйтте: "Син алынмаган булсаң, минем архив та, китапханә дә башка җиргә китеп бара иде...—диде ул. "Гариф Солтанның архивын алып кайта алдыгызмы?",—дип тә сорап куйды. Гариф Солтан белән Мюнхенда очрашуыбызны әйтеп: "Анын да архивын Татарстанга кайтарасы килүе турында Республика җәмәгатьчелегенә белдердем",—дидем...

Кичке азан бөтен Анкара шәһәре өстенә үзенең изгелеккә чакыруын тарата иде. Шул чак мин Гали абыйга әйтеп куйдым: "Исеңдәме, Гали абый, без Австралиядән кайткан Сәгыйт Садри абый белән минем өйнең лоджиясына чыгып, Мәрҗани мәчетендә әйткән азанны тынлап, күздән яшьләр тамызган идек. Ә безнең кадерле кунакларыбыз ул вакытта болай диделәр: "Бабаларыбызның туган иленә кайтып, Казаныбыз мәркәзендә азан тавышын ишетербез дип һич уйламаган идек..." Хәтереңдәме, син нинди матур шигырь укыган идең:

Кичке Казан,
Кичке азан,
Моңлы уйлар
Килә аннан.
Төшә искә
Иске заман,
Холусан мостәмигъ азан... *(Г. Тукай)*

Кызык бу дөнья дигәнең. Юкка гына дөнья түгәрәк димәгәннәр шул. Мюнхенда да бер гаҗәп вакыйга булган иде. Кичен, соңгарак калып, Гариф Солтан әфәнденең өеннән, кунактан отельгә кайтып барам. Метро станциясенә төшкәндә арттан килә

торган бер ханым алман телендә нindидер сорау бирде. Тирә-юньдә башка кеше юк. Мин җавапны татар телендә кайтардым. Их, мин әйтәм, әгәр алман телен белсәм, бәлки файдалы җавап бирер идем... Ул арада әлеге "фрау": "Абый, әллә сез татармы?"—дип сорап куйды. Әйләнеп карасам, янәшәдә чибәр генә татар хатыны басып тора. Кая барсаң—шунда татар, яһүдиләрдән бер дә ким түгел.

Шуны уйлап куям, бәлки безгә, Татарстан дәүләте чикләрендә, төрле илләрдә яшәүче татарларны барлау, берләштерү максатыннан чыгып, берәр министрлык-фәлән булдырырга кирәктер? Мәсәлән, Израильдә, Англиядә һ. б. кайбер илләрдә мондый департаментлар бар һәм алар уңышлы гына эшләп килә.

Иртәгесен күрсәтелгән ресторанга барып җиткәндә безне инде көтеп торалар иде. Кунаклар арасында таныш кешеләр дә күренә. Әле яңа гына Казандагы дипломатик хезмәтен (консул буларак) тәмамлап Төркиягә кайткан Әхмәт Рыза Демирер хәзерге вакытта Төркиянең чит илләр министрлыгында дипломатик эшен дәвам итә. Тагын Гали Акыш, Сәгыйт Хәйри әфәнде, Казаннан килгән берничә университет шәкерте—җәмгысе 15-17 кеше бар иде.

Мәҗлесне Шәүкәт Кунтай әфәнде ачып җибәрде, Әхмәт Рыза әфәнде үзенең Казан хатирәләрен уртаклашты. Казан аның күңелендә матур тәэсир калдырган. Әхмәт Рыза әфәнде үзе дә бездә, казанлыларда күңелгә ятышлы мөнәсәбәте белән җылы хатирә калдырды. Ул ел саен 29 октябрьдә Казандагы Төркия консуллыгында җәмәгатьчелекне җыйнап, Төркиянең Республика көнен билгеләп үтәдер иде. Безнен "Ак өмет" балалар пансионатына килеп, үзенең кинәшләрен дә биргән иде әле. Гомумән, Әхмәт Рыза әфәнде чын мәгънәсендә, зур колачлы дипломат. Бәлки әле ул киләчәктә Мәскәүдә дә илчесе вазифасын башкарыр.



*Анкара шәһәре күренеше.*

Омәр Озҗан әфәнде татар әдәбияты, тарихы белән кызыксынучы кеше. Ул берничә мәртәбә Казанда да булып китте. Килгән саен китаплар алып китә. Мәҗлестән соң Омәр әфәнде мине үзенең офисына чакырып, бик озак кына сөйләшеп утырдык. Ул миңа китаплар исемлеге бирде һәм: "Шушы китапларны табуда булышсагыз, мин бик рәхмәтле булыр идем",— диде. Хәзер мин ул сораган тарих китапларын тапкан саен җибәреп торам. Мәҗлес барышында бер тәнәфестә Сәгыйт Хәйри әфәнде, Төркия дәүләт радиосының татар телендә алып барыла торган программасының хәбәрчесе буларак, миннән интервью алды. Сәгыйт әфәнде Казаннан килеп, университет бетереп, өйләнеп Анкарада яшәп ятучы яшь буын вәкиле.

Истанбулда да мине киеренке сәяхәт программасы көтә иде. Музейлар, күргәзмәләр, институтлар, радио-телевидение, кунак-зыяфәтләр. Күбесен кыскартырга туры килде.

Иртәгесен Рәшид Лаеш, Яшәр Байтак, Атила Кунтуз килеп, мине Истанбулның Азия ягына алып киттеләр. Тау юлларын урап-урап, без диңгез ярына урнашкан бик матур балыкчылар авылына килеп, көне буе диярлек ял иттек. Алар үзләренең моң-зарларын да сөйләделәр: "Бу елда без Истанбулда Сабан туен уздыра алмадык. Чөнки чыгымнарын күтәреп булмады, халык та бик активлык күрсәтмәде",—диделәр.

Аркадашлар Истанбулның җир астына урнашкан алтын эшкәртә торган заводларын да күрсәттеләр. Төркия дәүләтенең зур бер харитасын (картасын) барып карау да зур тәэсир калдырды. Бу күренешне төрек Диснейленды дип тә әйтеп була. Мондый эшнең тәрбияви әһәмияте бик зур, бигрәк тә яшь буын өчен, алар

үзләренен тарихларын, мәдәниятләрен, архитектура ядкарьләрен күреп, белеп үсәләр. Милли горурлык әнә шундый энже бөртекләреннән ярала ул.

Мозаффар әфәнде мине тагын бер кызыклы музейга алып барды. "Борынгы Истанбулны күрәсең киләме?"—диде ул, һәм без тиз арада үткән гасырга барып җиттек. Агач йортлар, тар урамнар, таш юллар. Бу—ачык җирдә урнашкан музей иде. Милләтнең үткән гасырдагы көнкүрешен тамаша кыла, уйландыра, тормыштан канәгать булырга, шөкрана кылырга өйрәтә бу йортлар. Өске катлары музей булса, аскы катта яки ян бүлмәдә бәләкәй генә кафе, ресторан эшләп тора. Шунда ук сина милли ризык та әзерләп бирәләр. Ягъни музейларны тәртиптә тотар өчен бюджеттан гына акча көтеп ятмыйлар, үзләре дә акча эшлиләр. Ә бездә менә дигән шыгырдап торган бүрәнәдән салынган, матур итеп челтәрләп ясалган тәрәзә янаклы, милли бизәкле, кәрнизле йортларны сүтәләр, җимерәләр, яндыралар да, соныннан бомжларга сылтыйлар.

Биредә яшь кешеләр әнә шулай милли гореф-гадәтләрне белеп үсә. Югыйсә нинди тату булып күренгән яшь гаиләләр таркала бездә. Сәбәбе шул анын: милли гореф-гадәтләрне белмәү, санга сукмау. Яна тормышны аракы эчеп, "шумел камыш" дип акрып-бакрып башласаң, ахыры ни белән бетәсе билгеле инде анын..

Доктор Туран Язган белән очрашып булмады, ул кайдадыр сәяхәттә иде. Истанбулда тагын бер танышым артты. Ул—Яшәр Гувенч дигән әфәнде. Алар Гөлтан Ураллы белән берлектә музыка мәркәзендә музыкаль дисклар, кассеталар яздырып чыгара. Бер яшь җырчының дискларын бүләк итте. Үзенчәлекле җырчы, Кытайда туып үскән Рауза Мөслих булып чыкты бу. Измиргә баргач, алар белән дә танышкан идек.

Сәяхәтне тәмамлап, туган-үскән җиргә исән-сау, шәп кәеф белән кайтудан да рәхәтрәк нәрсә юктыр. Һәрхәлдә, икенче сәяхәткә кадәр сагыну хисләрен белән яшисен. Шулай Америкадан кайтып төшкәч бер күршем: "И-и, Илдус абый әллә нинди япон фирмалары ясаган электроник "Сони"лар алып кайткансындыр инде (ул вакытта бездә андый нәрсәләргә кытлык иде әле)",—диде. "Әйе, мин әйтәм, алып кайттым, ләкин "Сони" фирмасыныкын түгел, гыйбрәт дигән фирманыкын". Беркатлы да инде бездә кешеләр, "Гыйбрәт" фирмасы барлыкка ышанды, ә менә үз телен әле дә булса юньләп белми.

Борынгылар әйтмешли, бер табышсыз кайтсан да, дөнья күрүең үзе зур табыш ул.

# БЕЗНЕ САНАДЫЛАР

**Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары, тарих фәннәре докторы Дамир Мәүләви улы Исхаков белән әңгәмә.**

*Әллә кайчан караган бер мультфильм онытылмаган. Кәҗә бәтие корабльдәге җан ияләрен кычкырып саный башлый: үгез—бер, сарык—ике, әтәч—өч... Шунда, "ул безне саный!" дип, ярсыган кече туганнарыбыз мескен кәҗә бәтиенә ташлана... Бик кызык тоелган иде бу. Вәт җүләрләр, санау да булдымы шаккатарлык эш!*

*Яши торгач аңладым менә, бик тә хикмәтле нәрсә икән бит ул санау.*

*2002 елны Россиядә зур санау үткәрделәр. Башкалар белән бергә без татарларны да санадылар. Аннан бик озак исәпләделәр. Ниһаять, исәпләп бетергәннәр бугай. Дамир Исхаков белән әнә шул хакта гәпләшмәкче инде без.*

*Бу танылган этнолог һәм милли хәрәкәт әһеле белән күп тапкырлар әңгәмәләшкән бар. Әмма ишегенә мондый исем язылган бүлмәдә беренче тапкыр: "Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының этнологик мониторинг үзәге". Д. Исхаков шушы яңарак кына ачылган, безнең өчен бик тә кирәкле үзәкнең җитәкчесе була инде.*

## Батыйлардан ук башланган

***—Дамир әфәнде! Сүзне борынгы заманнардан башлыйк әле. Беренче халык исәбен алуны Алтын Урданың Болгар олысында да, урыс олысында да монгол-татарлар үткәргән бит, әйеме?***



—Әйе. XIII гасырда. Һәрхәлдә, документларда сакланган мәгълүматлар шуны күрсәтә. Бөтен Евразияне диярлек яулап алганнан соң алар хәзерге Россия җирендә беренче тапкыр халыкны исәпкә алалар. Дөрес, ул заманда бөтен халык түгел, ясак түләүчеләр генә теркәлә.

***—Үзләре өчен дә яңа эш булганмы бу? Әллә монголлар үз җирләрендә халыкны аңарчы да санап торганнармы?***

—Исәпләгәннәрдер. Хәрби бүленешләре дә шуны күрсәтә бит. Уннар, йөзләр, меңнәр, ун меңнәргә бүлү гаиләләр саныннан чыгып эшләнгәндер ул. Халык санын алу, бәлки, кытайлар йогынтысында кергәндер, шулар традициясеңдер бу.

***—Россиядә үткәрелгән халык исәбен алуларның кайсы да булса яктан аерылып торганнары бармы?***

—1897 елгысы—беренче дөрес итеп үткәрелгәне. Шуңарчы бөтен халыкны түгел, салым түләүчеләрне генә исәпкә алганнар. Монысының исеме үк "Всеобщая перепись". Әмма монда да бер кимчелек бар әле—милләтне тел буенча билгеләгәннәр. Туган тел белән милләт туры килмәскә дә мөмкин бит. Европада күптән инде милләтне кешенең милли аңы буенча билгеләгәннәр. Исәп вакытында туган телне дә теркәгәннәр... 1926 елгысы иң шәп исәп алу булып санала. СССР төзелгәннән соң 4 ел гына үткән, Сталин режимы ныклап урнашмаган әле... Сталин көчәйгәч, 1937 һәм 1939 елларда санныйлар халыкны.

***—Ике ел ара беләнме?***

—Әйе, чөнки беренче исәп алу халыкның нык кимегәнлеген күрсәтә—ялгыш үткәрелгәнгә чыгарып, ул нәтиҗәләрне "ябалар" һәм 1939 елны "дөрес итеп" үткәрәләр.

***—Ягъни репрессияләр булмаган итепме?***

—Әйе, монысында хәл яхшырак булып күренә инде. Социализм төзүдә “ин зур жинүләр яуланган” чорда бөтен саннар да ялтырап торырга тиеш була.

1959, 1970, 1989 елгы исәп алулар стандарт совет кысаларында, ныклап урнашкан методика буенча үтә. Тупас бозулар булмый шикелле. Ә менә 1979 елны ялган керде: Башкортстанда башкортлар саны арттырып язылды.

## Беренче кат санау кызык ул

***—Соңгы халык исәбен алулар 1970, 1979, 1989 елларда булган. 9-10 ел ара калдырып. Димәк, чираттагысы 1998 яки 1999 елда үтәргә тиеш булган. Шул вакытта узса, аның нәтиҗәсе башкачарак килеп чыкмас иде микән? Татарлар өчен диюем. Шуннан соңгы 3-4 ел нык кына чигенү вә кысылулар вакыты булып, икеле-микеле йөргәннәрдә татар саналу дәртен сүрелдерә төште шикелле.***

—Россиядә икътисади яктан авыр чор иде бу. Теге дефолтлардан соң. Әмма халык исәбен алуны чигерүнен сәяси сәбәпләре дә бардыр дип уйлыйм мин. Аны ничек итеп үткәрүнен тиешле сәяси кысалары юк иде ул вакытта. Россиягә беркадәр кереп өлгергән демократиядән бүтән төрле “халәткә” күчеп бару чоры бу.

***—Сәясәтне катыштырмыйча үткәрәселәре килмәде инде?***

—Мин шулай дип уйлыйм. Власть ул чакта зәгыйфьрәк иде. Үзе теләгәнчә үткәрә алмаган булыр иде. Һәм нәтиҗәләре дә ул теләгәнчә килеп чыкмас иде.

***—Монарчы бу олы эшне СССР башкаласы булган Мәскәү үткәрсә, монысын Россия Мәскәве үткәрде. Беренче мәртәбә. Аның өчен бик кызык бит инде бу. Сиңа калган абзардагы сарыкларны санаган кебек. Үзләре теләгәнчә, тәмләп, ләззәтләнеп санайсылары килгәндер. Аерма сизелдеме?***

—2002 елны иң каты дискуссия тел мәсьәләсендә булды. Бер төркем галимнәр, “туган тел” дигән графаны алып атып, “телләрне куллану” дигәнен куярга тәкъдим иттеләр. Бу инде совет чорындагы традицияне бозу иде, Россиянен яна юл белән үсүенә бәйле әйбер иде.

***—Халык исәбен алуга әзерлекнең сюжеты, вакыйгалануы ничек булды? Ничек башланды, ничек дәвам итте?***

—Әзерлек эшләре 2000 елда ук башланып китте. Моның бит бар чиста техник ягы,—исәпкә алу кәгазьләрен булдыру кебек. Бар методик ягы. Монысында бер әйбер әһәмиятле. Социологияне беркадәр аңлаган кеше буларак, беләм: сорашу вакытында нинди сорау бирсәң, шундый җавап аласың.

***—Чиләгенә күрә капкачы.***

—Әйе, синең соравыңа карап җавап бирәләр. Исәпкә алу кәгазьләренә кертеләсе сораулар турында бик нык уйландылар. Бәхәсләр дә булды. Тел турындагысын әйттем инде. Аннан соң милли состав буенча бәхәс китте. Исемлеккә нинди халыкларны кертергә? Безнең өчен генә түгел, башка күп кенә халыклар өчен дә үткен мәсьәлә булып чыкты бу. Хәтта русларның үзләренә дә кагылды. Казак дигән милли төркем бүленеп чыкмасын дип нык тырыштылар. Мордвалар, марийларны исә бүлеп, икешәр халык дип санайсылары килде. Эрзя һәм мокшалар, тау марилары һәм болын марилары булган бит. Кавказда, бигрәк тә Дагыстанда ризасызлык туды. Иң каты бәхәсләр татар мәсьәләсендә барды...

Менә болар методика дигән нәрсәгә карый инде. Дөньяда ике төрле методика кулланыла. Күпчелек илләрдә, бигрәк тә алдынгы илләрдә, исемлек төзеп тормыйлар, милләтен кеше үзе әйтә. Элек империя булган яки артта калганрак, демократия азрак булган илләрдә алдан халыклар исемлеге төзелә, җавап бирүче милләтен шуның ярдәмендә билгеләргә тиеш була.

***—Ни дип аңлаталар инде моны, исемлек нигә кирәк булып чыга?***

—Аңлатулары бик гади аларның: исемлек нииндидер күләмдә чикләнгәч, соңыннан машинада эшкәртү җинелрәк, янәсе.

***—Әйтәм аны ике ел ярым гына санадылар, ун елга сузмадылар!.. Бу эшнең башында кем торды инде?***

—Россиянен дәүләт статистикасы федераль хезмәте. Ул Россия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты белән шартнамә төзеде.

Институт теге исемлекне әзерләп бирергә тиеш иде. Һәм Тишков әфәнде җитәкләгән институт ике елга якын шул эш белән шөгыльләнде.

***—Шулкадәр катлаулы эш мени бу?***

—Юк, катлаулы түгел. Әгәр дә Россиядәге милләтләрнең, төбәкләрнең фикерен алдан белсән. Әмма эш алай алып барылмады. Мәскәүдә урнашкан бу академик институт үзе ничек уйласа, шулай төзеде исемлекне. Демократик юл белән бармады бу эш. Милләтләр һәм төбәкләргә фикерне соңыннан белдерергә туры килде.

***—Безне гел санап торганнар. Әмма татар үзенең ризасызлыгын беренче тапкыр белдерде бугай.***

—Әйе, беренче тапкыр. Патша заманында да, совет чорында да бездән, сез нинди халык, нинди милли төркемнәрегез бар, сезне исәпкә ничек кертик дип сорап тормадылар. Демократия булмаган заманда моны үзең әйтү мөмкин түгел иде. Шуңа күрә бу очракта татарларның үз фикерләрен әйтүе ул демократия шартларында халыкның уянуына бәйле иде.

***—Үзләре сорамагач, бу фикер алышуны диалог дип әйтеп булмыйдыр инде.***

—Юк шул, алар үзләре сорамадылар. Мәскәүгә татарлар көчләп такты бу диалогны. Галимнәребездән башланды бу. Татарстан Фәннәр академиясендәге галимнәр безнең Президентка да, Дәүләт Советына да мөрәҗәгать иттеләр. Шуннан соң безнең парламент исеменнән Россиянең Дәүләт Думасына һәм сонрак Россия хөкүмәтенә хат китте. Мин аларның икесенең дә эчтәлеген бик шәп беләм.

***—Үзегез язмагансыздыр бит?***

—Үзем әзерләдем. Соңрак Татар конгрессы башкарма комитеты мөрәҗәгать кабул итеп, аны Мәскәүгә җибәрде.




***—Гап-гади эшне катлауландыруда этнология институты директоры Валерий Тишковның өлеше зур булды бугай. Аның ихластан ялгышуымы бу, әллә...***

—Төрлесе бар монда. Беренчедән, Тишков сәяси һәм социаль заказ алды: татарны бүлгәләргә. Моны хәзер аермачык әйтеп була. Мәскәүне татарның саны мәсьәләсе борчый иде. Иң әүвәл, Татарстанда яшәүчеләрнең яртысыннан күбәеп барулары. 1989 елгы исәп алуда без 48,5 процент булсак, 1995 ел тирәсендә 50 процент чигеп үттек. Агымдагы статистик мәгълүматлардан килеп чыга иде мондый сан. Ә бу—үтә мөһим чик. Татарстанның статусына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә Мәскәү өчен татарларның Татарстанда 50 проценттан кимрәк булуы кулай. Тишков менә шуны тәэмин итәргә тиеш иде инде. Моның иң җайлы ысулы—татарны бүлгәләү.

***—Тишковның шундый заказны үтәргә маташуы нәрсәдә күренде?***

—Ул безнең татарны бүлгәләргә кирәкми дигән тезиска бик тә үҗәтләнеп каршы торды. Фәнни күзлектән караганда мондый мөнәсәбәтне һич аңлап булмый. Керәшеннәрне аерып чыгарсаң, татарларның мөселман өлеше Татарстанда яртыдан кимрәк булып кала дигән фикер Мәскәүдәге кайбер оешмалар, органнарда да янгыраган. Мәсәлән, куркынычсызлык органнарында эшләүче оешмаларның интернет сайтларында булды ул турыда хәбәр. Үзенең интервьюсында Тишков туптуры әйтте—керәшеннәрне аерым милләт итеп язарга кирәк дигән фикерне Россия патриархы да алга сөргән. Шундый үтенеч белән ул Россия Президентына хат та язган. Резолюция салынгач, бу хат Тишковка төшерелгән.

Башка якларын да истә тотарга кирәк. Татарны бүлгәләргә теләүчеләр фән кешеләре арасында да бар иде. Рус галимнәренең Себердә оешкан, Томилов әфәнде җитәкләгән мәктәбе, мәсәлән, Себер татарларын аерым, мөстәкыйль халык дип санап килде.

***—Аларга безнең кайбер татар галимнәре дә булышты бугай.***

—Әйе, андыйлар бездә дә булды. Әйтергә теләгәнем шул: Тишков үз фикерен генә көчләп такмады, әнә шундый кирәкле тарафтан янгыраган фикерләргә дә колак салды. Ул галим генә түгел, күпмедер дәрәҗәдә сәясәтче дә бит әле.

***—Министр да булып алды. Нәкъ менә милләтләр эше буенча.***

—Министр да булды, әйе. Халык исәбен алганда кылган гамәлләре анын үзенен карашларына да туры киләдер дип уйлыйм. Чөнки нәкъ менә Тишков министр чакта бер документ эшләнде. Татар диаспорасын Татарстаннан аерырга кирәк дигән. Бу да милләтне таркатунын бер юлы инде. Читтәгеләрне аерып алып.

***—Аның, милләтләр ясалма бер әйбер ул, дигән фикере дә бар бит әле.***

—Татарлар ясалма рәвештә барлыкка китерелгән милләт дип әйткәне дә, язганы да булды. Сез әйткәнчә, милләтләр гомумән ясалма әйбер дигән карашы да бар, әйе. Шуннан чыгып, кирәк чакта милләтләрне таркату аерым шәхеснен кулыннан килә дип ышанды ул.

## Көчләп тагылган диалог

***—Мәскәү белән Казанның "диалогы" ничек барды соң, Дамир әфәнде?***

—Асылда тарткалаш рәвешендә барды. Минем шул темага беренче мәкаләм 2000 елны ук чыккан. Татарны бүлүгә хәзерлек эше башланды, диелгән иде анда. 2002 елнын августларына кадәр тарткалаштык без. Мәскәүгә барып та даулаштык. Этнология институтынын шул мәсьәлә буенча үткәрелгән гыйльми советы утырышында. Бездән, Тарих институты директоры һәм Татарстан Президенты киңәшчесе буларак, Рафаэль Хәкимов һәм Татарстан Фәннәр академиясе галимнәре катнашты. Дискуссия бик каты барды анда.

Моннан тыш тагын Путиннын үзенә мөрәҗәгать итү дә булды. 2002 елнын августында Казанга килгән иде бит ул. Өченче бөтендөнья татар конгрессы тәгәлләнгәч, Путин татар җәмәгатьчелеге вәкилләре белән очрашты. Махсус хат язылып, шунда анын кулына тоттырылды. Конгресснын яна башкарма комитеты рәисе булып сайланган Ринат Закиров аны кычкырып укып та бирде. Тагын шунысы бик шәп булды: Путин белән Шәймиев сөйләште. Элек тә бер сөйләшкән иде ул анын белән, менә бу очрашу вакытында да сөйләште... Боларнын йогынтысы булмый калмагандыр дип уйлыйм мин. Һәрхәлдә, Путиннын тел мәсьәләсендә фикере менә шушы очрашудан сон үзгәрде. Ул исәп алу кәгазендә телне куллану турындагы графа урынына туган тел графасын кертергә күрсәтмә бирде.

***—Соңыннан Фәндәс Сафиуллин шау-шу куптарган нәрсә бит инде бу. Путин кулына шундый сораулы кәгазь тоттырылып та, калган бөтен халыктан иске сорауга җавап алынган түгелме соң?***

—Әйе шул, Путин күрсәтмә биргән бирүен, әмма ул вакытта анкеталар басылып өлгергән була инде. Шуна күрә нәтиҗәсе булмады бу эшнең.

***—Нәтиҗә булмау гына түгел, уен уйнала. Путинның күрсәтмәсен Путинның үзе өчен генә үтәгәннәр булып чыкты. Ягъни күз буяу гына булган бу... Ә менә халыклар исемлеген үзгәрттерә алдыгызмы соң?***

—Юк, исемлек шул баштагы төзелгәнчә калды. Бу институтта без тагын халык исәбен алу алдыннан да булдык бит әле. Без нык торгач, алар икеләнә башладылар. Исемлекне үзгәртмәделәр үзгәртүен, әмма исәп алу үткәч кайбер төркемнәрне татар эчендә санарга вәгъдә иттеләр.

***—Ничә халыкка бүләргә мөмкин иделәр безне? Исемлектә татар эченә кергән ничә төркемне аерып бирделәр?***

—Кырык биш төркемне.

***—Кырык биш? Моңарчы татар дип йөртелгән милләт эчендә шулкадәр халыкны ничек тапмак кирәк? Алайса, бәлки, мин дә татар түгелмендер? "Арчалар" дигән халык та юк идеме ул исемлектә?***

—Сез, Рәфикъ әфәнде, Арча кешесе буларак, Казан татарларының үзәк төркеменә карыйсыз. Белә идегезме моны?

***—Үзәктә булу әйбәт анысы, әмма бу хакта беренче сездән ишетүем.***

—Сергач ягында яшәгәннәр, мәсәлән, мишәрләрнең төньяк төркеменә керә. Әмма шунда керүләрен алар да һич белми яши бирә. "Үзәк төркем", "Төньяк

төркем" дигәнебез—этнографик төркемнәр була. "Казан татарлары" һәм "мишәрләр" дигәне исә—этник төркем. Этнографик төркемнәр этник төркемнәр эченә керә. Теге исемлектә татарның менә шундый, галимнәрнең үзләреннән башка беркем дә белмәгән этнографик төркемнәрен этник төркемнәр дәрәҗәсенә күтәреп биргәннәр. Шуннан килеп чыга бит ул кырык биш "халык".

***—Вәгъдәләрендә тордылармы соң Тишковлар?***

—Тордылар дияргә була. "Татарлар" дигән төркемгә Әстерхан татарларын, керәшеннәрнең бер өлешен дә кертттеләр. Башта аларны аерым халык итеп санарга уйлаганнар иде бит.

***—Аерып саналучылары кемнәр?***

—Себер татарларының бер өлеше, Нугайбәкләр белән Әстерханда яшәүче карагашлар, керәшеннәрнең бер өлеше татардан аерылып калды. Карагашлар нугайлар дип саналдылар. Чулым татарлары калды. Телеутлар аерым йөри.

***—Үткән исәп алуда кайда теркәлгән иде соң болар?***

—Телеутлар элек тә аерым санала иде. Әмма алар барыбер аерым билгеләре булган этник төркем түгел. Элек-электән Томск өлкәсендә, татарлар арасында гомер кичергәннәр, аларның икенче исеме дә—"татар кеше".

***—Дамир әфәнде, ничек кенә шаулап та мәскәүләр исемлекне үзгәртмәгәч, санаганда кушарбыз дип кенә вәгъдә биргәч, аларга уйнарга урын калган бит. Санап карыйлар да, әйтик, мишәрләр, керәшеннәр, Себер татарлары булып язылучылар күп икән, тоталар да аларны аерым халык дип игълан итәләр.***

—Әйе, бөтен максатлары шул иде инде аларның. Планнары барып чыкмагач, бу мәсьәләне күпертә генә алмадылар.

***—Ике-өч меңлек "халыклар" санын ишәйтү исә аларның үзләренә дә кызык түгел—мәшәкать арттыру гына була.***

—Нәкъ шулай, әйе. 10 мең кеше Себер татары булып язылгач, мәшәкатьләр генә түгел, зур-зур проблемалар туа башлады анда.

***—Себер татарларына махсус тукталырбыз әле, Дамир әфәнде. 5 ярым миллионлы татарны, димәк, халыклар исемлегенә 45 төркем итеп керткәннәр. 120 миллионлы рус халкы, алайса, йөзләрчә төркем булып кергәндер инде?***

—Юк, Мәскәүнең русларны консолидацияләнгән, бербөтен халык итеп күрсәтәсе килде. Казаклар бик тә аерымланырга теләгән иделәр. Саналуын аерым да саналды алар, әмма исемлеккә барыбер руслар эченда бирелделәр.

***—Монда, алайса, чыннан да шундый омтылыш аермачык күренеп тора: русларны бербөтен итеп саклап, калган бөтен халыкларны вакларга, таркатырга. Ягъни башка халыкларга бернинди ихтирамсыз, абзарларындагы сарыкларга караган кебек карау. Хәер, сарыкларны да, мал санап, сакларга тырышырлар иде әле.***

—Бар мондый әйбер. Бер интервьюсында Тишков, халык дәүләт өчен кирәк ул, дип тә әйтте әле. Ягъни һич тә дәүләт халык өчен түгел. Димәк, дәүләт милләтләрне дә теләсә нишләтә ала. Мәскәүнең кулыннан килсә, ул исәп алуны тулаем үзе кирәк санаганча оештырыр иде дә, күп кенә халыклар каршы булып чыкты. Бер татар гына түгел.

## Мишәр мәсьәләсен япсак та була

***—Исәп алуны кичкән милли төркемнәребезне барлап чыгыйк әле, Дамир әфәнде. Мишәр мәсьәләсе борчып, шикләндереп торган иде. Алар бүленеп чыкса, сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да зур, хәтәр югалту була ала иде бу. Милләтне икегә бүлү. Әмма иң җиңел хәл ителгәне дә шушы мәсьәлә булды шикелле, әйеме?***

—Мишәр дигән төркемне булдыру барып чыкмады ул. Тишков институтындагы дискуссия вакытында ук күренде бу. Мишәр булып язылырга теләгән бер генә иҗтимагый оешма да табылмады.

***—Әмма аларны бүлеп чыгару омтылышы көчле булды кебек бит?***

—Мондый омтылыш булды, әйе. Шул этнология институты нык тырышты. Хәтта сорап-сорап та карадылар, табыгыз әле, кая икән ул мишәр булып язылырга теләгән төркемнәр, дип.

***—Мәскәүдәге татар лидерлары ымсынмадымы? Аларның күбесе мишәр бугай бит.***

—Юк, кызыкмадылар. Төшеп калды бу мәсьәлә. Мишәр булып язылучылар 500 кешедән артмады.

***—Мишәрләрне аерып чыгару төшеп калдымы, әллә тулаем мишәр мәсьәләсеме? Татарны бүлгәләмәскә омтылу гына булдымы бу, әллә без гомумән мишәрләрне юк дип саный алабызмы?***

—Мишәрләрне юк дип карый алмыйбыз, чөнки бар алар. Казан татарларыннан тыш милләтнен икенче иң зур этник төркеме бу. Аларнын үзләренә хас мәдәни һәм тел үзенчәлекләре бар... Мишәр мәсьәләсен соныннан монда, үзебезнең галимнәр арасында да тикшереп карадык без. Шундый фикергә килдек: аларга хас үзенчәлекле аң һич тә милли аңга карамый. Ул—түбәндәгерәк нәрсә, төбәкчеклек аңы кебек. Минзәләлеләр яки сабалыларга хас булган кебек, урынчылык аңы гына ул. Шулай дип караганда, мишәрлекнең нигә һаман яши биргәнлеге аңлашыла. Мәсәлән, Мәскәү шартларында якташлык җәмгыятьләре бар, үзара бәйләнешлар бар. Менә шул бәйләнешлар моны беркадәр тотып, саклап киләләр. Ә болай реаль тормышта мишәрлекнең бернинди мәгънәсе калмаган инде.

***—Мишәрләрнең милли төркем буларак аерым ихтыяҗлары юк, әйеме?***

—Юк, чынлыкта юк.

***—Мишәрләрдән шактый кеше ул катлаулы мәлдә татарның бердәмлеген, бербөтенлеген яклап көрәште дә бит әле.***

—Әйе, шулай бу. Мишәрне аерып чыгарырга маташуның мәгънәсе булмады.

***—Мишәрләр үзләренең мишәрлекләрен онытырга да әзер бугай ул. Ләкин оныта алмаячаклар. Казан татарлары оныттырмаячак. Аларга мишәрләрнең гел борыннарына төртеп тору, шаярту, тел чарлау өчен кирәк бу.***

## Җирле халыкның җире булсын

***—Себер татарларыбыз калдымы әле безнең? Аерылып-таралып бетмәделәрме?***

—Исәп алу алдыннан без монда, Татарстанда, Себер татарлары мәсьәләсен бөтенләй ябып куярга ашыкмадык. Дөресен әйткәндә, ябарга бөтенләй тырышмадык. Чөнки бу мәсьәләнең сәяси-иҗтимагый ягыннан тыш икътисади ягы да бар. Себер татарлары үзләре бүленеп чыгарга бик атлыгып тормасалар да, җирле төркем булып язылу теләге дә юк түгел иде. Чөнки бу табигый ресурслар өчен көрәш белән бәйле. Җирне, күлләрне үзләренеке итеп беркетмичә торып Себер татарларының шактый өлешенә үсү мөмкинлеге калмый иде. Без каршы чыкмадык монa. 9,6 меңгә якын кеше исәп алганда Себер татары булып язылды.

***—Барсы күпме алар?***

—180 меңнән 200 меңгә кадәр, ягъни егермедән бер өлеше аерым теркәлде. Зур сан түгел, әмма абориген хокукларны беркетергә, бәлкем, ярдәм итәр әле.

***—Мондый вариант та бар иде түгелме? Себер татарларын үгетләп диярлек бөтенесен дә җирле халык итеп яздырасың. Себердә милли татар өлкәсе пәйда була. Соңыннан ике арада мәдәни, мәгърифәти һ. б. төрле күперләр саласың. Икътисади яктан да отыш, башка якларга да әлләни зыян килми кебек.***

—Оттырыш болай да юк монда. Аларның Себер татары булып язылган өлеше шушы нәтиҗә нигезендә абориген хокукларын көрәшеп ала алса, ул хокуклар аларның барысына да кагылачак. Әмма әлеге матавыклар шәһәрдә яшәгәннәрне бөтенләй кызыксындырмый, хокуклар авылда аучылык, балыкчылык белән шөгыльләнгәннәргә генә кирәк.

***—Аерып чыгарасы килгәч, Мәскәү Себер татарларын ымсындырган, иләсләндергән инде. Әмма, олы өйгә ни кирәк, кече өйгә шул кирәк дигәндәй, ихтыяҗларны үтәү кадәресе ничек булыр иде икән соң? Тулы бер халыкны халык итеп яшәтергә дә кирәк бит әле.***

—Этнология институтындагы сөйләшү вакытында бу хакта кисәткән идем мин. Себер татарларын аерып чыгарасыз икән, бу сезгә зур проблемалар тудырачак, дидем... Себердәге кардәшләргә үз фикеребезне көчләп такмыйча дөрес эшләдек без. Хәзер алар белән Мәскәү үзе сөйләшсен әнә.

***Безнең бу әңгәмәдән соң Д. Исхаков Себердә булып кайтты. Элек әйткәннәренә өстәп болай диде ул:***

—Себердә җирле администрация Себер татарларын аерып язмас өчен көрәш башлап җибәргән. Чөнки Себер татарлары, исәп алу нәтиҗәләренә таянып, аерым хокуклар даулый анда. Себер түрәләре хәзер, юк, алар аборигеннар түгел, татар милләте эчендә каралырга тиеш, дип бара... Бүленеп чыгыйк дип йөргән андагы лидерлар өчен дә сабак бу. Хокуклар даулап йөри башлагач, Мәскәүнең реаль сәясәтен күрделәр менә һәм әле тагы да күрәчәкләр...

***—Җир, су, дибез. Мәгариф мәсьәләсе дә бар бит әле.***

—Монысы Себер татарларының абориген булу-булмавына бәйләнмәгән. Анда хәзер үткен бер генә мәсьәлә бар: әдәби телдә укыту белән диалектта укытуның нисбәте. Монда Мәскәү кирәк түгел, монысын без үзебез дә хәл итәбез аның.

## Керәшен мәсьәләсенә керосин сибә алмадылар

***—Керәшен мәсьәләсендә көрәш шактый киеренке барды шикелле.***

—Тарткалаш бик авыр барды. Монда Мәскәү, үз мәнфәгатьләреннән чыгып, ахыргача каршы торды. 25 меңгә якын керәшен үзен керәшен дип яздырган. 10 меңгә якын кеше нугайбәк булып теркәлгән. Болары да чынлыкта керәшеннәр аның, фәкать заманында казак гаскәрендә хезмәт иткәннәр. Җәмгысе 35 меңгә якын кеше була. Керәшеннәрнең реаль санының уннан бер өлеше генә бу.

***—Рус дип язылучылар күп була алмыймы?***

—Юк, күп була алмый. Керәшеннәр арасында, гомумән, булмас дип уйлыйм. Нугайбәкләрдә булырга мөмкин әле. Керәшеннәрнең төп өлеше фикерләү җәһәтеннән югары дәрәҗәдә торуларын күрсәтте, вак төркемнәргә бүленүнең файдасыз икәнен аңлап, ул юлдан бармадылар.

***—Бүленеп чыгарга теләүчеләрнең үзләренә күрә лидерлары, идеологлары да бар иде бугай. Аларның эшләүләре җитмәдеме, әллә...***

—Ул идеологлар белән безнең хөкүмәт, хәтта Президент үзе дә сөйләшү алып барды. Кайбер вәгъдәләр дә бирелде аларга. Вәгъдә ителгән эшләрнең шактые инде эшләнеп бетеп килә дип уйлыйм... Ягъни керәшеннәрдә безнең хакимияткә ышаныч туды, шуңа күрә алар радикаль адымнар ясамадылар. Керәшеннәрнең төп өлеше монда, Татарстанда яши бит. Кечкенәрәк ике төркемнәре Башкортстанда һәм Удмуртиядә дә бар. Аларның ихтыяҗларын бүленеп чыгу юлы белән канәгатьләндереп булмасын, төп мәсьәләләрне барыбер монда хәл итәргә туры киләчәген мин дә әйттем үзләренә. Аннан бит керәшен өчен иң четерекле мәсьәлә ул—дин. Дингә кагылышлы эшләрдә исә Татарстанда кысу бөтенләй юк.

***—Патриархка ни җитми соң алай булгач? Керәшеннәр үз диннәрен тота алгач? Нигә ул аларны татардан аерып алмакчы?***

—Бәлки ул кайбер шикаятьләргә колак салгандыр. Керәшеннәр арасындагы радикаль төркемнәрдән Мәскәүгә безне кысалар дип язып җибәрүчеләр дә булды. Тикшергәч, берсенең дә дөреслеге расланмады аларның. Әмма башкача да уйларга була. Патриарх, бәлки, сәяси күзлектән карап эш иткәндер, Мәскәүдә кайбер даирәләрнең теләгенә кушылып, Татарстанда татарлар процентын киметмәкче булгандыр.

***—Безнең тагын кечерәк милли төркемнәр дә бар бит әле. Касыйм татарлары берәр төрле чагылмадымы монда?***

—Юк, үзләрен Касыйм татарлары дип аерып күрсәтүчеләр булмаган яисә бик аз булган.

***—Әстерхан татарлары бар бит. Нинди төркем бу безнең?***

—Әстерхан татарларының төп өлеше Алтын Урда заманнарыннан ук Әстерхан тирәсендә яшәгән, соңрак Әстерхан ханлыгы эчендә булган татарлардан гыйбарәт. Соныннан аларга нугайлар килеп кушылып, карагашлар дигән тагын бер төркем хасил була. Карагашлар, нугай теленең үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, шактый гына татарлаша төшә... Әстерхан татары дип язылучылар бик аз—2 мең чамасы гына, алары да бары тел ягыннан гына теркәлгәннәр. Әстерхан татарлары телендә сөйләшәбез дип. "Йорт татарлары"ның теле инде бу—татар теле белән нугай теле арасындарак тора... Карагашлар исә, 4,6 мең кеше, нугай дип теркәлгән. Әмма бу үткән исәп алуда да шулай булган иде.

***—Төп масса кайсы якта булып чыкты инде?***

—Тәгаен күпме икәнен әйтүе кыен, чөнки моны бик тикшереп булмый, әмма Әстерхан өлкәсендә яшәгән татарларның күпчелек өлеше татар булып теркәлгән.

***—Казанга Сөембикәне биргән нугайлар ничек исәп үтте?***

—Нугайларның гомуми саны 90 мең чамасы. Кавказ нугайларын кушып бу. Әстерхан нугайларының бер өлеше нугай дип язылган. 4-5 мең кеше булырга мөмкин, төгәл санын бирмәделәр әле.

## Ике икең биш башкорт?

***—Безнең иң олы дау Башкортстанда булды бит инде.***

—Башкортстандагы шау-шулы хәлләргә анализ ясап карарга мөмкин хәзер. Ин кызыгы шул—андагы башкортларның башкорт теллесе—912 мең чамасы. Һәм тагын 449 мең татар телле башкорт килеп чыкты. Үткән исәп алу белән чагыштырганда ике тапкыр диярлек күп бу. Менә шушы татар телле башкортлар эчендә татар утыра дип уйлыйм мин. Ким дигәндә яртысы татар. Минем исәпләүләр буенча, хәтта 250-280 меңгә житәргә мөмкин. Чынлыкта монда фальсификация булды, аның төгәл күләмен статистика буенча билгеләргә мөмкин.

***—Икенче яктан килик моңа: татар саны күпмегә кимегән?***

—1989 елны 1 млн. 120 мең иде. Хәзер 995 мең килеп чыккан. 125 меңгә, 10 проценттан артык. Бик зур сан бу.

***—Беркадәр артым да булырга тиеш иде бит әле.***

—Булырга тиеш иде. Татарларда бала туу күп булмаса да, читтән кайтучылар исәбенә сан бераз артырга тиеш иде. Һәрхәлдә, кимү булырга тиеш түгел иде.

***—Түгел иде, әйе, түгел иде. Әмма ун тапкыр "түгел иде" дисәң дә... Монда үлчәүнең бер тәлинкәсендә коры логика, икенче тәлинкәсендә исәп алу нәтиҗәсе, ягъни тормыш факты була түгелме соң?***

—Әйе, дәүләткүләм рәсми исәпләү үткәрелде. Әмма алай коелып төшәргә кирәкми, минемчә. Ул "тормыш факты"ның кайбер очракларда ничек ясалуын беләбез без.

***—1979 елны Башкортстанда нилләр майтарганнарын сөйләгән идегез шул. Халык исәбен алалар, шуннан соң татарларның районнардагы саннарын гел бүтәнчә утырталар да чыгалар.***

—Булган хәл бу, шул чактагы райком секретарьлары үзләре сөйләде моны. 1989 елны халык исәбен алганда, демократия туып килгән шартларда элекке ысулларны куллана алмадылар инде, шуна күрә объектив нәтиҗәләргә ирешелде.

***—Хәзер ничек 1979 елдагыча кыланып була соң? Кемнәр нәрсә эшләде?***

—Башкортстанның хөкүмәт даирәләре һәм башкорт милли оешмалары бер булып, бер яктан эш иттеләр.

***—Ә гадел арбитр булырга тиешле Мәскәү кая карады?***

—Кызганычка каршы, хәзер Мәскәүнең мәнфәгатьләре башкорт милләтчеләренең мәнфәгатьләре белән тәңгәл килә. Башкортстанда татарны кимετү тегеләренә дә, боларына да отышлы...

***—Башкортлар күпмегә арткан?***

—Башкортстанда башкортлар 863,8 мең иде. Хәзер 1221,3 мең.

***—Хата юкмы соң монда? 900 меңләп башкорт телле башкортка 450 меңләп татар телле башкортны кушкач, зуррак сан чыга бит.***

—Туган тел турындагы графаны телне куллану турындагы графага алыштыру зур ялгышлар китереп чыгарырга мөмкин иде, һәм китереп чыгарды да. Шуна күрә кайбер мәгълүматларның очы-очка ялганмый.

***—Шулай да бер халыкның йөзләрчә мең кешегә артып, икенчесенең нык кимүе үзе генә дәлил була аламы?***

—Бу да дәлил. Саннарның кинәт кенә үсүе һәм кимүе бернинди демография законнарына да туры килми ул. Дөрес, Башкортстан ягыннан идеологлар 1989 елда исәп алганда фальсификация булган, татарлар саны арттырылып, башкортлар саны нык киметелгән дип әйтергә маташканнар иде. Әмма Башкортстанда татар

милләтчелегенең хакимияткә килгәне юк бит әле, һәм бу—1979 елгы гайре табигый сикерештән соң кире эзгә кайту... Аннан, демографиядә прогноз дигән нәрсә дә бар. 1988 елда Мәскәүдә, "Демографический ежегодник"та басылган бер аналитик мәкаләдә Башкортстанда халыкның ничек үсәсен күрсәттеләр. Башкортстандагы нәтиҗә менә шундагы саннан 300 меңгә аерыла! Бу бит—демографлар тарафыннан демографик тенденцияләргә нигезләнеп эшләнгән объектив анализ.

***—Бусы аңлашылды. Тәгаенлек ягы да кирәк иде бит. Фальсификация фактлары бармы?***

—Андый фактлар бик күп. Моны раслаган фактлар, шикаятьләр Башкортстандагы иҗтимагый оешмаларга да, безгә дә килде. 1979 елгы алымнарны куллану: авылларда кирәкле җавапны мәҗбүрләп алулар да, соңыннан авыл һәм хәтта район күләмендә саннарны алыштырып куюлар да бар. Саф татар авылларыннан саф башкорт авыллары ясау булган да булган инде, хәтта кайбер мари авылларын да башкорт иткәннәр әле... Кыскасы, әгәр дә бу мәсьәлә буенча суд эше кузгатабыз икән, фактлар да, шаһитлар да житәрлек. Татарстан хөкүмәте дә читтә калмаска, халыкны исәпкә алу нәтиҗәләренә карата рәсми белдерү белән чыгарга тиештер.

***—Фальсификацияләргә 1979 елны каршы тора алмаганбыз ди инде. 2002 елны, Татарстанда һәм Башкортстанда милли оешмаларыбыз булган килеш, үз дәүләтебез булган килеш шулай кычкыртып талату кадәресе...***

—Башкортстандагы җирле татар оешмалары кулдан килгәнне эшләделәр. Әмма аларның ресурслары, бигрәк тә акчалары житеп бетмәде. Казандагы татар оешмалары да тырышып карамады түгел. Оештыру житмәде монда, минемчә. Каршы тору оештырылмады. Шушы югалтулар аермачык күрсәтте инде: иҗтимагый оешмалар хөкүмәт дәрәҗәсендә эш итүгә каршы тора алмый. Көч житми.

Мин монда үзебезнең хөкүмәт әһелләрен бераз гаепләр идем. Алар, күрше республика эшенә катышмыйбыз дип, читтә калдылар. Юкса, минемчә, катырак та торып була иде.

***—"Катырак та торып була иде" дип сез бик йомшартып әйтәсез. Минемчә, монда җебегәнлек күрсәтелде. Бөтен Башкортстанны колачлаган күзәтү хәрәкәте оештырырга кирәк иде. Хәрәм кертү омтылышы булган саен тавыш кубарлык итеп. Кая ул, концерт бригадаларын кертми борып кайтарганда да дәшми тордык. Юкса, хокукларны тупас бозу бит бу. Без башкорт артистларын кире борып кайтарсакмы? Башкортстан хөкүмәте Мәскәүгә генә түгел, Париж, Нью-Йоркларга ишеттереп кара тавыш куптарыр иде... Татарның үсешен тәэмин итми икән, татарны якламый икән, безгә Татарстан булды ни дә Казан губернасы булды ни.***

—Әйе, тавыш куптару мөмкин иде... Бу безгә башка яктан да сабак. Менә бу көрәштә безнең иң зәгыйфь урын күренде: Башкортстан эчендә йогынтылы татар мәгълүмат чаралары булмау. Татар телле гәжит-журналлар, дотациягә яшәгәнлектән, Башкортстан хөкүмәтенә буйсындылар. Нәрсә кушсалар, шуны яздылар. Казанда чыккан гәжит-журналларны исә анда житкерә алмадык—тираж кертү мөмкинлеге булмады. Спутник телевидениебез бар дип мактанабыз бит инде. Бу очракта ул бернигә яраксыз булып чыкты. Башкортстанның күпчелек районнарында аны карый алмыйлар.—"тәлинкәләр" кыйммәт.

***—Башкорт ягы ничек оештырды соң бу эшне?***

—Алар бөтен булган матбугатны жиктеләр. Район газеталарыннан башлап. Хәтта китап нәшриятларын да. XVIII гасырдан 1926 елга кадәрге бөтен элекке исәп алу материалларын чыгарып бетерделәр. Казан алынгач эзәрлекләүдән, чукындырудан, жирсезлектән качып башкорт ягына татарлар килә башлый. Алар башкорт эченә кереп, аерым бер катлам булып яшиләр. Ул иске "ревизские сказки"ларда әнә шул рәвешле башкорт сословиесенә керүче татарлар да теркәлгән бит. Шул "сказкалар"дагы "ямские татары", "мещане", "купцы" дигән "милләтләр" кебек үк. Менә шул "сказкалар"ны пропаганда максатында бик оста файдаланды башкорт ягы. Ә без үзебезнең сүзне ишеттерә алмадык. Фальсификацияләрдән тыш, менә шушы безнең гамьсезлек, оешмаганлык өлешенә тигән югалтулар да бар әле.

Башкортстан мәсьәләсе буенча Тишков та татарга каршы позициядә торды. Ул

житәкләгән институтта типтәрләр турында докторлык диссертациясе якланды. Башкортстан галиме Риф Якупов эшләгән бу диссертация типтәрләр дигән аерым бер этник төркем булуны раслый. Әлеге "теория" Башкортстан татарларын башкортлыкка күчерү "механизмы" итеп файдаланылырга мөмкин иде. Ин кызыгы шул тагын: исәпкә алу вакытында типтәр дигән төркем табылмады. Сәяси максаттан чыгып оештырылган эш шулай итеп уңышсызлыкка дучар булды... Тишковның махсус Башкортстанга килеп, татардан аерыр өчен, керәшен мәсьәләсен куертканы, соңыннан шушы темага телевидениедән чыгыш ясаганы да истә әле.

***—Башкорт саны Урал һәм Себердәге татарлар исәбенә ишәйтү теләге дә көчле иде кебек.***

—Чиләбе өлкәсендә татарларның бер өлеше башкортлар эчендә теркәлгән дигән мәгълүмат бар. Тик моны тикшереп карарга кирәк. Себердә булмады андый хәл. Анда берни дә эшләмәде алар.

## Бу барыбер дә җиңү булды әле

***—Безнең баланс ничек чыга икән соң, Дамир әфәнде? Иң зур оттырыш, югалту Башкортстанда бит инде.***

—Әйе. Дәшми калу шуны раслау, легитимлаштыру кебек булачак... Ләкин хикмәт кәгазьгә теркәлгән саннарда гына да түгел. Гомумән, Башкортстандагы милләттәшләребезгә мөнәсәбәтне үзгәртергә кирәк. Аларны яклау, милли ихтыяҗларын канәгатьләндерү юлларын табарга кирәк.

***—Моны Татарстан хакимиятеннән дә таләп итәргә тиешбездер. Башкортстан житәкчелеге белән мөнәсәбәтләрдәге тәтилек андагы татарлардан йөз чөерү исәбенә булырга тиеш түгеллер ул.***

—Шулай, әйе. Әмма тулаем караганда бу исәп алу вакытында безнең житәкчелек шактый дөрес эш итте дип уйлыйм мин. Тиешле мөрәҗәгатьләр дә кабул ителде, хатлар да вакытында китте. Президентлар дәрәҗәсендә сөйләшүләр дә булды. Дөрес, башлануын безнең галимнәрдән, интеллигенциядән башланды инде бу, шуларның ныклыгы, активлыгы хакимиятне дә бераз тәвәккәлрәк булырга мәжбүр итте... Ни дисәң дә, без татарлар арасында сирәк була торган хәл бу: интеллигенция, милли оешмалар һәм дәүләт органнары бер булып эш итте.

***—Әнә шундый очракларда гел жиңү яулана. Моның бер жете мисалы—референдум... Бу юлы бөтен эш-гамәлләр дә шундук нәтиҗә бирмәгән бирүен. Исәпкә алу кәгазьләре үзгәртелмәгән. Ләкин, тисә—тиенгә, тимәсә—ботакка дигәндәй, бу бердәм тырышлык халыкка тәэсир иткән, аның рухын күтәргән.***

—Әйе. Моны хәтта Тишков та танырга мәжбүр булды. "Татары воспользовались переписью и произвели консолидацию",—соңыннан шулай дип язып чыкты ул.

***—Үзе гаепле, оеткыны ул салды бит.***

—Әйе, без аңа рәхмәтлебез.

***—Отыш ягында ни инде безнең, Дамир әфәнде?***

—Иң әүвәл бу—Россия Федерациясендәге татарларның гомуми саны: 5 млн. 554 мең 601 (бу—"саф" татарлар саны).

***—Бер, дисезме? Исәпкә мине дә керткән бит болар!***

—Артым юк диярлек.—32,5 мең чамасы гына. Ләкин бу очракта кимемәүне дә казаныш дип санарга тиеш булабыз инде.

***—Ике ел ярым буе санагач, бик шикләндергән иде шул.***

—Әйе, сәяси сәбәпләр дә, һичшиксез, булды монда. Милләтләрне исәпләүдә каршылыклар килеп чыкты бит. Шул ук Башкортстандагы хәл әнә. Шуңа күрә нәтиҗәләрне игълан итү вакытын оч тапкыр чигерделәр. Ләкин ахыр чиктә барыбер бастырып чыгардылар инде. "Секретно" дигән мөһер сугып яшереп яткыра алмыйсың бит.

***—Сез милли төркемнәр аерып чыгарылу исәбенә татар 200 мең чамасы кеше җуя ала дип прогноз ясаган идегез.***

—Гомуми санга нугайбәкләр кертелмәде, тагын нугай эчендә исәпкә алынганнар, Себер татары дип аерып теркәлгәннәр. Көткәннән күп кимрәк чыга. Әмма әгәр

башкорт эченә кереп киткән татарны да кушып санасаң... Менә шул үкенечле югалту булмаса, күренеш, гомумән, дә бик матур килеп чыгасы иде.

***—Ике нәтиҗәне борчылып көттек: Татарстанда татарлар процентын һәм Россиядәге урынны.***

—Беренчесе хакында әйтә башлаган идем инде мин. Статистик мәгълүматлар Татарстанда татарларның 52 процентган ашканын күрсәтә иде. Димәк, халык исәбен алганда яртыдан ким булган күрсәткечкә бары татардан мишәрне, керәшенне аерып алу исәбенә генә ирешә алалар иде. Керәшеннәргә аеруча зур өмет багланды. Әмма барып чыкмады бу эш: 53 процентлы нәтиҗәгә ирешелде.

***—Димәк, Татарстан тарихында беренче мәртәбә 50 процент чиген уттек.***

—Әйе. Хәзер дә традиция буенча Татарстанда бөтен татарларның чиреге яши дип яза бирәләр. Чынлыкта хәзер монда татарларның 30 процентына якыны яши инде: 1959 елда Татарстан татарлары 1 млн. 345 мең булса, хәзер бу сан—2 млн. 18 мең. Ягъни беренче мәртәбә 2 млн. чиге дә үтеп кителде.

***—Россиядә өченче урында калырга мөмкинбез, безнең үкчәгә украиннар басып килә, дигән идегез.***

—Менә бу мәсьәләдә көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты. Украиннарның саны нык кимеде—алар 2 млн. 943 мең генә. Татарлар хәзер нык лы икенче урынны тота.

***—Мәскәүдә хәлләр ничек? Татарлар 800 мең дип шактый ышанып әйтүчеләр бар.***

—Әйе, матбугатта фантастик саннар күренгәли иде. Минемчә, анда мөселманнар саны белән татарлар саны бутала. Сәясәтчеләр дә тикшереп-нитеп тормыйча түгәрәк кенә саннар әйтеп җибәргәлиләр. Чынлыкта исә Мәскәү татарлары саны 166 мең. 1989 елгыдан 9 меңгә артык. Мәскәү өлкәсендә—53 мең чамасы. Сан буенча беркадәр артым булса да, урын буенча артка чиктек—5-6 нчы урыннарда калдык булса кирәк. Кавказлылар, бигрәк тә әзәрбәйҗаннар нык ишәйде Мәскәүдә.

***—Отыш, казаныш ягына тагын нәрсәләрне кертә алабыз?***

—Бер зур гына минус калды әле. Бик ышанычлы булмаса да, шундый мәгълүмат бар: миллионнан артык татар татар телен куллана алмый. “Не владеет”. Бу—бөтен татарларның 19 проценты чамасы.

***—Монысы көтелмәгән хәл түгел инде аның, Дамир әфәнде. Бу санны зуррак дип тә уйларга була иде әле.***

—Бәлкем, телне белеп житкермәүчеләр тагын да бардыр ул. Ләкин алары “владею” дип яздырган.

***—Монысы да әйбәт фал бит инде аның. Кеше үзен туган теленнән кисеп куярга теләми, аны белмәүнең гайре табигый хәл икәнен аңлый дигән сүз.***

—Шулай, әйе. Әмма бу күренешнең икенче ягы да бар әле: татар булмаганнардан 859 мең кеше татар телен беләм дигән.

***—Бик зур сан бит бу. Каян җыела ул?***

—Аның ярты миллионлабы башкорт булып язылган татарлар дип уйлыйм мин. Калганнарының кайсы милләт эчендә икәне исәп алу нәтиҗәләрен җентекләп өйрәнгәндә ачылыр. Әмма нәтиҗәне инде хәзер үк ясарга була: безнең татар теле бер яктан караганда татардан таррак булса (ягъни урыс теленә күчкән татарлар күп), икенче яктан караганда татардан киңрәк тә әле.

***—Бу сан тегесен каплый яза түгелме соң?***

—Беренчесе 1 млн.нан артыграк, монысы 859 мең—паритет диярлек.

***—Димәк, бу халык исәбен алуны татар өчен уңышлы дип санарга буладыр?***

—Ни дисәң дә, җиңү әле бу безнең. Татарстанда күпчелеккә әйләндек, Россиядә икенче урында ныгыдык, сан ягыннан тулаем кимемәдек. Һәм әле бердәм, бербөтен татар халкы булып калдык.

***—Милләттәшләр Россиядән читтә дә бар бит. Без 7 миллион дип йөри идек.***

—Төгәле 6 млн. 650 мең—1989 елгы мәгълүмат. Димәк, Россиядән читтәгеләр 1 млн. 128 мең була. Хәзерге санны чама белән әйтүе дә кыен—мәгълүматлар бик тә каршылыклы. Әйтик, Кытайның рәсми статистикасы буенча анда хәзер 4 мең татар яши. Бу күбрәк шул Синцзян-уйгур автономияле өлкәсендә. Әмма андагы татарлар белән сөйләшкәндә, алар безнең сан 10 мең чамасы диләр. Төркиядә дә татар

төркемнәре ачык итеп бүлеп күрсәтелми. Төрекләр начар булганга түгел, анда гомумән милләт буенча исәпләү юк. Элекке совет республикаларының берсендә дә диярлек шул 1989 елдан соң халык исәбен алу үткәрелмәде.

***—Илдус Садыйковның матбугатта чыкмаган бер тәкъдиме бар: бу исәп алуга ышаныч күрсәтмичә, татарлар үз исәпләрен үзләре алсын, дигән... Минемчә, бирелә яңадан исәп алып тормаган хәлдә дә, моны башка илләрдә башкарганда ярар иде. Тулы санны чамалар өчен. Татар конгрессы житәкчелегендәме. Бөтен дөнья татарларының берләшү бәйрәме рәвешендә, бәйрәмчә төс биреп тә үткәреп булыр иде. Бәлки, урыннарда мәжлесләр җыеп уктыр. Кул житмәгәннәрне, Илдус абый әйткәнчә, открыткалар аша барлап.***

—Сан аз булганда эшләп була моны. АКШ, Финляндия, Латвия кебек илләрдә. Әмма Үзбәкстан, Казакъстанда ай-һай.

***—Ярый, хәзер менә 2012-13 елларда үтәргә мөмкин исәп алу нәтиҗәләрен дә чамалап карыйк инде.***

—Дөресен әйткәндә, мин бик оптимист түгел. Демографик вәзгыять бик тискәре. Минем әйткән сүзем дә бар, шушындый хәл сакланса, тагын 50 елдан татарның саны 3 млн. гына калыр, дигән.

***—Вакыйгаларның объектив агышына төзәтмә кертәсе килә бит, Дамир әфәнде. Татарлар, милләтнең язмышы мөшкел икәнне аңлап, үсешкә юнәлтелгән гаиләләр корсыннар иде.***

—Гади генә эш түгел шул бу. Демографик модель дигән нәрсә бар. Татарлар XX гасырның башында ук Европа моделенә күчә башладылар. Әйтик, 20 нче еллар башында татар гаиләсендә 4-5 бала булган. Совет чорында исә ике-өч балалы гаиләгә күчтек. 80 нче елларда безнең модель әле шундый иде. Ике балалы гаилә милләтне үстерергә мөмкинлек бирми инде ул. Моның өчен гаиләдә уртача кимендә 2,2-2,3 бала кирәк.

***—Татарстанда 50 процент чиген ничек үттек соң алайса?***

—Читтән кайтучылар исәбенә.

***—Европа моделеннән тыш АКШ моделе дә бар бит әле.***

—Анда хәл яхшырак, әйе, гаиләгә 3 бала туры килә Әмма ак тәнлеләр баланы аз таба, башлыча Латин Америкасыннан күчеп килгәннәр хисабына килеп чыга 3 бала.

***—Безнең Мәтәскә яки Ямаширмә "моделе" нигә ярамады соң?Мин үзем менә 1943 елны Кәчедә тудым, Арча районы бу. Шул үтә авыр елда туган яшьтәшләремнең барсы да үсеп житеп кеше булды. Әти-әниләренә таяныч булды. Авылда бер бала белән ничек тормыш алып бармак кирәк?Балалар бер-берсен тәрбияләгән, гөрләп торган гаиләдән иркә бердәнберләр үстергән гаиләгә күчү милләттән тыш нәселне дә зәгыйфьләндермиме? Өстәвенә, бу әле ата-аналарның үзләренең дә картлык көннәрен четерекләндерә ләбаса.***

—Авылда халык аз калды. Аларның да күпчелеге пенсия яшендә. Шәһәрдә модель башка... Житди икътисади сәбәпләр дә бар бит. Баланы аякка бастыру авырга килә. Хәлнең ил өчен дә хәтәрлеген аңлап, хөкүмәт ярдәм күрсәтергә тиеш иде дә бит—аннан реаль ярдәм юк. Бәлкем, алга таба тормыш икътисади яктан рәтләнер дә ул, әмма демографик модель үзгәрми инде.

***—Ярый, хуш, 2002 елгы халык исәбен алу дигән гамәл башкарылды, саннары килеп ирешә... Без бу саннардан ничек файдаланырга тиеш инде?***

—Халык исәбен алу буенча саллы мәкаләләр булыр әле. Без монда милли мәсьәләгә кагылышлы нәтиҗәләренә генә күз йөртеп чыктык. Монда да гомуми анализдан тыш конкрет анализ булачак... Һәм без, әлегесендә җибәргән хаталарны, файдаланылмый калган мөмкинлекләрне җентекләп тикшереп, инде хәзер үк яңа исәп алуга әзерләнә башларга тиешбез.

***—Анысы хакында тагын да сөенебрәк гәпләшергә язсын.***

—Шулай булсын.

Әңгәмәдәш—**Рәфикъ ЮНЫС**

1 нче таблица

## Татарларның һәм аларның этник, этник-конфессиональ төркемнәренең Россия Федерациясендәге саны

| Этнослар, этник һәм этник-конфессиональ төркемнәр | Барлыгы | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Шәһәр халкы | Авыл халкы |
| I. Татарлар | 5669883 | 3814879 | 1855004 |
| Шул исәптән: | | | |
| +Керәшеннәр | 24668 | 12624 | 12044 |
| +Нугайбәкләр | 9611 | 4271 | 5340 |
| +Себер татарлары | 9600 | 1889 | 7711 |
| +Әстерхан татарлары | 2003 | 776 | 1227 |
| +Карагашлар (нугайлар, карагашлар)* | 4570 | ... | ... |
| II. Кырым татарлары | 4311 | 2217 | 1914 |

*Исәпкә алу материалларында нугайлар эченә кергән.

2 нче таблица

## Татарларның Россия Федерациясендә 1950 — 2002 елларда урнашу үзенчәлекләре

| № | Төбәкләр, республикалар һ. б. территориаль төзелмәләр | 1959 | 1970 | 1979 | 1989 | 2002 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | **1. Төньяк-Көнбатыш төбәге** | | | | | |
| 1 | Архангельск өлк. | ... | 4613 | 4906 | 5391 | 3076 |
| 2 | Ненец АО | ... | 167 | 284 | 524 | 211 |
| 3 | Вологда өлк. | ... | 1028 | 1582 | 1843 | 1859 |
| 4 | Калининград өлк. | ... | 2752 | 3226 | 3556 | 4734 |
| 5 | Санкт-Петербург ш. | 27178 | 32861 | 39416 | 43997 | 35616 |
| 6 | Ленинград өлк. | 4330 | 5376 | 6255 | 7757 | 9447 |
| 7 | Мурманск өлк. | 5566 | 7521 | 9532 | 11459 | 7954 |
| 8 | Новгород өлк. | ... | 804 | 1355 | 1963 | 2083 |
| 9 | Псков өлк. | ... | 465 | 705 | 1010 | 1502 |
| 10 | Карелия Республикасы | 4692 | 2603 | 2611 | 2992 | 2629 |
| | **2. Үзәк һәм Кара туфраклы Үзәк районнар** | | | | | |
| 1 | Брянск өлк. | ... | ... | ... | ... | 1179 |
| 2 | Белгород өлк. | ... | 575 | 1217 | 1539 | 3397 |
| 3 | Владимир өлк. | 8268 | 8447 | 9202 | 9214 | 8678 |
| 4 | Воронеж өлк. | ... | 1193 | 1428 | 1860 | 3501 |
| 5 | Тверь (Калинин) өлк. | ... | 4712 | 5196 | 6256 | 6719 |
| 6 | Кострома өлк. | ... | 3355 | 3054 | 2965 | 2732 |
| 7 | Калуга өлк. | ... | 1290 | 1814 | 2963 | 4306 |
| 8 | Курск өлк. | ... | ... | ... | ... | 1581 |
| 9 | Иваново өлк. | 9851 | 10511 | 11061 | 9910 | 8208 |
| 10 | Липецк өлк. | ... | 715 | 749 | 1000 | 1751 |
| 11 | Мәскәү ш. | 801489 | 109293 | 132388 | 157376 | 166189 |
| 12 | Мәскәү өлк. | 52520 | 49193 | 52141 | 51059 | 52892 |
| 13 | Орел өлк. | ... | ... | ... | ... | 1424 |
| 14 | Рязань өлк. | ... | 4057 | 4334 | 4922 | 5575 |
| 15 | Смоленск өлк. | ... | 571 | 1105 | 2163 | 2429 |
| 16 | Тамбов өлк. | ... | 2141 | 2193 | 2298 | 2732 |
| 17 | Тула өлк. | 15431 | 11500 | 10306 | 9551 | 8974 |
| 18 | Ярославль өлк. | 7166 | 7211 | 7400 | 7162 | 6175 |
| | **3. Төньяк Кавказ төбәге** | | | | | |
| 1 | Краснодар крае | ... | 17709 | 26072 | 34430** | 25615 |
| 2 | Ростов өлк. | 13857 | 16106 | 16948 | 17132 | 17892 |
| 3 | Ставрополь крае | ... | 9405 | 10610 | 12951 | 12909 |
| 4 | Адыгей Республикасы | 1886 | 2154 | 2420 | 2666 | 2904 |
| 5 | Карачаи-Черкас Республикасы | ... | 1668 | 1890 | 2496 | 2022 |
| 6 | Дагыстан Республикасы | 6013 | 5770 | 5627 | 5579 | 4669 |
| 7 | Кабарда-Балкар Республикасы | ... | 2664 | 3169 | 3005 | 2852 |
| 8 | Төньяк Осетия-Алания Республикасы | ... | 1658 | 1903 | 1968 | 2113 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Калмык Республикасы | 1044 | 1230 | 1331 | 1312 | 1086 |
| 10 | Чечен-Ингуш Республикасы | 5225 | 5571 | 5484 | 5102 | ... |
| | 1. Ингушетия Республикасы | ... | ... | ... | ... | 151 |
| | 2. Чечен Республикасы | ... | ... | ... | ... | 2137 |
| | **4. Идел-Урал төбәге** | | | | | |
| 1 | Түбән Новгород өлк. | 66996 | 71798 | 68637 | 58603 | 50616 |
| 2 | Ульянов өлк. | 96918 | 122409 | 134767 | 159093 | 168773 |
| 3 | Пенза өлк. | 62233 | 74838 | 78236 | 81307 | 86806 |
| 4 | Мордова Республикасы | 38636 | 44955 | 45765 | 47328 | 46261 |
| 5 | Саратов өлк. | 34075 | 43238 | 47948 | 52867 | 57583 |
| 6 | Волгоград өлк. | 17744 | 23518 | 25531 | 25973 | 28848 |
| 7 | Әстерхан өлк. | 57230 | 67062 | 70781 | 71655 | 77142 |
| 8 | Киров өлк. | 41211 | 45309 | 44900 | 45666 | 43637 |
| 9 | Удмурт Республикасы | 71930 | 87151 | 99141 | 110347 | 109868 |
| 10 | Коми Республикасы | 8459 | 11908 | 17837 | 25980 | 15690 |
| 11 | Мари Иле Республикасы | 38821 | 40280 | 40917 | 43747 | 43464 |
| 12 | Чуаш Республикасы | 31357 | 36217 | 37573 | 35689 | 36399 |
| 13 | Татарстан Республикасы | 1345195 | 1536431 | 1641607 | 1765404 | 2018893 |
| 14 | Башкортстан Республикасы | 768566 | 944507 | 940446 | 1120702 | 995253 |
| 15 | Самара өлк. | 74226 | 93687 | 103605 | 115280 | 127984 |
| 16 | Пермь өлк | 165829 | 169372 | 157726 | 150460 | 135524 |
| 17 | Коми-Пермяк АО | 5623 | 3432 | 1910 | 1454 | 1100 |
| 18 | Свердлов өлк. | 158222 | 176029 | 179347 | 183781 | 168224 |
| 19 | Ырынбур өлк. | 120944 | 145376 | 151384 | 158564 | 165989 |
| 20 | Чиләбе өлк. | 190227 | 216809 | 219744 | 224605 | 214220 |
| 21 | Курган өлк. | 19567 | 23932 | 23507 | 22567 | 21986 |
| | **5. Себер төбәге** | | | | | |
| **Шул исәптән:** | | | | | | |
| **а) Көнбатыш Себер** | | | | | | |
| 1 | Төмән өлк. | 72306 | 102861 | 136757 | 103306 | 116055 |
| 2 | Ханты-Манси АО-Югра | 2938 | 14046 | 36899 | 97689 | 107954 |
| 3 | Ямал-Ненец АО | 3952 | 4653 | 8556 | 26431 | 27795 |
| 4 | Омск өлк. | 36421 | 44330 | 46714 | 49784 | 48116 |
| 5 | Томск өлк. | 13449 | 15226 | 17630 | 20812 | 20151 |
| 6 | Новосибирск өлк. | 24926 | 28825 | 28549 | 29428 | 27886 |
| 7 | Кемерово өлк. | 67382 | 69313 | 64821 | 63116 | 51065 |
| 8 | Алтай крае | ... | 8052 | 7864 | 8078 | 8904 |
| 9 | Алтай Республикасы | ... | ... | 334 | 388 | 462 |
| **б) Көнчыгыш Себер** | | | | | | |
| 1 | Краснояр крае | 39945 | 46623 | 49894 | 54052 | 43872 |
| 2 | Таймыр (Долган-Ненец) АО | ... | 429 | 522 | 783 | 427 |
| 3 | Эвенк АО | ... | ... | 141 | 330 | 162 |
| 4 | Иркутск өлк. | 39061 | 41500 | 41474 | 36609 | 26987 |
| 5 | Усть-Урда (Бурят) АО | 4213 | 5692 | 4782 | 4374 | 4102 |
| 6 | Бурят Республикасы | 8058 | 9991 | 10291 | 10496 | 8196 |
| 7 | Тыва Республикасы | ... | 822 | 988 | 1071 | 588 |
| 8 | Саха (Якутия) Республикасы | 5172 | 7679 | 10980 | 17415 | 10817 |
| 9 | Чита өлк. (ш. исәптән | 4014 | 14283 | 13372 | ... | 7769 |
| | Агин-Бурят АО) | ... | ... | ... | ... | 390 |
| **в) Ерак Көнчыгыш** | | | | | | |
| 1 | Приморье крае | 17004 | 18256 | 19464 | 20211 | 14572 |
| 2 | Хабаров крае | 14130 | 14571 | 16591 | 17591 | 10982 |
| 3 | Еврей АӨ | ... | 1158 | 1460 | 1499 | 1196 |
| 4 | Амур өлк. | ... | 5369 | 7948 | 9095 | 4889 |
| 5 | Камчатка өлк. | 2921 | 3728 | 4652 | 5837 | 3404 |
| 6 | Коряк АО | 298 | 353 | 441 | 471 | 216 |
| 7 | Чукот АО | 504 | 1607 | 1995 | 2270 | 535 |
| 8 | Магадан өлк. | 3021 | 5295 | 6793 | 8024 | 2002 |
| 9 | Сахалин өлк. | 11679 | 11153 | 11030 | 10699 | 6832 |

*Кырым татарлары татарлар эчендә исәпкә алынган.

**1989 елгы исәпкә алуда Краснодар краенда татар дип язылган 17217 кеше — Кырым татары.

**Таблица 2002 елгы халык исәбен алу материаллары буенча Д. Исхаков тарафыннан әзерләнде.**

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

## ТӨРЛЕ-ТӨРЛЕ УЙЛАСАК ТА...

Дискуссиябезнең жанланып китүенә Айдар Хәлимнең "Сез беләмсез кая барганны?" дигән язмасы сәбәп була алса, әңгәмәбез әле озак дәвам итәр, сүндерергә теләмәсәк, сан саен берәр тәнкыйть мәкаләсе чыгып баруы таман гына булыр. Иң әвәле, Айдар агай да күрсәткәнчә, сүз югында сүз булсын дип, язучыларның фамилияләрен, язган әсәрләрен яртышар бит санау гадәтеннән баш тартырга вакыт. Бусы аның үзенә дә тиеп уза. Әгәр редколлегия андый санауларның бер квадрат метры өч тиен гонорар белән бәяләнә дигән карар кабул итсә, хәл үзгәрер. Айдар аганың бинһая зур хезмәт куеп язылган әлеге язмасына карата аның тәнкыйть сәнәгенә эләгүче бәя бирсә, ул объектив ук була алмас, һәм әңгәмәбезнең "син үзең фәлән" дигән әйткәләшүгә кайтып калу куркынычы да бар. Аллага шөкер, бик күпләр, шул исәптән Гаяз Исхакый һәм Әмирхан Еники, Фатих Хөснилләр дә тәнкыйтьтән коры калмаган, һәм дискуссиягә керүчеләргә шәп кенә йодрыклар төшкән шартларда фәкыйрегез мәкаләсе хакында нигездә уңай фикер әйтелгән. Димәк мин, мантыйк буенча, бәйрәм ашы—кара-каршы дип Айдар агайны мактарга тиеш булып чыгам. Әмма никтер алай эшлисе килми, авторның ялкынланып язган язмасы да ихлассыз талпынышларга урын калдырмый.

Рус язучысы Н. Носовның "Белмәмеш мажаралары" дигән әсәрендә Белмәмеш үз иптәшләренең портретларын ясый. Алар карикатуралар булып чыга. Һәр нәнүс моның күргәзмәсен ошата, башкаларның карикатуралары уңышлы чыккан дип бәяли, әмма ләкин үзенә ясалганын ошатмый, ертып атылуын таләп итә. Безнең бу дискуссиядә дә шундый ситуация кабатланырга мөмкин.

Минемчә дә, А. Хәлим "ФИЛ"ләр турында шәп әйткән, галим-галимәләрнең, кайбер язучыларның "тәнкыйть" дип бастырган, тешкә тия торган сафсаталарына да урынлы эләккән. Университет эскәмиясе һәм редакция коридорыннан гайре бер ни күрмәгән, биографиясез, редакция кәнәфие югарылыгында калган язучылар да лаек бәя алган. Дәреслек тәпәләүчеләрнең дә "чапаннарын сырган". Әмма автор күтәргән тәжел мәсьәләләрне хәл итәр өчен язучыларыбызның моңа егәре бармы, юкмы икәнлеге ачыкланмаган.

Айдар агай Факил Әмәкнең "Саташып аткан таң" романына битараф түгел. Ул әлеге роман хакында әйтелгән бер генә уңай фикерне дә кабул итми. Әйтик, мин фәкыйрегез "әлеге романда автор Дәүләт системасы асылын сәнгатьчә тасвирларга җөрьәт итте һәм "уңышка да иреште" дигән идем. Миңа калса, бу әсәрдә төп герой, тере зат дәрәҗәсендә бәян ителгән Система үзе, ә геройлар—шөрепләр, хәтта дәүләт җитәкчесе Дәүләтьяров агай да шуның нык кына чарланганы. Ә Айдар агай мине Рафаэль Мостафин хатасын кабатлый дип уйлый. Гафу итә күрегез: минем хатам—үзгә! Тагын кабатлыйм: Дәүләтьяров дигән чиновник минем өчен герой түгел.

Габдулла Тукайның: "Безнең Муса һич тиктормас, ялгыш тапкан Коръәннән" дигән юллары бар. Әлбәттә, Фатих Хөсни әсәрләрен Изге Китап белән тиңләү дөрес булмас. Әмма "Йөзек кашы"—татарның кадерле әсәре бит. Ә Айдар Хәлим әсәр герое Айдардан да гаеп тапкан.

Һәр чорның әдәби мөмкинлеге төрлечә. Тоталитар режим яшәгәндә язучылардан плакат геройлары тудыру таләп ителде, һәм күпчелек шул заказны үтәде дә. Ә Фатих Хөсни шул шартларда—чор әдәбияты мохитында үле, плакат персонажлар гына "яшәгән" заманда—чын, тере кешене, тискәре сыйфатларга иясен, хатадан хали булмаган чын татар кешесен төп каһарман сыйфатында әдәби мәйданга чыгара алды. Һәм шушыннан соң әдәбиятыбызга тере җаннар тәпили башлады. Шул исәптән олуг язучыбыз Аяз аганыкылар... Ә Мөхәммәт Мәһдиев, Мәхмүт Хәсәнов геройлары да өстәлгәч, әдәбиятыбызның яшәү тонусы тәмам ныгыды.

Әмирхан ага Еникинең төп персонажының башкорт булуы проблемамы? Шул тактик алымны кулланмаса, без мондый гүзәл әсәрне укый алыр идекме ул заманда? Айдар агай "сонарабыз" дип аһ ора оруын, ә бу әсәр, әлеге тактик алым аркасында ул теләгәнчә, нәкъ вакытында укучыга ирешә. Ә татар әдәбиятында гүзәлләрдән гүзәл татар хатыны образы бар: ул—Мәхмүт Галәүнең "Болганчык еллар" романындагы Сәҗидә.

Айдар агай башка халыкларның аллап булса да үз каһарманнарын булдыруларын (хуплап дип аңладым) бәян итә. Ә без булганын да тәгаенли алмыйбыз икән. Әмма автор үзе үк татар әдәбияты пьедесталындагы Гаяз Исхакый, Фатих Хөсни, Әмирхан Еникиләрнең олуглыклыгын какшатырдай дәлилләр юллый. Ул мәкаләсе башында, Мансур Вәли-Баржылының геройлар хакында стереотип фикер кысаларыннан чыкмый калуын купайтып, әйбәт "провокация" бу дип тамгалап тел шартлатты шартлатуын, ә үзенең авторитетлар тәгаенләү зарурлыгы турында тулы бер тәгълимат тудыргач, хакыйкый авторитетларыбызны какшатырга алынуын ничек аңларга?

Милициягә эшкә алганда йөзләрчә сораулардан торган тест уздыралар. Арада төрлечә яссылыкта бирелгән бер үк сораулар да урын ала. Әгәр эшкә кирәргә теләүче боларга төрлечә җавап бирә икән, димәк тестны кичә алмый. Сорау туа, Айдар Хәлимнең бер үк мәсьәләгә төрлечә якын килүе махсусмы, әллә ялгышыпмы?

Айдар агай Гаяз Исхакыйны, "Ул әле өйләнмәгән иде" әсәре унаеннан, маржага "һәйкәл" салуда гаепли. Әмма мин, әйтик, әлеге әсәрне, маржа кочагына бер эләккәч котылып булмавын кисәтү дип аңлап укыган идем. Янә килеп, кайсыдыр классигыбызны түбәнәйтеп, кайсындыр кирәкмәгән югарылыкка күтәрергә омтылу да сәерсетте. Айдар агай Мансур Баржылыны Вахит Имамовны мактауда чама югалтуын искәртә. "Тот та Нобель премиясе бир!",—дип тә шаярта. Әмма үзе Габделҗаббар Кандалыйны Пушкиннан югары куя, бөтен дөнья поэзиясендә сирәк шагыйрь, дип бәяли. Әйдәгез, әлеге шагыйрьнең Айдар агай мактап телгән алган "шәп" әсәре—Сәхибҗамал абыстайга язганнарын—күздән кичерик. *(Габделҗаббар Кандалый. Шигырьләр һәм поэмалар, 1988 ел, Татарстан китап нәшрияты.)*

Килә белмәсәң, и җаным
Бәнемдик мелла гашыйкка,
Барырсың к..е юмаган
Надан бер кара мажикка.

Суган, икмәк тоеп эчкә,
Алыр сулышыны көчкә,
Гүя тын йибәрер мичкә,—
У..ыр, и абыстай ла.

Егерме бишкә йөш йиткәч,
Чырай һәм үзгәреп киткәч,
Имиләр салынып бетсәч,
Кадерсез була кочагың.

Гашыйк Кандалый сөйгәнен "миңа килмәсәң каргыйм һәм тәмугка эләгәсен" дип, анда булачаклар белән өркетә:

Зәбанилар орыр чукмар,
Күзеңдин күстәрер утлар,
К...дин чыгарыр б...лар,
Әгәр барсаң надан йарга!

Гел шушы рухта язылган поэмадан алынган әлеге юллар бу агайның Пушкиннан ни дәрәҗәдә югарылыгын күрсәтергә житеп торыр дип уйлыйм. Боларны яздым һәм шиккә калдым: мин дә провокация корбаны түгелме соң, мине һич кирәкмәгән бәхәскә тартып керттеләр түгелме, шайтан алгыры?..

Батыршаны да күкләргә чөеп буладыр... Башкачарак та язып була аның хакында...

Фәкил Әмәк "Соңгы көз" әсәре һәм "Саташып аткан таң"ы белән яңа сүз әйтте. Нәкъ вакытында. Чинауниклар мохитын татар язучылары бу дәрәҗәдә ача алганнары юк иде әле. Шушы урында нәни бер чигенү ясарга рөхсәт итсәнче, хөрмәтле укучы.

Рус классик әдәбиятында чинаунникларның лаеклы үз урыны бар. Гоголь, Чехов һәм Достоевский аларны ахмак, бичара санап, кызганып тасвирласа, Салтыков-Щедрин иҗатында боларның Русия иле тәнендә мыж килүче паразитлар булуы тәгаенләнә. Чинауникның ин әйбәт дигәннәре ришвәтне "тиешенчә" генә ала... Бар шундый фикер әйтүчеләр: имеш ки, югары катлам вәкилләренең, татар урыслашкан сыман чинауниклашуы монархияне һәлакәткә китергән. Алай ук булмагандыр да, әмма бу процессның хәтәр якларын ул чорның иң югары даирәләрендә дә яхшы аңлаганнар кебек. Әйтик, патша хөкүмәтенең министрлар кабинеты рәисе Сергей Витте хәзерләгән һәм 1905 елның 11 декабре көнне игълан ителгән закон нигезендә Дәүләт Думасына сайланачак депутатларның 43% авыллардан, 34% эре җир биләүчеләрдән һәм 23 проценты сәүдәгәр, эшче һәм һөнәрче вәкилләреннән торырга тиеш була. Хәрбиләр, чиновниклар, хатыннар вә студентлар сайлауга катнаша алмый. Сталин заманында чинауниклар хакимиятенең җәелүен, киңәюен, үрчүен репрессияләр ярдәмендә чикләгәннәр. Сталиннан соңгы заманнарда Югары Советка эшчеләр, крестьяннар, галимнәр, конструкторлар, язучылар, рәссамнар, ягъни фәнни һәм иҗат интеллегенциясе һәм, билгеле бер пропорциядә, Витте кире каккан чиновниклар да бар иде. Әмма ул вакытта чинауниклар эш кешеләренең бугазыннан ала торган канун проектларын каралуга кертергә батырчылык итәрлек куәткә ия түгел иде әле.

Хәрбиләрне, фискаль органнарны, студентларны һәм чинаунникларны асрау өчен күпме акча бүлүне Витте заманында реаль житештерү секторындагылар хәл иткән. Бүген исә парламентта реаль житештерү секторы гавәме гомумән күренми, ил байлыгын Витте кире каккан әһелләр бүлә. Шулар канун яза. Нәтиҗәдә һавадан акча ясап, кәгазь биреп һәм җыеп утыручы, ягъни чинауниклар туплаган оешмалар артканнан арта, һәртөрле офислар бүселгәннән бүселә бара. Алар өчен чыгымнар да арта. Ә реаль секторда хезмәт куючыларның, эшчеләрнең, крәстияннәрнең, хезмәтчел интеллегенциянең, галимнәрнең педагогларның, ветераннарның хәле мөшкелләнде. Өлкән буынның, нинди дә субсидияләр алырга дип, чинауниклар каршына мескеннәр сыйфатында кул сузып басарга мәхкүм ителүен генә алыйк. Нинди хурлык!

Иманым камил: олуг бер түрә кинәт "артны үбегез!", дип кычкырса, аның кул астындагы чинауниклар, пәйда булган аклыкка иреннәрен тидерергә ашыгып, бер-берсен таптап бетерәчәк! Чинауник өчен: үзеннән өстә торучы—илаһи зат, ә аста калучы—чүп. Югарыдагы каршында—ул пудель, ә түбәндәгеләргә—бульдог! Ришвәт кем кулына керә? Чинауник кулына. Ул ришвәт бетсен дип көрәшә аламы? Юк! Чинауник кемне таларга корылган? Халыкны. Кәгазь боткасын куертудан кем ота? Ул! Коррупция кемгә кирәк? Аңа. Әлбәттә, бер җәмгыять тә, бигрәк тә "цивилизацияле" дигән тамгалылары аларсыз яши алмый. Әмма аларның популяциясе барлык илләрдә дә контрольгә алынган. Ә бездәге чиновниклык, гөмбә чире сыман, бөтен Русия тәненә таралган. Һәм үрчүен дәвам итә. Элек оешмаларда түрә белән янәшә, аңа торырлык вәкаләтле баш инженерлар була иде. Хәзер шушы вазифа "техник директор" дип үзгәртелде, ягъни инженерлар элитасы чиновниклаштырылды. Өлкәгә, яки республикага җитәкчене сайлап кую урынына билгеләү дә, бу вазифаларны чиновник кулына калдыру дигән сүз. Ярый, рәхмәт Татарстан халкын саңга сугып, үзе сайлап куйган, кабат сайлаулар узса да бер сүзсез сайланачак шәхесне республикабызга җитәкче итеп калдырдылар. Әлбәттә, Минтимер ага Шәймиев эшләгәндә бу вазифа Кириенкога буйсынучы чиновник дәрәҗәсенә төшмәячәк. Ә аннары?

Хәзер ижтимагый палата оештыру хакында сүз бара. Анда да чинауниклар кереп тулмас микән соң?

Кайчандыр дворяннарның чинауниклашуы монархиянең башын ашаса, бүген

житештерү чаралары, капитал алар кулына күчеп", "чинауник-капиталист", чинауник-бизнесмен", чинауник-депутат" атлы мутантлар барлыкка килде. Әмма бу төр хужалар үзара ярышып, прогресска омтылмыйлар, эш пешсен дип тә бик интекмиләр, ә кануннарны үзләренә жайлап, көч һәм акыл сарыф итми, ягъни үзләреннән бер ни бирми, халыкнын канын эчеп, кандалалардай симереп, яшәп яталар. Илне күп миллиард суммаларга бурычка батыру бер хәл, хәзер һәр кешене бурычка батырып богаулау тормышка ашырыла. Мәктәп реформасынын да асылы, акылы бар һәр яшь кешене югары белем алу максатында кредит алдырып, финанс бәйлелегенә дучар итү. Димәк ки, беренче этапта ил бурычка батырылды, инде һәркемне аерым-аерым да бурычка батырып, халыкны кат-кат әҗәт "капчыгында" калдыру хәл ителә.

"Сүз башым бит Шүрәле" дигәндәй, әдәбият турында сөйләшә идек бит әле... Әлбәттә, әдәбиятыбыз да чинауниклашудан читтә калмады, "чинауник-әдип" атлы мутантлар да тормыш сәхнәсендә үз өлкәләрендә хужа була алды. Ә аларга априори чын тәнкыйтьнен кирәге юк. Шул шартларда бер журналда тәнкыйть бүлеге штатына куелган гади хезмәткәр Мансур Баржылыны корбан текәсенә әйләндерү мина гадел эш булып тоелмады.

Мин фәкыйрь дә яшь чакта язучы булырга хыялландым. Байтак кына китаплар укыдым. Үземә остаз булырлык авторларны төрле халык әдәбиятларыннан эзләдем. Һәм укыган саен, 70 еллар азагында тәнкыйтьче Мансур Вәлиевнең "Яшь язучыга ачык хат" дигән мәкаләсендә күтәрелгән күренешкә юлыгып сөрлектем. Мансур әфәнде Вәлиев ул мәкаләсендә яшь авторны "Карт һәм сыер" әсәренен Хэмингуэйның "Карт һәм диңгез"ендәге охшашлыгына анализ ясап, гаепләгән иде. Әдәбиятыбыз тарихында бүтән бер язучы да мондый ихласлыкка, батырлыкка җөрьәт итмәде. Хәтта үтә батыр, калай әтәч образына кереп кылыч уйнатучы "баһадирларыбыз" да... Ә баксан, гаепләнүче яшь язучы бернинди дә мөгез чыгармаган, ул артык мәгълүм автор әсәрен үзенекенә нигез итеп алып кына хата ясаган, үрнәк сайлауда тәҗрибәсе житенкерәмәгән икән!

Ә бит балалар өчен язылган урыс һәм башка халык авторлары шигырьләре игезәкләрен татар шагыйрьләре иҗатында очравы күптән яналык түгел. Хәзер заманча көйләрнен татар моныннан читүе, аларны чит-ят жырларны гыйбадлаштырып, мелизмнар өстәштереп "ясаулары" хакында яздылар. Баксан, әлеге ысулны иң әвәл язучы һәм шагыйрьләребез күптән куллана икән инде! Рус авторлары язган әсәрләрнең татар мохитына жирләштерелүе хакында *("Казан утлары", 9 сан, 2004 ел. "Пегас кашына микән?")* бераз әйтеп узган идем инде. Әлбәттә, нәрсәдән булса да үрнәк алуның гаебе юк, бәлкем ул үсеш шартыдыр? Кытайда элек-электән шагыйрьлеккә мәгълүм бер авторга ошатып язу юлы белән өйрәнгәннәр. Әмма, ахыргы максат остазны узу булган. Безнекеләр узамы соң? Әлбәттә, Хэмингуэйны әлегә уздыручы татар авторы күренмәде.

Роберт Энсон Хайнлайн дигән, 1907 нче елны Миссури штатында туган Америка язучысының, хатыны белән бергә язган "Явызлыктан өрекмәгән" ("Не убоюсь я зла") романы бар. Бу әсәрнең русча тәрҗемәсе илебездә ике тапкыр ике исем астында дөнья күрде һәм анын буенча төшерелгән "Таныш булыгыз, Джо Блэк" фильмын да карауны телевидение насыйп итте. Әсәрдә төп каһарман—сыгылмас рухлы, иманлы Кеше. Аны алмага кеше кыяфәтенә ия булып, Әҗәл килә. Әлбәттә, бу әсәрнең геройлары "Зәңгәр шәл"дәге кортка әйткәндәй, "синдәй-миндәй бозау" түгел. Гыйбадлык, прастуйлык, шапырынкылыкка анда урын юк. Әсәр—мистик драма жанрына карый, анда нечкә фәлсәфәгә корылган, аксөякләргә хас нәзакәтле һәм тирән мәгънәле тансык әңгәмәләр күңелне жәлеп итә... Төп герой үзе ирешкән югарылыкны жуймый, иманына хилафлык китерми, һәм Әжәлне дә үзе белән хисаплашырга (фикерләренә инандыру аша) ирешеп, Мәңгелеккә үтә.

Хәер, чинауник—иң әвәле карьерачы. Ә карьерага омтылучы "әдип", әгәр образлар турында күп баш ватса, төп максатына ирешү өчен чаралар күрергә житешмәячәк, ялгышлыклар да ясавы мөмкин... Аннары талантлылардан барысын да күтәргә мөмкин, димәк бу сыйфат та "үсү" өчен зарур була алмый. Димәк, шәп әсәр язу өчен берданбер юл—әллә ни таныш булмаган берәр чит халык язучысы яки шагыйре әсәрен татар мохитына (гыйбадлаштырып, көлкегә куып) жирләштерү.

Озын сүзнең кыскасы, Мансур Вәли дигән тәнкыйтьчебезнен узган гасырда язганнары бүген дә тәжел. Әгәр ул әлеге мәкаләсен бүтән авторларга турылап кабаттан

язса, бу бик яңа булып яңгыраячак. Әмма аны тагын да утка керергә кодалау, кабат кермәгәне өчен гаепләү—намуслы гамәл булмас. Әйдә бүтәннәр дә керсен әле. Керик әле... Без бит татарлар! Һәммәбез дә азмы-күпме Айдарлар. Мин Фатих Хөснинең "Йөзек кашы"ндагы образны күздә тотам...

Айдар Хәлимгә "Саташып аткан таң" романы өчен Факил Әмәкнең Тукай премиясе алу переспективасы тынгылык бирми. Ә бит, рас бездә чинауниклар хакимлек итә икән, һәртөрле титулларны, премияләрне беренче чиратта чинауниклар алуы табигый. Әйтик, партия чинаунигы Рәис Беляевка һәйкәл "ә" дигәнче күтәрелде, ә чинауник түгел Салих Сәйдәшкә, халык акча җыеп та, аны салганнары юк. Миңа калса, тиздән Тукай премиясен чинауник-әдипләребез яңа чират төзеп, икенче тапкыр ала башлаячак. Факил Әмәк тә аннан читкә тибәреләалмый, әлбәттә. Премия алу, әдип-депутат-чиновникларның бюджет акчасын үз кесәләренә юнәлтү әмәле булып аңлашылмасын өчен, аны талант ияләренә дә биргәләргә мәҗбүрләр. Әмма теләр-теләмәс кенә! Әйтик, Мөхәммәт Мәһдиев кандидатурасы өч тапкыр куелып, Тукай бүләге аңа өченче тапкырында гына көч-хәл белән иң югары даирәләр катнашкач кына эләкте.

Ә гомумән алганда "Сез беләмсез кая барганны?" әдәбиятыбыз мәйданында шаккаткыч күренеш. Бу кадәр ихлас һәм хисләргә бирелеп, үз-үзең белән каршылыкларга керер дәрәҗәдә ярсып, чын дискуссия уятырлык язма басылып, чыкканы юк иде әле. Виват "Казан утлары"! Рәхмәт Айдар ага! Курәләтә утка керү мәсьәләсендә һәрхәлдә Сезнең дә Фатих Хөснинең без яраткан Айдары белән туган икәнлегегез шикләндерми!

**Рөстәм ЗАРИПОВ**

---

# Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

Ғәп
Фән

Флүн
Мусин

# ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫН ЯҢАЧА ӨЙРӘНҮ

Узган гасыр ахырында татар дөньясында башланган яңарыш хәрәкәте халкыбызның иҗтимагый-мәдәни үткәнен дә фәнни яңартып өйрәнү һәм бәяләү бурычын көн тәртибенә куйды. Бу яктан XX йөз татар әдәбиятын тикшерү үзгә бер игътибарга һәм әһәмияткә лаек. Элекке елларда бу дәвер нигездә шул вакыттагы мәгълүм идеология кысаларында анализланды һәм бәяләнде. "XX йөз татар әдәбияты" дигән феноменаль әдәби процессны чын булганынча белергә теләгәндә иң әүвәл процессны фәнни яңартып өйрәнү концепциясен эшләргә кирәк. Бу мәкалә әлеге концепциягә караган кайбер уй-фикерләр белән уртаклашу ниятендә язылды.

Әмма ул концепция турында сүз башлаганчы "XX йөз татар әдәбияты" дигән әдәби-тарихи процессның идея-эстетик асылын һәм чикләрен ачыклау сорала. Бу дәвердә татар дөньясында әдәбиятка йөкләнгән вазыйфа гаять зур. Эш шунда: XIX гасыр урталарыннан татарлар арасында күзәтелә башлаган милли үзаң уяну һәм үсү хәрәкәте халык тормышында иҗтимагый-рухи яңарыш башлануга китерә. Ә әдәбият шушы процессны әйдәп баручы көчкә әверелә. Татар дөньясында милли үзаң һәм яңарыш башлану әдәбиятның идея-эстетик асылына да тәэсир итә, ягъни ул төп максатын милләткә хезмәт итүдә күргән милли мөстәкыйль сәнгать төсен ала. Үзләренең милләтне саклап калуга һәм үстерүгә юнәлтелгән программаларын тормышка ашыруда әдип сүзен иң мөһим чара итеп сайлаган җәдитче-мәгърифәтчеләр әлеге максатта әдәбиятны милли юнәлештә үстерү эшен һәм аның күпгасырлык тарихындагы яңа этапны башлап җибәрәләр. Әдәби иҗат өлкәсендәге мондый яңарыш XIX гасырның соңгы чирегеннән проза өлкәсендә башланып китә һәм ул тиз арада әдәби хәрәкәтнең алгы сафына чыга. Шул сәбәпле, яңа заман әдәбияты төсен алган XX йөз әдәби хәрәкәтен безгә хәзер XIX гасырның соңгы чирегеннән, шул вакыттагы мәгърифәтче әдипләр иҗатыннан башларга кирәк. Мондый гамәл тагын әлеге мәгърифәтчеләрнең идея-эстетик карашлары XX йөз башы әдәбиятында да үзәк урын тотуы белән нигезләнә.

Инде XX йөз татар әдәбиятының финалы мәсьәләсенә килсәк, ул финал әлегә күренми. Чөнки әдәбиятта XIX йөзнең соңгы чирегендә башланган идея-эстетик яңарыш кебек бөтен яңару хәзергә процесс буларак күзәтелми, бәлки моңа аерым омтылышлар гына күзаллана. Әгәр мәгърифәтчеләр милләт язмышы мәсьәләсен күтәреп, аны хәл итү өчен аң-белем һәм тәрбия кебек "рецептлар" тәкъдим иткән булсалар, хәзерге әдәбиятыбызның безнең көннәрдә кабат актуальләшкән әлеге мәсьәләне ныклап күтәргәне юк һәм, табигый, язучылар тарафыннан аны хәл итү өчен ниндидер яңа "рецептлар" да күрсәтелгәне юк. Биредә әдәбият тормыш агымыннан калыша дияргә мөмкин. Әйтик, соңгы вакытта җәмәгатьчелек милләтне саклап калуның мөһим чарасы итеп төрле җирләргә таралып яшәгән милләттәшләребезне берләштерүне, аларның милли бердәмлегенә ирешүне карый һәм шуңа омтыла башлады. Әдәбиятның исә бу хәрәкәттә катнашуы, мөнәсәбәте күренми әле. Г. Исхакый узган гасырның беренче елларында язган программа

характерындагы "Ике йөз елдан соң инкыйраз"ы кебек әсәрләрнең дә тудырылганы юк әле.

XX йөз татар әдәбияты тарихын яңартып язуның мөһим методологик принципларыннан берсе булып аны милли юнәлтелгән рәвештә өйрәнү һәм бәяләү торырга тиеш. Бу принцип әлеге дәвер әдәби тарихыбызны аның аерым чорларын элеккеге кебек бер-берсенә каршы куеп тикшерүдән арынуны һәм аны бербөтен итеп карауны сорый. Бу нәрсә бигрәк тә гасыр башы әдәбияты белән 1917 елдан соңгысының үзара мөнәсәбәтләрен ачуга карый. Шул ук вакытта әлеге ике дәвер арасында, аларның төрле идеологияләргә нигезләнүләре аркасында, мәгълүм аерымлыклар да хасил булуын да танымыйча ярамас.

XX йөз башы әдәбиятына килсәк, аны хәзер фактик яктан баетып һәм идея-эстетик планда яңартып өйрәнү сорала. Бу гамәл ахыр чиктә әлеге дәвер әдәбиятыбызның иң зур яңалыгын һәм казанышын, ягъни аның мили үзаңлы сәнгать булып үсеп китүен тулырак һәм тирәнрәк күзалларга булышачак. Табигый, безгә хәзер әйтелгән дәвер әдәбиятына караган кайбер теоретик мәсьәләләрне дә яңартып өйрәнү сорала. Әйтик, ул вакыттагы иҗат ысулларын "мәгърифәтчелек реализмы" һәм "тәнкыйди реализм" кебек төшенчәләр белән бәйләп карау үзен акламый. Чөнки болар революциягә кадәр гамәлдә булмаганнар, ә соңрак, совет чорында мәгълүм идеологик максатларда уйлап чыгарылганнар. Чынлыкта исә, XX йөз башында татар әдәбиятында милли хәятны җәдитче-мәгърифәтчел идеаллардан торып яктырту үзәк урын ала. Шушы идеалларны сәнгатьчә гәүдәләндергәндә романтизмга өстенлек бирелсә, чынбарлык күренешләрен шулардан чыгып сурәтләгәндә тәнкыйтьчел-аналитик башлангыч көчәя. Андый әсәрләрдә гадәттә романтизм һәм реализм элементлары күбрәк стиль өлкәсендә күзәтелә. Шуңа күрә XX йөз башы әдәбиятының иҗат ысуллары турында сүз алып барганда хәзер шул вакытта кулланышта булган өслүб (стиль) төшенчәсенә мөрәҗәгать итү урынлырак булыр. Бу категорияне индивидуаль өслүб, өслүбләр агымы һәм милли өслүб кысаларында карарга мөмкин. Шушы рәвешле аңлатылган өслүбләр системасын өйрәнү әдәбиятыбызның милли үзенчәлекләрен эстетик планда да нигезләп ачарга булышачак. Әдәбиятыбызның ул вакыттагы өслүб табигатен өйрәнү аның жанрлар системасын тикшерүгә тәэсир итәргә мөмкин. Чөнки өслүб һәм жанр категорияләре үзара бәйләнгәннәр. Соңгы мәсьәләгә конкретрак килгәндә, XX йөз башы әдәбиятының жанрлык табигатен тикшергәндә аның милли үзенчәлекле якларын ачуга игътибарны арттыру мөһим.

Әлбәттә, XX йөз башы әдәбиятында форма өлкәсендәге үзгәрешләрне үзалдына гына карарга ярамый, чөнки алар әдәби үсештәге идеологик-мәгънәви үзгәрешләр белән турыдан-туры бәйләнгәннәр. Ачыграк әйтсәк, ул дәвердә әдәбиятка милли идеологиянең йогынтысы бермә-бер көчәю, шул нигездә әдәби иҗатның миллиләшүе әсәрләрнең идея-проблематикасына тәэсир итә, анда мәгълүм үзгәрешләр тудыра. Моны, аерым алганда, һәрвакыт әдәбиятның төп проблемаларыннан булган герой мәсьәләсен аңлауда һәм яктыртуда күзалларга мөмкин. XIX йөз мәгърифәтчеләре әлеге мәсьәләне милли идеология позициясеннән торып карыйлар һәм бу хәл узган гасыр башында да дәвам ителә. Шул сәбәпле, искә алынган чор әдәбиятындагы герой концепциясен хәзер шушы яссылыкта аңлатуга игътибарны арттыру сорала. Әлбәттә, бу мәсьәләгә эстетик карашлар бертөрле генә була алмый. Әдипләр аны еш кына романтик, драматик һәм сатирик планда карыйлар һәм бәялиләр. Бигрәк тә романтик герой белән сатирик антигерой образларын тудыруга басым ясала.

Әдәбиятыбызның XIX һәм XX гасырлар аралыгындагы идея-эстетик үсешен тулырак һәм дәлилләбрәк ачу өчен хәзер ул дәвердә төп әдәби төрләрнең—поэзиянең, прозаның һәм драматургиянең—үсеш тенденцияләрен һәм гомум әдәби хәрәкәттә тоткан урыннарын ныклабрак ачыкларга кирәк.

Мәгълүм ки, мәгърифәтчеләрнең әдәби иҗатны реаль тормышка—милли яшәешкә—якынайту башлангычы әлеге төрләрнең үсешенә дә тәэсир итә. Әгәр урта гасырларда укымышлы даирәләргә йөз тоткан әдәбиятта шул элитаның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә поэзиягә өстенлек бирелсә, XX йөз башында исә әдәбият халыкның киң массаларына йөз белән борыла. Шул нигездә әлеге массаларга аңлаешлы демократик формаларга игътибар арта. XIX йөз ахырыннан әдәбиятыбызда проза белән драматургиягә дикъкать көчәюенең һәм ул әсәрләрнең тиз арада популярлык казануларының мөһим сәбәпләреннән берсе шуннан гыйбарәт. Бу әдәби төрләрнең киң даирә укучыларга якынрак булуы аларның халыкчан телгә нигезләнүләре белән дә бәйләнгән. Гомумән алганда исә XX йөз башында әдәби иҗат, эчтәлегенең миллиләшүе нәтиҗәсендә, поэтика өлкәсендә демократлашуны кичерә, ягъни бу өлкәдә халык иҗаты традицияләрен үзләштерү көчәя, икенче яктан, татар әдипләренең башка дөньяви әдәбиятлар, беренче чиратта рус әдәбияты белән танышулары аларны заманча эзләнүләргә рухландыра. Шушы хакыйкатьне хәзер ачыграк күзаллау әлеге чорда әдәби йогынты мәсьәләсен дә яңачарак аңлатуга һәм бәяләүгә китерер иде. Мәгълүм ки, элекке елларда милләтләрне зур һәм кечеләргә бүлеп карау аларның хезмәттәшлеген һәм тарихтагы урынын берьяклы бәяләүне тудырды. Мондый тенденциозлыкны кире кагып, М. Горький, мәсәлән, 1911 елда болай язган иде: "Минем башыма торган саен ешрак шундый фикер килә: әгәр берәрсе рус халкының тормышны күзаллавына татарларның күршелеге ничек йогынты ясаганын күздән кичерергә алынса, ул русларга да, татарларга да яхшылык эшләр иде". Күренекле рус әдибе таныган мондый гомуми йогынты, күрәсең, заманында русларның әдәби-эстетик карашларында һәм фикерләвендә дә чагылмый калмагандыр. Әмма аның беркайчан да өйрәнелгәне генә юк. Тарихта булган шундый бәйләнешләрне, йогынтыны күрергә теләмәү, халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрне берьяклы хәрәкәт рәвешендә генә аңлату мәдәни өлкәдә әдәбиятларны "остаз"га һәм "шәкертләр"гә бүлеп карау белән мавыгу тудырды. Әлбәттә, мондый очракларда чын иҗади бәйләнеш турында сүз була алмый, бары "шәкертләр"нең "остаз"га иярүләре, ягъни өйрәнчеклек хакында гына сөйләргә мөмкин.

Әгәр догмалардан арынып, әдәби чынбарлыкка мөрәҗәгать итсәк, анда башкарак хәлне күзәтербез. Бу яктан, мәсәлән, Тукайның Пушкинга мөнәсәбәте игътибарга лаеклы. Билгеле бер эволюция кичергән ул мөнәсәбәт үз чиратында байтак дәрәҗәдә Пушкинның Байронга үзгәрешле карашын хәтерләтә. Мәгълүм ки, иҗатының баштагы өлешендә XIX гасырның егерменче еллары башында, романтик рухта булган яшь Пушкин Байронның шундый ук рухлы шигърияте йогынтысына бирелә. Мисал өчен, аның "Чегәннәр" поэмасы шул хакта сөйли. Әмма алга таба идея-эстетик карашлары үзгәрү белән бәйле рәвештә Пушкин үзенең кичәге кумирына тәнкыйть күзлегеннән карый башлый. 1827 елда язылган "Байрон һәм аңа ияручеләр турында" дигән мәкаләсе һәм бу хәл аңа иҗатында сыйфат ягыннан яңа адым атларга булыша. Рус шагыйре инглиз романтик шагыйре йогынтысыннан арынып реализмга йөз тота һәм үзенең иҗади мөстәкыйльлеген ныгыта. Мондый үзгәрешне аның югарыда искә алынган "Чегәннәр" поэмасын егерменче еллар уртасында язылган "Руслан һәм Людмила"сы белән чагыштырганда ачык күрергә мөмкин. Бу әсәрләр һәм идея, һәм эстетик яктан бер-берсеннән шактый аерылалар.

Шундыйрак эволюция Тукайның Пушкинга мөнәсәбәтендә дә күзәтелә. Әйтик, башлангыч чор иҗатына караган "Пушкинә" шигырендә (1906). Әле романтиграк рухлы яшь Тукайның бөек рус шагыйренә мөнәсәбәте шактый дәрәҗәдә яшь Пушкинның атаклы Байронга карашы белән аваздаш. Ягъни әлеге шигырендә Тукай да бөек шагыйрьгә соклануын, аның алдында баш июен чагылдыра. Табигый, үзенең мондый мөнәсәбәтен татар шагыйре

романтик пафос һәм тасвир чаралары белән гәүдәләндерә.

Шәхес һәм иҗатчы буларак җитлеккәч язылган "Пушкин вә мин" шигырендә (1912) инде Тукай үзе белән бөек рус шагыйре арасында һәм идея, эстетик планда принципиаль аерма барлыгына басым ясый. Бу аерманы ул, мәсәлән, хәзрәти Пушкинның авылда чакта аның халкы турында түгел, бәлки бу халыктан ерак торган кешеләр хакындагы "Евгений Онегин" романын язуында, ә үзенең шундый ук авылда торып "бәрәңгенең көен" җырлавында, ягъни авыл яшәешен сурәтләвендә күрә. Иҗатында халык мәнфәгатьләрен кайгыртуы сәбәпле, шагыйрь үз әсәрләренең озын гомерле булачагына да өмет итә. Соңгы шигырьләреннән булган "Кыйтга"да (1913) исә Пушкин белән Лермонтовны кояш белән, ә үзен шул кояштан нур алган ай белән чагыштырса да, иҗатта һич тә Пушкинга иярә алмавын, чөнки аның "шигърене хаинанә үз итеп" булмавын таный.

Тукайның бу шигыре әдәби йогынты мәсьәләсен аңлату ягыннан үзгә әһәмияткә ия. Әйтергә кирәк, татар шагыйренең әдәби йогынтыны аңлавы В. Г. Белинскийның бу мәсьәләне аңлаткан мәгълүм бер фикеренә шактый авазадаш булып чыга. Күренекле рус тәнкыйтьчесе әлеге уңайдан образлы итеп болай дип язган иде: "Бөек шагыйрьнең башка шагыйрьләргә йогынтысын аның поэзиясенең аларда чагылуында түгел, бәлки аларның үз көчләрен уятуында күренә: кояш нуры да, җирне яктыртканда, аңа үз көчен бирми, ә бары аның үзендәге көчне уятып җибәрә".

Күренә ки, әдәби йогынты турында сүз алып барганда һәр ике очракта да "нур" төшенчәсе кулланыла һәм ул рухи көч мәгънәсен ала. Ягъни олы шагыйрьдән нур алу аның иҗатыннан рух алу рәвешендә аңлатыла. Белинский да, Тукай да әдәби йогынтыны иҗатка рухландыру, үзендәге иҗади көчләрне уятып җибәрү чарасы итеп аңлыйлар. Һәр ике очракта да шагыйрьнең иҗади яктан мөстәкыйль, үз йөзле булып калырга тиешлеге раслана. Биредә милли үзенчәлек мәсьәләсенә дә игътибар итеп, Тукай башка төрле сәнгатьчә фикерләү системасы казанышларын яки кагыйдәләрен милли җирлеккә күчерү, аларны "үз итү" мөмкин булмавын да күрсәтә.

Белинский белән Тукайның әле генә искә алынган карашлары хәзер, аерым алганда, XX йөз башындагы әдәби бәйләнешләр мәсьәләсен яңартып аңлату кирәклеген искәртәләр. Мәгълүм ки, ул вакытта әдәбиятта гына түгел, бөтен татар дөньясында яңарыш хәрәкәте башлана һәм ул еш кына искелек белән яңалык арасындагы көрәш байрагы астында бара. Соңгысы тарихка кадимчелек белән җәдитчелек көрәше иseme астында кереп калды. Бу көрәш бездә озак вакытлар романтик рухта каралды һәм бәяләнде. Ягъни кадимчелек белән җәдитчелек антагонистик күренешләр итеп һәм капма-каршы төсләрдә фаразланды. Хәзер безгә мондый романтик фаразлардан арынырга, XX йөз башында татар тормышында һәм әдәбиятында күзәтелгән үзгәрешләрне фәнни объектив бәяләү эшенә керешергә кирәк. Бу хәл әле генә искә алынган кадимчелек белән җәдитчелекне традицияләр һәм яңалык рәвешендә аңлау һәм аларны үзара бәйләнештә карау кирәклеген искәртәчәк. Мәгълүм ки, XIX гасыр урталарыннан җитди үзгәрешләр юлына баскан татар мәгыйшәтендә традицияләр белән яңалык арасындагы мөнәсәбәтләр бермә-бер катлаулана һәм каршылыклы төс ала. Моңа кадәр үз эченәрәк бикләнеп яшәгән татар дөньясы яңа иҗтимагый-икътисади шартларда мондый йомыклыктан арына һәм башка халыклар, бигрәк тә рус дөньясы белән бәйләнешләрен ныгыта башлый. Әмма бу интеграция процессы җиңел бармый, җитди эчке каршылыкларга да очрый. Болар татарның рухи-әхлакый яшәешендә аеруча ачык күренә. Чөнки биредә моңа кадәр гасырлар дәвамында көнчыгыш-ислам кануннары һәм карашларына нигезләнеп, яшәгән татар дөньясы бөтенләй башка төр яшәү һәм фикерләү рәвеше белән очраша. Бу хәл традицион яшәү һәм фикерләү белән яңача, европача яшәргә һәм фикерләргә омтылу арасында зур гына каршылыклар тудыра. Яңалыкка

омтылыш көчәйгән саен әлеге каршылыклар да үсә. XX йөз башында татарның төп иҗтимагый мөнбәре булып торган матбугат белән әдәбият милли мохитта шундый традицияләр белән яңалык арасындагы көрәшне үзлегеннән тагын да кискенләштереп күрсәтү юлына, ягъни роматинтизм юлына баса. Әдәбиятыбызның ул вакыттагы эстетик үсешенә килсәк исә анда милли традицияләр белән рус-гаребчә фикерләүгә омтылган яңалык арасындагы мөнәсәбәтләр башкачарак төс ала. Моны, аерым алганда, модернизмга мөнәсәбәттә шактый ачык күрергә мөмкин. Белгәнебезчә, бу күренеш безнең әдәбиятта озак вакытлар, идеологик планда гына каралып, бөтенләй кире кагылды яки күләгәдә калдырылды. Безнең көннәрдә исә әдәбият фәнебез өчен яңа кызыклы мәсьәлә яки объектка әверелүе аркасында, модернизмны романтик рухта бәяләүгә өстенлек бирелә башлады.

Инде XX йөз башы татар әдәбиятында эстетик традицияләр һәм яңалык мәсьәләсенә аеграк карап һәм объективрак килсәк, башкарак хәл белән очрашабыз. Барыннан да элек, милли мөстәкыйльлеккә омтылган әдәбиятта традицияләргә нигезләнгән милли үзенчәлекле фикерләүнең өстенлек алуы күзәтелә. Тормышны һәм шәхесне милли идеаллар һәм максатлар яссылыгында яктыртуга игътибар арту әдәби иҗатта үткәннән килә торган романтизмның роле ныгуга китерә. Мисал өчен "мәгърифәтчелек реализмы" дигән күренешнең нигезендә асылда романтизм ята. Бер үк вакытта татар дөньясын европалаштырырга омтылу, табигый, әдипләребезнең рус-гареб әдәбиятлары белән кызыксынуын көчәйтә. Бу чорда әдәби тәнкыйть белән фәнне формалаштырганда, әлбәттә, зур гына үсешкә ирешкән рус-гареб фәне казанышларыннан актив файдаланыла. Ә моңа кадәр инде мең елга якын тарихы һәм тәҗрибәсе булган әдәби иҗат өлкәсендә исә башка әдәбиятлар казанышларына мөнәсәбәт катлаулырак төс ала. Бер яктан, әдипләрдә, бигрәк тә русча күбрәк аң-белем алганнанрында, рус-гареб әдәбиятларының эстетик тәҗрибәсен үзләштерү теләге көчәя. Икенче яктан исә милли-эстетик рухта тәрбияләнгән авторлар бөтенләй башка сәнгатьчә фикерләү системасын, Тукай әйткәнчә, "үз итү"нең бик авыр булуын һәм хәтта мөмкин түгеллеген аңлыйлар. Шундый хәл, аерым алганда, инде искә алынган модернизмга мөнәсәбәттә шактый ачык күзәтелә. Рус-гареб әдәбиятларына хас бу күренеш белән башлыча әлеге әдәбиятларга якынрак торган яшьрәк авторлар кызыксына һәм алар татарның сәнгатьчә фикерләү системасын рус-гареб модернизмы рухында яңартырга омтылышлар ясыйлар. Әмма мондый омтылышлар аерым фактлар гына булып калалар, татар әдәбиятында ниндидер бер системага әверелә алмыйлар.

Гомумән, XX йөз башы әдәбиятыбызда модернизм мәсьәләсен объектив бәяләү өчен "модернизм" төшенчәсенә дөресрәк аңлатма бирергә кирәк. Бу төшенчәне ике төрле мәгънәдә аңларга мөмкин. Таррак мәгънәдә: ягъни рус-гареб әдәбиятларында XIX һәм XX йөзләр аралыгында хасил булган яңа фәлсәфи-эстетик юнәлешләр рәвешендә. Киңрәк мәгънәдә: ягъни гомумән әдәбиятта идея-эстетик яңарыш мәгънәсендә. Мәгълүм ки, XIX һәм XX йөзләр аралыгында татар әдәбияты шундый яңарыш кичерә. Бу вакытта көнчыгыш романтизмына хас күренешләр безнең әдәбиятта яңа сулыш алалар һәм аңдагы эстетик яңарышта мөһим роль уйныйлар. Шул сәбәпле, XX йөз башы татар әдәбиятындагы хәзер рус-гареб модернизмы белән бәйләп карала башлаган кайбер фактларны—мисал өчен Г. Исхакый, М. Гафури яки Ф. Әмирхан кебек әдипләрдән алынган мисалларны—татар әдәбиятының үз җирлегендә хасил булган һәм үзендә яшәп килгән романтизм белән бәйле яңарыш күренешләре дип бәяләү дөресрәк булыр кебек.

Гомумән алганда, әдәбиятлар арасындагы уртаклыкны өйрәнүгә басым ясалган элекке еллардан аермалы буларак, аларның милли асылын һәм закончалыкларын ачуга игътибар арткан безнең көннәрдә татар әдәбиятының да XX йөз башындагы милли үзенчәлекле үсешен яктырту заман таләпләренә

турырак килә. Шушы позициядән торып эш итү, тулаем алганда, әдәбиятыбызның ул дәвердәге идея-эстетик эзләнүләрен һәм табышларын да объективрак чагылдырырга булыша. Ягъни әлеге процесс XIX йөз ахырыннан мәгърифәтчел идеялар һәм карашлар рухындагы эзләнүләрдән башлана да, 1905—1907 елгы революция дәверендә бераз сыйнфый карашларга бирелә һәм алга таба янә мәгърифәтчел-милли позициягә баса.

XX йөз башы татар әдәбиятын яңартып өйрәнүнең тагын бер мөһим бурычы булып бу дәвердәге аерым әдипләр иҗатын җентекләбрәк анализлау, аларның әдәби тарихтагы урынын һәм ролен объективрак бәяләү тора. Димәк, бу бурычны хәл итү өчен ике төрле эш башкару сорала. Бердән, аерым әдипләр иҗатын фактик һәм идея-эстетик яктан тулырак анализларга кирәк. Икенчедән, аерым әдипләрнең әдәбият тарихындагы урынын һәм ролен объективрак бәяләүгә игътибарны арттырырга кирәк. Бу мәсьәләне без моңа кадәр еш кына романтик рухтарак хәл итеп килдек. Бүгенге көндә бу тенденциягә характерлы мисал итеп Г. Исхакыйга мөнәсәбәтне алырга мөмкин. Мәгълүм ки, аның исеменең һәм мирасының ниһаять "реабилитация" алып туган иленә кире кайтуы узган гасырның 90 елларыннан татар дөньясы өчен тарихи вакыйгага әверелде һәм шунлыктан ул гомум игътибар үзәгендә калды. Шушы хәл фән дөньясына да хас. Анда да Исхакый мирасы фәнни тикшеренүләрнең иң популяр объектына әйләнде һәм бу затның татар иҗтимагый-рухи яшәешендә тоткан урынын ачуга басым ясалды. Бу хәл, гомумән алганда, тормыштагы яки әдәбияттагы мөһим яңа күренешне бәяләү белән бәйле романтик омтылышның бер чагылышы булып тора.

Хәзер исә мондый романтизмнан арынып, Исхакый иҗатын реалистик рухта анализлауга, аның әдәбиятыбыз тарихындагы күркәм урынын Тукай, Ибраһимов, Әмирхан кебек әдипләргә күләгә төшермичә бәяләү сорала.

Инде узган гасыр әдәбиятыбызның вакыт ягыннан да, күләм ягыннан да зуррак булган икенче дәвере—1917 елдан соңгы чорына килсәк, аны яңартып өйрәнү буенча тагын да зуррак һәм катлаулырак бурычлар тора. Барыннан да элек бу дәверне гасыр башы белән күчемле бәйләнештә карау кирәк. Ул бәйләнешнең җанлы шаһитләре булып Тукай традицияләренең совет чорында да дәвам иттерелүе, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал, К. Тинчурин кебек әдипләрнең революциядән соң да актив иҗат итүләре тора. Г. Исхакый исә мөһаҗирлектә әдәбиятыбызның үткәндәге милли асылы белән вазыйфасын яңа тарихи шартларда да саклап кала һәм дәвам итә.

1917 елдан соңгы әдәби хәрәкәтне хәзер элекке еллардагыча Октябрь революциясеннән түгел, бәлки Февраль революциясеннән башлау сорала. Чөнки әдәбиятыбыздагы җитди үзгәрешләр нәкъ менә шушы революция йогынтысында башлана. Бу вакытта алга таба әдәбиятта мөһим урын алган ике юнәлеш формалаша. Аларның берсен рәсми-романтик юнәлеш дип атарга һәм аның илдәге хаким идеологиягә хезмәт итүе аркасында совет чоры әдәбиятында әйдәп баручыга әверелүен әйтергә кирәк. Бу юнәлеш социалистик реализм таләпләренә нигезләнде һәм ул таләпләр, бигрәк тә тормышны аның революцион үсешендә күрсәтү таләбе йогынтысында, еш кына романтик рухта булды. Чөнки социалистик реализмның әлеге таләбе бөтен әдәбиятны һәм аерым язучы иҗатын реаль чынбарлыктан читләшә барып, булырга тиешлене яки мөмкинне инде булды дип күрсәтүгә китерде. Шул нигездә совет чоры әдәбиятында яңа социалистик заманны һәм феодаль-буржуаз үткәнне сурәтләүдә романтизмга хас берьяклы һәм контраст буяулар белән эш итү өстенлек алды.

1917 елдан соңгы татар әдәбиятындагы икенче мөһим юнәлешне беренчесенә теге яки бу күләмдә оппозициягә булган тәнкыйди-аналитик һәм демократик рухтагы юнәлеш дип атарга мөмкин. Мондый рухлы әсәрләрнең совет илендә язылганнары үз вакытында совет чынбарлыгын бозып күрсәтүдә, милләтчелектә, динилектә һ. б. гаепләнеп кире кагылдылар

һәм әдәбияттагы "ак тап"ларга әверелделәр. Мөһаҗирлектә язылганнары исә озак вакытлар бездә бөтенләй билгесез булып калдылар. Ә хәзер андый әсәрләр татар әдәбиятының революциядән соң да үткәндәге милли вазыйфасын дәвам итүен күрсәтүче мөһим факторга әвереләләр. Шунлыктан безнең көннәрдә алар 1917 елдан соңгы әдәбиятыбызның милли асылын һәм үзенчәлеген билгеләүдә зур әһәмияткә ия булып торалар.

Совет чоры әдәбиятыбызны яңартып, ягъни объективрак бәяләргә алынганда хәзер аның реаль хәлен ачу сорала. Чөнки элеккерәк елларда совет системасын данлауга корылган идеология йогынтысында ул вакыттагы әдәбиятны да башлыча уңай яктан, ягъни аны күбрәк үсеш-казанышлар яссылыгында карау һәм бәяләү белән чикләнелде. Хәзер исә әлеге чорны фәнни объектив анализлау ул дәвердә әдәбиятта билгеле бер эзләнү-табышлар белән бергә зур гына югалтулар да булганын күрсәтә. Бер яктан, татар әдәбияты идеологик һәм сәяси сәбәпләр белән бәйле рәвештә үзенең күп кенә күренекле вәкилләреннән мәхрүм кала. Мондый югалтулар дулкын-дулкын булып бара. Мисал өчен XX йөз башы әдәбиятыбызда һәм гомумән мәдәниятыбызда мөһим роль уйнаган шәхесләрдән Г. Исхакый, Й. Акчура, С. Максуди, Ф. Туктаров һәм башкалар, октябрь борылышыннан соң илдә башланган үзгәрешләрне кабул итә алмыйча, мөһаҗирлеккә китеп баралар һәм шуннан соң аларның туган илләре белән бәйләнешләре өзелә. Октябрьгә кадәр шулай ук танылган әдипләребез булган Ф. Әмирхан, Дәрдмәнд, С. Рәмиев, Г. Коләхметов h. б. революциядән соңгы шартларда әдәби иҗаттан теге яки бу дәрәҗәдә читләшәләр. 20 елларда ук иҗат мөмкинлекләрен тиешенчә ачып бетерә алмыйча, фани дөньядан вакытсыз китеп тә баралар. һ. Такташ, Ш. Бабич, Ф. Әсгать кебек әдипләр дә вакытсыз вафат булалар. Әдәбиятыбызга тагын да зуррак югалтуларны утызынчы еллар ахырындагы репрессияләр китерә. Гомумән, бу репрессияләр җиле кагылмаган татар язучысын табуы кыен. Югалтуларның тагын бер дулкыны Ватан сугышы чоры белән бәйләнгән. Бу вакытта татар әдипләренең зур күпчелеге, бөтен язучылар оешмасы диярлек фронтта була һәм бер төркем танылган әдипләр белән беррәттән әдәбиятыбызның киләчәге булган күп кенә яшь авторлар сугыш кырында ятып кала.

Совет чоры әдәбиятыбыздагы югалтуларның икенче төре бу дәвердә рәсми идеологиянең иҗат ирекен шактый чикләве, әдипне тар идеологик кысаларга кертеп куюы белән бәйләнгән иде. Бу гамәл чынлыкта язучыга социалистик реализм принципларын көчләп тагу юлы белән башкарылды. Шулай да әдәбият, тулаем алганда, әлеге кысаларда гына кала алмады, кайчак андый кысаларга сыеша алмаган, хәтта аларны җимергән әсәрләр дә хасил булды. Әйтергә кирәк, моның ише әсәрләрнең язмышы гадәттә аянычлы төс алды, алар совет әдәбияты өчен чит-чт күренешләр дип кире кагылдылар һәм "ак тап"ка әверелделәр. Хәзер исә андый "ак тап"ларның шул дәвер әдәбиятын фәнни объектив бәяләүдә принципиаль әһәмияте булуы ачыклана. Аерым алганда, аларның милли әдәбият вазыйфасына тулырак һәм ачыграк җавап бирүләренә инанасың. Шунлыктан алар 1917 елдан соңгы әдәбиятыбызның милли асылын һәм үзенчәлекләрен ачуда мөһим роль уйныйлар.

Совет чоры әдәбиятын, аның аерым күренешләрен, теге яки бу язучы иҗатын, конкрет бер әсәрне объектив бәяләү, реаль кыйммәтен ачу өчен хәзер методология характердагы тагын бер моментны искә алырга кирәк. Эш шунда: совет чорында татар әдипләренең, бер яктан, рәсми идеологиягә ышанып иярүләре, икенче яктан исә укучыларның милли ихтыяҗларын да күпмедер канәгатьләндерергә омтылулары кайчак әсәрләрнең эчтәлегендә һәм мәгънәсендә икекатламлылык хасил булуга китерде. Ачыграк әйтсәк, тормыш һәм кешеләр хакында рәсми идеология рухында фикер йөртергә алынып, алар яшәешенең иҗтимагый-сәяси ягын яктыртуга игътибар бирәләр һәм болар әсәр эчтәлегенең өске катламын тәшкил итәләр. Элеккерәк елларда

без конкрет әсәрне шушы катлам буенча гына бәяләргә күнеккән идек. Хәзер исә әсәрнең милли әдәбият күренеше буларак мәгънәви асылын ачыклау өчен игътибарны аның эчтәлегенең икенче, эчкәрәк яшерелгән катламына юнәлтергә кирәк. Чөнки бу катламда авторның милли әдип буларак эзләнүләре һәм табышлары ачыграк чагыла.

Совет чоры әдәбиятыбызның конкрет әсәрләрен шушы рәвешле анализлау ахыр чиктә уртак бер максатка: бу дәвердә дә әдипләребезнең үткәннән килә торган милли вазыйфаларын онытмауларын күрсәтергә, әдәбият-сәнгатькә миллилектән һәм мирастан азат ителгән, бары социализм идеяләре белән азыкланып яшәгән интернационалист совет кешесен сурәтләү каттый рәвештә йөкләнгән шартларда да үз халкы турында кайгыртудан туктамауларын ачуга хезмәт итәр иде. Әлбәттә, алар совет пропагандасы йогынтысыннан читтә кала алмыйлар, еш кына аның идеяләрен инанып кабул итәләр. Шул сәбәпле, татар әдәбиятында революциянең, социализмның безнең халыкка азатлык, бәхет алып килүе идеясе киң урын ала һәм ул, табигый, романтик планда чагылдырыла. Нәтиҗәдә әдәбиятыбызда, гомумән, яңа җәмгыятьне сурәтләүдә романтик башлангыч өстенлек ала һәм ул төп идея-эстетик тенденциягә әверелә.

Рәсми пропагандага ышанып, Октябрь революциясенә, илдә яңа җәмгыять төзү өчен көрәшкә дан җырлаган күпсанлы әсәрләр белән беррәттән, 1917 елдан соңгы әдәбиятта яңа заманны бүтәнрәк позициядән торып бәяләү, башкарак мотивларны яктырту очраклары да күзәтелә. Һәм болар гадәттә әдипләрнең совет чорында да милли мәсьәлә белән актив кызыксынулары һәм бу мәсьәләдә рәсми пропаганда белән килешеп бетмәүләре нәтиҗәсе булып тора иде. Шушы хакыйкатьне ачыклау совет чоры әдәбиятыбызны милли әдәбият итеп өйрәнгәндә әлеге төр әсәрләргә игътибарны көчәйтүне сорый. Мәгълүм ки, мондый әсәрләр башлыча егерменче елларда языла. Характерлы мисаллар итеп әлеге еллар поэзиясендә, бигрәк тә Ф. Бурнаш, С. Сүнчәләй, Т. Ченәкәй иҗатында дини мотивларның көчәеп китүен, прозада Ф. Әмирханның "Шәфигулла агай" һәм Г. Ибраһимовның "Адәмнәр" повестьларын, драматургиядә Һ. Такташның "Югалган матурлык" драмасын алырга мөмкин. Мондый әсәрләрне игътибар үзәгенәрәк куеп анализлау, бер яктан, әлеге чор әдәбиятыбызның үткән белән күчемле бәйләнешен дәлилләп ачарга булышса, икенче яктан, әдәбиятны рәсми төстә яңа җәмгыять җырчысы итү кампаниясе алып барылган вакытта бездә бу җәмгыятькә тәнкыйтьчел караш та булганлыгын ачыкларга мөмкинлек бирә. Мондый карашның нигезендә еш кына халкыбызның яңа җәмгыятьтәге милли хәл-әхвәленнән канәгать булмау ята иде. Гомумән алганда, искә алынган фактлар татар әдәбиятының егерменче елларда әле үзенең милли позициясен күпмедер дәрәҗәдә саклый алуы турында сөйлиләр. Бу хакыйкать әдәбият тарихын яңартып өйрәнгәндә искә алынырга тиеш.

1917 елдан соңгы татар әдәбиятын милли үзенчәлекле итеп өйрәнүдә хәзер мөһаҗирлектәге әдипләр иҗатының әһәмияте бермә-бер арта. Андый әдипләр иҗаты бу дәвер әдәбиятыбызның яшәү офыгын киңәйтү белән бергә, милли яшәеш һәм язмыш мәсьәләләрен актив яктыртып, яңа заман татар әдәбиятын идеологик яктан да колачлырак итә, ягъни аны үткәннән килә торган милли идея белән сугара. Биредә иң күркәм үрнәк булып, әлбәттә, Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге әдәби эшчәнлеге тора. Аның "Көз", "Өйгә таба", "Дулкын эчендә" кебек әсәрләре милли проблематиканы яктыртулары белән бөтен егерменче еллар әдәбиятыбызны һәм мәгънәви яктан, һәм эстетик планда баеталар. Аларда күтәрелгән мәсьәләләрнең бүген дә актуаль булуларын искә алсак, әлеге әсәрләр хәзерге әдәбиятыбыз өчен генә түгел, бәлки, бөтен татар дөньясы өчен дә әһәмиятле булып калалар.

Егерменче еллар татар әдәбиятының милли үзенчәлеген эстетик планда ачу турында сүз алып барганда ул чорда үткәннән килә торган гыйсъянчылык

күренешенең һәм нәсер жанрының җанлануына да игътибар итәргә кирәк.

Гомумән алганда, егерменче елларда, яңа идеологиянең әле әдәбият-сәнгатьне тулысынча үз кулына алып өлгермәве аркасында, иҗат ирекке билгеле бер дәрәҗәдә сакланган иде. Шул сәбәпле, ул вакытта үткән әдәби тәҗрибә белән күпмедер бәйләнеш тә булды, язучыларның төрле әдәби оешмалары төзелеп, алар арасында азмы-күпме иҗади конкуренция һәм сәнгатьчә эзләнүләрнең төрлелеге дә хасил булды, кайбер әдипләр илдә төзелә торган яңа җәмгыятькә тәнкыйтьчел карашларын чагылдырырга да батырчылык иттеләр. Болар барсы егерменче елларны совет әдәбиятының "алтын дәвере" дип анализларга һәм бәяләргә мөмкинлек бирә.

Ә инде утызынчы еллардан, дөресрәге, СССР язучыларының беренче съездыннан соң (1934), әдәбият өлкәсендә яңа чор башлана дияргә мөмкин. Бу чорга объектив бәя бирергә алынганда, иң әүвәл, социалистик реализмның реаль максатын һәм вазыйфасын ачыкларга кирәк. Әгәр бу иҗат ысулының ничек барлыкка килүенә дикъкать итсәк, аның асылда әдәбият-сәнгать белән большевиклар партиясе җитәкчелек итүен фәнни-теоретик нигезләү өчен уйлап чыгарылганы ачыклана. Мондый җитәкчелек мәсьәләсе В.И. Ленинның XX йөз башында ук "Партия оешмасы һәм партияле әдәбият" дигән программа рухындагы мәкаләсендә (1905) күтәрелгән һәм нигезләнгән иде. Ленинның бу өлкәдәге күрсәтмәләре язучыларның беренче съездында кабул ителгән документларның нигезенә салынды. Төп программ документ булып, әлбәттә, Язучылар союзы уставы тора. Анда совет әдәбиятының бердәнбер иҗат методы дип социалистик реализм игълан ителде һәм аңа директив билгеләмә бирелде. Моннан соң совет илендә әдәби иҗат шушы метод кысаларына кертелә, ягъни яңа идеологиягә ныклап буйсындырыла. Шул нигездә яңа җәмгыять төзү өчен көрәшнең төрле фронтларында һөҗүмгә күчкән социализм әлеге чорда әдәбият-сәнгать өлкәсендә дә җиңүле адымнар ясый, ягъни аны үзенең идеологик коралына әвелдерә. Мондый шартларда әдипләр милли мәнфәгатьләр турында кайгыртуларын йә яңа идеология рухына буйсындыралар, яисә аны рухи-әхлакый өлкәгә юнәлтәләр.

Мәсәлән, утызынчы еллар әдәбиятында, бер яктан, халкыбызның күркәм әхлакый сыйфатларын хезмәткә, мәхәббәткә яки гаиләгә мөнәсәбәттә ачуга басым ясала. Икенче яктан, шундый ук өлкәләрдә әхлаклылыкны саклау һәм ныгыту өчен көрәш яктыртыла. Икенче төрле әйткәндә, ул елларда яңа җәмгыять шартларында халык әхлагын саклауга һәм үстерүгә игътибар арта. Сугыш чоры әдәбиятында исә халкыбызның шул дәһшәтле елларда сугыш кырында һәм тылда зур әхлакый сынау үтүен чагылдыруга игътибар көчәя. Әлеге сынау вакытында татарның илгә тугрылык, туган җирне ярату, батырлык, кыюлык, яшәү дәрте, оптимистик рухы кебек традицион сыйфатлары калку булып ачылалар. Сугыштан соңгы еллар әдәбиятында халкыбызның сугыш сынавын узган әхлак йөзен ачуга игътибар тагын да арта.

Утызынчы-кырыгынчы еллар әдәбиятын объектив бәяләргә алынганда тагын бер моментка игътибар итү сорала. Билгеле булганча, бу дәверне элек гел күтәренке пафоста карау гадәткә кергән иде. Ягъни ул чорда "әдәбият яңа тормыш төзү яки аны саклау өчен җиңүле көрәш пафосын, бу тормышта яшәү шатлыгын чагылдырды" дигән фикер үткәрелде. Чынлыкта исә мондый пафос-хисләрне гәүдәләндерү белән бергә, әдипләр, андый бертөрлелектән туйгандай, башка төрле хис-кичерешләргә дә мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, утызынчы еллар поэзиясендә күтәренке иҗтимагый хисләр өстенлек иткән бер вакытта Ә. Фәйзинең "Умырзая", М. Җәлилнең "Сагыну", С. Хәкимнең "Юксыну" кебек мәхәббәткә бәйле моң-сагышны чагылдырган җырлары языла һәм алар риторикадан туйган, моңга сусаган укучылар тарафыннан бик җылы каршылана, халык җырына диярлек әверелә. Мондый мотивлар күбрәк көрәшкә, батырлыкка дан җырлаган сугыш еллары поэзиясендә дә вакыты-вакыты белән чагылып китәләр. Алар яңа пропаганданың

көчәйгәннән-көчәя барган йогынтысына дучар булган әдәбиятны пафос бертөрлелегеннән коткаралар, шундый шартларда да күпмедер дәрәҗәдә тере һәм төрле уй-хисләр белән яши алганын раслыйлар.

Совет чоры әдәбиятының гомум торышын, аның мөһим тенденцияләрен яңартып анализлау һәм бәяләү белән беррәттән, хәзер бу дәвергә караган аерым әдипләр иҗатын да фәнни дәлилләбрәк өйрәнү сорала. Бигрәк тә әлеге чор әдәбиятында лидерлык һәм остазлык вазыйфаларын башкарган Г. Ибраһимов белән һ. Такташ иҗатлары игътибарны җәлеп итә. Иҗтимагый-социаль планда хәзер аларны совет чоры әдәбиятының фаҗигале язмышлы вәкилләре итеп карарга кирәк. Аларның фаҗигасе—үзләре инанып хезмәт иткән система тарафыннан юкка чыгарылуында. Мәсьәләнең әдәби ягына килсәк, бу әдипләргә объектив бәя бирү өчен, барыннан да элек, аларның мирасын тулы белергә кирәклеге ачыклана. Мисал өчен Г. Ибраһимовның "Татар хатыны ниләр күрми" белән "Безнең көннәр" романнарының беренче вариантларына игътибарны көчәйтергә, "Адәмнәр" повестен тирәнтен анализлап, әдәбият тарихына кайтарырга. һ. Такташ шигъри әсәрләренең кульъязма вариантларын да искә алу, драматургиясенә һәм прозасына игътибарны көчәйтү сорала.

Инде аларның моңа кадәр киң мәгълүм әсәрләренә килгәндә, аларны хәзер бигрәк тә идея, мәгънә ягыннан еш кына яңартып аңлату сорала. Мисал өчен Г. Ибраһимовның революциядән соңгы яшәешне чагылдырган "Кызыл чәчәкләр" повестена һәм "Тирән тамырлар" романына яңартылган анализ һәм бәя бирергә, "Татар хатыны ниләр күрми" белән "Безнең көннәр" романнарының икенче вариантларын беренчеләре белән чагыштырып анализларга кирәк. Мондый гамәлләр әдипнең совет чорындагы иҗатына карашларыбызның шактый яңаруына китерәчәк.

Такташка килсәк, барыннан да элек, аның поэзиясенең мәгънәви асылын тулырак ачу сорала. Мәгълүм ки, элегрәк елларда бу мәсьәләне шагыйрьнең революция һәм социализм тудырган яңа матурлык җырчысы булуы рәвешендә шәрехләү киң урын алган иде. Әлбәттә, совет чорында иҗат иткән һәр әдиптәге кебек, Такташта да бу мәгънә бар. Әмма трибун шагыйрьнең шигъри куәте, зурлыгы шунда ки: ул бер үк вакытта үзе дан җырлаган җәмгыятьнең тәнкыйтьчесе дә була алган. Шунлыктан хәзер шагыйрьнең яңа системага тәнкыйтьчел карашын өйрәнүгә дикъкатьне көчәйтергә кирәк. Бу яктан аның драматургиясе дә игътибарга лаеклы.

Ибраһимов белән Такташ иҗатын фәнни объектив өйрәнергә алынганда тагын бер мәсьәлә игътибарны сорый: аларның кайбер әсәрләрендә дөнья әдәбиятында күптән күзәтелә торган бер күренеш күзаллана. Ул түбәндәгедән гыйбарәт. Дөнья әдәбияты классикларының кайберләрендә аларның шәхси иҗтимагый-сәяси карашлары белән әсәрләрендә чагылган карашлар арасында тәңгәллек булмый. Ягъни талантлары аларга иҗатларында дөньяга киңрәк карашлы булырга булыша. Бу күренешкә классик мисаллар итеп гадәттә француз әдәбиятыннан Бальзак белән Стендальне, рус әдипләреннән Достоевкий белән Толстойны китерәләр. Әлеге күренеш Г. Ибраһимовның "Кызыл чәчәкләр" повестенда, һ. Такташның "Гасырлар һәм минутлар" поэмасында да күзаллана. Бу әсәрләрендә әдипләр үз чорына хас карашларны чагылдырырга алыналар, әмма аларның таланты тудырган мәгънә автор ниятенә туры килеп бетми яки аны кире кага.

Г. Ибраһимов һәм һ. Такташ мирасын шул рәвешле өйрәнү, гомумән алганда совет чоры әдәбиятын яңартып тикшерүдә үзенә бер методологик ачкыч ролен дә үтәргә мөмкин.

Узган гасырның алтмышынчы елларыннан башланган әдәби чорны фәнни нигездә өйрәнгәндә исә бу яңарышның нигездә әдәбиятның революциягә кадәр формалашкан милли вазыйфасына әйләнеп кайтуы, ягъни милләт яшәеше һәм язмышы мәсьәләләренә йөз тота башлавын истә тоту сорала.

Әдипләр, милләт яшәешенә еш кына тәнкыйтьчел-аналитик позициядән карап, андагы борчу уята торган мәсьәләләргә яки күренешләргә дикъкатьләрен көчәйтәләр. Милләт яшәешенең мөһим рухи-әхлакый чыганаклары яки нигезләре рәвешендә халык тарихына, авылга, күптөрле мираска, табигатькә, буыннар арасындагы мөнәсәбәткә, гаиләгә һ. б. игътибар арта. Боларның барысын милли рухта яктыртырга алыну тора-бара әдәбиятыбызның эчтәлегендә дә, формасында да үзгәрешләр тудыра. Хәзергә бу үзгәрешләрнең эчтәлек ягына дикъкать ителә. Алга таба әдәбиятның эчтәлеге белән формасын тыгыз бәйләнештә карап, һәр ике өлкәдә дә барган үзгәрешләрне бердәй игътибар белән өйрәнү сорала. Мондый яңарышның алга таба тагын да нәтиҗәлерәк төс алуына ирешү өчен аны беренче чиратта фәнни-теоретик планда өйрәнергә кирәк. Ягъни әдәбиятта миллиләшүгә нигезләнгән яңарышның нинди ысул, стиль һәм жанр чаралары ярдәмендә гамәлгә ашырылуын ачыклау мөһим. Социалистик реализмнан читләшә бару, табигый, аның урынына башка төр иҗат ысулларын куллануны сорый. Шуннан: "Хәзерге әдипләребез нинди ысуллар белән иҗат итәләр соң?" дигән сорау туа. Хәзергә бер фикерне ачык әйтергә мөмкин: иҗат ирегенә киң юл ачылган безнең заманда совет чорындагыча бертөрлелек була алмый.

Әдәбиятыбызның үз милли асылына әйләнеп кайта башлавы әдипләрнең сәнгатьчә эзләнүләренә дә тәэсир итә, ягъни анда милли башлангыч көчәя. Ачыграк әйтсәк, бу өлкәдә халыкның күптөрле мирасына: фикерләү рәвешенә, гореф-гадәтләренә, йола-инануларына, миф һәм фольклор традицияләренә һ. б. мөрәҗәгать итү күзәтелә. Болар барысы әдәбиятның стильләр һәм жанрлар системасында да чагылыш таба.

Әдәбиятыбызның шушы поэтик дөньясын һәм, гомумән, яшәү даирәсен тулырак күзаллау ягыннан тарихи ватаннарыннан читтә яшәгән әдипләребезнең иҗаты аерым игътибарга лаеклы. Бик әһәмиятле булган бу факторга моңа кадәр без көндәлек тормышта да һәм фән өлкәсендә дә рәтләп игътибар итмәдек. Хәзер исә—әдәбиятыбызның тулы объектив тарихын тудырырга алынганда һәм татарның милли бердәмлеге белән бөтенлеге өчен көрәш көчәйгәндә—әлеге факторга игътибарны бермә-бер көчәйтергә, конкретрак әйтсәк, XX гасыр татар әдәбият тарихын яңартып язганда, мисал өчен, А. Таһиров, С. Кудаш, Н. Нәҗми, Ә. Атнабаев, Я. Зәнкиев, Б. Сөләйманов иҗатларына тиешле урын бирергә кирәк булачак.

Инде югарыда язылганнарны гомумиләштереп әйтергә алынсак, күпгасырлык әдәби тарихыбызда гына түгел, гомумән, бөтен хәятыбызда үзгә бер урын тоткан XX йөз татар әдәбиятын яңартып өйрәнүнең асыл максаты—интеграция процесслары бермә-бер көчәйгән бу дәвердә әдәбиятыбызның милләт яшәешен һәм язмышын чагылдыру белән бәйләнгән үз йөзен һәм үз юлын тулырак та, тирәнрәк тә ачуга кайтып кала. Шул нигездә узган гасыр әдәбиятыбызның төрле иҗтимагый-сәяси шартларда да үзенең бөтенлеген саклап кала алуы ачыкланачак. Монысы исә әдәбиятны татар дөньясының бердәмлеге өчен хәзерге көрәштә җитди коралга әверелдерә.

# Адлер Тимергалин

## МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ЛӘКАБ*** *г.* – **1.**Кушамат; кешенең хөрмәтле исеме, титулы, гонваны – *мәсәлән:* Гыйззәтдин (диннең хөрмәтлесе). **2.**Яшерен имза, псевдоним, фамилия. **3.**Гыйльми дәрәҗә.

Ләкаб бирү мәсьәләсенең дәүләт төзелеше өчен мөһим бер эш булуы турында солтан Малик-шаһның атаклы вәзире Низам әл-Мөлек түбәндәгеләрне яза: "Әмирләрнең ләкабләре түбәндәгечә: Сәйф əд-дәүләт – Дәүләт кылычы, Әмин əд-дәүләт – Дәүләт сакчысы кебекләр. Хужа, амид һәм хөкүмәт кешеләренең ләкабләре түбәндәгеләр: Амид əд-дәүләт – Дәүләт таянычы, Заһир әл-мөлек – Дәүләт ярдәмчесе, Киввам әл-мөлек – Дәүләт терәге һәм шуның кебек башкалар." "Саманидларда мондый ләкабләр булган: Шаһиншаһ – Патшалар патшасы, Әмир-и-садид – Туры сүз сөйләүче һәм эш йөртүче әмир, Әмир-и-гадел – Гадел әмир".

"Кадиларга, имамнарга һәм галимнәргә мондый ләкаблар бирелгән: Мәҗ əд-дин – Иман даны, Шәрәф әл-Ислам – Ислам шәрәфе, Сәйф әс-сөннәт – Сөннәт кылычы, Зин әш-шәригать – Шәригать зиннәте, Фәхр әл-голәмә – Галимнәр даны һәм башка шуның кебекләр."

Күплек саны шәкеле-*әлкаб.*

Тагын кара: ***ГАРӘПЧӘ ТУЛЫ ИСЕМ.***

***ЛӘНГӘР*** *ф.* – Якорь. "Ләнгәр" термины һинд-европа телләрендәге анкер (якорь) сүзенә барып тоташа. Мәс., Каспий диңгезе буендагы (Әзәрбайҗан) *Ленкорань* – "ләнгәр (якорь) сала торган урын". Ләкин Урта Азиядә, Иранда, Әфганстанда, Синцзянда (Кытайдагы Көнчыгыш Төркестан) ләнгәр атамасы йөрткән уннарча торак пунктлар бар һәм аларның мәгънәсе бик төрле – "мәнзил", "кәрван-сарай", "монастырь", "ям станциясе", "якорь салу тукталышы", "зират" һ.б. *//* ***Көймә ләнгәре.***

***ЛУАТА*** *г.* – Ирләрнең ирләр белән якынлык кылуы. Ул иң яман фәхишлек, адәмне һәлакәткә илтә торган гөнаһ булып исәпләнә. Лут пәйгамбәрнең кауме шундый гөнаһка баткач, ул өммәтен һәлакәттән йолып калырга тырышып карый, әмма каумдәшләре аның сүзенә колак салмыйлар. Шуннан соң Аллаһу гөнакярларның барчасын һәлак итә. Бу хакта "Әгъраф" сүрәсенең 80 нче аятендә сөйләнә.

"Лут кауменең эшен кылучыны да, кылдыручыны да үтерегез,"-дигән риваят бар (Әбү Даудтан килеп ирешкән).

***МАГАЗИН*** *г.* – Сәүдә йорты, кибет; амбар, келәт. Бу сүзнең башка мәгънәләре дә бар (*магазинлы мылтык,* физикада – *каршылыклар магазины* һ.б.). "Магазин" сүзе гарәп теленнән (*"махәзин"/"мәхзән", "мәгазә"*) француз һәм немец телләре аша рус теленә кереп үзләшкән (XVIII гасыр башы) һәм хәзерге формасында татар теленә рус теленнән алынган. Халык телендәге *мөгәҗи, мөгәҗин* формасындагы әйтелешләр дә шуны раслый, чөнки рус телендә дә бу сүз башта *магазейн, магазея, магазей* рәвешендә йөргән. Электә Саратов өлкәсенең камышлы сөйләшендә "магази – авыл халкы тарафыннан гомуми фондка салынган игенне саклау урыны, келәт". *// -Олы Ширданга*

---

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2004 елның 1нче санында.*

*чыга торган күпер җимерелгән, мөгәҗи келәтенең түбәсеннән су үтә, каравыл өенең миче җимерелгән.* М.Гали.

Тагын кара: ***МӘГАЗӘ.***

***МАКСУРА*** *г.* — Шәһәрнең үзәк мәчетендә *михраб* һәм *мөнбәр* белән янәшәдә бизәкле агач рәшәткә белән әйләндереп алынган урын. Хакимият башлыклары өчен билгеләнгән булган.

***МАЛ САМИТ*** *г.* — "Саңгырау мал", "телсез" мал, җансыз мал; алтын-көмеш.

***МАЛАЙ*** — Хәзерге татар телендә — ир бала, угыл, олан. Татар теленең кайбер сөйләшләрендә (Тау ягы, мордва-каратай, Алабуга керәшеннәре) ир бала булса да, кыз бала булса да малай диләр (***ир малай, кыз малай***). Ләкин татар кызлары (хәтта хатыннары да) еш кына бер-берсенә *"малай, малакаем"* дип мөрәҗәгать итәләр (ахирәтем, кәбәм дигән кебек).

"Малай" сүзе төрки сүз түгел, ул татарга рус теленнән кергән. Вл.Даль сүзлегендә: "Малый — парень, молодец, молодой человек; слуга, прислужник." Р.Әхмәтьянов "малай" сүзенең ("лакей" мәгънәсендә) үзбәк теленә рус сәүдәгәрләре теленнән кергәнлеген искәртә (мәс., үзбәктә *"империализм малайлары"*-лакеи империализма, ә бездә монда "ялчылары" сүзе урынлы). Электә сүзнең бу мәгънәсе татарда да актив булган. М.Горькийның "В людях" повесте татар теленә "Малайлыкта" дип тәрҗемә ителгән. "Малай-шалай" дигән җыйма сүзнең дә икенче өлеше русча "шалава", "шалопай" кебек сүзләргә барып тоташа. Телебездә саф төрки сүзләр булуга да карамастан, рус сүзенең шушылай актив кулланылуын, тәмам үзләшеп бетүен ничек аңлатырга? Казан ханлыгы җимерелеп, безнең төбәккә күпләп руслар күчеп утыра башлагач, күрәмсең, җиңүче милләт вәкилләре җирле халык вәкилләренә кимсетебрәк: "Малый!" дип кенә дәшкәннәр булса кирәк. Тел даирәсендә дә көч җиңеп чыккан.

"Малай" сүзенең тарихы Минзәлә-Сарман яклары сөйләшендә әле дә очрый торган "слушый" сүзен искә төшерә. "Тыңла, ишет" мәгънәсендәге бу рус сүзен дә ("слушай!") безнең халык үзе белән югарыдан торып сөйләшкән элекке рус түрәләре һәм аларга ияргән гади мужиклар авызыннан ишеткән булыр.

***МАМӘНӘТ*** — Мамонт. *Мамонт* атамасы рус теленә тунгус яки ненец телендәге *туфрак ашаучы, аю* мәгънәсендәге "мамонт" сүзеннән алынган дип уйлыйлар. Ләкин иске татар китапларындагы *мамәвәт* сүзенең ничек барлыкка килүе миңа ачык түгел. "Идегәй" дастанында мамонт теше мәгънәсендә *киртеш* сүзе очрый, ягъни *кир* — мамонт.

Тагын кара: ***КИР.***

***МАНКОРТ, МАҢКОРТ*** — Беренче тапкыр кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов кулланган сүз. Туган илен, ата-бабаларын, газиз анасын оныткан һәм дошманнарның телсез колына әверелгән бичара мәгънәсендә. Африканнардагы ышану буенча каһин тарафыннан җаныннан мәхрүм ителгән һәм аның колына әйләнгән *зомби* төшенчәсенә дә туры килә. Манкорт ясау өчен әсирләрнең башын чи каеш белән коршаулап бәйләгәннәр дә богауланган килеш кешене кояшта калдырганнар. Каеш кипкән саен баш чүмечен һәм баш миен кыса барган һәм шушындый газаплы операциядән соң кеше үзенең хәтерен җуя торган булган. Баш чүмеченә металл коршау кигезеп, шөреп ярдәмендә кысу алымын СССР да Сталин чорында сәяси гаепләнүчеләрне газаплау өчен дә кулланганнар. Хәер, Сталин үзе дә миһырбанлы җаннан мәхрүм ителгән зомби булган дигән фикер бар.

Америка һиндусларында (индеецларда, индианнарда) дошманның муенын чи каеш белән кысып бәйләп, кояшта калдыру җәзасы да булган.

Хәзерге вакытта манкорт төшенчәсен үз ихтыяры белән дошманга сатылган бәндә мәгънәсендә еш кулланалар, ләкин моның өчен эвенк телендәге тирән мәгънәле "лючеткан" ("бәләкәй урыс", ягъни урыска тагылып, койрык булып йөрүче кеше мәгънәсендә) сүзе кулайрак икәнлеген әйтеп китик.

***МАНТЫЙК*** *г.* — **1.** Нотык. **2.** *Гыйльмул мантыйк* — логика гыйлеме, фәне; схоластика. Гомумән, хәзерге вакытта мантыйк сүзен *логика* мәгънәсендә куллануны популяр әдәбият белән чикләү тиеш, чөнки логика фәне терминнарының бүгенге тирәнлеген һәм нечкәлеген әлеге гарәби алынма сүз белән колачлап бетерү мөмкин булмаячак. // *Мантыйк ноктаи нәзарыннан* — мантыйк күзлегеннән, логика күзлегеннән.

Элекке мәдрәсәләрдә мантыйк дәреслегенең беренче кисәге *"Исагуҗи"* дип, икенче кисәге *"Сәләм"* дип, дәреслеккә өстәмә аңлатмалар китабы *"Шәмсия"* дип аталган.

***МАНАРА*** *г.* — Ут (яктылык) кабызыла торган урын, маяк мәгънәсендәге *мәнара-т-ун* сүзеннән. *Нур* сүзе дә шул тамырдан. Чаг.: *Бөрҗүн, Калә, Маш.* Иске чыганакларда "манара" мәгънәсендә *"илекмән"* сүзе дә очрый.

Манара — мәчет өстендәге яки мәчет янындагы биек корылма, аннан торып *мөәззин* азан әйтә. Багдад янындагы Самаррада IX гасыр урталарында махсус төзелгән манара иң беренчеләрдән санала. Ул 52 м биеклектәге кисек конустан гыйбарәт. Манара тирәли 1,5 м киңлектәге спираль пандус уза. XIII гасырга кадәр мәчетләрнең бер генә манарасы булган һәм ул, кагыйдә буларак, мәчет бинасыннан аерым торган (дүрт манаралы Мәккә мәчете бу исәпкә керми). Баштарак манараларның стандарт үрнәкләре, өлгеләре дә булмаган әле. Соңра берничә манаралы һәм гөмбәзле мәчетләр төзелә башлый. Шунысын да әйтергә кирәк, беренче чорларда манаралар мәчет өстендә генә түгел, төрбә-мавзолейлар, ханәкалар (дәрвишханәләр), мәдрәсәләр өстендә дә калкып торганнар. Күккә омтылышлы биек һәм нәзек манаралар Кече Азиядә госманнар чорында корылган. Борынгы Болгар шәһәрендә җәмигъ мәчетнең дүрт манаралы, ә Казан ханлыгы чорында Казандагы Кол Шәриф мәчетенең сигез манаралы булуы турында мәгълүматлар бар. Истанбулдагы Әхмәд солтан мәчетен алты манаралы итеп төзегәннәр һәм хәтта шуның аркасында Истанбул белән Мәккә арасында низаг чыга язган дип сөйлиләр. Чыннан да, Мәккәдәге Изге мәчетнең биш кенә манарасы булганда Истанбулдагы яңа мәчетнең алты манаралы булуы бернинди канунга да сыймаган. Ахырда Әхмәд солтан бирелергә мәҗбүр булган: дөрес, ул яңа мәчетнең артык ике манарасын җимертмәгән, бәлки үз хисабына Мәккә мәчетенә өстәмә рәвештә ике манара төзеткән.

Берничә манара булу, әлбәттә, азан әйтү өчен уңайлы түгел, алар мәгълүм дәрәҗәдә бер-берсенә комачаулыйлар, аның каравы монда Ислам хакимлек иткәнлеген әллә кайлардан күрсәтеп торалар. Шул ук вакытта ян-яктагы манаралар диварларга терәк (контрфорс) булып та хезмәт иткән.

Манараларның формасына килгәндә, Испаниядә һәм Төньяк Африкада аларның аркылы кисеме дүрткел, Төркиядә түгәрәк, ә очы конуссыман, Мисырда түгәрәк һәм дүрткел формалар берләштерелә, Һиндстанда исә манара кайчак сигез кырлы булып, очында гөмбәз ясала. Кайчагында мәчет манарасы берничә башлы итеп төзелә. Мәсәлән, Әл-Әзһәр мәчетенең бер манарасы янәшә ике гөмбәзле, тагын бер манарасының башында биш гөмбәз ясалган.

Рус архитектурасындагы чиркәү гөмбәзләрендә шәрык йогынтысы аермачык сизелә. Ләкин шунысын да әйтеп китик: XVII гасыр рус руханилары аерым культ храмнарының очлаеп күккә сузылган булуына каршы чыкканнар, чөнки, янәсе, алар татар манараларына охшыйлар.

Манараның очына куелган ай урагы *маһичә* дип атала. Каһирәдә мәчет манараларына беренче маһичәләр мәмлүкләр чорында (XIII гасыр уртасы-XVI гасыр башы) куелган.

Гадәттә манараның уртасындарак, аның әйләнәсендә азанчы өчен бер яки берничә балкон-галерея эшләнгән була, ул *мәәзәнә* яки *шәрәфә* дип атала (бездә *керфек* сүзе булган). Кайчагында манараның үзен дә мәәзәнә диләр. Манарада мәәзәнә булмаган очракта мөәззин азанны тәрәзәдән (*шәрәфә*) әйтә.

Электә манара эчендәге баскычны төзү эше үзе бер сәнгать булып исәпләнгән. Мәсәлән, XVI гасырда төрек архитекторы Синан Стамбулдагы Сөләймания мәчете манарасы эчендә ике баскыч төзегән һәм бу баскычлардан һәркайсы үз мәәзәнәсенә менүче мөәззиннәр бер-берсен очратмаганнар.

Азан әйтүдән тыш, манара күзәтү өчен дә хезмәт иткән. Бохарадагы Кәлян

манарасыннан үлемгә хөкем ителгәннәрне ыргыта торган булганнар (икенче төрле ул "Үлем манарасы" дип тә аталган).

Хәзерге вакытта Мароккодагы Касабланкада Олуг Хәсән II мәчетенең манарасы дөньяда иң биек манара булып исәпләнә: аның биеклеге 200 метр, ә мәчетнең гыйбадәт залы 25 000 кешене сыйдыра.

Мөселман илләрендә булып кайткан көнбатыш сәяхәтчеләре күккә омтылышлы мәчет манараларын еш кына "күккә яза торган очлы каләмнәр" һәм менә-менә очып китәргә торган космик ракеталар белән чагыштыралар.

***МАТДӘ (МАДДӘ)*** *г.* — **1**.Әйбер, нәрсә, әйберлек; матдә. Гаяз Исхакый искәргәнчә, электә шәкертләр өйдән килгән күчтәнәчне *маддә* дип йөрткәннәр. 2.Әйбернең төбе, маясы, материалы. 3."Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге"ндә бу сүзнең фәлсәфи мәгънәсе — материя (кеше аңыннан бәйсез рәвештә яши һәм аның аңында чагыла торган объектив чынбарлык) дип бирелсә дә, бүгенге физикада һәм, гомумән, философиядә материя белән матдәне катгый рәвештә аерырга туры килә, чөнки дөньядагы материя ике халәттә — *матдә* хәлендә һәм *кыр, дулкын* халәтендә булырга мөмкин. Мәсәлән, яктылык — материаль нәрсә, ләкин ул матдә түгел. Шулай да иске чыганакларда бу сүз материя мәгънәсендә кулланылгалый: мәсәлән, Ф.Әмирханда "*гали матдәләр*" — югары материяләр. 4.Аерым бүлек, пункт, параграф, статья. Хәзерге вакытта сүзнең бу мәгънәсе, язылыш ягыннан да аерылып, *маддә* рәвешендә кулланыла.

***МАХМАЛ, МӘХМӘЛ*** *г.* — Киң мәгънәсендә — дөягә урнаштырылган паланкин, ягъни өсте ябулы тәхет, анда бай сәфәрчеләр, гадәттә хатын-кызлар утырган. 1266 елдан алып 1652 елга кадәр кайбер мөселман илләренең идарәчеләре үз илләренең хаҗга баручы төп кәрваннары белән Мәккәгә зиннәтле мәхмәл җибәрә торган булганнар. Зиннәтле буш мәхмәл изге урыннарга — Мәккә белән Мәдинәгә сәяси химаячелекнең символы булып исәпләнгән. Мәхмәл махсус дөягә яки вагонга урнаштырылган һәм кәрванның үзәге булган. Мәккәгә килгәч, башта аны шәһәрнең күренекле җиренә куйганнар, аннары Гарәфәт тавы янына китергәннәр. Мәхмәлне хаҗилар кәрваны белән алып кайту үзе бер бәйрәмгә әверелгән.

// *Мәхмәл шәриф.*

***МАҺИЧӘ*** *г.* — Мәчет манарасындагы һәм байрак очындагы ай. Каһирәдә мәчет манараларына беренче маһичәләр мәмлүкләр чорында куелган.

***МӘГЪҖУН Г.*** — **1**.Дару (үлән) төнәтмәсе; төрле наркотик матдәләрдән торган препарат (әфьюн). Ф.Әмирханның "Фәтхулла хәзрәт" исемле тәмамланмаган фантастик хикәясендә мәгъҗүн препаратына бирелгән билгеләмә игътибарга лаек: "Мәгъҗүн — татар искеләренең исерер өчен истигъмаль иткәннәре, әфьюн вә башка берничә төрле чүп-чардан тәркип ителгән, адәмнең миенә зарар бирә торган бер нәүгы "дәва"дыр. Иске заманнарда Бохари муллалар һәм ишаннар шушы бәдбәхет нәрсә белән гомерләре буенча исереп йөриләр иде." **2**.Измә, паста (теш пастасы, томат пастасы h.б.).

***МӘГЪРӘКӘ*** *г.* — Сугыш урыны (гарәп телендәге төп мәгънәсе); халык җыены, хозур урыны, сабантуй. Бу сүз татар теленә *мәрәкә* рәвешендә ("күңел ачу" мәгънәсендә) кергән. Охшаш сүз чуаш, мари, удмурт телләрендә дә бар. Кайбер этимологлар рус телендәге "скоморох" сүзен дә гарәпчә *сахир-мәрәкә* (сихерче-мәзәкче) сүзеннән чыгаралар. // *Мәгърәкә кичәсе* — күңел ачу (хозур) кичәсе. Электә мәдрәсәләрдә атнакич үткәрелгән уен кичәсе. Уеннарда шәкертләрдән җырчылар, курайчылар, кубыз уйнаучылар, биючеләр, мәзәкчеләр катнашкан. Уеннар тәмам булгач, өлкән шәкертләр үзләре акча салышып алган клиндер, вареньелар белән чәй эчеп сыйланганнар. Кичәдә мулла, мөдәррис, хәлфәләр катнашмаган, ләкин нәшәргый уеннарга юл куелмаган (Исмәгыйль Рәми буенча). Гаяз Исхакыйның шулай ук Казан мәдрәсәләрендә күргәннәренә таянып язылган "Мулла бабай" романында мондый хозур кичәсе "калпания" (компания) дип аталган, бу "калпания"ләрдә хәлфәләр дә катнашкан, читтән скрипкәче дә чакырганнар.

***МӘГЪРИБ*** *г.* – **1**.Кояш бата торган урын яки вакыт. "Әр-Рәхман" сүрәсенең 17 нче аятеннән күренгәнчә, "Аллаһ ике мәшрикънең һәм ике мәгърибнең раббысыдыр". *"Дәрәҗә"* сүрәсендә дә мәшрикъләр һәм мәгърибләр төшенчәсе бар (70:40). Моны *җәйге кояш торгынлыгы* һәм *кышкы кояш торгынлыгы* көннәрендә кояшның чыгу һәм бату нокталары дип аңларга була. Ягъни Рәсүлулла заманнарында ук гарәпләргә иң озын һәм иң кыска көннәрдә кояшның күктәге хәрәкәте ачык билгеле булган. Бу факт турында шул ук "әр-Рәхман" сүрәсендә: "Кояш вә ай үзләренең юлларында бер билгеле үлчәү белән йөрүчеләрдер", – диелгән (55:5; Ногмани тәфсире буенча). **2**.Гадәттә көнбатыш Африканың төньяк-көнбатыш өлешен (Алжир, Тунис, Марокконы, ягъни Гарәбстан ярымутравыннан көнбатыштагы кара тәнле кешеләр илен) мәгъриб дип йөрткәннәр. Кыскасы, төптә мәгъриб сүзе *мөселман көнбатышы* мәгънәсенә генә ия, ләкин хәзер аны киңрәк мәгънәдә куллану күзәтелә.

*// Мәгъриб әл-шәмс* – кояш байый торган җир.

*Мәгъриб*-нең күплек саны шәкеле – *мәгариб*.

***МӘГЪФИРӘТ ДИҢГЕЗЕ*** – Коръәннән соңгы хикәяләргә караганда, Хак Тәгалә хикмәте белән пәйда булган нур икегә бүленеп, оҗмахта шуның бер кисәгеннән "Мәгъфирәт диңгезе", икенчесеннән "Рәхмәт диңгезе" барлыкка килгән. Фәрит Яхин, Ә.Бижанның "Әнварел-гашыйкин" хезмәтенә таянып, бу диңгезнең исемен "Ярлыкау яки Шәфкать диңгезе" дип дөрес аңлата (ләкин "Иман" китабында (1993) да, "Пәйгамбәрләр. Фәрештәләр. Ахирәт" китабында (1999) да диңгезнең исеме дөрес язылмаган, "Мәгърифәт" диңгезе дип бирелгән һәм мәгънә буталган).

***МӘҖД*** *г.* – Дан, абруй. *// Гакылны рамлап эштән чыгаручы, дин белән уйнап бозып бетерүче, гыйлем белән сугышып, аны харап итүче, мәҗд белән тартышып, аны вәйран итүче, аның урынына тәмҗидне куючы – һәммәсе истибдад.* Г.Бубый.

Мәҗднең берничә төре бар:

1.*Мәҗде кирам* – малны мәкатиб вә мәдарис юлына вә гомумән нәфге гамга сарыф итү белән буладыр.

2.*Мәҗде фазыйләт* – гыйлемне җәмгыяте инсания файдасына сарыф белән буладыр.

3.*Мәҗде әлмәбналә*-хаклыкка ярдәм вә гадәләтне саклау юлында нәфесен мәшәкать вә куркынычларга гарыз белән буладыр. Мәҗднең иң югары дәрәҗәсе шушы (Г.Бубый буенча).

***МӘҖУСИ*** *г.* – **1**.Потка, төрле сыннарга, утка һ.б. га табынучы. Бу сүз Европа һәм рус телләренә "маг" рәвешендә кереп үзләшкән. "Мәҗүс" сүзе Коръәндә бер тапкыр "маглар" мәгънәсендә очрый һәм утка табынучыларны белдерә. **2**.Яңа дәвергә кадәр II-I меңьеллыклар чигендә *Заратуштра (Зороастра пәйгамбәр)* нигез салган борынгы *зәрдәшт* дине тарафдары-борынгы фарсы *магу* сүзеннән.

***МӘЙСИР*** *г.* – Уклар белән отышлы (комарлы) уен, җирәбә салу. Гарәпләр арасында киң таралган юрау, бу вакытта очсыз һәм койрыксыз уклар кулланганнар (гадәттә ачлык вакытларында уйнаганнар). Уктагы тамга туралган дөя түшкәсенең тегеяки бу кисәген күрсәткән. Мәҗүси потханәләрдә эшләүче махсус каһиннәр түләү хакына шундый тамгалы укларны тартып чыгара торган булганнар. Отыш фәкыйрьләр файдасына китә торган булганга, мәйсир күркәм эш булып та саналган. Ләкин уйнаучылар, мавыгып китеп, бөтен малларын оттырып бетергәнгә күрә, бу эш Коръән-Кәримдә хәрәм кылынган ("Маидә" сүрәсе, 5: 90,91).

Русча чыганакларда: *маисир, майсир.*

***МӘКНАТАСИЯ*** – Магнетизм. Бу сүз татар телендә "бер-береңә тартылу" мәгънәсендә еш кулланылган. *// Куәи мәкнатасия гыйшкия* – гыйшыкның магнит көче.

***МӘКРУҺЛӘР*** *гт.* – "Көчләп чукындырылып та яисә рәсми документларда чукындырылган дип теркәлгән, әмма үз диннәренә тугрылыклы калган мөселманнар (рус телендә "отпавшие" гыйбарәсе белән мәгълүм)." (Аңлатма Гайнетдин Әхмәров

турындагы тарихи-документаль җыентыктан. Аннары Гаяз Исхакыйның "Зөләйха" исемле пьсасы башта "Мәкруһ яхуд Зөләйха" дип аталганлыгы мәгълүм). Мәкруһләрнең хәле гадәттән тыш мөшкел булган. 1863 елда Чистайга патша варисы Александр III килгәч, Тубылгы атавы карьясендә яшәүче мәкруһләрнең варис хәзрәтләренә язган шикаятендә мондый сүзләр бар: "Без һичбер вакытта насари динендә булганыбыз юк. Бала вакытыбыздан бирле дине Исламда торабыз, безнең бабаларыбыздан кем вә кай вакытта отпавший дип санала башлагандыр, безгә мәгълүм түгел. Безнең бу эшләребез, һич өзелмәенчә, бик күптән бирле тартылып килә, без һич гаепсез җәзаланабыз, мондагы начальникларыбызны төрлечә кысалар, читкә хезмәткә барырга безгә язу (билет) бирмиләр." Хакимиятләр мәкруһләрнең мөселманча никахын танымаганнар, хәтта балаларына аналарының исеме буенча "Фатыймин", "Гайшин" кебек фамилияләр такканнар. Күренекле татар шагыйре Хәсән Туфан, мәсәлән, инде XX гасыр башында, әнисе исеме буенча, "Гульзизин" фамилиясендә йөрергә мәҗбүр булган.

*//"Казан мөхбире"нең 72 нче номерыннан Чистай өязендә Тубылгы атавы карьясенең мәкруһләренә мөселман булып ислам дәфтәрләренә язылырга рөхсәт бирелгәне мәгълүм булды.* Г.Әхмәрев. (1906 ел турында сүз бара).

Тагын кара: ***СОЛЫЛЫ БОРАЙЛАР.***

***МӘМЛҮК*** *г.* – Милекләнгән, берәүнең милке булган кеше мәгънәсендә. *Габде* һәм *голям* сүзләренең синонимы, ягъни *кол*. Баштарак, тумыштан кол булганнардан аерып, сатып алынган колларны шулай атаганнар. Коръәндә бу төшенчә бер урында *габде мәмлүк* рәвешендә очрый (16:75/77). Гадәттә сугышчы колларны мәмлүк дип йөрткәннәр, алар гаскәри хезмәттә зур дәрәҗәләргә дә ирешкәннәр, кайчагында хәтта дәүләт хакимиятен яулап алганнар (Мисырда 1250 елда *Айбек солтан*). 1250-1517 еллар арасында мәмлүкләр Мисыр һәм Сүрия дәүләтләре белән идарә итәләр. Мәмлүкләр династиясеннән солтан *Заһир Сәйфетдин Татар* (1421) игътибарны җәлеп итә. Күбесенчә мәмлүкләр төркиләрдән һәм чиркәсләрдән булган. Алар гадәти төрки телдә сөйләшкәннәр. Мисырны французлар яулап алганнан соң, мәмлүк гвардиясе Наполеон I гаскәренә дә кертелә һәм 1812 елда Россия белән сугышта катнаша. Ә Мисырның үзендә мәмлүкләр Мисыр пашасы Мөхәммәд Али тарафыннан 1811 елда кырып бетерелгәннәр.

***МӘНҖӘНИКЪ*** *г.* – Дошман кальгаларына зур таш ату коралы, катапульта. Бу коралны Пәйгамбәр гаскәре дә кулланган. Болгар йортының төп шәһәрләреннән Биләр харабәләрен казыганда археологлар шушындый таш ату коралы детальләрен тапканнар. Чыңгыз хан гаскәрендә дә мәнҗәникълар кулланылган. "Элекке төрки гаскәрләрдә авыр чана сыман станлы мәнҗәникъларны еш кына җирдән сөйрәтеп күчереп йөрткәннәр". "Сугышлар тәмамлангач, мәнҗәникъларны түнкәреп, калак урынына төрән куеп, сабанга "әйләндергәннәр". (Р.Әхмәтьянов.) Ихтимал, "сабан" сүзе башта "катапульта"ны белдергәндер (төрек телендә *сапан* сүзенең "катапульта, мәнҗәникъ; праща, балалар рогаткасы" мәгънәләре дә бар.). Хәер, татар телендә дә "Йөз каргага бер сабан ташы" дигән мәкальдә таш ата торган "сабан" – мәнҗәникъ күздә тотыла (Нәкый Исәнбәт "Сабан ташы – рогатка" дип искәртеп китә). Кыскасы, "Кылычтан сабан ясыйк" ("Перекуем мечи на орала") дигән сүзләр тарихи чынбарлыкны чагылдыралар икән.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# "БУ КИТАП ХАН ДОГАСЫ БЕРЛӘ ТӘМАМ..."


Казан ханлыгы чорында яшәп иҗат иткән бөек татар шагыйре Мөхәммәдъярның язган "Нуры содур" поэмасы (1541)—әдәби җәүһәрләребезнең иң кыйммәтләләреннән санала.

Мәгълүм ки, әдәбият галиме Шакир Абилов "Нуры содур" әсәренең тәнкыйди текстын әзерләп, 1997 елда аны аерым китап итеп бастырып чыгарды. Ул китапта Мөхәммәдъярның "Нуры содур" поэмасы кульязмаларының фәндә билгеле булган 7 нөсхәсе турында кыскача мәгълүмат та бирелгән иде. Аларның өчесе—С.-Петербургтагы Көнчыгышны өйрәнү институты фондында; берсе—Казан дәүләт университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә; берсе—Башкортстан Милли китапханәсендә; берсе—Нәкый Исәнбәт архивында; берсе—тарихчы Дамир Гарифуллин архивында сакланулары әйтелгән.

Поэманың Ш.Абилов тарафыннан файдаланылмаган тагын ике кульязмасы Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсендә саклана. Шуларның берсе—1978 елда Әгерҗе районының Яңа Аккуҗа авылында табылган XVIII гасыр күчермәсе, икенчесе 1994 елда Әтнә районының Олы Мәңгәр авылында табылган XVII гасыр башы кульязмасы. Икесен дә археограф галим Марсель Әхмәтҗанов тапкан. Шул рәвешчә, XX гасырның ахырына кадәр фәндә "Нуры содур" әсәре тугыз кульязма күчермәдә билгеле булып килде.

1999 елда әлеге әдәби ядкярнең тагын бер нөсхәсен табуыбыз турында матбугатта хәбәр бирелгән иде инде *(Казан утлары.—2002.— № 3.—Б. 128)*. XVIII гасыр башында, моннан 290 еллар әүвәл күчерелгән ул ядкяр Кукмара районыннан табып алынды һәм хәзерге вакытта Татарстан Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

Башкалабыз Казан шәһәренең 1000 еллык бәйрәменә тагын бер куанычлы рухи бүләк әзерләнде—"Нуры содур"ның янә бер кульязма күчермәсе табылды. Поэма тексты язылган бу кечкенә күләмле дәфтәр Удмуртия Республикасының башкаласы Ижевск шәһәрендә (татарлар аны Ижау дип йөртәләр) яшәүче Рәисә апа Дәүләтшинаның (1923 елда туган) гаилә архивында сакланган. Рәисә ханымның бабасы ягыннан туганнары 1854 елдан алып 1930 елларга кадәр Ижау шәһәрендә указлы имамнар булып торганнар. Р.Дәүләтшиналарда сакланган кыйммәтле язма истәлекләрнең берсе—Хисаметдин Мөслиминең "Тәварихы Болгария" әсәре 1836 елда Нократ авылында (хәзерге Киров өлкәсендә) Мөхәммәтсадыйк мулла Галиәкбәр улы тарафыннан күчереп язылганлыгы теркәлгән. Ахун Мөхәммәдсадыйк Галиәкбәр улы (1799—1869) турында татар тарихчысы, әдип, дин эшлеклесе, педагог һәм журналист Ризаэтдин Фәхретдиннең "Асар" хезмәтендә язып үтелгән *(Фәхретдин Ризаэтдин. Асар. 2 жилд, 14 жөзъэ.—Оренбург, 1908.—Б. 489-494)*. Тарихчы билгеләп үткәнчә, Мөхәммәтсадыйк Галиәкбәр улы (Галиәк-



*Ижевск шәһәрендә табылган кульязма.*

бәрнең әтисе Гайсә, аның әтисе Ягкуб, аның әтисе Габдераззак, аның әтисе Галим хафиз) әл-Орыйның төп ватаннары—Казан губернасындагы Оры авылы (хәзер Татарстанның Арча районында). Мөхәммәтсадыйк хәзрәт 1840 елдан 1854 елга кадәр Уфа Диния Нәзарәте идарәсенә әгъзалык хезмәтенә сайланып торган, 1854-1869 елларда Иж заводында имамлык иткән. Аннан соң уллары һәм оныклары шунда ук имамлык вазыйфаларын башкарганнар.

Мөхәммәдъярның "Нуры содур" поэмасы язылган, Ижауда табылган дәфтәрнең сакланышы уртача. Текстның үзендә кайсы елда һәм кем тарафыннан күчерелгәнлеге күрсәтелмәгән. Ләкин кәгазендәге су билгеләре буенча вакытын ачыкларга мөмкин. Су билгеләре—филиграньнәрне өйрәнеп тикшергәннән соң, поэма тексты язылган кәгазьнең 1748-1756 елларда Ярославль шәһәрендәге Алексей Затрапезный мануфактурасында эшләнгән булуы ачыкланды. Димәк, "Нуры содур"-ның бу нөсхәсе якынча XVIII гасыр урталарында, моннан 250 еллап элек теркәлгән дип әйтергә мөмкин. Язуының карасы—караңгы коңгырт төстә.

Дәфтәрнең ике ягы да язулы, 11х17 см зурлыктагы 59 кәгазьдән тора. Һәр биттәге текстның мәйданы 7х12,5 см тәшкил итә. Дәфтәрнең һәр битендә унар юл исәпләнә. Бу дәфтәрдә "Нуры содур" поэмасы бер юлга берәр бәйт (икеюллык) итеп парлап язылмаган. Ягъни, дәфтәр битендәге текст ике багана рәвешендә түгел, һәр бәйтнең ике юлы да аерым-аерым юлларга язылган. Поэма текстының баш өлеше һәм ахыры сакланмаган. Дәфтәрнең беренче бите әсәрнең икенче фасылындагы "Бер хәдис мәгънәсен әйтәйен сахих" дигән юл белән башлана. Бу бәйт 1997 елда басылган китапның 181 битендә 153 нче бәйт *(алга таба да бәйтләрнең тәртип саны 1997 елгы басмадагыча бирелә)* буларак билгеләнгән. Ә дәфтәрдәге соңгы юл унынчы бабтагы "Айгай ирдем жан вә дел берлә сәна" (771 нче бәйт) сүзләре белән тәмамлана. Берничә урында дәфтәрнең битләре җуелу сәбәпле, текстка өзеклек тә кергән. Мәсәлән, бишенче баб-бүлектәге тугыз бәйт, алтынчы бабтагы ун бәйт һәм тугызынчы бабтагы тугыз бәйт һәм бер юл сакланмаган. Ижау шәһәрендә табылган бу кульязма дәфтәрдә "Нуры содур" әсәренең барлыгы 1131 юлы, ягъни 556 бәйт һәм бер юл язылган.

Яңа табылган текстны Ш.Абилов бастырган тәнкыйди текст белән чагыштырганда, эреле-ваклы күп кенә үзенчәлекләре дә бар. Аларның берсе—шигъри әсәрләргә хас булганча ике баганага язылмаган булуы турында алдарак әйтелде. Тагын бер үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: кайбер баб-бүлек башларында шул бүлекнең эчтәлегенә туры килә торган хәдисләрдән һәм Коръән сүрәләреннән аерым җөмләләрнең, хәзергечә әйткәндә эпиграф рәвешендә бирелүе. Мәсәлән, "Бишенче баб. Газа кыйлмак сүзләрен бәйан кыйлур" дип бүлек исеме язылганнан соң, "Калә галәйһис-сәлям: рәҗәгъна мин җиһадел-ахирәт" дигән сүзләр бар. Шулай ук "Сабыр кыйлмак..." турындагы алтынчы баб башындагы "Йа, әййуһа әлләзинә әмәну, әсбиру..." һәм сигезенче бабның исеменнән соңгы гыйбарә дә 1997 елгы басмада юк. Поэманың Ижау нөсхәсендәге алтынчы һәм сигезенче баб башларындагы кебек үк гарәби гыйбарәләр Кукмара районында табылган кульязмада да теркәлгән. Аңысында исә, төп тексттан аермалы буларак, мондый өземтәләр кызыл кара белән бирелгәннәр. Поэманың бүлек башларында Коръән һәм хәдис өземтәләренең бирелүе, әлбәттә, әдәби әсәрне бизи һәм мәгънәви җәһәтен көчәйтә. Ә ике кульязмада бер төрле үк гыйбарәләрнең очравы—аларның аерым күчерүче тарафыннан гына өстәлмәгәнлегенә ишарә итә. Ихтимал, поэманың авторы Мөхәммәдъяр төп нөсхәдә үк шулай язган булгандыр. Һәрхәлдә, бу фаразны әдәбият тарихын өйрәнүче галимнәребез тәгәлрәк ачыклар.

Ижау кульязмасының тәнкыйди тексттан аермалы кайбер урыннарына тукталыйк. Мәсәлән, басма китапта 608 нче бәйтнең:

*"Йәнә сайәңезгә сыгныб килгән кеши,*
*Гадлеңез берлә йитәр барчә эши",—*

дигән юллары Ижау кульязмасында:

*"Сайәңезгә бүкүн сәфир килгән кеши,*
*Гадлеңез берлә табар барча эши",—*

рәвешендә бирелгән.

Кайбер бәйтләрдәге аермалар тагын да зуррак. Мәсәлән, китаптагы 679 нчы бәйтнен:

*"Тәңренең һәйбәтендин нагәһан*
*Заһид мескин сусагаи ул заман",—*

кебек юллары кульязмада:

*"Бу һәйбәтдин исе киткәй ул заман*
*Заһид мескин сусагай нагәһан",—*

дип теркәлгән.

Әсәрнең текстын баета торган мондый аермалар белән беррәттән, шактый ук төгәллек-ачыклык кертә торган урыннары да очрый. Әйтик, монарчы:

*"Кем мөбарәк Урдуга барсам үзем*
*Худның котлуг йөзүн күрсә күзем",—*

рәвешендә билгеле булган 730 нчы бәйт соңгы табылган кульязмада:

*"Кем мөбарәк Урдуга барса үзем*
*Ханның котлуг йөзене күрсә күзем",—*

буларак, бөтенләй башка төсмер бирә. Сүзнең Урдага барып, ханның йөзен күрү турында барганлыгы ачыклана. Абилов файдаланган кульязмаларда "хан" сүзе урынына "хут" яки "худ" дип бирелгән булган.

Яна табылган кульязмада поэманың монарчы билгесез булган бәйтләре булуы аеруча мөһим. Ижау кульязмасында шундый өч бәйт барлыгы ачыкланды. Фәнни әһәмиятен искә алып, аларны монда күчереп бирәбез. Шундый мисал 319 һәм 320 бәйтләр арасында теркәлгән:

*"Кем газа хали ирур әср-ү хәлаль*
*Алса кяфер малыны булмас вәбаль".*

Икенче бәйт 604 нче белән 605 нче бәйтләр арасында язылган:

*"Бу китаб хан догасы берлә тәмам*
*Кыйлганын бәйан кыйлыр кем мөдам".*

Өченче бәйт исә 640 нчы һәм 641 нче бәйтләр арасында бирелгән:

*"Гафу кыйл йазыкларымны, и, гафур,*
*Йаратканым, тагатемне кыйл кабул"!?*

Соңгы бәйттәге "йаратканым" сүзен яратучы, барлыкка китерүче, ягъни Алла мәгънәсендә дип анларга кирәк.

Әлбәттә, һәрбер яна табылган кульязма истәлек уникаль, алар монарчы билгеле булган әсәрнең текстына нинди дә булса яналык өсти һәм төгәллек төсмере бирә. Бу яктан "Нуры содур"ның Ижау шәһәрендә сакланган нөсхәсе, һичшиксез, әһәмиятле табыш дип бәяләнергә хаклы. Мөхәммәдьяр әсәрләре кульязмаларынын табылып торуы һәм аларда яналык өстәүче жәһәтләрнең булуы—бөек әдип ижатын нәзари өйрәнүне дәвам итү белән беррәттән, киләчәктә гамәли тикшеренү-эзләнүләрне дә туктатмаска кирәклеген искәртә. Бу юнәлештә гыйльми китапханәләрдә, архив һәм музейларда тупланган биниһая зур кульязма мирасыбызны жентекләп тикшерү дә унай нәтижә бирергә мөмкин. Һәрхәлдә, тулы текстлары булмаса да, өзекләр рәвешендәге фрагментар күчермә нөсхәләре табылуы ихтимал.

Казанда 464 ел элек ижат ителгән "Нуры содур" поэмасының мона кадәр мәркәзебездә дүрт кульязма күчермәсе сакланган булса, соңгы еллардагы археографик табышлар нәтижәсендә тагын ике нөсхәсе өстәлде. Шулай итеп, хәзерге вакытта фәнгә әсәрнең 11 күчермәсе билгеле. Аларның алтысы Казан шәһәрендә саклана. Соңгысының чал тарихлы башкалабызның мең еллыгы алдыннан табылуын, чын-чынлап, Казан юбилеена бүләк дип атарга мөмкин.

**Раиф МӘРДАНОВ,**
*археограф,*
*филология фәннәре кандидаты.*

## Məcit Ğafuri
(1980 — 1934)

# KÜZ SALAMIN XALQIMA...

### Almaşınu

**Yasadılar qulnı—ayaq, ayaqnı—qul,**
**Didelər: "Bu zamanda şulay məğkül!"**
**Almaşındı qolaq-küzlər urınınnan,**
**Kurende xalıq ara uşbu məqbül.**

**Alğa, artqa, unğa, sulğa kitə torğan**
**Açıldı uşbu kəndə berniçə yul.**
**Əlxasıyl', əllə niçə firqa bulıp,**
**Buldılar almaştıru belən məşgul'.**

**Qatıştı altın—kəmeş, baqır—cizgə,**
**Ber surattə kurendelər bolar kuzgə.**
**Fikerlər tulqın kebek qaynaştılar,**
**Can iəse berse qalmıy kilde süzgə...**

**Bolıt çığıp, kük kükrəp attı yəşen,**
**Kütərde qurquınnan hərkem başın.**
**Hər keşe istiqbalen tə'min əçen**
**Dərtenə çara tapsın—tik tormasın...**

**Ber təstə tordı dənya niçə ğasır —**
**Şul surəttən üzgərelep inde almaşır.**
**Uşbu kəndə tərəddedtə torsa da bu,**
**Monnan son, inşa Alla, alğa basır.**

**Wəğzelər tawğa menər əçen bardı,**
**Wəğzelər mendermaskə tayaqlaşır.**
**Niqədər maniğlar kürensə də,**
**Himmətle ir kükrək birep alğa aşır.**

**Dəwre ğələm xərəkətne almaştırdı,**
**Əwwəlge plannarnın barın qırdı.**
**Xaqiqət dip uylanılğan küp nərsələr**
**Bulıp çıqtı bu zamanda həp lıqırdı.**

**Qaranğı barı betep tannar atar,**
**Ni səbəple beznen xalıq ğafil yatar?**
**Hərniçek ğafil yatu yaramas dip,**
**Şiğer yazdı Gabdelməcid — ibne tatar.**

***

**Niçə yəz yıl izelgəngə tatar yuaş,**
**Bez tatarın yuaşlığı dənyağa faş.**
**Zur eşlərgə batırçılıq itə almas:**
**Əwwələdən qurqa-qurqa əyrəngən baş.**

**Eş kürsətep əyrənməgəç buna çaqlı,**
**Hiçber eşkə kereşalmıy çın ixlaslı.**
**Bundıy eşne kürep ğadət almağanğa,**
**Bu tuğrıda süzləşergə süz də tapmas.**

**Qoyaş çıqtı, eş başlandı uşbu kəndə,**
**İnşa Alla, inde tatar qarap yatmas.**
**Ğəfləttən uyandıylar, küz açtılar,**
**Cəhalətnen çoqırına inde batmas.**

---

Məğkül—urınlı.
Məğbül—qabul itelerlek.
Əlxasıyl'—qısqası.
Firqa—tərkem, partiə.
İstiqbal'—kiləçək.
Tərədded—ikelənü.
İnşa Alla—Alla teləsə.
Bəğzelər—qayberlərе.
Himmətle—teləkkə omtıluçan, tırış.
Dəwre ğələm—dənyanın əylənüe.
Həp lıqırdı—barısı lığırdaw.
Ğafil—uysız, wayımsız.
İbne tatar—tatar ulı.
Tatarın—tatarnın.
Cəhalət—nadanlıq, an-belemsezlek.

Bu kəndə də ğəflət ilə qarap qalsaq,
Monnan son beznen ocen taņnar atmas.
Birgənenə şoker qıylıp almay torsaq,
Soņra bezne Xodayım hiç yaratmas.

## Kənnərebez...

Bezneņ cirdə bik zur eştən bəxəs açıp,
Toralar uşbu kəndə tartqalaşıp;
Mizannın tabaqları kütərelgən,
Axırında qaysı taraf kitər basıp.

Bu xaqta bu zəncaldan qacan tuyar?
Çın matur qız niqabına qaçan suyar?
Zahirən, hərnərsəne eşləw dərest,
Asılda hiç nərsəgə yuq ixtıyar.

"Zarar"lıraq süz kürensə cəridədə,
Çıqmas borın çıqmas cirgə alıp quyar;
İkençe rət qurıqmayınça fiker yazsan,
Gəzitəne taratudan çınlap tıyar.

Qəder yuq bu zamanda yazuçığa,
Ul cirgə meņ yazuçı bulsa sıyar;
Küp keşe uşbu kəndə məğyub buldı,
Qalmadı yaxşılarğa hiç iğtibar.

Alar doşman bezgə, doşman bez alarğa,
Doşman bulğan bılbıl belən ala qarğa.
"Xərriət!" digən çaqta zolım tuldı,
Bu zamanda iltifat yuq ah-zarlarğa.

İnsannarnıņ bəğzese tuq, bəğzese aç,
Açlarğa mərxəmətle küzenne aç!
Dənya tulğan məzlumnarğa küze təşep,
Gəbdelməcid şiğer yaza aptırağaç.

*1907*

## Tatar cegetenə!

***(Şuralar cəmhüriəten ğəməlgə quyuçı cegetlərebezgə)***

Waqıt citte*, ceget! Canıņ bulsa,
Uyan, sikerep kükbüz atqa men!
Kürəsenme İdel buylarında
Matur al, qızıl taņ atqanın?..

---

Mizan — ülçəw (qiəməttə gənah, sawaplarnı ülçi torğan ülçəw).
Niqabını — biten qaplağan pərdəsen, bərkənçegen.
Zahirən — tıştan qarağanda.
Cəridə — gazeta.
Məğyub — ğəyeple.
Zolım — yawızlıq.
Məzlum — izelgən, cəberləngən (keşe).
Şuralar cəmhüriəte — Sovetlar respublikası
Ğəməlgə quyuçı — tormışqa aşıruçı.
*Avtorda: "yitte".

Ural tawlarınnan kük taş alıp
Qayra qılıçınnı şunarğa,
Tan cillәre iskәn matur caqta
Kit sin doşmannarnı quarğa.

Ber nәrsәdәn qurıqmıy, canfәrmanğa
Alğa çap sin, cirlәr selketep;
"Dәnya beznen!.." diep qıçqır şunda
Ğәyrәt belәn yorәk cilketep.

Sin qıçqırğan çaqta sәrәn salıp,
Astındağı atın keşenlәr.
Sine kürep şunda: "Tatar cegete
Qorallanğan ikәn!.." disennәr.

Şulay itep wәxşi yırtqıçlarnın
Qotların al, salıp qurqınıç.
Qıp-qızıl qan belәn bizәklәnsen
Un qulına totqan şul qılıç.

Şul waqıtta çınlap tınıçlanır
Kükrәgendә yanğan yәrәgen.
Şul waqıtta birgәn bulırsın sin
Mәzlüm ilnen kotkәn telәgen...

## Sәlam

Әy qaharman ceget — tatar cegete!
Qua-qua doşman yauların,
Nәq arıslan kebek, nәğrә orıp,
Yarıp çıqtın Ural tawların.

Cille kәndә yanğan ürtlәr kebek,
Tirә-yaqnı qaplap yanasın;
Kozge konge totaş bolıt kebek
Seber ilen qaplap barasın.

Sin Ğazrail buldın doşmannarğa,
Berәm-berәm alıp cannarın;
Yığıldılar cansız kiskә kebek,
Taptap ütten mәrdar qannarın.

Sarıq kebek әrekkәn doşman qaçar
Sinnәn qurqıp, anı quarsın,
Cәrәxәttәn aqqan qannarınnı
Baykal küllәrendә yuarsın.

Barәqәallah, ceget, ğәyrәtenә!..
Tar-mar kilә doşman yauları;
Alda kәtә sine kükrәk kierep
Kükkә çıqqan Altay tawları.

Arttan sәlam uqi qәmәr kebek
Nazlı, matur, sılu il qızı,
Ğәyrәtenne kürep ul yılmaya,
Nәq şәreqnın nurlı yoldızı.

Batır ceget belәn, ay, matur qız—
Bolar—tuğan ilnen bizәge,
Sәlam uqi sina, batır ceget,
Tuğan ilnen nazlı yәrәge.

*1919*

---

Keşenlәr — keşnәw mәğnasendә.
Nәğrә — açı, qatı tawış.
Ürt — dala yanğını.
Mәrdar — pıçraq, şaqşı.
Barәqәallah — bik şәp.
Qәmәr — ay.

# СОҢГЫ КӨННӘР ХАТИРӘСЕ

...2003 елның 20 август көнне, сәгать өч тулганда, үзенең фатирында бу дөнья, шушы мәгыйшәт белән "алыш-биреш" ясады да, олуг шагыйребез Гамил ага Афзал арабыздан китеп барды.

Менә ул язган иң соңгы шигырь юллары:

> Кызларым Рауза, Раушания, Галиябану, хатыным Нәфисә:
> Бәхетле һәм бөтен италмадым,
> Ал ефәккә төреп киталмадым,
> Җан өстендә калды шушы боз,
> Җандай газизләрем, хушыгыз...

Уиламаган да идек... Бер көн алдан гына янына кергән идем—бер дә үләм димәде... Нур Әхмәдиев тә хәлен белеп чыккан булган. Соңыннан хатыны Нәфисә апа сөйләп утырды: гел гармун тавышы ишетәсе килә дигән. "Бу бит сиңа Башкортстандагы Шәрип авылы түгел", дигәч: "Алайса җырла!..."—ди икән.

—"Син сазыңны уйнадың", "Рәйхан"ны җырладым, рәхәтләнеп китте,—дип искә ала Нәфисә апа. Аннары:

—Яшь язучылар нишләр инде,—дип борчыла башлады.

— Ул хәтле яшьләр юк инде, аларына да илле тирәсе,—дим. Аннан соң:

—Нәфисә, син миңа кияүгә чыгасыңмы?—дип сорап куйды. Мин бу тәкъдимне чынга алган булып:

—Ризалыгымны бирәм инде, бик озак көттердем,—дим.

Бераздан аңына килде... Врач чакырттык—дару язды. Йөрәгем авырта, ди. Җиргә ятасым, урамга чыгасым килә, ди. Ишек-тәрәзә төбендә машина күп бит инде, шуңамы, гел автовокзалда яшибез, дия иде.

—Мин сизенә идем үлеме якынлашканын,—дип дәвам итә Нәфисә апа.—Юындырдым, киемен алыштырдым. Ә ул: "Әллә мине туп-туры оҗмахка әзерлисең инде",—дигән була. Гел йөреп китәр төсле иде, таягы караваты янында гына. Әкрен генә тын алудан туктады, йөрәгендә җан юк, аяклары кичә үк сап-салкын иделәр.

Әйе, язмыш аны төрлечә сынады. Өнәп бетермәүчеләр дә булды, ләкин гади халык түгел. Аның иҗаты халыкчан иде. Татар, рус, башкорт телләрендә басылган утыздан артык китап авторы, дистәләгән яшь язучыларны чын иҗатка тәрбияләгән остаз, җәмгыятебезнең әхлакый сафлыгы сагында торучы уяу солдат... Милләтебезнең йөзек кашы саналучы Гамил Гыймазетдин улы Афзаловның кырык ел гомере Әлмәттә үтте. Ул шушында яшәсә дә шәһәрне язучылар үстереп чыгара торган гүзәл бакча итеп санамады. "Талант шәхестә була, җирдә түгел. Әллә кайдагы караңгы авылдан да шәп язучы чыгуы мөмкин", дия иде.



*Гамил Афзал эш бүлмәсендә.*
*Үткән гасырның 60 нчы еллары.*

Яраткан язучысы Сибгат Хәкимгә гел рәхмәтле булды: Ул бит Г. Афзал иҗаты "Тукай шигырьләренең койрыгына ялганып китә шикелле" дигән иде "Шундый-шундый эшләр" исемле китабының сүз башында (ТКН, 1988 ел).

Аны кемнәрдер "әче телле, усал шагыйрь" диделәр. "Ярар, әйтсеннәр. Тәмле телле, шома ялганчы булудан Алла сакласын! Халыкны рухи һәм гади бөлгенлеккә төшергән сәясәтне һәм шул сәясәткә ябышып яткан политикларны мактап шигырь яза алмыйм. Иң зур гөнаһ—халыкны алдау, дип исәплим мин", диде ул.

"Беркайчан да, беркемгә дә минемчә яз!" дип кушу, боерык бирү кирәкми, иҗат иреге икән, һәркем үзенчә язсын, һәркемгә заман үз бәһасен бирер", ди.

Әйе, ул берәүне дә "бу минем шәкертем" дип әйтмәде. "Шәкерт" әле ул үсә, кырыкка кырыла. Бик күп шәп "шәкерт"ләр остазларына хыянәт иткәннәр, шәкертләр турында сөйләшмик, дия иде.

"Аның шигырьләрендәге юллар күптән халык әйтеменә, халык телендә йөргән гыйбарәләргә әверелеп бетте инде. Чын мәгънәсендә зирәк аксакалга әверелде ул. Гамил Афзал иҗаты булмаса, әдәбиятыбызның шактый зур өлеше буш калган булыр иде. Халык язучысы нәкъ менә шундый булырга тиештер дә инде!.. Аны беркем белән дә чагыштырып торырга кирәкми. Гамил Афзал ул, ни дисәгез дә, бер генә инде! Аның барлыгы өчен рәхмәтле булыйк!.."—ди Зөлфәт.

Поэзия сөючеләр яхшы хәтерлидер: Гамил Афзал әдәбиятка килеп кергәндә кин катлау укучылар күңелен иң элек юмористик шигырьләре белән җәлеп итте.

Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә әллә кайчан ук лаек булса да, ана бу иң абруйлы бүләкне бик авыр бирделәр. Шулай килеп чыкты инде: беренче тапкыр аны Шәүкәт Галиев белән күрсәттеләр. "Балалар елы" дип игълан иткән ел иде, балалар язучысы буларак премиягә ул елны Шәүкәт ага лаек булды. Икенче тапкыр Гариф Ахунов белән көч сынашырга туры килә ана. Ул—Язучылар берлегенен идарә рәисе... Өченче юлы, соңгы тапкыр, Сажидә Сөләйманова белән. Бу юлы ана Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирәләр. Ләкин Сажидә ханымның хәтерен калдырып...

Әйе, Сажидә апага да җиңел түгел иде. Беренче юлы Г. Афзал белән, икенче тапкыр Р. Фәйзуллин белән аны ярыштыру, алар иҗаты белән тиңләү—бик мактаулы булса да.

Әйе, Гамил Афзал вафатына да ике ел була. Ул әле дә арабызда кебек. Үзенең өчтомлыгын күреп безнең сыман сөенә кебек.

Мин айга бер тапкыр Язучылар берлегенә барганда шатлыклы хәбәрләрне гел кайтып сөйли идем. Терелеп киткән сыман була иде. Китабын бик көтте инде. Шөкер менә, китаплары үзеннән соң булса да дөнья күрде. Сигнал дигәннәрен дә мин алып кайттым.

Ул миңа бигрәк тә якын. Монарчы шундый бөек шагыйрь күргән булмагангамы, аның белән якыннан танышырга бик теләдем. Өйләрендә була башладым. Баштарак килгәнемдә урындыкка утырган килеш сәгатьләр буе сөйли иде. Ә соңгы араларда урында яткан килеш... Мәгълүмат күп иде анда, үзебезнең репрессия еллары турында да, әллә кайчангы Алмания социал-демократлары турында да, каләмдәшләре иҗаты турында да бик күп сөйләде. Миңа гел "укы" диде. "Менә бу китапны укы!" ди, аннан, тагы килгәч, башкасын тәкъдим итә. Керми торсам, нигә кермисең, ди. Берлеккә кабул итү коллегиясенә тәкъдимнамәне дә ул язды, нәкъ үзенчә: "З. Дәүләтов башлап язучы да, яшь язучы да түгел. Ул өлгергән язучы", дип... Азагында: "Аны берлеккә кабул итеп, Әлмәт Язучылар оешмасына кушып куярга кирәк"—диелгән.

Ул миңе үз итте. Еш керергә кыенсынып керми торсам, нигә кермисең, ди. Миңа берәүгә дә әйтмәгән, китапка язарга ярамаган нәрсәләр турында да сөйли иде.

Мин иске гадәт белән хәзер дә аларга кергәләп йөрим. Заманында Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, Г. Афзал яшәгән фатирда ниндидер бер рәхәтлек тоям. Мәгълүм ки, алар бар да Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары. Берсеннән-берсенә күчеп калган тумбалы язу өстәле, китап шкафы һаман шул килеш. Шул фатирда булып, олы шәхесләр рухын тоеп утыруы рәхәт. "Зингер" машинкасы да яп-яңа кебек. Мондый фатир дөньяда юктыр, мөгаен. Музей ачарга иде шушында дип йөрибез әле... Хыял өметсез түгел!

**Зөфәр ДӘҮЛӘТОВ,**
*Татарстан Язучылар берлегенең*
*Әлмәт бүлеге җитәкчесе*

*Сафа Сабировның тууына 90 ел*

# ИСКЕ ЙОРТ АКСАКАЛЫ

Питрәч якларында авыллар бихисап, тик аларның күбесе Татарстан карталарына кертелмәгән; данлыклы шәхесләре дә байтак, тик аларның исемнәре тиешенчә *макталмаган* гына...

Сафа Сабиров үзенең беренче китабы чыкканнан соң ("Яшь диңгезчеләр". Таткнигоиздат. 1949) тагын илле еллык иҗади гомер кичерде. Ике дистә китап авторы, заманында нәшриятның баш мөхәррире булып эшләп танылган агайның: "Мин язучы!"—дип, күкрәк каккан мәлләрен хәтерләмим. Шулай, Питрәч кешесе йә менә шундый чамасыз тыйнак була, йә алар үтләтерлек мактанчык.

Алтмышынчы еллар уртасында, районның "Алга" газетасы каршындагы әдәби берләшмә утырышларында еш күрә идем мин аны. Калку гәүдәле, киң җилкәле, салмак адымлы, тыныч йөзле якташыбыз безгә—Питрәч төбәгенең яшь шагыйрьләренә киңәш биргәндә сүзләрен тәмләп кенә, тавышын көйләп, иреннәрен кысып, хәреф-авазларын кечерәйтеп кенә сөйләр. Еш елмайганын беләм, кычкырып көлгәнен хәтерләмим. Тыйнаклык бик *килешә* иде аңа. Сафа Сабиров үзе генә йөрми, Рәшит Гәрәй, Абдулла Сәләхетдинов, Хәсән Сарьян кебек танылган язучыларны да алып кайта. Алар безнең өйрәнчек шигырьләребезне, хикәяләребезне укып тикшерәләр, яшь авторлар өчен искиткеч тансык булган файдалы киңәшләрен бирәләр. Ул вакытларда үзенең яше, активлыгы һәм тырышлыгы белән яшь шагыйрь Павел Апушев шактый алга киткән иде. Әдәби берләшмәгә йөрүчеләр арасыннан иң беренче булып, ул шигырь китабы чыгарып өлгерде ("Сукмагым". ТКН. 1971 ел). Китапка кереш сүзне Сафа Сабиров үзе язган иде. Бер җөмләсе әле дә хәтердә калган: "Павел Апушев шигърияткә үз *сукмагы* белән килеп керде..." Еллар үткәч, һәр сукмак үз вакыты белән олы юлга килеп кушылыр. Безне өлкәннәр сүзен хөрмәт итәргә өйрәттеләр...

Питрәчтәге әдәби берләшмәнең исеме "Мишә дулкыннары" иде. Бәлки бу исемне нәкъ менә Сафа Сабиров кушкандыр да әле. Туган авылы Иске Йорт, Ил карталарында күрсәтелмәсә дә, борынгыдан Мишә буенда. Тагылмалы трамвайга сыеп бетәрдәй халкы булган Иске Йорт өчен калын урманнарга төренгән, тугайлары-болыннары белән сипләнгән, тургай-былбыллар аһәңе белән өретелгән Мишә елгасы, табигать тарафыннан бирелгән, әйтеп бетергесез олы бүләк. Һәм Мишә буенда туып үскән ятим баланың, диңгезгә сусап, диңгезче булырга хыяллануы бик тә табигый хәл.

Сафа Сабиров Казан елга техникумына урау юллар аша килә. Балалар йортында тәрбияләнеп, тимер юлчылар ФЗӨ мәктәбендә укый, паровозчы-слесарь һөнәре ала, ләкин бу һөнәр буенча эшләми, туган якка кайтып, Тау Иле авылына укытучы булып урнаша.

1938 елда, елга техникумын тәмамлап, буксир пароходында капитан ярдәмчесе булып эшли башлагач, аны армиягә алалар. Ул сигез ел буе (1938-46) Ерак Көнчыгышта Хәрби диңгез флотында хезмәт итә. Кыскасы, Мишә-йорттан килгән егет, Идел-йортны кичеп, аннан диңгез-океаннарны гизеп, иҗат каләмен хәрби хезмәттә чыныктыра, сугышчан газеталар белән язышa, әдәби түгәрәкләрдә катнаша. Елгачылар, хезмәттәшләр арасында татар егетләре бик күп була. Владивосток тирәсендәге бер авиачастьта Сафа Сабиров очучы өлкән лейтенант Салих Баттал белән таныша. Ял көннәрендә ул үзенең коры паегын кыстырып кунакка килә, диңгезче якташына шигырьләрен укый. Шунысы кызык, Сафа Сабировның беренче хикәяләрен Казанга—Фатих Хөсни исеменә юллаучы кеше дә Салих Баттал... Ул вакытта Фатих Хөсни "Совет әдәбияты" (Хәзерге "Казан утлары") журналында эшли. Шулай итеп, Сафа Сабировның иң беренче хикәяләре, 1945 елда, "Совет әдәбияты"нда басылып чыга. Ул сайлаган һөнәрен шултиклем ярата ки, алга таба

да гел дингезчеләр язмышын, елга стихиясе һәм кеше батырлыгын үзенә төп тема итеп куя. Дөнья күргән китапларының исемнәре дә дулкынлы-акчарлаклы: "Яшь дингезчеләр" (1945), "Дүрт елга буйлап" (1951), "Су өстендә акчарлак" (1966), "Идел йолдызлыгы" (1996) һәм башка җыентыкларының исемнәрен санап чыксан, язучының татар әдәбиятындагы үз сукмагын, дингезчеләр теле белән әйткәндә *фарватерын* күреп сөенәсен.

Очрашкач, хәл-әхвәлен сорашсан, ул үзеннән-үзе фикер агышын бөтенләй икенче юнәлешкә борып, Новиков-Прибой әсәрләрен мактарга керешә, Айвазовский картиналарындагы давылларны көчәйтә башлый, теле белән атап әйтмәсә дә сизәбез—күнеле белән гел алар янәшәсенә баса, *хикәяче-маринист* буларак игътибарны җәлеп итәргә тели иде.

Чордашлары ана, шаяртып кына, "Мистер Сафа" дип эндәшкәлиләр. Мин моның серен сонрак анладым.

Балачакта без мажаралы китапларны китапханәгә чиратка язылып укый торган идек. Авторының кем икәненә игътибар итеп тору юк, әсәр куллан-кулга китап исеме белән генә йөри. "Салават Юлаев", "Хәнҗәр. Бакыр кош", "Плутон иле", "Ундүрт яшьлек капитан" кебек тышлары таушалган китапларның авторларын без сонрак кына белдек. Күз алдына китерегез... Житмешенче еллар уртасы. Илнен икмәккә кинәнгән, ябагаларнын киенгән чагы, табигать сау-таза, мәрхәмәтле. Жәйге челләләрдә ягымлы дулкын булып яшенле янгыр үтеп китә. Юеш авыл кибә тора, ә без, теге дулкынны туктатып калырга теләгәндәй, урамга йөгереп чыгабыз, гөрләвекләрне буалап су коенабыз. Инештә янгыр ташуы тынгач, субай кага торган сәкеләрне сал итеп, "Су сугышы" оештырабыз, пиратлар булабыз, "дошман корабларын" батырабыз. Китапларда укыган мажараларны сәхнәләштерү бу үзебезчә. Күрәсен, Жюль Вернны гына укымаганбыздыр... Бер хикәядә сугыш чоры тасвирлана... Хәвефле заман дип тик ятмыйлар—балыкчы ятьмә белән дингезне иләп көн күрүен дәвам итә. Безнекеләрнен хәрби корабы узып барганда, кинәт, дошман су асты көймәсе торпеда жибәрә. Аны балыкчылар шундук күреп ала. Араларында Таухетдин атлы татар егете бар, ул тыныч дингез өстендә "Шахта" көен жырлап йөрүче балыкчы буларак хәтердә калган. Менә шул Таухетдинне "Мистер Таух" дип (тора-бара "Мистер Тавык"ка әверелә) үртәп үз итәләр. Торпеданың туп-туры корабка юналүен күреп, хәрби корабны коточкыч афәттән коткарыр өчен, Мистер Тавык тиз арада балыкчылар көймәсен торпеда юлына аркылы куя. Үз гомерен корбан итеп күпләрне саклап кала. Дингезнен дә амбразура каплый торган үз Газинурлары бар... Без ятлап диярлек укыган бу хикәянен авторы Сафа Сабиров булган икән. Жир шарын су юллары буйлап аркылы-торкылы гизгән дингезче-язучыбызга "Мистер Сафа" кушаматы бик килешә иде.



*Уңнан сулга—Сафа Сабиров, Аяз Гыйләҗев, Ринат Мөхәммәдиев. 1985 ел, май.*

Сафа Сабиров хикәяче. Сиксән яшьлегенә багышлап нәшер ителгән "Идел йолдызлыгы" (ТКН, 1996) китабының кыскача аннотациясендә "повестьлар һәм хикәяләр" дип куелса да тәкъдим ителгән күләмле әсәрләре элеккеге елларда басылган хикәя-очеркларның бәйләме рәвешендә генә бара. Ә чын-чынлап повесть жанрына тотынуы "Алтын балдаклы абыстай" өчен генә булгандыр. Повесть, Сафа Сабиров үзе исән чагында ук, "Казан утлары"нда басылып өлгерде (2001 ел, №10). Басылуын тиз басылды. Әмма язылу тарихы шактый озын... Автор, 1938 елның көзендә, Хәрби диңгез флотында хезмәт итүенең беренче көннәрендә үк, Владивосток порты эшчесе Шакир исемле бер агай һәм аның хатыны Фәгыйлә белән таныша. Фәгыйлә иренә караганда зыялырак, әдәбият белән кызыксына, китаплар сатып ала, Тукайның күп шигырьләрен яттан белә. Кайчандыр ул Тукай белән якыннан таныш булган. 1912 елның җәендә, Троицк шәһәреннән ерак түгел казакъ даласына кымыз белән дәваланырга килгән авыру шагыйрьгә ике ай ярым буе аш-су пешереп торган, керләрен юган, еш кына серле әңгәмә корган...

Салих Баттал белән киңәшеп, Тукайга бәйле хатирәләрне Казанга—Язучылар союзына җибәргәч, Сафа Сабиров кырыс җавап ала. Бактың исә, Тукайның рәсми расланган, дәреслекләргә басылган тулы биографиясе билгеле икән, кая барганы, кайда күпме торганы, кемнәр белән аралашканы,ниләр сөйләшкәне—барысы да билгеле, анда Фәгыйлә язмышына, гомумән Тукайның Троицк шәһәре тирәсендәге казакъ даласында кымыз илә дәвалануына *урын калмаган* икән...

Бу факт белән, "Тукай" романының икенче томын язып яткан чагында, Әхмәт Фәйзи дә кызыксына. Ул, Сафа Сабировка ияреп, Владивосток каласына иҗади сәфәргә җыена. Ләкин Ә. Фәйзинең кинәт авырып гүргә иңүе аркасында әлеге хыял хыялда килеш кенә кала.

Холкы-фигыле белән бәхәс-әрләшүләрне өнәми торган Сафа Сабиров "Алтын балдаклы абыстай"ны *алтмыш ел* буе күнелендә йөртә. Һәм Тукайчы оппонентларның рәте тәмам сирәгәйгәч кенә, ниһаять, повестьны "Казан утлары"на китерергә җөрьәт итә. Әлбәттә, Сафа Сабиров әлеге повестьны документаль әсәр рәвешендә тәкъдим итә. Ләкин, повесть әдәби эшләнеше ягыннан болай да камил, Фәгыйлә язмышы—гражданнар сугышын кичкән яңа дәүләт кешесе өчен типик язмыш буларак калку сурәтләнгән.

Бөек Ватан сугышыннан соң Сафа Сабиров гел Казанда яшәде. Диңгезченең шәһәргә күчүен коры ярга ташланган дельфин итеп күз алдына китерсәк тә, язучы иҗаттан аерылмады, сиксән сигез яшенәчә гел актив тормышта иде. Язучылар берлегенең XIV Корылтаен (2002 ел, май ае) ул ачып җибәрде... Исән язучыларның иң өлкәне, фронтовик, гуманист һәм гап-гади Кеше буларак...

**Камил КӘРИМОВ**

## «Татар энциклопедиясе» битләреннән

# А

**АНАК** (псевд., чын фамилиясе һәм исеме Мәхмүтов Шамил Гомәр улы) (25.11.1928, хәзерге Башкортстан Респ-касы Әлшәй р-ны Габдрәшит а.), шагыйрь, БАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1990). 1950 елда Мәскәү ун-тын тәмамлый. 1957-59 елларда М.Горький исем. Әдәбият ин-тында укыта. А. тәрҗемәсендә төрек язучылары Решат Нури Гюнтекин, Омер Сәйфетдин, Орхон Кемал, Фаик Байсалның кайбер әсәрләре, шулай ук Назыйм Хикмәтнең "Сайланма әсәрләр"е (1955) татарча басылып чыкты. А. татар, башкорт, рус телләрендә иҗат итә. Ул "Юл өстендә кояш" (1966; русчага тәрҗемәсе "Солнце на дороге", М., 1962), "Күтелмәгән очрашулар" (1971), "Тыйнак табын" (1982), "Европа уртаһынан репортаж" (Өфө, 1963), "Таш тамгалар" (Өфө, 1978), "Зәңгәр Өстүбә иле" (Өфө, 1984; русчага тәрҗемәсе "Три синих холма", М., 1971), "Һөйөү тамгалары" (Өфө, 1988) һ.б. шигъри җыентыклар авторы. А. яңалыкка омтылучы шагыйрь. А.ның шигырьләре масштаблылык, дөньяны глобаль сурәтләү белән аерылып тора. Лирик геройлары рухи яктан бай, югары әхлаклы кешеләр. А. хәзерге татар шигыре төзелешенә, аның жанрларына үзенчәлекле өлеш кертте: татар һәм башкорт поэзиясенә верлибр (иркле шигырь) формасын алып керде, беренчеләрдән булып татар поэзиясендә сонетлар бәйләме булдырды, итальян терцинасын кулланды, ода, касыйдә жанрларын яңартты, япон поэзиясенә хас булган хайку һәм танка жанрларында назирәләр иҗат итте. Аның шигырьләре фәлсәфи уйлануларга бай, афоризм булып кабул ителә. Иҗатында еш кына новелла һәм шигъри проза формасына да мөрәҗәгать итә. А.ның шигырьләре немец, чех, словак, болгар һ.б. телләргә тәрҗемә ителде, кайберләре көйгә салынды. Башкортстан Респ-касында яши.

Әд.: Мустафин Р. Ищите крупицы добра // Образ времени. К., 1981; Харисов Р. Юл өстендә кояш // Казан утлары. 1967.№12; Галиуллин Т. Тыйнак табынга кил, укучы! // Казан утлары. 1983.№11.

**АНОНИМ ӘДӘБИ ӘСӘР**, авторның исеме яки псевдонимы куелмаган әсәр. Татар әдәбиятында А.ә.ә. рәтенә "Кисекбаш китабы" (14 йөз), "Кыйсса-и Сәкам" (15 йөз), "Нәсыйхәтес-Салихин" (16–17 йөзләр), "Комедия Чистайда" (19 йөз) керә.

**АНТОЛОГИЯ** (грек. anthologia, "чәчәкләр бәйләме" дигән мәгънәдә), берничә язучының иҗатын яки аерым бер период-тагы әдәбиятны, әдәби агымны, халык мәдәниятен чагылдыручы җыентык. Урта гасыр Шәрекъ һәм төрки халыклар, шул исәптән татар әдәбиятында А.нең беренче үрнәкләре — тәскирә, мәҗмуга, җыентык. Мәс., Фәридеддин Аттарның "Тәзкирәт әл-әүлия" (12 йөз ахыры -13 йөз башы), Дәүләтшаһ Сәмәркандинең "Тәзкирәт әш-шугара" (1487), Алишер Нәвоинең "Мәҗәлис әннәфаис" (1490–98), Шәрекъ шагыйрьләренең татар теленә тәрҗемә ителгән сайланма шигырьләреннән торган "Шәрекъ гөлләре" (1919) җыентыклары. Татар поэзиясендә А. төзү 20 нче йөзнең 2 нче яртысында таралыш ала: "Татар поэзиясе антологиясе" (1956), "Антология татарской поэзии" (1957), "Көнчыгыш шагыйрьләре" (1959), "Татар балалар поэзиясе антологиясе" (1980), "Татар поэзиясе антологиясе" (т.1–2, 1992), "XX гасыр башы татар шигърияте" (1998–99), "Татар хикәясе антологиясе" (2001).

*Автор: Ш.Ш Абилов*

**АППАКОВА** Дәрҗия Сәйфулла кызы (2.3.1898, Уфа губ., Минзәлә өязе Байгол а. – 28.5.1948, Казан), язучы. Казандагы керәшеннәр өчен ачылган укытучылар мәктәбен тәмамлагач (1917), Казанда һәм туган авылында балалар укыта, шул ук вакытта 1918 елдан "Кызыл аләм" г-тасының авылдагы хәбәрчесе булып эшли. 1922–23 тә Совет-партия мәктәбендә һәм Казан Зур драма театры каршындагы те-

атр студиясендә укый, 1925–28 дә комсомолның Татарстан өлкә комитеты инструкторы, РКП(б)ның Бөгелмә кантоны бүлегендә оештыручы-хезмәткәр булып эшли. 1928–43 тә Ташкентта укытучылык итә. 1938 дә "Кечкенә Бануның тарихы" повестен яза, ул аңа танылу китерә һәм рус, үзбәк, инглиз телләренә тәрҗемә ителә. Ташкентта яшәгән чорда "Сәнәкчеләр" (1932), "Мәмәт һәм Аман карт" (1934), "Лули" (1937) повестьларын, "Михнәт" (1934–35) романын иҗат итә, 1943 елда Казанга кайта; биредә А. "Шүрәле" (1944), "Тапкыр егет" (1945, Татар академия театрында куела), "Бишек җыры" (1946), "Илдус" (1947) пьесаларын яза. "Иске чиләк", "Гөлчәчәк белән Сандугач", "Сараның башыннан үткәннәре" әкиятләренең авторы.

Әсәр.: Хикәяләр һәм пьесалар. К., 1953; Избранное. К., 1957

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

*Ф. Ибраһимова.*

**АРДАШИР** ибне Ишгали Чалкави-Болгари (19 йөз), шагыйрь. "Кыяфәтнамә. Рисаләт фи бәйан кыяфәте женсел-инсан" ("Кешенең тышкы кыяфәте турында рисалә", К., 1858) исемле әсәр авторы. Фарсы телендәге оригиналына таянып язылган. Тезмә өлеше кешенең тышкы кыяфәтендәге физиогномик сыйфатларны тасвирлауга багышланган, чәчмә өлешендә хиҗри ел айларының әһәмияте һәм аларга туры килә торган мөселман бәйрәмнәре, атнаның кайсы көннәрендә нинди эшне эшләргә рөхсәт ителә, нинди эшне эшләргә тыела икәне турында мәгълуматлар бирелә. А.ның иҗаты һәм тәрҗемәи хәле аз өйрәнелгән.

*Автор: М.В.Гайнетдинев.*

**АРСЛАНОВ** Нури Газиз улы (19.9.1912, Казакъстанның Петропавловск (Кызылъяр) ш. – 12.4.1991, Казан), шагыйрь. 1931 елда Казан сәнгать техникумын тәмамлый. 1931-34 елларда Урта Азия һәм Ерак Көнчыгыш шәһәрләрендә татар әдәбияты һәм рәсем укытучысы, соңрак рәссам-бизәүче булып эшли. 1936 дан "Пионер каләме" ж-лы һәм "Яшь ленинчы" г-тасы редакцияләрендә хезмәттәшлек итә. Фин (1939-40) һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Сугыштан соң Татарстан китап нәшриятында, "Социалистик Татарстан" г-тасында рәссам вазифаларын башкара. 1964-72 елларда "Казан утлары" ж-лының поэзия бүлеге мөдире. Сугышның иң кызган чорында аның заман кешесенең тормышка мәхәббәтенә, рухи көченә дан җырлаган беренче "Мәхәббәт" (1942) исемле һәм Зоя Космодемьянская турында "Рус кызы" (1943) исемле поэмалары басыла. Шагыйрь поэзиясенең тематикасы күптөрле, әмма сугыш һәм туган ил азатлыгы темасы аның иҗатында күп еллар үзәктә торды. Байтак шигырь һәм поэмаларында ул әкият сюжетларына, халык мифларына мөрәҗәгать итә: "Ай Хан белән Ли" (1951), "Корея гөле" (1951), "Давыл кызы" (1954), "Көзге" (1955) һ.б.ш. А. "Девон фонтаннары" (1953) шигырьләр циклы белән татар шагыйрьләре арасында беренчеләрдән булып республикабыз нефтьчеләре хезмәте темасын күтәреп чыкты. 1960 еллар башыннан А. иҗатында классик көнчыгыш шигъриятенең (ш. и. татар поэзиясенең дә) традицион формалары белән баетылган фәлсәфи лирика өстенлек ала. Еш кына ул көнчыгыш поэзиясенә хас булган касыйдә, мәснәви, газәл жанрларында иҗат итә. Төрле елларда А.ның "Ак таңнар" (1967; русчага тәрҗемәсе "Белые зори", 1982), "Моңсар" (1971), "Талпыну" (1974), "Иделем-илем" (1982; ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, 1985), "Сөмбелләрем" (1987) исемле шигъри җыентыклары дөнья күрде. А. поэзиясенә хас сыйфатлар – тирән мәгънәлелек, сүзнең тасвирлау байлыгы, кыскалык, формаларның җыйнаклыгы. Ул ш. у. җырлар һәм балладалар авторы. Тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләре дә игътибарга лаек. А. А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Байрон, Гете, Гомәр Хәйям, Хафиз, Абай һ.б.ларның әсәрләрен татар укучысына ирештерде. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы, "Почет Билгесе" орденнары белән бүләкләнде.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1992.

Әд.: Галиуллин Т. Нури Арсланов // Здравствуй, поэзия! М., 1987; Мөхәммәдиев Р. Якутлар табыладыр вакыт белән // Әгәр без янмасак. К., 1980.

**АРЦЫБАШЕВ** (Арцыбышев) Николай Сергеевич (1.12.1773, Казан. губ.-сы, Цивильск өязе Мамино а. – 27.8.1841, шун-

да ук, Рындино а.), тарихчы, язучы. 1793 елда С.-Петербургта немец пансионын тәмамлый, Семёнов лейб-гвардияле полкына хезмәткә керә. Якынча 1797 дә Казан гарнизонына прапорщик итеп күчерелә. 1806–07 дә Казан ополчениесендә (Земство милициясендә) хезмәт итә. 1812–23 тә Ядринск һәм Чабаксар уч-щеләренең шәрәфле смотрителе була. 1802 елдан рус тарихын өйрәнү б-н мавыга башлый. "Вестник Европы", "Русский зритель" ж-лларында тарихка караган мәкаләләр бастыра. Н.М.Карамзин хезмәтенә карата язылган "Россия дәүләте тарихы"на искәрмәләр" ("Замечания на "Историю государства Российского" мәкаләсендә ("Казанский вестник" ж-лында басыла, 1822–23) авторны төгәлсезлектә, тарихи вакыйгаларны беллитристик рәвештә күрсәтүдә гаепли һәм шуның белән рус тарихчылары, публицистлары арасында зур бәхәс куптара. А.ның иң киң хезмәте – "Россия турында кыйсса") ("Повествование о России", М., 1838–43). Аны язганда, ул 500 дән артык чыганактан файдалана. 1811 дән "Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте" әгъзасы булып тора. "Күңелсезләнү" ("Скука", 1800), "Очраклы вакыйга" ("Слепой случай", 1841) одалары, "Рогнеда, яки Полоцкны җимерү" ("Рогнеда, или Разорение Полоцка", СПб., 1818) тарихи повестьләре авторы.

Әд.: Аристов В.В. Казанские находки. К., 1985; Русские писатели. 1800–1917: Биогр. Словарь. М., 1989. Т.1; Гусаров Ю.В. Цивильский затворник. Чебоксары. 2000.

*Автор: Ю.А. Благов*

**АСАНБАЕВ** Нәҗип (Николай Васильевич) (7.11.1921, Уфа губ. Бәләбәй өязе, хәзерге Башкортстан Респ-касы Бакалы р-ны Ахман а.), драматург, прозаик, Башкортстан АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1977), РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). Татар һәм башкорт телләрендә иҗат итә. 1939 елда Уфа финанс-икътисад техникумын, 1963 тә Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият институты каршында Югары әдәби курслар тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1949-59 елларда әдәби хезмәткәр, соңрак бүлек мөдире вазифасында Уфада чыгучы "Кызыл таң" г-тасында эшли. 1959-61 дә Салават драма т-ры, ә 1963-65 тә Башкорт академия драма т-ры директоры. Әсәрләре 1939 елдан бирле басылып килә. Балалар өчен "Кәрим" (Өфө, 1947), "Вәлимә" (Өфө, 1953) исемле хикәяләр, Башкортстан нефтьчеләренә багышланган "Минең геройым" (Өфө, 1953) дигән очерклар җыентыклары авторы. Драматург буларак киң танылa. 1955 елда үзенең беренче драма әсәрен – "Безгә егетләр кирәк" комедиясен яза. "Рәйсә" (1958), "Кыйыу кешеләр" (1959), "Фәйзи" (1960), "Зәйтүнгөл" (1975), "Ак сирендәр" (1976) драмалары язучының иҗади үсешен билгеләделәр. "Канат йәйгәндә" (1969) драмасында М.Җәлилнең тормыш юлын сурәтләде. Кискен конфликтка корылган "Кәләш әйттергәндә" (1964), "Күктән төшкән бәхет" (1969), "Һыу юлы" (1972) комедияләре бүген дә актуальлекләрен югалтмыйлар. Революционер, дипломат Кәрим Хәкимов образын сурәтләгән "Кызыл паша" (1982) драмасы А.ка аеруча уңыш китерде. Ул 1983 елда Башкортстан Респ-касының Салават Юлаев исем. Дәүләт бүләгенә лаек булды. А.ның пьесалары Казан, Уфа, Сибай, Салават, Әлмәт, Оренбург, Минзәлә т-рларында куелды. Ул 1 һәм 2 дәрәҗә Ватан сугышы, ике тапкыр Кызыл Йолдыз, Халыклар Дуслыгы орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнде. Уфа ш. нда яши.

Әсәр.: Красный паша. Пьесы. Уфа, 1987; Һайланма әсәрзәр. Өфө, 1991; Сәхнә әсәрзәре. Өфө, 1997.

Әд.: Абсалямов Г. Решать мирным путём // Театральная жизнь. 1983. №12; Нургалин З. Теманы тормош бирә // Агизел. 1984. №6.

*Автор: С.Г.Сафуанов*

**АСАНОВА** Нилүфәр Абдулла кызы (27.11.1935, Крым АССРның Ялта ш. – 16.5.2000, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1981), проф. (1983). Үзбәкстан ун-тын тәмамлый (Ташкент, 1956). 1961 елдан Казан ун-тында, 1987–89, 1993–94 тә Пекин ун-тында укыта. Жанна д'Арк исем. халыкара үзәк (Франция, Орлеан ш.) эшендә даими катнашып килә. Хезмәтләре хәзерге француз әдәбиятында роман жанры үсеше проблемаларына, романтизм теориясенә һәм әдәбиятның, сәнгатьнең бүтән төрләре белән бәйләнешенә карый.

Хезм.: "Жан Кристоф" Р.Роллана и проблема взаимодействия в искусстве. К., 1978; Проблема взаимодействия литературы и музыки. К., 1978; Философский роман Мишеля Турнье. К., 1997.

**АТНАБАЕВ** Әнгам Касыйм улы (23.2.1928, хәзерге БашкортстанРесп-касы Тәтешле р-ны Иске Күрдем а. — 13.10.1999, Уфа ш.), шагыйрь, драматург, БАССРның һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1977;1988), Башкортстан Республикасының халык шагыйре (1997). Татар һәм башкорт телләрендә иҗат итте. 1943-51 елларда туган авылында укытучы, 1951-68 дә Уфада чыга торган "Кызыл таң" газетасында, 1977-89 елларда "Һәнәк" ж-лларында баш редактор ярдәмчесе булып эшләде. 1946 елдан бирле матбугатта басылып килде. 1958 дә "Йөрәк менән һөйләшеү" исемле беренче шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы басылды. Ул яшьлекләре авыр сугыш елларына туры килгән буын вәкилләре кичерешләре турында. Гомумән, А. поэзиясенең төп темасы — замандашлары тормышы. Ул "Йәшлек менән осрашыу" (Өфө,1961), "Йылдарзан йырзар кала" (Өфө, 1975), "Мөхәббәт юлы" (Өфө, 1982), "Шигырьләр һәм поэмалар" (1993), "Җиз кыңгырау моннары" (1998) исемле шигъри җыентыклар авторы. Аның поэзиясе өчен тапкырлык, эчкерсезлек, нечкә лирика, ягымлы юмор хас. А. "Ул кайтты" (1960) пьесасы белән, беренчеләрдән булып, тоткынлык газапларын кичереп, ватанына тугры калган совет солдаты образын чагылдырды. "Шоңкар" (1968) пьесасында шагыйрь Ш.Бабич образын сәхнә биеклегенә күтәрде. "Әсә хөкөмө" (1963), "Законлы никах менән!" (1965), "Мөхәббәт турында йыр" (1968), "Балакайзарым" (1970), "Ут" (1975) кебек пьесаларында бүгенге көн проблемаларын һәм тарихи вакыйгаларны яңартты. А.ның күп кенә пьесалары Башкортстан һәм Татарстан театрлары сәхнәләрендә куелды. Аның сәхнә әсәрләрендә җитди проблемалар күтәрелә, сюжет-композицион җирлек җитди уйланылган, кискен драматик көрәнешләр ягымлы юмор белән гадәти үрелеп бирелә. 2 нче дәрәҗәдәге "Ватан алдындагы бурычлары өчен" ордены һәм медальләр белән бүләкләнде. Уфада яшәде.

Әсәр.: Әсәрзәр: 2 томда. Өфө, 1988; Атнабай — халык шагыйре. К.,2000.

Әд.: Амиров Р. Годы оставляют песни //Чтобы шагнуть завтра. Уфа, 1982; Васфи Г. Поэмала заман геройы //Агизел.1962. №4; Каримов М. Шагир илендә //Агизел. 1978. №2.

*Автор:Р.К.Әмиров*

**АТРИБУЦИЯ** (лат. attributio — ачыклау, аныклау), аноним яки псевдоним астында язылган әсәрләрнең авторларын, язылу урынын һәм вакытын ачыклау. А. — текстологиянең мөһим бер өлеше. Сәнгать, әдәбият белемендә, тарихи чыганакларны өйрәнү эшендә А.ның әһәмияте зур. Урта гасыр татар әдәбияты ядкарьләрендә, кагыйдә буларак, әсәрнең соңгы бәйтендә автор үзенең псевдонимын куя торган булган:

Аты — Гали моны төзгән зәгыйфь колның,
...Изге рәҗәп аеның нәкъ утызында,
һәм тарихның нәкъ алты йөз утызында,
Бу зәгыйфь кол бу китапны төзде инде.

Гарәб графикасында язылган текстларны транскрипцияләгәндә еш кына, бер үк исемнең төрле укылышлары барлыкка килә, мәс., Мәүлә Колый һәм Меллагол. А. чыганакларны, аларның эчтәлеген анализлауга, автор теленең һәм стиленең индивидуаль үзенчәлекләрен ачыклауга нигезләнә. Ф.Сәйфи-Казанлы, Х.Хисмәтуллин, И.Нуруллин, Р.Гайнанов, И.Абдуллин, Р.Нафиков, М.Госманов, Ш.Садретдинов, З.Рәмиев, Г.Гыйльманов һ.б. тарафыннан Тукайның (70 ләп псевдонимы билгеле), Ф.Әмирханның (20 гә якын псевдонимы бар), С.Рәмиевнең, М.Гафуриның, Г.Камалның, Ш.Бабичның, М.Галинең, Г.Коләхмәтовның, Г.Кандалыйның күп кенә псевдоним белән язылган яки аноним әсәрләре ачыкланды.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*З.З.Рәмиев.*

**АУЭЗОВ** Мохтар Омархан улы (16.9.1897, Семипалат губ.-сы Чыңгыз волосте Чыңгызтау җәйләве — 27.6.1961, Мәскәү), казакъ язучысы, әдәбият галиме, җәмәгать эшлеклесе, Казакъ ССР ФАнең хакыйкый әгъзасы. "Караш-Караш үткәндә булган хәл" (1927), "Текәлек" (1935) повестьлары, "Яшьләр токымы" (1962) тәмамланмаган романы, "Енлик-Кебек" (1917), "Ак каен" (1938, А.Таҗибаев б-н берлектә), "Абай" (1940, Л.С.Соболев б-н берлектә), "Кобланды" (1945) пьесалары һ.б. әсәрләр авторы. Татар әдәбиятын үз иҗатын туендырып торучы мөһим чыганак — "сөт анасы" итеп исәпли. Мәс., Г.Ибраһимовның "Казакъ кызы" романы А.ның "Абай юлы" роман-эпопеясын язуга этәргеч ясый (1 китап "Абай", т.1–2, 1942–47, СССР Дәүләт бүләге, 1949; 2 китап "Абай юлы", т.1–2, 1952–56, Ленин премиясе, 1959). 1957 елда роман С.Әдһә-

мова тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителә. 1950 елларда М.Җәлилне татар халкына кайтаруда А. зур роль уйнады.

Әсәр.: Тандамалы шыгармалар: 6 томдык. А.-А., 1955–57; Сочинения: в 5 т. М., 1973–75.

Әд.: Каратаев М. М.Ауэзов. А.-А., 1967; Хәмидуллин Л. Чыңгыз иле Мохтары // Шәһри Казан. 1997. 19 сент.

*Р.К.Ганиева.*

**АФАНАСЬЕВ** Порфирий Васильевич (20.2.1942, Чирмешән р-ны Яңа Әлмәле а.), шагыйрь, Чуаш Респ-касының халык шагыйре (1998), атказанган сәнгать эшлеклесе (1992). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1964). 1965 елдан журналистлык эшендә, 1977–85 тә "Хатер пул" ("Әзер бул", Чабаксар ш.) балалар ж-лында баш мөхәррир булып эшли. 1986–90 да Чуаш АССРның Язучылар берлеге рәисе. 1998 дән Чуаш респ-касының Матбугат һәм мәгълүмат буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары. А.ның "Сакар" ("Икмәк", 1974), "Сан ятупа" ("Синең исмең белән", 1983), "Хевел хапки" ("Кояш капкалары", 1988) шигырьләрендә һәм поэмаларында, "Урхамахпа трубач" ("Ат һәм быргычы", 1969) балласында, "Вучах" ("Учаг", 1978) повестенда заман һәм кеше турында уйланулар урын алган. А.ның күп кенә әсәрләрендә — "Сарамсан кеввисем" ("Чирмешән көйләре", 1975) китабы, "Тав" (1999) исемле шигырь һәм поэмалар җыентыгында Татарстан темасы чагылыш таба. "Сан ятупа" драматик поэманың сюжеты Чирмешән буйларында барган Гражданнар сугышы вакыйгалары б-н бәйле. "Әльмәле чишмәләре" (1984) китабы туган авылына багышланган. Чуаш теленә Г.Тукай, Р.Харис, Р.Фәйзуллин һ.б. шигырьләрен тәрҗемә итә.

Әсәр.: Чирмешәннең йотым суы. К., 1990; Солнечные врата. Чебоксары, 1992.

Әд.: Ставский М. Эстетика тата чаваш илемле литературии. Шупашкар, 1993.

*В.П.Станьял.*

**АФЗАЛ** (Абзалов) Гамил Гыймазетдин улы (23.5.1921, ТАССРның Минзәлә кантоны Актаныш волосте Такталачык а. – 20.8.2003, Әлмәт ш.), шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1985), ТССРның халык шагыйре (1991). 1936-37 елларда Чиләбе өлкәсе Троицк ш.ндә Татар пед. техникумында укый. 1939-49 да Магнитогорск металлургия комб-тында төрле авыр хезмәтләр башкара, шунда сәламәтлеген югалтып, эштән китәргә мәҗбүр була. 1953 елда Башкортстан АССР Кушнаренко р-ны Шәрип а. на кайтып урнаша. 1965 тән Әлмәт ш.ндә яши. Әдәби иҗат эше белән 1936 елдан бирле шөгыльләнә. Беренче шигырьләре "Баку эшчесе" г-тасында (Магнитогорск) басыла башлый. 1955 елда "Совет әдәбияты" ж-лында басылган шигырьләре әдәбият тәнкыйтьчеләре һәм шигырь сөючеләр игътибарын җәлеп итә. А. шигъриятенең төрле жанрлары үсешенә мөһим өлеш керткән шагыйрьләребезнең берсе. Поэзиягә нечкә хисле лирик буларак килеп, 1960-70 елларда үткен, кыю телле сатирик булып танылa, фәлсәфи лирикага өстенлек бирә, 1980 елларда аның иҗатында публицистик аһәң көчәя, 1990 еллардан — тарихилык, халыкның үткәнен иңләү, мөстәкыйльлек, бәйсезлек өчен көрәшенә ярдәм итү, милли үзаңны уяту рухы арта. А. — "Кар сулары" (1957), "Вөҗдан сүзе" (1958), "Кояшлы яз" (1961), Ышаныгыз" (1971), "Айлы кичләр" (1977; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе, 1977), "Шундый-шундый эшләр" (1988), "Август йолдызлары" (1994), "Гомер кичүләре" (2001), "Туган як моңнары" (2001) исемле шигырьләре һәм поэмалары тупланган җыентыклар авторы. А. кыска хикәяләр, юморескалар авторы буларак та билгеле ("Кышкы озын кичләрдә", 1986; "Туган як моңнары", 2001 җыентыклары). Шигырьләре рус һәм башкорт телләренә тәрҗемә ителеп нәшер ителде; кайберләре көйгә салынып популяр җырлар булып китте. Әдәбият өлкәсендәге уңышлары өчен "Почет Билгесе" ордены белән бүләкләнде (1981).

Әсәр.: Бессонной ночью. М., 1966; Өфөф итеп. Өфө.1967; Сайланма әсәрләр. К., 1991; Гомер кичүләре.К., 2000.


Әд.: Юзиев Н. Ул матурлык эзли дөньядан // Шигърият дөньясы. К., 1981; Фәйзуллин Р. Халыкчан шагыйрь // Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т.4; Галиуллин Т. Тынгысыз каләмнең үлемсез шигърияте // Татарстан. 2001. №5.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Kitap kuzətu
Китап күзәтү

# КҮҢЕЛ КҮЗЕ НИ КҮРӘ?

Язучы Нәбирә Гыйматдинова 30 елга якын вакыт эчендә берсеннән-берсе кызыклы, мавыктыргыч, геройлары гыйбрәтле язмышка ия әсәрләре белән меңәрләгән китап укучының күңел дөньясына үз сукмагын салды, аларны табигатькә һәм кешеләргә мәрхәмәтле булырга өйрәтте. Туган җиренең, табигатенең кадерен белмәгәннәр үз-үзен һәлакәткә илтә. Бүгенге заманда халыкның вәхшиләнүе, кыргый хисләрне, явызлыкны алга сөрүе дә табигатьне нечкә тоемлый белмәүдән, аннан читләшеп, каланың таш диварлары арасына кереп посудандыр.




Әдибәнең "Икебезгә дә авыр" дип исемләнгән повестьлар, хикәяләр җыентыгын (2003) бер тын белән укып чыктым. Җыентыкка биш повесть, өч хикәя, тормышта булган хәлләр хакында язмалар тупланган.

"Тәкъдир" повесте ныклы гаилә кору һәм башка демографик, социаль, әхлакый проблемаларны күтәрә. Сәләтле, сөйкемле актриса Нәзирә, булдыксыз Гамилгә кияүгә чыгып, аның хыянәтен кичергәч, җаны чирле, үзе хиссез, төссез карачкыга әйләнә. Авторның портрет остасы булуы соклану уята. Бернича уңышлы чалым аша да күзендә уты сүнгән, моңлы-сагышлы хатынның эчке дөньясын ача ул. 35 яшеннән җаны картайган Нәзирәнең күңелендәге зилзилә сине үз эченә бөтереп ала, аның белән бергә шатланасың, кайгырасың, тетрәнәсең.

Яшьли сөйгәне Илһамның сөйрәлчек Маша белән йоклаганын ишеткәннән соң, бер дә киелмәгән туй күлмәге белән техникум тулай торагының коридорын юучы кыз хакында укыганда күзләргә яшь мөлдерәп тула. Бу күренеш аша автор яшь кыз кичергән фаҗиганең асылын ачып бирә. "Адәмгә ярату хисе вакытлыча гына бирелә, ә нәфрәт озакка...,—дип искәртә Нәзирә.—Әбиемнең догалары рәнҗегәндер",—дип тә өсти.

Авторның образ-характер тудыруда чагыштырулары да уңышлы: "үкенеч—көтүче чыбыркысы сыман", "чикерткә кебек бер сораудан икенчесенә сикердем", "Гамил куык кебек шиңде", "ак түшәм—кәфен кебек" һ. б. Әсәрдә юморга да урын бирелә: "запас ир ашарга сорамый, колхоз үгезе түгел". Шушы кечкенә генә деталь аша автор замананың бозыклыгыннан яшь аралаш көлә, аны фаш итә, җирәнү хисе уята. Ә әсәр эчендәге "Аккош әкияте" исә Нәзирә-Самат мәхәббәтенең сафлыгын сурәтли.

Повестьта тагын бер кискен мәсьәлә—сугыш һәм тынычлык проблемасы күтәрелә. Саматның әтисе Чехословакиядә ятып калса, үзе Чечняда, үзебезнең солдатлар кулыннан дөньядан китә. Ватандашларының бер гөнаһсызга бер-берен кырудан, бәхетенә бер генә адым калган, карынында сабыен йөрткән Нәзирәләрнең язмышы җимерелүдән, ятим-толлар артудан ил-көнгә ни файда? Бу әсәре белән Н. Гыйматдинова чаң кага. "Ярты-

Нәбирә Гыйматдинова. Икебезгә дә авыр: Повестьлар, хикәяләр. — Казан: «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы., 2002. — 416 б.

шар метр буйлы, фатирсыз, акчасыз ирләр беренче очрашуда ук Сылудан: "Фатирың ничә бүлмәле? Акчаң күпме? Туган-тумачаң бармы?"—дип сорыйлар. "Безнең илдә ирләрне төрмәдә черетәләр, Әфганда үтерәләр, Чечняда кыралар. Шулардан арткан фахишәләр тартып ала..." Бу юллардагы хакыйкать барыбызга да таныш. Ул бүгенге демографик кризиска тарыган җәмгыятьне сәяси гаепләү булып яңгырый.

Әсәргә сиздерми генә "Коръән" аятьләренең асыл фикерләре килеп керә. Ходайга ялвару, догалар көченә таяну кирәклеге китап укучының күңеленә кереп урнаша, гамь уята. Үзенең нарасые дөньяга "җилдән туган" булып килмәсен өчен, Нәзирә ирен тартып алган азгын Зәридә белән Гамилгә театр сәхнәсендә никах укыта. Бу йола гайре табигый шартларда үтәлүе белән гыйбрәтле. Горурлыгы булмаган, вакчыл, мескен, саран Гамилнең хатыны өйдә юкта йорт җиһазларын төяп чыгып китүе, хыянәте, соңыннан шартлаган куык хәлендә калуы—замана ирләренә чын гыйбрәт. Әйе, җинаять җәзасыз калмый. Киң күңелле, булдыклы, гаярь Самат Хәеровның хатын-кызга мөгамәләсе, ихластан сөя, кайгырта, яшәү өчен шартлар тудыра белүе соклану хисләре уята. Автор биредә чын гаилә башлыгының нинди булырга тиешлегенә ишарәли, бу образ укучы өчен өлге ролен үти. Ни кызганыч: асыл ир, сабые туачагын да белмичә, өзелеп сөйгән ярын бәхетсез итеп, вакытыннан элек дөньядан китәргә мәҗбүр. Бу—замана фаҗигасе, тәкъдирнең кабатлануы да. Әсәрдә психологизм, эчке киеренкелек көчле. Драматизм да ярылып ята, персонажлар сөйләме кызыклы, колоритлы, ул образларның холкын ачарга ярдәм итә. "Яшьлек бөресеннән картлык яфрак ярыр", "Караңгы баздагы бака да яктыга үрмәли". "Мин ак чәчәк таҗларына ябышып күтәрелмәкче булам", "Кульяулык кебек, кесәмә генә салып йөртер идем", "Бер-беребезнең күзендә йотылдык", "Хатын түгел, хәзинә икән син!" кебек төгәл, тирән эчке мәгънә салынган җөмләләр халык авыз иҗатының җәүһәрләрен хәтерләтә, әсәрнең идея-эчтәлеген ачарга ярдәм итә. Н. Гыйматдинованың туган телне әйбәт белүе, мишәр шивәсенең бизәкләрен оста файдалануы башка әсәрләрендә дә ярылып ята.

Н. Гыйматдинова рус әдәбиятындагы "говорящие имена" алымын да оста куллана, тәмәкечене—Моржабай, хатыны ташлап качкан Шакирны—Нокталы Мыжык дип атый. Нәзирә—назлы гөлгә тиң, Гамил исә ике дөньядан гафил калган. "Йөземдә таш елмаю, йөрәккә шыбыршыбыр яшь коела" дигән җөмләдә исә нисби сыйфат белән белдерелгән эпитет—Нәзирәнең эчке халәтен бер җөмлә аша ачып сала.

Авторның фәлсәфи фикерләре әсәрнең егәрен арттыра: "Безнең яшәү—ул ак белән караның чиратлашып еллар упкынына коелуы." Ул китап укучыга гомернең кадерен белеп, игелек кылып, яхшы уй уйлап, мәгънәле итеп яшәү кирәклеге хакында сөйли. Нәбирәнең үткен каләме битараф чырайлы бюрократларны "чеметкәләргә" дә онытмый. Әсәрдә социаль психология киң чагылыш таба: "Гаҗәп кеше дигән зат: син бәхетле икән—көнләшүеннән изә, таптый; мескен икән—кулына күтәрә." Ә нигә, дөрес түгелме? Аз гына уңышка ирешсәң дә, бүре көтүедәй ябырылып, сине өзгәләп атарга тырышучылар азмы?

Әсәрдә Нәзирәнең чын ир-егет Саматтан балага узып калуы символик мәгънәгә ия. Димәк, асыл нәсел дәвам итәчәк! Ә буш куык Гамилнең бозык Зәридәсе тапкан бәби аныкы түгел икәнлеге ачыклана.

"Тәкъдиремдә язылган ролем искиткеч катлаулы. Мин—зиратта йоклаган Саматымның догачысы, мин—әүлия кайнанамның килене, мин—улымның әнисе, мин—Илһам атлы ирнең мәңге сүрелмәс ялгыз мәхәббәте..."

Әсәрне күңел күзе белән уку гаилә корырга, бәхетле тормышта сөелеп һәм сөеп яшәргә омтылган һәркемгә җан азыгы бирә, гыйбрәт алырга мөмкинлек тудыра, әхлак сафлыгын сакларга өндиөйрәтә.

"Аргы очта, бирге очта" повестенда замана яшьләрен талаштырган Җәнҗал образы сюжет сызыгының буеннан-буена сузыла. Ул интригалар кора, гашыйкларны аера, карындагы сабыйлар язмышына кизәнә, яшьләрне ут йотарга мәҗбүр итә, аерылмас дус булырга, мәңге бергә яшәргә ант иткәннәрне чәкештерә. Әгәр Нәбирәбез бу повестьне драматик

әсәр итеп үзгәртеп язса, шәп кенә трагокомедия чыгар иде дигән тәкъдимем бар, чөнки репликалар шәп, динамика көчле. Бу әсәрдә детектив элементлары да, серлелек тә бар.

Җыентыкка исем биргән "Икебезгә дә авыр..." повесте исә тирән фәлсәфи мәгънәгә ия. Исеме үк шомландырып тора. Әсәрнең төп герое, Зәмзәмиянең әтисе Хәбир мулла мәчет манарасын кисәргә күтәрелгән Кызыл Гыйниятне атып үтерә, үзе урманга— серле, сихерле Тоба чокырына яшеренә, шунда суык тидереп үлеп тә китә. Язмыш бу фаҗиганең тамырларын тирәндә калдырса да, ябалдашлары белән яшь буынны да бәйли, аннан үч ала. Мәчетсез, манарасыз, иман нурыннан аерылган буыннан башкисәр Ибрай белән Фәррахлар, җан көеге, куркак Зәкиләр үсеп чыга. Хәбир мулладан заманында дин сабагы укып калган, тәне гарипләнсә дә җаны мәрхәмәт белән сугарылганга, эчке дөньясы матур, саф калган Вәгыйз генә кара каргалар төркемендә ак күгәрчендәй аерылып тора. Иң авыр минутларында, вәхши абыйларыннан кыйналып, гарипләнсә дә, мәхәббәтеннән ваз кичми, Зәмзәмиягә тугрылыклы дус булып кала. Аның милиционер булып эшләүче башкисәр абыйлары икесе дә якты дөнья белән вакытсыз хушлаша, бу—залим хакимлекнең үлемгә дучар ителәчәгенә ишарә.

"Бүре каны" повестенең нигезендә "бүре канын эчкән бала гаярь була" дигән гыйбарә ята. Аю Кәрим, ерткыч җанварны юк итү бәрабәренә, җебек Рамазанда хәйләкәрлек, явызлык көчен генә уята ала, малайдан башкисәр үсә.

Әтисенең "йонлач кулы", арттан этүе белән вузга кергән Рамазан, сәләтсез булса да, әрсезлеге, юлында очраганнарны сытып, изеп баруы бәрабәренә, карьера өчен үзенә игелек иткән кешеләр өстеннән гайбәт җыя, яратмаса да, түрә кызына өйләнә, йомшак кәнәфигә үрмәли. Мәкер һәм хәйлә юлы белән әдәбият мәйданына еландай шуышып керә. Чын шагыйрь Рөстәм Акчуринга кизәнә, талантлы шәхеснең эш урынын тартып ала, аны үлемгә этәрә. Ләкин тыштан карагандa барысы да ал да гөл тоелган, максатына ирешкән Рамазанның да тамыры черек шул: улы Руслан аның нәкъ үзе шикелле пешмәгән, чирләшкә бала булып туа. Әтисе ысулын кабатлап, аңа да бүре каны эчертеп дәваларга омтылган ир, ерткыч тешләреннән үзе җан тәслим кыла. Бу—символик финалга эчке мәгънә салынган. Табигатьнең эчке закончалыкларына буйсынмаганы, кешелексезлеге, мәкер белән үткән гомере өчен Илаһи көч аннан шулай үч ала.

Әсәрдә табигать һәм кеше проблемасыннан тыш, җәмгыятьнең төрле катламнарындагы, гаиләдәге, эш урынындагы, югары даирәләрдәге, түрәләр вә халык арасындагы үзара мөнәсәбәтләр оста ачып бирелә. Язучының тормышны тирән аңлавы, төрле катламнарның хәләхвәлен, яшәү рәвешен, социаль психологиясен шәп белүе тулыканлы образлар тудыра. "Түрә белән бер ләүкәдә парланып утырсаң, фатирсыз икәнсең—фатирга тиенеп чыгасың, хәерче икәнсең—байыйсың. Яши белә түрәләр! Орып бирәләр халыкның аһ-зарын. Халык аста, түбәндә, ә байлар өстә—күрмиләр, ишетмиләр." Бу юллар аша Нәбирә тормыш чынбарлыгын, хакимияттәгеләрнең нинди юллар аша дәрәҗәле кәнәфиләргә ирешүен, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып, таптәреп яшәвен ачык мисаллар, җанлы образлар аша фаш итә. Язучы-журналист буларак, ул халык белән еш аралаша. "Хакимияттәгеләрдән зарланып, елый-елый сөйлиләр",—ди Н. Гыйматдинова. Халык моң-зары "Утарда" повестендагы ятимә, ире ташлап киткән, ярымкыргый хәлендә яшәүче Хәят образында тоела. Автор аңа теләктәшлек күрсәтә, хәленә керә. "Урмандагы һәр агач, һәр үлән, һәр бөҗәк әңгәмәдәш миңа",—ди ул. Хәтта ач бүреләр дә ялгыз хатынга зыян салмый.

Пәри Хәят урман уртасында, буранда ташлап калдырылган Рөстәмне үлем халәтеннән чыгара, Газраил кочагыннан тартып ала. Яшәү өчен көрәш кискен була. Кабаттан тормыш бүләк итүче Хәят та өлешсез калмый, Ходай Тәгалә Рөстәм белән икесе арасында сихри мәхәббәт хисен уята. Ырудан читләшкән ак бүре халәтендәге Хәят кешелек сыйфатларын югалтмавы, бай күңел дөньясы, язмыш җилләрендә газапланса да, сүндермичә, исән-имин калган мәрхәмәт хисе белән матур, үзенә җәлеп итә. Әсәрдә диалекталь сүзләр дә отышлы файдаланылган.

"Урман эче бозлы баз кебек. Пәри Хәятның умарталыгыннан халык бал

алырга да курка". Бу—табигыйлеген югалткан җәмгыятьнең ялгышына, курkaклыгына ишарә. "Биш ел утымны сүндермичә сакладым, йөрәгемдә генә ут юк, сүнде, бетте",—ди Хәят. Ул бәлагә тарыган адәм баласын да, җәнлек-җанварларны да дәвалый, терелтә, кабат җан өрә. Әсәрдә Ак бүре белән Соры бүренең мәхәббәт кыйссасы күзләргә яшь китерә. Ерткычларда да тугрылык, сөю бар икән. Ялгыз бүре белән Хәятнең сөйләшүе тәннәрне чеметтерә: "Искәндәр мине синең туфракка орлык итеп күмде, ни шыта, ни үлә алмыйм." Бу юллардагы тирән мәгънә илен җуйган, туган туфрагыннан аерылган меңләгән мөһаҗирләрнең, качакларның фаҗигасе түгелме соң? Әсәрдәге замана эшкуарларының үзара мөнәсәбәтләре, гамәле, эчке дөньясы, кыланмышлары ышандыргыч итеп, хәтта беркадәр комик төсмердә сурәтләнгән.

Әсәргә, гомумән, уңай бәя бирсәк тә кытыршылыклар хакында да искәртеп үтмичә булмый. "Аргы очтан-бирге очта" әсәрендә (93 бит) фактик төгәлсезлек киткән. "—Җә, мин гаепле ди, җә, кичер... Дамир кызның каршысына тезләнде." Бу очракта Дамир түгел, Галим Равиядән гафу үтенергә тиеш иде. 112 нче биттә: "Галим малаеның әтисе Дамир дип битемнән көләчәкләр"—диясе урынга, "битемә төкерәчәкләр" яки "күземә карап көләчәкләр" дип төзәтү урынлы булыр иде. 114 нче биттә: "Беренче Дамир телгә килде" дигән җөмләдә төгәлсезлек күзәтелә. Ирексездән, "Икенче Дамир да бар микәнни?"—дип уйлыйсың. Ул җөмлә әсәр кабаттан нәшер ителгәндә "Беренче булып Дамир телгә килде",—дип төзәтелсә отышлы булыр иде.

"Озын чәчле, йомшак куллы, моңсу карашлы" Хәятнең шәүләсен Рөстәм җанына салып алып кайта. Мәхәббәт күзлегеннән карый башлагач, аның үз дөньясы, эчке байлыгы барлыгы, ясалма чәчәктәй Җем-җемияләрнең исә иссезлеге, хиссезлеге күренә. "Күкенең бала чыгарырга тән җылысы җитми, шуңа бәхетсез"—дигән гыйбарә дә йөрәккә уелып кала. "Ә бездә бәхетле булырга, якыннарыбызга шатлык өләшергә, мәгънәле итеп яшәргә җылылык җитәрме?!" Бу риторик сорауга да җавапны китап укучы үз күңеленнән эзләр.

Нәбирә Гыйматдинованың "Икебезгә дә авыр..." җыентыгында тормыш фәлсәфәсенә бай, тирән кичерешләр уятырлык "Базар хатыны", "Сурәт", "Манара" кебек хикәяләре дә урын алган. "Тормышта булган хәлләр" циклындагы язмалары гыйбрәтле вакыйгаларны, язмышларны йөгерек тел белән сурәтли.

Бу җыентыкны талантлы язучыбызның тынгысыз рухи эзләнүләре нәтиҗәсе, татлы иҗат җимеше, уңышы диясе килә.

**Хәмидә ГАРИПОВА**

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Язучы, тәнкыйтьче, рәссам бергә киңәшләшә.*
*Уңнан сулга—Шәриф Камал, Гази Кашшаф, Байназар Әльминов.*
*1941 ел.*



*Татарстанның баш архив идарәсе башлыгы, тарихчы-публицист Дамир Шәрәфетдинов. 1998 ел.*



*Татарстанда яңа оештырылган телевизион үзәктә. Сулдан уңга: шагыйрь Мостафа Ногман, композитор Рөстәм Яхин, музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина. Үткән гасырның 60 нчы еллары.*



*Язучыларның Матбугат йортында урнашкан (Бауман, 19) Тукай исемендәге клубның эчке күренеше. Ярты гасырдан артык дәвердә әдипләрнең бергә-бергә җыйналышып фикер алыша торган үзәге иде ул. Үткән гасырның 50 нче еллар фотосы.*



*Язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе Зәки Зәйнуллин. 1996 ел.*



*Мәскәүдә яшәүче язучы-публицист Вахит Юныс. Лондон, 1997 ел.*

## *Укучы сүзе*

* * *

Кадерле редакция!

“Казан утлары”н мин даими рәвештә һәр санын укып барам. Күбрәк шигырьләр, әдәби тәнкыйть, яналыклар белән кызыксынам. Үземнең күнел тәнгәллегенә туры килгәннәре турында бер-ике кәлимә сүз язып китмәкчемен.

2004 нче елда Солтан Шәмсинең “Күк капусы ачылса...” дигән гыйльми язмасын һәр сан саен кызыксынып укып бардым.

“...2003 нче елның 21-28 нче мартлары тирәсендә (ялгышмасам) Җиргә Аллаһ тарафыннан Өченче амнистия җибәрелгән” дигән хикмәтле юллар бар иде. Мин дә, туктале, бу көннәрдә берәр нәрсә яздым микән дип, шигырьләр язып йөрткән калын дәфтәремне күтәрдем, һәм хәйран калдым. 27 нче мартта минә шушы юлларны язган булганмын:

Терәү таянычым булган “ауган”
Аллаһ миңа янә сынау куйган:
—Әлиф таягына таянырга Вакыт,
колым,
Сере изге Корьән. Үзең, улың,
Илең илә өйрән!

“Казан утлары” 2005. 1, 2 нче саннарында Айдар Хәлимнең: “Сез беләмсез кая барганны?” дигән язмасын эчендә җаны булган адәм тыныч кына укый алмагандыр, дип уйлыйм. Бик тә мөһим мәсьәләләрне күтәреп чыккан Айдар абыйның бу язмасы күнелдә зур тәэссоратлар тудырды. “Тәнкыйть—тыйнак тәкать таләп итә”—дигән үз әйтемем белән, сүземне куәтләп, ахырында тагын бер фәһемле юлларга тукталып үтәсем килә:

“Иман кирәк, милләтебезне, телебезне саклап калу өчен, динебезне аякка бастырырга кирәк”.

Айдар абыйның бу юллары Киләчәккә мәкаль булып яңгырагандай. Шундый тирән эчтәлекле, каршылыклы фикерләр тудырудан элек, тәрбияви мәгънәгә ия булган язмалар тудыручы әдипләребез, милли рухлы журналларыбыз исән булганда, иншалла, милләтебезнең, әдәбиятыбызның дәрәҗәсе түбән тәгәрәмәс дип ышанасы килә.

### Вәсвәсәле дөнья

**Рәхмәттән сөрелмеш, азгын җанлы**
**Иблис күзен буган хаклыкның**
**Вәсвәсәле дөнья мәшәкате,**
**Мал кайгысы кайгы халыкның.**

**Дөнья фетнәсенә аңын җигеп**
**Билен бөгә телсез, күрәмсез.**
**Хөкүмәтнең икътисади хәле**
**Халык инен баса иләмсез.**

**Кан басымы төсле күтәрелә**
**Яшәешкә түләү бәясе.**
**Хезмәт хакын күтәрергә Илнең**
**Үлчәүләре көйсез, күрәсең.**

**Вәсвәсәле дөнья хөрриятен**
**Хәрам малдан тапса Кешелек,**
**Интернеттан хәерчелек яный**
**Илнең дәрәҗәсен төшереп.**

**Җинүчедәй айлы әләм тоткан**
**Төн күкрәгеи ачкан Галәмгә,**
**Аллаһунын ризалыгын тапмый**
**Дәрәҗәләр иңмәс дәвергә.**

**Наилә МИҢНЕХАНОВА,**
*Башкортстан, Туймазы шәһәре.*

*Котлыйбыз!*

# ҖИР УЛЫ



Бөтен гомерләрен, хезмәтләрен, иҗатларын авылга багышлаган, язар өчен җирлекне, рухи байлыкны да шул мохиттән, яшәештән алып иҗат иткән шәхесләребез бар безнең. Шушы айда үзенең олуг юбилеен билгеләп үтүче Фәйзи ага Галиев әнә шундый олпат затларыбызның берсе. Фәйзи Галиевнең тормышы да, иҗаты да туган җирдән, авыл кешеләреннән аерылгысыз. Бар тырышлыгын оештыру эшенә—колхоз белән җитәкчелек итүгә багышлаган Ф. Галиевнең әсәрләрендәге геройлары да үз авылының фидакарь затлары, җир кешеләре.

1925 елның 14 июлендә Әтнә районы Түбән Шашы авылында туган егетнең дә язмышына Бөек Ватан сугышы җилләре кагылмыйча калмый. 1942 елда армия сафларына алынып, командирлар әзерләү мәктәбен тәмамларга да өлгермичә сугышка озатыла, 1944 елда яраланып туган авылына кайта. Кайтуына озак та үтми, аны шушы ук авылга колхоз рәисе итеп сайлап куялар, 1993 елга кадәр 49 ел буена рәислек дилбегәсен кулыннан төшерми. Әйе, күңел салып, намус белән башкарган хезмәтнең даны да, дәрәҗәсе дә, хөрмәте дә зур. Ф. Галиев эш дәверендә, СССРның һәм Татарстанның Югары Советлары депутаты итеп сайлана, Ленин ордены, ике мәртәбә Хезмәт Кызыл байрагы орденнары, Ватан сугышында катнашкан өчен икенче дәрәҗәдәге Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә, Татарстан республикасының атказанган агрономы һәм РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы эшчесе дигән мактаулы исемнәргә лаек була.

"Фронтта—солдат, ә авылда генерал булдым",—дип әйтергә ярата Фәйзи ага. Ә генералның киләчәк буыннарга әйтеп, язып калдырасы сүзләре аз булырмы?! "Булгач булгач булсын инде", дипме, Ходай ана каләм сәләтен дә өстәп биргән. Аның тарафыннан татар халкының гореф-гадәтләрен, тырыш хезмәт белән көн күргән яшәеш рәвешләрен чагылдырган, игенчегә, авыл халкына багышланган "Икмәк язмышы", "Авылым гадәтләре" исемле китаплары дөнья күрә. 1992 елның 15 апрелендә ул Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә. Күпне күргән ветеран бүгенге көндә дә исән-сау, ил-көн өчен борчылып яши, иҗат итә.

**Редакция коллективы юбилярны олуг бәйрәме белән чын күңелдән котлый, иҗат уңышлары тели.**

*Берлекнең яңа әгъзалары*

## Дания Заһидуллина



Заһидуллина Дания Фатих кызы 1964 елның 1 октябрендә Мөслим районы Әмәкәй авылында туа. Мәктәптә укыганда шигырьләр яза, алар район газетасында басылалар. "Авыл утлары" каршында Ф. Садриев оештырган әдәби түгәрәккә йөри.

1981 елны Казан дәүләт университетының филология факультетына укырга керә. Монда да "Әдәби сүз" стена газетасын чыгаруда, Мөхәммәт Мәһдиев җитәкләгән "Әллүки" түгәрәгендә актив катнаша, әдәбият белән кызыксынып китә, профессор Й. Г. Нигъмәтуллина оештырган семинарларга йөри.

1986 елны университетны кызыл дипломга тәмамлагач, гаиләсе белән авыл мәктәбенә укытырга китәләр. Балтач районы Түнтәр урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.

1989 елны гаилә Казанга күчә, Д. Ф. Заһидуллина рус мәктәбендә татар теле укыта башлый. Шул ук елны Мәскәү Милли мәктәпләр институты каршындагы аспирантурага керә, әдәбият укыту методикасы мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Казанда татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты ачылгач, аспирантурада укуын биредә дәвам итә. 1992 елдан—университетта укытучы. 1993 елны "Татар әдәбияты дәресләрендә лирик әсәрләр өйрәнгәндә укучыларга әхлакый-эстетик тәрбия бирү (V-VIII класслар)" дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Республикада чыга торган газета-журналларда фәнни мәкаләләр, язмалар белән даими чыгышлар ясый.

Д. Ф. Заһидуллина фәнни тикшеренүләрне берничә юнәлештә алып бара. Татар әдәбиятын мәктәпләрдә укыту методикасы мәсьәләләре белән бәйләп, 1917 елга кадәр эшләп килгән татар укыту системасы, мәктәп-мәдрәсәләрдә гамәлдә йөргән әдәбият дәреслекләре хакында мәгълүматлар туплый. Бу дәреслекләр бөтенләй өйрәнелмәгән өлкәгә—әдәбият теориясеннән беренче дәреслекләр һәм татар әдәбият нәзариясенең формалашуына алып килә. Нәтиҗәдә, 2000 елны ике зур хезмәт бастырып чыгара: "Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы" һәм "Әдәбият кануннары һәм заман *(Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары)". 2001 елны "Татар әдәбият нәзариясенең формалашу һәм үсеш этаплары (XX гасырның беренче чирегe)*" дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Хәзерге вакытта да Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетында, татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасында эшли, профессор. "Татар әдәбиятын укыту методикасы", "Әдәбият белеменә кереш" дигән предметлар укыта, филология фәннәреннән диссертацияләр яклау Советында Гыйльми сәркатип вазифасын башкара.

Заһидуллина Д. Ф. татар әдәбияты, аның тарихы, бүгенге торышы белән дә ныклап шөгыльләнә. XX йөз башы татар әдәбияты, иҗади һәм фәлсәфи фикер үсешен күзәтеп, моңа кадәр татар укучысына аз билгеле булган әсәрләрне анализлап, татарлар өчен яңа өлкәгә караган зур хезмәт—"Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы" (2003) дигән монография яза. Әдәби мирасны укучыга кайтаруга үзеннән өлеш кертә. Мәсәлән, Гали Рәхимнең әдәби мирасын гарәп язуыннан кириллицага күчереп бастырып чыгару—шундыйлардан *(Гали Рәхим. Сайланма әсәрләр, 2004)*. Д. Заһидуллина 80-нән артык фәнни хезмәт авторы. Галимә бүгенге татар прозасын өйрәнә, бигрәк тә татар әдәбиятындагы стиль үзгәрешләре, әдәбиятка яңа алымнар үтеп керү, юнәлеш-агымнарның барлыкка килүе кебек үзенчәлекләр белән кызыксына. "Казан утлары", "Мәйдан", "Мәгариф" журналларында мәкаләләре даими басылып килә.

2005 елның 24 маенда, Кабул итү комиссиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә язучылар: Т. Н. Галиуллин, Ф. М. Сафин, Х. Й. Миннегулов), Язучылар берлеге Идарәсе Заһидуллина Дания Фатих кызын Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.

Ictimaği-mədəni
tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни
тормышыбыздан

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ КОРЫЛТАЕ

27 май көнне "Казан милли мәдәният үзәге"ндә Татарстан язучыларының XV корылтае булды. Аны кереш сүз белән күренекле драматург Туфан Миңнуллин ачты.

Премьер-министр Рөстәм Миннеханов корылтайда катнашучыларны Татарстан Президенты, Министрлар Кабинеты һәм Дәүләт Советы исеменнән сәламләде. "Язучылар съезды—республикабыз өчен күренекле вакыйга,—диде ул. — Сезнең иҗатыгыз җәмгыятьтә барган вакыйгалар белән аерылгысыз. Сез социаль тотрыклылыкны тәэмин итүдә, демократик процессларны ныгытуда, милли мәдәният һәм телне саклауда алгы сафта торасыз. Күптән түгел үзенең 70 еллыгын билгеләп үткән ТР Язучылар берлеге республикада мәдәниятнең югары үсешен билгеләүче иҗат оешмаларыннан берсе санала".

Хөкүмәт Рәисе үзенең чыгышында бүгенге язучыларның иҗат итү өчен чикләнмәгән иреккә ия булуларын, үз чиратында, сүз осталарының да җаваплылыкны арттыруын билгеләп үтте. "Шуңа күрә дә иҗатыгыз өчен шартлар тудыру мәдәният өлкәсендә республика дәүләт сәясәтенең өстенлекле бурычларыннан берсе булып тора. Милләтне рухи яктан савыктыру, тормыш дәрәҗәсен күтәрү, җинаятьчелек белән көрәш, социаль киеренкелекне йомшарту—җәмгыятьнең төп бурычлары. Шушы эшләрнең башында безнең язучыларыбыз торырга тиеш",—дип искәртте Премьер-министр.

Аннары Рөстәм Миннеханов каләм әһелләре Роберт Миңнуллин, Рәфкать Кәрами, Рәдиф Сәгъди һәм Нонна Орешинага Татарстан һәм Россиянең мактаулы исемнәрен бирү турындагы таныклык һәм билгеләрне тапшырды, ә Язучылар берлегенә яңа "Газель" микроавтобусы бүләк итте.

Язучылар берлеге идарәсенең ике корылтай арасындагы эшчәнлеге турында хисап доклады белән идарә рәисе Фоат Галимуллин чыкты. Ул үзенең чыгышында соңгы өч елда үткәрелгән күпкырлы оештыру чаралары хакында бәян итте, шушы чордагы әдәби хәрәкәткә кыскача анализ ясады, төрле жанрлардагы аерым уңышлы әсәрләрне бәяләп узды, әдәби тәрҗемә эшен җайга салу, милләтара әдәби бәйләнешләрне ныгыту, язучыларның иҗат һәм көнкүреш шартларын тагын да яхшырту, китап сәүдәсен җанландыру буенча көнүзәк мәсьәләләргә игътибар юнәлтте, каләм әһелләре алдында торган күп кенә проблемаларны чишүдә республикабыз җитәкчелегенең булышлык күрсәтүен билгеләп үтте.

Ревизия комиссиясе хисабын аның рәисе Фарсель Зыятдинов ясады. Әдәбият фонды идарәсе рәисе Гәрәй Рәхим үз чыгышында язучыларны матди яктан кайгырту мәсьәләләрен үзәккә куеп сөйләде.

Әдәби жанрлар буенча Дания Заһидуллина (проза), Тәлгат Галиуллин (шигърият), Дания Гыйммранова (драматургия), Лилия Газизова (рус телендәге әдәбият), Рафис Корбан (балалар әдәбияты), Әлфәт Закирҗанов (әдәби тәнкыйть), Кыям Миңлебаев (әдәби тәрҗемә) махсус докладлар белән чыкты.

Докладлар буенча фикер алышуда Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, язучылар Рим Идиятуллин (Уфа), Вахит Имамов, Рабит Батулла, Равил Фәйзуллин, Нонна Орешина, Зөфәр Дәүләтов, Айдар Хәлим, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Владимир Лавришко, Фәйзи Галиев, Эльмира Шәрифуллина, Факил Сафин, Мансур Вәлиев, Альберт Хәсәнов, Галимҗан Гыйльманов, Лев Кожевников, Мәдинә Маликова, Нияз Акмал, Нәҗибә Сафина, Рәшит Ягъфәров, Әхмәт Рәшит, Лена Шагыйрьҗан катнашты. Алар үзләренең чыгышларында иҗтимагый тормышта әдәбиятның, һәрбер каләм әһеленең, иҗат оешмасының ролен күтәрү, китап бастыру һәм аны тарату, милли көндәлек матбугатны үстерү, күренекле әсәрләрне дөньяга тагын да киңрәк таныту, язучылык хезмәтен закон тәртибендә яклау h. б. шундый мөһим мәсьәләләр буенча уй-теләкләрен белдерделәр.

Фикер алышу барышында әйтелгән эшлекле фикер-тәкъдимнәр нигезендә корылтай резолюция кабул итте.

Корылтай утырышларын Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, шагыйрьләр Роберт Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев алып барды.

Съезд эшендә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов, Казан хакимияте башлыгы урынбасары Әлфия Тутаева, Дәүләт Советы депутатлары катнашты.

Корылтайда альтернатив нигездә зур күпчелек тавыш белән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп Илфак Ибраһимов (Мөхәммәт Мирза) сайланды. Берлек идарәсенә түбәндәге язучылар үтте: Рабит Батулла, Мансур Вәлиев, Мөдәррис Вәлиев, Разил Вәлиев, Лилия Газизова, Марсель Галиев, Мансур Гыйләҗев, Зөфәр Дәүләтов, Дания Заһидуллина, Ркаил Зәйдулла, Вахит Имамов, Камил Кәримов, Рафис Корбан, Сергей Малышев, Зиннур Мансуров, Роберт Миңнуллин, Газинур Морат, Шаһинур Мостафин, Гәрәй Рәхим, Данил Салихов, Факил Сафин, Равил Фәйзуллин, Зиннур Хөснияр.

Язучылар корылтаенда шулай ук ревизия комиссиясе сайланды.

## ТАТАР ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫ

Медиа-форумны "Йөз еллык матбугатыбыз: үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге" дигән темага фәнни-гамәли конференция ачып җибәрде. ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин конференциядә катнашучыларга юллаган котлауда билгеләнеп үткәнчә: "1905 елда чыккан "Нур" газетасы белән халкыбызга нур тарала башлый. Мәгърифәткә, янарышка һәм милли үсешкә сусаган татар халкын әлеге басма үзенә тарта. Алай гына да түгел, үзеннән соңгы басмаларга да нигез сала. Шул вакыттан бирле татар вакытлы матбугаты егерменче йөзнең төрле катлаулы чорларындагы тарихи вакыйгаларның алгы сафында булды".

КДУның Журналистика һәм социология факультеты деканы Васил Гарифуллин чыгышында татар журналистикасын өйрәнү проблемаларын яктыртты, шул исәптән күп томлы татар журналистикасы тарихы булмавын, мөһаҗирлек матбугатының тиешенчә өйрәнелмәвен ассызыклады, аларны хәл итү өчен ул махсус үзәк төзергә тәкъдим итте. Пленар утырыш 1990 елда Санкт-Петербургның татар җәмгыяте көче белән кабат нәшер итепә башлаган "Нур" татар газетасының баш мөхәррире Ренат Мәһдиев чыгышы белән йомгакланды.

## ЯХШЫЛАР ИСӘБЕНДӘ

Лондонның Mercer Human Resource Consulting компаниясе экспертлары, иминлек һәм кешеләрнең тормыш дәрәҗәләренә карап, дөньядагы шәһәрләрнең рейтингын төзегәннәр.

Мондый рейтинг һәр елны төзелә һәм бу төрле илләр турында тулырак мәгълүмат бирү өчен эшләнә. Тикшеренү нәтиҗәләре буенча, дөньяда иң куркынычсыз шәһәр дип Люксембург танылган. Икенче урында—Хельсинки һәм Швейцариянең Берн, Женева, Цюрих шәһәрләре. Алдагы урыннарда тагын Вена, Мюнхен, Осло, Франкфурт, Омута, Цикуба, Копенгаген, Сидней кебек шәһәрләр бар.

Россия шәһәрләре, илдәге икътисади киеренкелек һәм тотрыксызлык аркасында, лидерлар рәтенә эләкмәгән. Әмма, дөньяда шәһәрләрнең бихисап күп булуын искә алсаң, 200 иң-иң шәпләр арасына керүчеләр бар. Мәсәлән, Санкт-Петербург—175 нче, Мәскәү 198 нче урында. Ә Казан белән Новосибирск башкаланы уздырганнар—әлеге ике шәһәр 179 нчы урынны бүлешә.

Бу исемлекне төзегәндә 39 фактор, шул исәптән шәһәрнең сәяси, социаль-икътисади, экологик хәле, кеше гомере өчен куркынычсызлыгы, сәламәтлек саклау, мәгариф һәм транспорт системасы эшчәнлеге искә алына.

## БЕЗНЕҢ БӘЙРӘМ

***

19 майда Татарстан журналистлары үзләренең профессиональ бәйрәмен билгеләп үтте. Бәйрәм "Идел-Пресс" нәшрият йорты янында журналистлар аллеясын ачудан башланды. Тантанада ТР Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева һәм "Татмедиа" мәгълүмат агентлыгы генераль директоры Марат Моратов һәм башка рәсми вәкилләр катнашты. Газета-журналларның баш мөхәррирләре һәм журналистлар аллеяга зәңгәр чыршылар утырттылар. Аллеяның башында беренче булып "Казан утлары" хезмәткәрләре утырткан үсенте яшелләнеп утыра.

Бәйрәм Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы янында дәвам итте. Биредә журналистлар газета-журнал укучылар белән очрашып, төрле тамашаларда катнаштылар, сәнгать осталары чыгышын карадылар.

***

Татарстан Матбугаты көненең кульминация мизгеле Татарстан Республикасының "Бәллүр каләм—2005" VIII журналистлар конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булды.

Быел йомгаклар 15 номинация буенча чыгарылды. "Яңа гасыр" телерадиокомпаниясе генераль директоры, ТР Дәүләт Советы депутаты Илшат Әминов җитәкчелегендәге конкурс комиссиясендә танылган журналистлар, республика ММЧ җитәкчеләре һәм әйдәүче хезмәткәрләре бар иде.

Тантаналы чараны ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, республиканың Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова һәм ТР "Татмедиа" массакүләм коммуникацияләр агентлыгы генераль директоры Марат Моратов ачты. Татарстан Президенты, Республика Дәүләт Советы Рәисе исеменнән котлау сүзләрен ТР Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов җиткерде. Ул җәмгыятьтә күзәтелгән процессларның иң катлаулылары да журналистлар хезмәте ярдәмендә күпкә җиңелрәк узуын билгеләп үтте.

"Темасы җирле, осталыгы—башкаладагыча" номинациясендә район һәм шәһәр газеталары битләрендә бастырылган иң яхшы журналистик хезмәтләрне Наталья Клюева ("Ленинская правда" Түбән Кама берләштерелгән газетасы), Елена Сабакаева ("Нижнекамское время" газетасы), Элифел Таразова ("Яшел Үзән" газетасы) тәкъдим иткән. Шәһәр газеталары арасында алдынгы дип "Ленинская правда" (Түбән Кама) газетасы табылган, ә районныкылар арасында—"Нократ" (Мамадыш).

Республикадан читтә татар телендә нәшер ителүче ММЧ өчен "Туган тел" номинациясендә җиңүче дип "Авылым хәбәрләре" нәшрият йортының (Новгород өлкәсе, Краснооктябрьск районы) баш мөхәррире Камил Фәтхуллин билгеләнгән. Бу номинациядә кызыксындыру бүләген керәшен татарларының "Туганайлар" (Чаллы) газетасы алды.

Конкурс комиссиясе карары нигезендә, Рөстәм Миңнеханов "ВАЗ–2110" автомобиле ачкычын Югары Ослан районы газетасы мөхәррире Римма Троицкаяга тапшырды.

## КИТАПХАНӘ ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАП

16-17 майда Казанда Татарстан Милли китапханәсенең 140 еллыгына багышлап, китапханә хезмәткәрләренең төбәкара фәнни-гамәли конференциясе булып узды. Ул "Бүгенге социаль-мәдәни үзгәрешләр барышында китапханәләрнең үсеш тенденцияләре" дигән темага багышланды.

Конференциядә кереш сүз белән Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Милли китапханәнең Химаячеләр шурасы рәисе Р. Вәлиев чыкты. Аннан соң киңәшмәдә катнашучыларны Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева котлады, аларга эшләрендә уңышлар теләде.

Фәнни-гамәли конференциядә Татарстан Милли китапханәсе директоры Н. Камбеев, Санкт-Петербург шәһәреннән Русия Милли китапханәсенең фәнни-күзәтү бүлеге мөдире Е. Смолина, Чабаксар шәһәреннән Чуашстан Милли китапханәсе директоры С. Старикова, Уфадан Башкортстан Милли китапханәсе директоры Р. Буканова, Йошкар-Оладан Мари Иле Милли китапханәсенең сектор мөдире Н. Осокина, Сыктывкардан Коми Республикасы Милли китапханәсе директоры урынбасары Е. Иевлева, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты проректоры Р. Баһаветдинова, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының китапханә-мәгълүмат үзәге директоры Ю. Дрешер һ. б. чыгыш ясады.

## ТӨРКИЯ КАЗАННЫ ОЛЫЛЫЙ

Башкалабызга нигез салынуга 1000 ел тулу уңаеннан дөньяның татарлар яшәгән бик күп илләрендә, шул исәптән Төркиядә дә күптөрле чаралар оештырыла. Шундыйларның берсе—Истанбулда үткәрелде.

Төркиядә гомер сөрүче милләттәшләребез әлеге истәлекле дата уңаеннан Казан шәһәре тарихына багышланган фәнни конференция уздырды. Татар һәм төрек дөньясының күренекле галиме, тарих фәннәре докторы Кадыйр Дәүләт җитәкчелегендә оештырыла торган әлеге конференциядә Төркиянең төрле институт һәм университет галимнәре, шул исәптән Садри Максудиның оныгы, Босфор университеты галимәсе Гөлән Пултар һәм Мәрмәрә университетының тел галиме, профессор Эрдал Шахин һ. б. катнашты. Конференциягә Төркия галимнәре генә түгел, Татарстан фәннәр академиясенең Тарих институты галимнәре Дамир Исхаков, Фаяз Хуҗин, Гамир Дәүләтшин һәм Илдус Заһидуллин да чакырылган иде. Алар Казан шәһәренең тарихы, архитектурасы һәм халкының рухи дөньясы турында чыгыш ясадылар.

## МУСА ҖӘЛИЛНЕ ИСКӘ АЛЫП

Мәскәү Милләтләр йорты бинасында татар халкының каһарман шагыйре Муса Җәлил истәлегенә багышланган әдәби кичә булды.

Кичәне оештыруда Мәскәү шәһәренең төбәкара бәйләнешләр һәм милли сәясәт комитеты, Мәскәү Милләтләр йорты, Россия Язучылар берлеге, М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты һәм Мәскәү региональ милли-мәдәни мохтәрияте катнашты.

### "АЛТЫН УРДА ҺӘМ АНЫҢ ВАРИСЛАРЫ"

22-24 апрельдә Истанбул каласында әнә шул исемдәге халыкара фәнни конференция булды. Аның эшендә, Төркия, АКШ, Япония, Франция, Германия, Үзбәкстан, Санкт-Петербург, Уфа һәм кайбер башка илләрнең, шәһәрләрнең галимнәре белән беррәттән, Казанның да бер төркем галим-әдипләре (М. Госманов, М. Зәкиев, Н. Хисамов, Х. Миңнегулов, Д. Исхаков, Ф. Урманче һ. б.) катнашты. Гыйльми форумда чит мәмләкәтләрдә яшәүче Надир Дәүләт, Вил Мирзаянов, Шамил Юлай, Гайшә Рорлих кебек мәшһүр милләттәшләребез дә бар иде.

Конференциядәге доклад-чыгышларда Алтын Урданың Евразия, аеруча төрки-татар тарихында, мәдәниятендә гаять мөһим роль уйнавы ассызыкланды.

Казан галимнәре һәм әдипләре, конференциядә катнашу белән беррәттән, бер атна эчендә Фатих, Тракия университетларының житәкчеләре белән очрашып, бу уку йортларындагы гыйльми, укыту-тәрбия эшләре белән таныштылар, лицей-мәктәпләрдә булдылар. Аларны Истанбул шәһәрендәге өч районның хакимият башлыклары, Юнанстан (Греция) янәшәсендә урнашкан Әдернәнең (Госманлы империясенең элеккеге башкаласының) мэры кабул итте. Берничә телдә чыгучы "Ауразия" журналы редакциясендә дә житди сөйләшү булды.

### ИСЕМЛЕ ПРЕМИЯЛӘР

Яшь талантларны ижади үстерү ниятеннән соңгы елларда кайбер күренекле язучыларыбыз үз премияләрен булдырдылар. Алар, табигый, беренче чиратта, үз туган төбәгендәге сәләтле яшьләргә булышу максатын күз алдында тоталар. Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис Буа шәһәрендәге А. Луначарский исемендәге мәктәпнең сәләтле укучыларына бүләкләр тапшырды. Күренекле җәмәгать эшлеклесе, әдип Разил Вәлиев Түбән Кама төбәгендә яшәүче талантлы балаларга шефлык итә. Ул да үз исемендәге премия булдырып, ел саен аларга кыйммәтле призлар тапшыра. Турыдан-туры аның булышлыгы белән быел яшь каләм ияләренең ижат жимешләре тупланган "Иң яхшы бүләк" исемле китап дөнья күрде. Шулай ук, үткән ел Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин да Балык Бистәсе районында үз премиясен булдырды. Премия фонды "Авыл офыклары" газетасы каршында оештырылган әдәби түгәрәкнең эшчәнлеген активлаштырырга юнәлтелгән. Быел шагыйрь премиясенә егерме яшь һәм башлап язучылар лаек булды.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

* * *

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бүлеге мөдире **Сәгъдиев Рәдиф Нәҗип улына** "Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Әдәбият һәм журналистика өлкәсендәге олы казанышлары өчен **Орешина Нонна Николаевнага** "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Президенты Указы нигезендә, Чаллы педагогия институтының татар әдәбияты һәм укыту методикасы кафедрасы мөдире, профессор, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Шәрипов Әнвәр Мәгъдәнур улына** "Татарстан Республикасының атказанган укытучысы" дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

2005 елның 7 апрелендә Мәскәүдә яшәп ижат итүче каләмдәшебез—тәрҗемәче-галим, шагыйрь **Вил Хәлим улы Ганиев** 71 яшендә вафат булды.

### *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Иске Казан. Госман мәчете. **А. Тимергалина** эше.


*Тышлыкның дүртенче битендә:* публицист язучы **Локман Закир**.

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Поэзия Золотой Орды** (Алтын Урда шигърияте). Шигырьләр һәм поэмалар (Равил Бохараев тәржемәсендә).—Мәскәү: "Наталис" нәшр., 2005.—174 б. Тиражы—1500 данә.

Мәгълүм булганча, татар әдәбияты үсешендә Алтын Урда дәвере мөһим урын алып тора. Ул заманда иҗат ителгән гуманистик әсәрләр шактый. Н. Рабгузиның "Кыйссасел-әнбия", Котбның "Хөсрәү вә Ширин", М. Болгариның "Нәһҗел-фәрадис", Х. Кятибнең "Җөмҗемә солтан", Хәрәзминең "Мәхәббәтнамә", Сәйф Сараиның "Гөлстан биттөрки", "Сөһәйл вә Гөлдерсен" һәм башкалар әнә шундый әсәрләр рәтенә керә. Күренекле шагыйрь, тәржемәче Равил Бохараев беренче мәртәбә Алтын Урда чоры шагыйрьләрен рус теленә тәржемә итеп, аларны киң катлау укучыларына тәкъдим итә. Китапта шул чорның иҗтимагый-икътисадый хәле турында тәржемәченең "Соловьиный сад Золотой Орды" исемле, фәнни дәлилләргә бай мәкаләсе дә урын алган.




Рәсимә Гарифуллина. **Яшәү мәңгелек.** Поэма-кыйссалар һәм очерклар.—Казан: "Идел-Пресс" нәшр. 2005.—80 б. Тиражы—1000 данә.

Яшь шагыйрәнең бу яңа китабы "Миңлебикә Гарифулла кызы Мусинаның якты истәлегенә багышлана" дигән сүзләр белән ачыла. Олы җанлы, кешеләр күңелендә якты эз калдырып яшәп киткән мөгаллимә апасы образы аша яшьлекләре сугыш елларына туры килгән бик күп хатын-кызларның уртак язмышын сурәтли автор. Китапның "Гомер белән гомер арасы" дигән бүлегендә шагыйрәнең ике поэмасы урын алган. "Ак сарайда серләр бар" дигәнендә борынгы хан ярлыгы язмышы бәян ителә. Рәсимә Гарифуллинаның бу китабы быел Татарстан журналистларының "Бәллүр каләм" бүләгенә лаек булды.

Индекс 73210



Локман Закир

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)